ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

10.2010



# САНАУ СЫНАВЫНДА СЫНАТМЫЙК

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ ТАТАР ХАЛКЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле милләттәшләр!

2010 елның октябрь аенда Бөтенроссия халык санын алу кампаниясе узачак. Ул халкыбыз өчен чираттагы зур сынау булачак. 2002 елгы җанисәп нинди авыр шартларда узуын һәркайсыбыз яхшы хәтерли. Ул чакта Россия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты тырышлыгы белән бердәм татар милләтен төрле төркемнәргә бүлеп, таркатып теркәү (мишәрләр, керәшеннәр, Себер, Әстерхан татарлары һ.б.) кузалланган иде. Ләкин үзенең бай әдәбиятын, телен, күпкырлы мәдәниятен, сәнгатен, мәгариф системасын булдыра алган, дәүләтчелек рухын, милли үзенчәлеген гасырлар аша саклап килгән борынгы милләт бу сынауларны намус белән узды.

Бүген дә безнең милләтне бүлгәләп, объектив санын киметеп, бозып күрсәтү омтылышлары ачык сизелә. Җитмәсә, соңгы елларда халкыбызның рухи нигезен тәшкил иткән милли яшәеш даирәләренә зур зыян салынды: милли-төбәк компоненты мәгариф системасыннан төшереп калдырылды, татар телендә бердәм дәүләт имтиханын (БДИ) тапшыру хокукы гамәлдән чыгарылды. Нәтиҗәдә, бүгенге көндә дөнья цивилизациясенә зур өлеш керткән туган телебездә уку һәм укыту мөмкинлеге юкка чыгып бара. Ә бит безнең ана телебез Бөек Ватан сугышы фронтларында да көчле корал булып хезмәт итте. Татар телендә нәшер ителгән дистәләгән газеталар сугышчыларны Җиңү хакына каһарманлыкка рухландырды. Бөек Тукай сүзләренчә:

*Без сугышта юлбарыстан көчлебез,*
*Без тынычта аттан артык эшлибез.*
*Шул халыкныңмы хокукка хакы юк?—*
*Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!*

Кадерле милләттәшләр, канкардәшләр!

Бу җанисәп кампаниясендә һәркайсыбыз—яшенә-картына карамастан, битарафлык күрсәтмик, һичшиксез катнашыйк! Сан алу документының 7нче пунктын тутырганда, бигрәк тә игътибарлы булыйк: зирәк акыл, олы җаваплылык күрсәтеп, милләтебезне икеләнмичә «татар» дип яздырыйк!

Бөтенроссия халык санын алу кампаниясенең милләт язмышы өчен ни дәрәҗәдә мөһим икәнен истә тотып, без барлык татар җәмгыятьләреннән, оешмаларыннан бу җитди чарага бүгеннән үк әзерлек эшләрен башлап, әлеге чорда зур җаваплылык, активлык күрсәтүләрен сорыйбыз. Милләтне төрле төркемнәргә бүлгәләтүгә юл куймас өчен барысын да эшлик!

Без яшьләребезне җанисәп чорында аеруча активлык күрсәтергә һәм үз язмышына, милләт язмышына битараф булмаска өндибез. Гаиләнең бу мәсьәләләрдә тоткан урынын югары бәяләп, без үзебезнең аксакалларыбыз, дәүәтиләр, дәүәниләр, ата-аналар яшьләребезгә акыллы киңәшләрен бирер, дөрес юнәлеш күрсәтер дип ышанабыз.

Без зыялыларыбызны, мәгариф, мәдәният, сәнгать һәм дин әһелләребезне милләт бердәмлеге мәсьәләсендә актив һәм принципиаль караштa торырга чакырабыз. Без бу юлы да халкыбызның бердәм һәм бүленмәс милләт булып калуына ышанабыз.

Халкыбызның иминлеге, якты киләчәге өчен мәңгегә бердәм, бергә булыйк!

# Казан утлары
# Qazan utları

2010

# 10
**(1056)**

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

**НАШИРЕ:**
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*
*Казан, Академия ур.; 2*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

Казан утлары

ӘДӘБИ–НӘФИС һӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Татар булып калыйк! *Шигырь* ..... 5

**ШИГЪРИЯТ һӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Камил КӘРИМОВ. Игезәкләр йолдызлыгы. *Роман-фарс* ..... 6
Бикә РӘХИМОВА. Дөнья тынып калган ак тында... *Шигырьләр* ..... 53
Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Көт кенә гомер язымда... *Шигырьләр* ..... 93
Җәүдәт ДӘРЗАМАН. Ап-ак карлар ява... *Поэма* ..... 96
Рүзәл МӨХӘММӘТШИН. Нәтиҗәләр чыгарыр чак житте. *Шигырьләр* ..... 109

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Зөлфәт ХӘКИМ. Кайда син, Аттила?!. *Тарихи драма-роман* ..... 57

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Марат ӘМИРХАНОВ. Их, мать якасын, Черчилегезнең сатыйм каргасын... *Сатирик хикәя* ..... 101

**ФӘН**

Дамир ИСХАКОВ. Татар юлы такыр түгел... *(Халкыбызның этник тарихы, халыкны исәпкә алу һәм сәясәт)* ..... 112
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ..... 153
«Татар энциклопедиясе» битләреннән ..... 156

**Г. ТУКАЙНЫҢ 125 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП**

Бөеклек баскычлары ..... 132

**ТЕЛ ДӘРЬЯСЫ**

Халисә ШИРМӘН. Хәл итәсе иде ..... 137

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Без янмасак... *(Р. Низаминың «Шәһри Казан» газетасы баш мөхәррире М. Мортазин белән әңгәмәсе)* ..... 144
Без бит керәшчеләр затыннан... *(Р. Низаминың «Гасырлар авазы» журналы баш мөхәррире Д. Шәрәфетдинов белән әңгәмәсе)* ..... 147

**СӘНГАТЬ**

Расим МӘҺДИЕВ. Татар ядкаре ..... 159

**ХӘТЕР**

Фирдәвес ХУҖИН. Күкләр шаһит. *Документаль бәян* ..... 164

**АК ҖИЛКӘН**

Гөлфия СОЛТАНОВА. Бәләкәй Гөлфия ..... 180
«Казан утлары» архивыннан ..... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Роман-фарс К. КАРИМОВА «Созвездие Близнецов», сатирический рассказ М. АМИРХАНОВА; стихи Р. ЗАЙДУЛЛЫ, Г. МУХАМЕТШИНА, Б. РАХИМОВОЙ, З. ДАРЗАМАНОВА.
«Творчество молодых»: стихи Р. МУХАМЕТШИНА.
«Драматургия»: Роман-драма З. ХАКИМА «Где ты, Аттила?!.»
«Наука»: Д. ИСХАКОВ. «Этническая история татар, перепись населения и политика» (прод.); Х. ШИРМАН. «Актуальные проблемы языка»;
Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень». (прод.)
«К 125-летию Г. Тукая»: хронология жизни поэта.
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Память»: Ф. ХУЗИН. «И небо тому свидетель».
«Искусство»: «Наследие татарского народа».
«Юбилеи»: беседы Р. НИЗАМИ с гл. ред. газеты «Шахри Казань»
М. МУРТАЗИНЫМ и гл. ред. журнала «Эхо веков» Д. ШАРАФУТДИНОВЫМ.
«Белый парус»: Г. СУЛТАНОВА. «Маленькая Гульфия».
«Наш календарь».
Их фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Дворец земледельцев в городе Казани; поэт Ринат МАННАН.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry: Novel-farce by K. KARIMOV «Gemini constellation», satirical tale by M. AMIRHANOV; poems by R. ZAYDULLA, G. MUHAMETSHIN, B. RAHIMOVA, Z. DARZAMANOV.
«Creation of youth: poems by R. MUHAMETSHIN.
«Drama»: novel-drama by Z. HAKIM «Where are you, Attila?»
«Science»: D. ISKHAKOV. «Ethnic history of Tatars, census and Policy (continuation); H. SHIRMAN. «Actual problems of language»;
F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
«To 125th anniversary of G. Tukay: chronology of poet's life.
Pages from Tatar Encyclopaedia.
«Memory»: F. HUZIN. «And heaven is witness».
«Art»: «Heritage of Tatar people.»
«Jubilee»: interview with R. NIZAMI with Ch. Ed. of newspaper «Shahri Kazan»
M. MURTAZIN and Ch. Ed. of magazine «Echo of Centuries» D. SHARAFUTDINOV.
«White Sail»: G. SULTANOVA. «Little Gulfia».
«Our calendar».
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Palace of farmers in the city of Kazan, writer Rinat MANNAN.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 1.10.2010, график буенча 1.10.2010.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О–1382. Тираж 4087.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2010 ел.

Ркаил
Зәйдулла

## ТАТАР БУЛЫП КАЛЫЙК!

Сынатмастыр—сүрелмәстер күңел,
Дөрләр дә ул, балкып яныр да.
Гаҗәп түгел—Тукай каны ага,
Татар каны ага тамырда.

Бу башлардан барсы үткәндер, шәт,
Давыл булып күпме яу килгән?!—
Тузан баскан ташлар сөйли башлый:
Йә җиңелгән татар, йә җиңгән.

Бу дөньяда яралганнан бирле
Язмыш безне азмы кыйнады,—
Беләзекне богау кысса кысты,
Югалтмадык әмма иманны.

Һәр гасырның ата шайтаны бар—
Урландылар кайбер өметләр.
Без, барыбер, бирелмичә калдык,
Татар булып калдык, егетләр!

Камил
Кәримов

# ИГЕЗӘКЛӘР ЙОЛДЫЗЛЫГЫ

РОМАН-ФАРС

**Хислимәсе Нурия**

Микулай-Седой: «Кайсы редакциягә урнаштырыйм»,—дип сораганда Шәехнур, озак уйлап тормастан, тел очына килгән беренче шәһәрне Чулман дип атаган иде. Бөтенләй башка якларны да әйтеп куярга мөмкин иде лә ул... Чулман икән Чулман инде. Алай ук очраклы хәл дип әйтеп буламы соң моны? Франгизәнең туган ягы буларак та хәтер буразналарына яңарак язылган һәм соңгы елда шактый еш кабатланган шәһәр исеме иде ул.

Әйе, армиягә барып кайтышлыйммы, төзелеш отряды юлларында дисеңме, Шәехнурның поезд тәрәзәсе аша булса да чит өлкәләрне, герой шәһәрләрне, һәр шәһәрнең архитектура уенчыгы итеп салынган тимер юл вокзалларын, һәр хакимиятнең Башкала Пайтәхетенә охшатып салдырган район Кремльләрен күреп калганы бар.

Тик барыбер ул үзенең туган ягын күбесенчә газета-журналлардагы рәсемнәрдән, милли каналдагы сюжетлардан гына күреп белә икән бит.

Чулман тек Чулман инде... Зур суның якынлыгын тоеп яшәргән, көнозыны кояш астында кызынып ятучы күләгәсез ак шәһәр... Тарихы зур түгел, яшьлеге хак, шуңа күрәдерме, урамнарга исем итеп кушардай шәхесләре берән-сәрән генә. Кая карама төзелеш, юл, ерганак, агач, химия атамаларын адрес иткән проспектлар.

Хезмәт кенәгәсенең беренче битенә языласы редакция «Жиденче төзелеш» урамында иде. Гигант мөштек сыман торба төбендәге ике катлы йортның аскы өлешендә. Заманында «Чулман утлары» район газетасы буларак ачылган. Аннары зур берләшмәнең күп тиражлы матбагасы иткәннәр. Әле яңарак кына муниципаль статус алган, зурайган, хәбәрчеләр саны да арткан. Бигрәк тә хатлар бүлеге киңәйгән, Шәехнурны шунда өченче кеше итеп билгеләделәр.

Бу тирәдә кырык-илле чакрым саен шәһәр салынган. Ул шәһәрләр Чулманга Менделеев таблицасы белән бәйләнгән. Шуңа күрәдер, «Чулман утлары» үзәкләшкән газетага әверелеп бара. Хәзер ул ике дәүләт телендә чыга.

Иван Иваныч, житмеш яшькә житкән редактор, өстәленә куелган

---

*Ахыры. Башы 9 санда*

эшләрне күзен бәйләп тә башкара ала, әмма житәкче буларак инде сүлпән, чиновниклык гаярьлеге сүрелгән, бүген йә иртәгә үз урынына яшьләр киләсен тәгаен белеп, хәтта теләмәсә дә көтеп утыра иде.

—«Пролетариат—капитализмга кабер казучы!»—дип әйткән ди Ленин бабабыз.

Күпне күргән карт редакторның яшь хезмәткәрләр белән сөйләшкәндә бик еш әйтергә ярата торган канатлы сүзе инде бу. Планёрка вакытында шарнирлы күн тәхетеннән төшеп, коллектив арасындагы агач аяклы урындыкка күчеп утыруы да гадәттәгечә гадилек уены гына. Аңлатмалар, план, телеграмма, котлауларга ниләр язылачын алдан ук белеп торгандай, кәгазьдән укырга яратмый. Шәехнурның гаризасын да яттан әйтеп бирде.

—Иптәш Шәехнуровка килгәндә, миңа тиз генә чокыр казый алмас әле ул. Читтән торып укуын дәвам итәсе бар. Журналистлар союзына керәсе, фатир мәсьәләсен хәл итәсе, гаиләсен алып кайтасы бар... Без аны хатлар бүлегенә беркетәчәкбез, Кол Хариска күптән бер егет кирәк иде инде.

Бүлек мөдире белән бу турыда жыешлыкка кадәр үк сөйләшенгән, ахрысы, редактор сүзен яңалык дип кабул итмәде, исе китмичә генә тыңлап утырды, «Яшь хәбәрчегә сорауларыгыз бармы?» дигәч ахрысы үзенен кемлеген сиздерергә ниятләде.

—Исемеңне үзгәрт. Журналист озын-озын фамилияләрдән котылып кыска гына псевдоним алырга тиеш. Шәехнур Шәехнуровны тутырып язар өчен техник редакторлар телендә әйтсәк биш квадратлы ике-өч баганага аркылы җәяргә кирәк, заголовок, язманың жанрын куярга урын да калмый. Эпиграфлар өстәүне әйтеп тә торасы юк. Менә ичмасам мин Кол Харис. Шәп яңгырый бит, әйеме, Шәехнур?! Колахмәтов Харисҗан идем мин монда килгәндә. Иван Иваныч беренче көнне үк исемемне сөннәткә утыртып... үзенчә әйтсәк—чукындырып куйды.

Кол Харис жыелыштагыларның көлешкәнен көтеп торды да янә дәвам итте:

—Исемне бермә-бер кыскартып Шәех Нур дип калдырырга киңәш итәм. Белмим, Шәехнуров үзе ни дияр тагы?

—Миңа бик ошый. Фамилиям артык бозылмый. Әти дә үпкәләмәс.

—Ошаткач әйбәт инде,—дип хуплады Иван Иваныч.—Әнә, бүгенгедәй хәтерлим, Мөнирә апагызның детдомнан соң полиграфистлар курсын бетереп тәүге эш урынына килгән чагы. Озын җиңле, ябык изүле ак кофта өстеннән канатлы кара сарафан кигән. Аягында түрле чанага охшатып тегелгән утыз сигезенче үлчәмле туфлие, чәч толымнарын баш түбәсенә өйгән...

—Нужәли шуларны хәтерлисез, Иван Иваныч?! Илле ел бит инде ул көннәргә!—диде ак яулыкны дүртпочмаклап япкан Мөнирә әби-апа, оялып кына.

—Хәтерлим, хәтерлим... Керәшен малай булмасам кияүгә дә чыга иден әле син миңа.—Редактор да коллективының көлгәнен көтеп торды.—Фамилиясе Гатауллина, озын инде, әйтеп бетерерлек түгел. Кияүгә чыккач тагын да озынайды, Галимәрданова булды. Тәки кыскарттырмады. Хезмәт кенәгәсендә безнең редакциянең бер мөһере тора. Техник редактордан башлап җаваплы секретарь дәрәҗәсенә чаклы күтәрелде.

—Давлениеем дә ике йөз егермегә чаклы күтәрелде инде, Ваня... Иван Иваныч,—дип төзәтергә ашыкты ак яулыклы әби-апа.

—Бераз түзәргә инде, Мөнирә...

Редактор кайтып китсен өчен генә тәнәфес ясап алдылар. Иртәнге якта өенә әбәткә кайтып килә торган гадәтен беләләр. Аннан соң танышу «жыелышы» хатлар бүлегенә күчте. Армиядәге дедовщина кагыйдәләре буенча исәпләгәндә «салага» Шәех Нур кибеткә барып килергә тиеш иде. Ләкин Кол Харис аның юлына аркылы төште. Чулман Алан бистәсендә

тәвә кошы үрчетүче фермер үзен зурлап язганнары өчен редакциягә «рәхмәт төенчеге» китергән, бушата торгач, бөтен өстәл тулды. Иван Иваныч белән Мөнирә апа өлешенә кермәделәр, хәмер катнашкан табынга утырмыйлар икән, икесенең дә кан басымы күтәрелә ди.

Төенчекне бушата торгач, телләр ачылды—Шәех Нур Кол Харисның күптәнге һәм ышанычлы дустына әверелә барды. Кызыклы хәлләр белән бизәлгән тостлар, киңәш-теләкләр бик күп әйтелгән иде дә, тик иртәгесен бер-ике кәлимәсе генә истә калган.

—Чынлапмы, Иван Иваныч моннан ярты гасыр элек Мөнирә апаның нәрсә кигәнен хәтерлиме?—дип гаҗәпләнде Шәех Нур.

—Чынлап!—диде Кол Харис.—Ул һәр вак-төякне энәсеннән җебенә чаклы хәтерли... Карун кешенең хәтере шәп була аның.

—Карун, комсыз дигән орышлар байларга карата гына әйтелә бугай?

—Бай ул, кыяфәтеннән сизелми генә, пеләшен сыйпап садака бирәсе килә... Ә бит сайланма түрәләр өчен генә салынган йортта ике сутыйлы фатиры бар, ярамаган урында өч катлы коттедж салып куйган. Аның кулына кергән акчасы бөтен коллективка зарплата түләргә җитә. Алган орден-медальләрен, мактаулы исемнәрен исәпләп пенсиясе дә депутатларныкы чаклы. Бюджет хисабына шофер тота, коттеджга бөтен гаиләсе редакция машинасы белән йөри... Ә без газетага срочно берәр язма кирәк дигәндә олы юл чатына кул күтәреп чыгабыз.

—Аның урынына куйсалар үзең дә Иван Иванычка әверелер идең әле, Кол Харис. Төшемле кәнәфигә утыргач мал сөю хроник авыруга әйләнә бит ул.

—Без болар чаклы ук булдыра алмабыз. Үз кесәсенә алыр өчен генә килгән буын бу.

—Бәлки, Иван Иваныч, җитте дип, китәргә йөридер?

—Урынына кем кызыкканын беләсең килсә, бераз югалып тор дигәннәр аңа... Хәзер әнә отпускыга китәргә дә курка. Пенсиягә чыкканнан бирле ял алганы юк. Әле аның җиде яшьлек оныгын укытып эшкә урнаштырасы бар. Редакторлыгыннан китсә сүзе үтмәячәк. Ул моны яхшы белә. Ауган агачка тукран да кунмый...

—Ә Мөнирә апага ник һаман түзәргә куша?

—Франгизә кайтуга җаваплы секретарь урынын икәүләшеп саклыйлар.

—Кем соң ул?—диде Шәех Нур, Франгизәне белмәгәнгә сабышып.—Көтепләр алырлык даһимы әллә?

—Язып караганы юк әле аның. Мәктәпне «өчкә» бетереп, институтка көчкә барып эләккән, әнисе налоговыйда эшли, мәркәздә сүзе үтә, кем аркылыдыр керткән кызын...

Чулманда иске кунакханә сүтелмәгән иде әле, аны озаклап килгән гаиләләр өчен саклыйлар. Шәех Нур яшәгән бүлмә газета баллансына күчерелгән, яшәү хакын, уты-суы өчен редакция вакытында үзе түләп тора. Агач кунакханәдән бүлмә алу—ул инде озакка сузмыйча проспектларның берсеннән заманча корылган аерым фатир алуның беренче шарты иде. Университетны тәмамлап юллама белән килгән Кол Харис та фатир алу лабиринтларының шушы юлын үтә башлады. Ике тәрәзәгә бер үзе хуҗа булып, Чулман каласына унынчы каттан карап ятырга исәбе. Әгәр сабырлыгы җитеп, редакциядә пенсиягә чыкканчы эшли алса ведомство фатиры бөтенләйгә аның исемендә калачак. Ашыгып килгән җиңел сөенечне гел шулай берәр көенеч сагалап тора инде ул.

Кечкенәдән хыялланмаган килеш тә атна-ун көн эчендә яратып өлгерде Шәех Нур журналист һөнәрен. Космонавт булырга телим, мина врач һөнәре ошый, йә төзүче-инженерлыкка укыячакмын дип әти-әниләрнең башын катырып, укытучылар «5» куйсын өчен һәйбәт иншалар язып интегәсе дә юк, кулыннан килгән бөтен эш тә якын икән ул. Шәех Нур хәзер Микулай-Седой киңәшенә

ышанып Чулман каласына китеп барганына сөенеп туя алмый. Четерекле хатлар буенча, язылган фактларны ачыкларга дигәндә күп очракта әле Кол Харис үзе ияреп чыга. Гади халык теләгән дөреслек белән җитәкчеләр кушкан дөреслекнең урталыгын табу җинел түгел. Бигрәк тә авылдан килгән жалобалар белән эшләве авыр. Хәбәрче алдында халыкны клубка куып кертәләр дә: «Кайсыгыз язды?» дип хакимият исеменнән Кияү Тархан имән бармагы белән бер генә селтәнә. Конфликт шундук юкка чыга. Батрак хәленә төшкән авыл кешесе авызындагы канын түкәргә дә курка... Шулай да хәбәрченең гадиләрне яклап килүе күпчелекне сөендерә. Кунакханәдә көтеп торган кешесе булмагач, Шәех Нур командировкадан туп-туры редакциягә кайта. Куен дәфтәренә теркәлгән моңзарларны төн чыкканчы эшкәртеп, иртән бүлек мөдир өстәленә сала. Өстәлдәге кәгазьләр өстенә башын куеп кунып калган очраклары да байтак булды.

***

Дөньяны әкияткә батыра шушы Яңа ел бәйрәме. Сәүдәгәрләр ике ай алдан уенчыклар сата башлый. Өйдәгеләр ай буе ризык әзерли. Ә бала-чага Олы Кирмәндә яшәүче Кыш бабай исеменә бүләк сорап хатлар яза. Бөтен кеше самимиләнеп могҗиза көтә. Могҗиза нәкъ төнге сәгать уникедә килергә тиеш. Иң мөһиме—чаңнар сугып еллар күченгән мәлдә табын артында япа-ялгызың калма... Ә могҗиза экранда! Биш минутлык чыгыш... Ике Президентның гади халыкны яратып, үз итеп һәм рухландырып искә ала торган иске елның соңгы минутлары.

Шәех Нур Чулманга килгәч беренче Яңа елын ялгызы гына каршылады. Ике көн кала Хислимә законлы иренең эш урынына шылтыратты. Әйтер сүзе дә телеграмма кебек кыска иде: «Мине көтмә, Зачетлардан котыласым бар. Бәйрәм үтүгә үк имтихан куйганнар. Гафу ит, бәгырем...»

Нинди төче сүз бу—бәгырем! Шәехнурым дип кенә әйтсә ни була соң?! Һич югы җимешем, аппагым, тупырчыгым дисен. Барысына да риза ла Шәех Нур! Тик мут хатыннар шикелле бәгырем, матурым димәсеннәр...

Яңа ел төнендә кунакханә телевизорын кабызмыйча гына хат язды Шәех Нур. Сагыну, юксыну, үкенүләр белән тулы өч битлек өзгәләнү, Хислимәнең багалмадай асыл чагына юллап язды Шәех Нур ул хатны.

Багышлавын чынлап та Хислимәгә багышлады, тик конвертка салгач Хаҗитархан тарафына, Нуриягә адреслады.

Көндезге бүлектәгеләр каникулга чыккач, читтән торып укучылар сессиягә килә. Шәех Нурны анда да каршы алучы күренмәде. Хислимәне ике атналык кышкы сәяхәткә Ялчык күленә киткән диделәр.

Бөтенләй үк күрешмәделәр түгел, бәйрәмнәр кушылган озын ялларда, Шәех Нурның йомышы төшеп Азан каласына килгән чакларында күрештеләр алар. Аймыл булып яшәгән килеш, Хислимә диплом алганчы тагын ике ел вакыт үтте. Шушы ике ел эчендә җиде-сигез тапкыр кавышканнардыр шәт.

Нуриянең хатлары ешрак килә...

Ә Хислимә, Чулманга кайткан саен, төнге клубка кич утырырга кергән ише генә...

Нуриянең һәр җавабында «Мәрхәмәтлем Шәех Нур»га хат язганы өчен рәхмәт сүзе бар.

Диплом алгач та Чулманыңа төяләп кайтам дигән Хислимә тагын өч елга аспирантурага калган... Фәләх Сәмигуллин фәнни җитәкчесе булып расланган.

Нуриянең кесә телефоны бар. Хаҗитархан өлкәсе МТС элемтә зонасына кергән. Шәехнурга да МТС тарифына күчәргә куша.

Хислимә ерагая...

Нурия якыная...

## Мөхәммәт өммәте

Галстук сайлый Шәех Нур. Ишек катындагы түгәрәк көзге белән кием шкафы арасында таптана. Берсен ала, кия, сала... Янасын ала, бәйли, сүтә. Көзгегә карый, көзгедән китә, тагын килә... Бүгенге вакыйга өчен үзенең йөзен эзли.

Ә бүген Чулманда зур мактану көне. Йөк ташучы машиналар өчен мотор мае чыгара торган евролиния эшли башлый. Мае әллә кайчан чыга инде аның, күрше өлкәләргә төяп-төяп җибәрделәр, рәсми рәвештә ачылмаган килеш тә.

Оник Мөхәммәт килер алдыннан автоцистерналарга май тутырып яткан заводны сүндереп тордылар. Кирмәннең протокол хезмәте раслаган исемлектә Шәех Нур да бар. Иван Иваныч тантанада катнашырга бик теләсә дә чакырылмаган иде. Баш мөхәррирдән узып хатлар бүлеге хәбәрчесенең зур кунаклар исемлегенә эләгүе аны тагын да сагаерга мәҗбүр итте—димәк, кабер казучы люмпен пролетарий Шәех Нур булып чыга...

Кызыл тасма янына «гасыр» каналыннан телевидение төркеме, репортерлар, фотохәбәрчеләр килеп өелде, төбәк шәһәрләренең башлыклары койма булып басты.

Алар завод идарәсеннән өчәү чыкты: Оник Мөхәммәт үзе, Кияү Тархан һәм генераль директор. Тән сакчылары, референтлар, иминлек хезмәте бераз калышыбрак иярде.

Оник Мөхәммәт белән үзара сөйләшкәндә завод технологы, химия министры, бигрәк тә хәбәрчеләр сүз иреге яулап алды: чыгыш ясаучылар тарафына елан башыдай микрофоннар ябырылды, сораулар яуды, фотояшеннәр өзлексез яшьнәде.

Ярты сәгатьлек митингтан соң, өч биюче кыз чүпләмле өч кызыл сөлгегә куеп өч кайчы алып килде. Капка баганасына тарттырылган өч колачлы тасмадан өч кисәк комач кисеп алынгач, кулларында папараци коралы булганнар «Ура!» кычкырды, буш куллылар кул чапты. Өч фотоаппаратын да муенына элгән Микулай Седой экраннардан күренерлек итеп алкышлады, ә Шәех Нурга таба борылгач, күз кысып «Ура!» кычкырды.

Үзәк диспетчер залына кергәч, түрдәге стенада үзенең зур портретын күреп Оник Мөхәммәтнең кәефе күтәрелде.

Кияү Тархан бүлмәсендә дә бар бу портрет. Эш урынына килеп кергән саен, ул сынга табынган мәҗүси кебек, аның каршында тукталып кала: соклана, кызыга, көнләшә, хыяллана... Аның да шушы бизәкле рам эчендә үзенең рәсемен күрәсе килә.

Идарә итү пультындагы патша тәңкәсе чаклы көмеш төймәгә баскан чакта Оник Мөхәммәтнең елмаюы әлеге оешкан тантанага уен төсмере биреп тора иде.

Бер-бер артлы гүелдәү көчәйде, гөрелте артты, торбалар пышылдады. Шоуны әкренләп шау күмде.

Күп тә үтмәде, диспетчер янындагы уенга сөенеч булып дөньяның иң ак халатын кигән лаборант кыз килеп керде. Кулындагы бүксәле колбада яңа пешкән сосла төсендәге май иде. Илбашчы мазут исе аңкып торган колбаны алгач эчеп карарга теләгәндәй авызына китереп күтәргәндәй итте... Үзенчә шаяруы иде. Аннан ул бик якын китереп иснәп-иснәп карады. Колбаны кире биргәч тә борын саңакларын лебердәтеп иснәнеп торды. Майның агылып калу ихтималын шәйләп, пинҗәк кесәсеннән яшел кульяулык чыгарып борынын сөртте. Аны ташларга дип чүп чиләге эзләгәндәй итте. Ул арада, Кияү Тархан кулын сузып өлгерде... Һәм кульяулык кулдан кулга күчеп, шул минутта ук завод музееның пыяла шүрлегендә экспонат булды.

Оник Мөхәммәт җөмһүрият хәбәрчеләренең язмасына калын хәрефләр белән языллык соңгы юлны әйтергә тиеш иде.

—Бик һәйбәт май, холестирины юк!.. Сез булдырасыз!

Яңалыкны бөтен илгә таратыр өчен чакыртылган матбугат кунаклары, аягөсте генә чәй эчеп, ашыгыч рәвештә мәркәзгә кайтып китте. Шәех Нур завод белгечләре белән бергә район җитәкчеләре арасында калды. Генеральный бүлмәсендә илле кешелек кинәшмәне үткәргәч Оңык Мөхәммәт, СССР гербы куптарып алынган иске трибуна артына басып тезислар укуга күчте.

«Мөхтәрәм иптәшләр!

Капитализмга күчү котылгысыз. Коммунистлар безгә юлдаш түгел. Үткәнгә кире кайту юк! Федераллар сызган туры юлдан—алга, бары тик алга!

Иске агач өйләрдән, панельле «хрущевка»лардан качыгыз! Виллалар, коттеджлар, ял йортлары салыгыз! Җаныгыз теләгән флора һәм фаунага замоклар корыгыз. Әкияти гротлар казып керегез, утрауларда фамильный шәһәрләр күтәрегез, хосусыйлаштырыгыз.

Бездә төзелгән—бездә калачак. Торган җиребез дөньяның иң матур җиренә әверелсен.

Илләрнең байлыгы миллионерлар саны белән билгеләнә. Акча табарга өйрәнегез!

Яңача яшәгез!

Мисырга барып мунча керегез, Кызыл диңгезгә барып су коеныгыз, Алып батыр тауларына барып чаңгы шуыгыз. Парижга барып өйләнегез! Балаларыгыз чит илләрдә укысын. Утырган машиналарыгызга карап сезнең кемлегегезне танысыннар! Онытмагыз шуны—сез иске кабыгын салган җәмгыятьнең яңа буржуйлары!!!

Һәр тармакның үз банкы, ябык инфраструктурасы, беркетелгән хезмәт армиясе һәм хокук ирегe булсын!

Мин сезнең гарант!..»

Бәйрәм актлар залына күчте. Анда сайланма артистлар концерты башланырга әзер иде инде.

Оңык Мөхәммәтнең ярты концерттан соң саубуллаша торган гадәте бар. Ләкин ул китмәде. Кул көчен кызганмады, алкышлап ахыргача утырды. Пәрдә ябылгач тән сакчыларын ияртеп сәхнә артына да керде—сәхнә йолдызларын хөрмәтләп мактар өчен, рәхмәт әйтер өчен.

Олы җанлы кешенең кочагы да зур бит аның—ике дистәләп артист Оңык Мөхәммәтнең канат астына сеңырга дип тыпырчына. Шәех Нур ятим бәпкә кебек берүзе читтә калды.

Һәм тегеләр, якты чырай күреп, тотындылар ямаулык сорарга... Ул җавап биреп өлгерә алмый хәтта.

—...миннән хуҗылар мактаулы исем алып бетерде. Звание күрмичә картаям ич инде.

—Синең директорың депутат кеше, тутырсын наградной лист. Уйларбыз...

—...утыз яшьлегемне бик сиздермичә генә бенефис үткәрмәкче идем, залларны арендалаган өчен күп сорыйлар.

—Аңладым. Газовикларга хат языгыз. Шылтыратырмын.

—...зыярат кылганда әни каберенә якын килерлек түгел. Бер генә чакрым асфальт җәйдерәсе иде.

—«Нур»га кереп чык әле. Синдәй примадоннага юк дип әйтә алмас ул.

—...телевидениедә ун ел алып барам инде...

—Беләм. Экранда син бик чибәр күренәсең.

—...анысы шулай. Торырга урыным юк. Өч кешелек гаилә коммуналкада яшәп ятабыз.

—Генеральныегыз белән киңәшербез. Җае табылыр.

—...чыгып качарга урын булмагач, әрәм ятам. Хатын түгел, аждаһа, көнтөн талый. Мин бит гениальный композитор, үзегез беләсез.

—Ну, без сезнең җырларны җырлап үстек инде.

—...әйтәм ич, бер бүлмәле аерым фатир бирсәгез, шушы стервамны ташлап китәр идем.

—Һәй, егетләр, бер бүлмәле фатир бирсәләр мин дә апагызны ташлап китәр идем ул... Аерыласы килгән һәр иргә фатир өләшә башласак Башкалабыз капкасына дегет сылап китәрләр бит.

Якты чырайдан ямаулык сораучылар шулкадәр кыюландылар ки, тагын бераз түзсә, менә хәзер, менә хәзер Онык Мөхәммәтнең кесәсенә кереп конфет эзли башлаячаклар иде.

—...менә миңа...

Читтәрәк басып калган Шәех Нурны ишетүче булмады. Ул тагын эндәшеп карады.

—...ә менә миңа бернәрсә дә кирәкми!—дигәч, өченче тапкырында гына Илбашы, артистлардан ваз кичкәндәй, аңа текәлде.

—Хәтта минем үземә дә күп нәрсәләр кирәк әле... Ну, миңа бернәрсә дә кирәкми дигәч—гамьсез, хыялсыз, бөтенләй өметсез кешедер син?

—...гафу итегез, өметем бар—Сезнең белән фотога төшәсем килә...

Ул артистлар төркемен ерып чыкты.

—Кайсы елгы соң син? Моңарчы күргәнем булмады. Юк, хәтер шәп минем анысы...

—...гафу итегез, Сездән яшьрәк... гафу итегез, акылым белән дип әйтергә теләгән идем.

—Ярар инде, апаем, нәрсә кылтаеп торасың. Акланма. Картлык ул кешенең яше баш киеме размерын узып киткәч башлана. Ә безнең нәселдә җитмеш өченче размердан да кечкенәрәк бүрек кигән ирләр юк!.. Кем диден әле син үзеңне?

—Шәех Нур мин. «Чулман утлары»нда эшлим.

—Шәех Нур! Шәп исем, хәтердә кала торган... Ә фотога төшәрбез. Үс әле бераз! Минем белән менәсе килгәннәрнең бик төшәсе килә...

Һәм ул башын артка чөеп рәхәтләнеп көлде. Аннан соң көлүеннән ничек кисәк туктаган булса, йөзе дә кинәт җитдиләнде. Тагын шунысын да күреп өлгерде Шәех Нур, көлгәндә күзе гел ачык иде аның. Ул хәтта көлгәндә дә уяу!

Шушының белән рәхмәтнен дә регламенты бетте.

## Нәфнәф туе

Быелгы Сабантуйны март аенда үткәрү турында Кияү Тархан карар чыгарды...

«Чулман утлары» газетасы ошбу вакыйгага багышлап уналты битле сан әзерләргә тиеш иде. Хәбәрчеләрне, берсен-бер калдырмыйча, бәйрәмгә куып чыгарачаклар. Иң мөһиме—язмаларда җиңү булсын, уен-көлке, тамаша балкып торсын, фотоларга бөтен җиһан сыйсын.

Хатлар бүлегенә килеп кергәч Иван Иваныч гүя анда Шәех Нурны гына күрде, башка хезмәткәрләргә артык илтифатлык күрсәтеп тормады. Редактор, озак еллар буе тегүче булып эшләгән ателье остасы кебек, егетне баштанаяк җентекләп күзәтеп чыкты, әйтерсең лә аңа яңа костюм өчен үлчәм алырга җыена...

—Сине Кияү Тархан эзләтә.

—Минеме, ни өчен?!.

Шәех Нурның кабатлап соравы Иван Иванычның тыелып торган ачуын тышка чыгарды.

—Сине, сине! Башка беребезне дә түгел, тик сине генә! Ни өчен икәнен дә сизенәм...

—Ни өчен дип уйлыйсыз?

—Хәзерге яшьләрнең бик тиз үсәсе килә. Главаның «любимчигы» булгач, үсәрсең дә.

—Кышкы Сабантуй унаеннан берәр йомыш кушадыр ул.

—Сиңа гына, аерым, махсус йомыш...

Шәех Нур бәйрәм алдыннан кичерә торган күтәренке кәефен сакларга тырышты. Микулай Седой биреп җибәргән фотоларны да бүген, никтер алырга булды. Дөресен генә әйткәндә, Чулман каласының һәр вакыйгасы Кияү Тархан катнашында уза, «газетчик»ларның аның белән күрешмичә калган атналары бик сирәк. Тик Шәех Нур охшаш фотоларны һаман үзендә саклый торды, уен ясар өчен главаның кәефе һаман «мач» килмәде.

Кабинет алдындагы бүлмәдә видеокамера кем килгәнне алдан ук хуҗага хәбәр итеп тора. Шуңа күрәдер инде озын өстәл янында үрә каткан Шәех Нурга исе китмәде. Аерым-аерым битләрне тутырып нидер яза Кияү Тархан—доклад түгелдер, чыгышларны Иван Иваныч язып бирә аңа, моны инде редакциядә һәркем белә.

Кияү Тарханның йөзе искиткеч төзек, кем әйтмешли, колагы да, күзе дә, авыз-борыны да үз урынында. Чем-кара чәченең таракка буйсынмас кыскалыгы, җыерчык эзе төшмәгән маңгаеның каз мае сөрткәндәй ялтырап торуы килешле генә... Аны күзләреннән танып була. Кырыслыгын җыеп торган, милли мәрхәмәте кабынмаган, туп-туры текәлсә дә барыбер кырын карашлы, елмаюы сүнгән күзләр...

Ун минутлап басып торганнан соң, Шәех Нур чыгып китәргә дип борылган иде, Кияү Тархан шундук күреп алды.

—Син нәрсә, мальчишка, минем өстән жалу писать иткәнсең.

—Беркая да язганым юк.

—Оныҡ Мөхәммәтнең аппарат руководителенә обращаться иттеңме?

—Әйе.

—Ну вот и все!

—Шәхси үтенеч иде ул.

—Какой-такой личный! Минем инстанцияне игнорировать итеп. Димәк жалоба!

—Нинди жалоба?!

—Имеш, мин трибунадан Оныҡ Мөхәммәтнең туганы дип заявить иткәнмен. Хәзер, вот, столичный властька объяснительный писать итәмен.

—Туганлыкның зыяны юк ич аның...

—Мин Оныҡ Мөхәммәтнең якын туганы дигәннәре өчен ике главаны снимать иттеләр инде: берсе пекарняда директор әнә, икенчесе бытовой комбинатта... В конце-концов, Оныҡ Мөхәммәтне туганым дип признавать итү модада ул хәзер.

—Камчы очына кургаш төере бәйләү кебек инде. Халык көтүен куркытып тотар өчен.

—Вот видишь, признавать итәсең...

—Юк. Язмадым.

—Всеровно журналистлар эше. Простой халык Президентларның адресын да, телефонын да белмәс. Вообще, Иван Иваныч бдительностьны потерять итте, урамнан случайный кешеләр принимать итә... Бөтен скандалга да сез журналистлар, писательләр виноваты, Четвертая власть имеш, ни прессу, ни языка, ни литературу, ни нацию защищать итә алмадыгыз.

—Сезнең кебек ана телен белмәгән, китап яратмаган житәкчеләр үсә башлагач бетте ул безнең милләт.

—Умничать итеп утырма, писака!

—Сез дә шикәр түгел, Альянс Фәридунович. Кемлегезне бик яхшы беләбез... Кирәксә фаш итеп язып та чыгармын.

—Вон отсюда! Мальчишка!

—Китәм, китәм. Чулманда калмыйм. Җавап кына килсен миңа.

—Да я тебя...—дип Кияү Тархан кәнәфиеннән күтәрелгән иде, Шәех Нур аның каршына интим хәлләренә ишарәле фотоларны ыргытып авызын япты һәм хушлашып та тормыйча чыгып китте. Хуҗаның нәфрәте ташыды.: «Нуҗәли теге хәлләрне белә инде бу журналист кисәге?! Ну, погоди!..»

***

Җыен капкасыннан килеп керүгә, Шәех Нурның кесәсендәге телефоны сизгер җирне кытыклый башлады. Ул аның тавышын сүндереп, виброрежимга куйган иде. Шылтыратучы ир кешене тавышыннан танымаса да сөйләшеп алырга туры килде.

—Нихәл, Утыз өчле Шәех Нур?

—Кем бу?!

—Син артык эчмә әле бүген, яме, сөйләшәсе бар.

—Кайда? Кайчан?!

—Тагын шылтыратырмын.

—Нәкъ менә бүген үк дигәнме инде?

—Иртәгәгә калдырырга ярамый. Мәсьәләсе бик җитди.

—Кайсыгыз шаярта инде анда?

—Бик җитди дидем. Пока...

Шәех Нурның кемлеген шактый ук белеп сөйләште бу кеше. «Утыз өчле Шәехнур» дигән кушаматын классташлары чыгарган иде, әллә шылтыратучы да якташларның берсе микән?

Сигезьеллыкны тәмамлагач, Шәмдәл мәктәбе интернатына күрше-тирә авыллардан укучылар килеп тулды. Укуын алга таба дәвам итәргә теләгән балаларны җыйнап-барлап дигәндәй, икегә бүлделәр. Зур-зур класслар килеп чыкты. Утыз өч укучының фамилиясен тезеп төшә торгач, журнал бите шыплап тула торган иде. Үч иткәндәй, исемлекнең иң ахырындагы утыз өченче укучы Шәехнуров иде. Кимчелекләргә аеруча игътибарлы, кыек-мыек сүзләреннән җыйнаулашып көлә торган, кылган хаталарыңны гафу итмәстәй, һавалы, чамасыз горур һәм дә мин-минлекнең бөгелмәс, ә кушаматларның аеруча тәэсир итә торган җете чагы иде шул. Мәктәп кичәләрендә, зур егет булып, күңеленә якын кыз белән сөйләшеп торганда берәр шалапае килә дә күрешә: «Нихәл, Утыз өчле Шәехнур?!» Сөйгән кызынның күнелен биздерер өчен, юри мыскыллап дәшә, «туксан тугызлы»дан өч тапкыр хуҗырак итеп мыскыллый.

Килер бер көн—алфавит тәртибендә санау дигән гаделсезлек бетерелер, исемнәрне тезгәндә—кешенең буена, яшенә, авырлыгына, байлыгына һәм акылына карап язу тәртибе гамәлгә керер... Хыяллары тормышка ашса, Дияр агайның «Утыз өчле» малае исемлекләрнең башында язылыр, җөмһүрияттә «Ш» хәрефе хакимлек итәр...

Сабантуйда халык күбәйгән саен Шәех Нурның кушаматы да үзеннән ерагая барды. Уеннар башлангач ул хәтта сәер таньшның көрәшүгә өметләнеп шылтыратуын да оныта төште. Бәйрәм дәрте аны үзенә бөтереп алды.

Көрәш мәйданына калын итеп кар тузаны түшәлгән, бил алышучылар берсен берсе күтәреп ыргытканда уртада буран дулап ала. Чана тәртәсенә бәйләнгән тәкә аяк астында тапталган карны тешләп-тешләп каба... Иң очына телевизор паспорты бәйләнгән кәгазь тартманы алып төшәр өчен бозлы колга төбенә малай-шалай тезелгән.

Көн өйләгә авышканда Себер ягыннан искән җилләргә ияреп кар чәчәкләре очына башлады. Халык өендә булган һәммә җылы нәрсәсен алып чыгып бөркәнгән, төренгән. Тамашачылар өчен корылган озын-озын эскәмияләрдә сырган чалбар хәтлек ирләр бишмәт хәтлек хатыннарын кочаклап утыра.

Язгы сабанны бер атнага алданрак тәгәлләдек дип ел саен рапорт бирә торгач, кыр эшләре шактый алга күчте. Сафура буранында борчак чәчеп, 1 апрельдә бәрәңге күмгән хуҗалыклар майның унбишләрендә печәнгә төшә хәзер.

Урамда ун градус чамасы суык эленеп тора.

Зур өстәлгә охшатып корылган сәхнәдә ялангач артистларның энҗеле кендекләре җемелди. Мәйдан читендәге карлы чыршыларга эленгән радиотартмаларда сандугачлар фонограммасы сайрый. Атракционнарга, күрәшкә, уеннарга битараф халык бердәм булып сәүдә рәтләрендә җавапсызлыгы чикләнмәгән ширкәтләрнең тәм-томын чемченеп йөри. Кызлар кулында каен җиләге өелгән пластик стаканнар, егетләр кулында боз салынган ширбәтле бокаллар...

Азанлылар—һәр эштә дан казанырлар, тотынган икән һәрвакыт арттырып үтәрләр, йә бергә декадага алданрак башкарып чыгарлар.

Узган гасырның беренче яртысында гамәлгә ашкан колхозлашу, кулакларны талау, заем кәгазьләре сату һәм дә репрессияләү планнарын башка губерналарга караганда күпкә алданрак үтәгән, Алмания рейхстагына аерым байрак кадап, Җину көнен 1 май көнне үк бәйрәм иткән гайәр халык бу!.. Атаулылар җиңелү белмәс, чигенсәләр дә борылып, тагын алга бара торган булганнар!

Кесә телефоны янә Шәех Нурны кытыклады.

—Машиналар туктаган аланга кил. Чия кызыл «БМВ»ны табарсың.

—Үзең кил. Батырларның карда коенганын карап утырабыз...

—Машинада көтәм. Ашык, тизрәк әйдә. Безне өйдә көтәләр.

—Ә мин ләх исерек... Утырган җиремнән тора алмыйм.

—Грамм да эчмәгән әле син... Күрдем инде.

—Күрдең? Ә ник соң килеп дәшмәдең?

—Шулай кирәк. Срочно көтәм!

Сөенергә дә, көенергә дә белмәде Шәех Нур. Хатын-кызлар чакырса бер хәер, ир-агайның чамасыз төчеләнеп чакыруы күңелне тырный. Хислимәнең шаяртуымы бу? Ә бәлки Нурия ягыннан җылы хәбәр бардыр. Ел саен килә торган Сабан туеннан нинди кызык көтәрсең тагын...

Бу кеше машинаны җылытыр өчен руль артында утыра иде, Шәех Нурны ерактан ук күреп алып чыгып басты. Икеләнерлек тә чара калдырмыйча, озак күрешмәгән туганнарча кочаклап күреште. Машинага дәшкәч тә үзе белән янәшә алга утырырга кушты.

Шәех Нур сагаеп калды. Әлеге чия төсендәге «БМВ» Кияү Тарханның шәхси машинасы, ул урамга бик сирәк чыга, дөресрәге аның барлыгын да бик аз кеше генә белә булыр.

—Гәүдәңне каеш белән арканлап маташма, безне гаишниклар туктата алмый,—дип, ул ике арадагы серле киеренкелекне көчәйтте генә.

—Мин беркая да барырга җыемыйм, бәйрәмнән репортаж язасым бар, фотога да төшереп өлгермәдем,—дип карышырга маташкан иде Шәех Нур, бу кешенең җавабы катгый чыкты.

—Барабыз! Көтәләр. Ә репортажга узган елгы сабантуй фотоларын бирерсең. Барыбер лә ул. Сабантуй белән сабантуйның аермасы юк. Кунаклары да, житәкчеләре дә, батырлары да шул ук.

Машина кузгалып, Чулман шәһәренә таба юнәлгәч, Шәех Нурның күңеле тынычлана төште: димәк, бернинди дә мажаралы сәяхәт көтми.

—Барыбер искә төшерә алмыйм сезне. Күргән кешем түгел, ни тавышыгыз, ни йөзегез белән хәтерләмим.

—Танышыйк соң, алайса, минем исемем...

Ниндидер, Нәфнәф кебегрәк исем әйтте бу кеше. Ләкин Шәех Нур кабатлап сорарга теләмәде, «ярар» дигәндәй баш изәде дә тынды.

Ул арада машина шәһәр читендәге Магистральная урамына килеп туктады. Җиргә төшкәч тә әле шактый озак атлап, бөтенләй икенче урамга юнәлделәр.

Көтеп торган йорт янында да килеп туктарлык урын иркен иде юкса, «Нәфнәф»нең бу тирәдә әлеге машина белән балкыйсы килмәде, ахрысы.

Сүз куешкандай ияреп бара торгач, өченче подъездның 37нче фатирына килеп кергәнен сизми дә калды Шәех Нур. Алар керүгә, күрешми-нитми генә каршы алган житмеш-житмеш биш яшьләрдәге бер әби өйдән ашыгып чыгып китте, калын пәлтә, мамык шәл бөркәнгән килеш шактый көткәнгә охшаган, уттан качкандай саф һавага ашкынуы иде бугай.

Ике бүлмәле фатир эчендә кунакны җәлеп итәрлек, йә булмаса хәтердә калырлык, һичьюгы күзне сөендерерлек бер яңалык та юк: иске җиһаз, таушалган савыт-саба, ишексез шкафта соры кием-салым. Байлыгы балкып тормаса да, урам ягы ишеге «Гардиан» фирмасыннан икән—танкка каршы ата торган мылтык та тишә алмас үзен.

Бу фатирда гомергә ислемай сибелмәгән, аш бүлмәсенә кергәч тә ризык исе юк, бөтен җирлеккә тәмәке ысы ягылган.

Күн курткасын шкафка элгәч, Нәфнәф урта звено интеллигенциясенә охшап калды. Кабинетларда утырып терсәк-тез өлешләре бөгәрләнгән, түше ялтыраган костюм чалбары бер-ике үлчәмгә запас белән тектерелгән. Галстугы юк.

—Безнең Шәмдәлдә җыенга гел яңа күлмәк киеп чыгалар.

—Сиңа бәйрәм—миңа каторожный эш ул.

—Нигә дип килдек инде без бу фатирга?

—Йә, Шәехнуров, Нәсимәттәй әниең бәрәңге шәңгәсен гел шулай йомырка сарысы ягып пешерәме?—дип, Нәфнәф үзе сораулар яудыра башлады.—Ыслушай, Шәех Нур Диярович, синең әтиең йөздән узды бугай инде, әйеме?

—Алты паспорт алыштырырлык гомер кичкән кеше...

—Әниең өченче хатыны бит инде, ә! Ул да абыстайлар яшенә җитте.

—Тәк, булды...

—Шәехнуров, йөз грамм гына каплап куясыңмы? Ни дисәң дә бәйрәм ич бүген. Миңа ярамый—рульдә!

—Гаишниклар туктата алмый дигән идегез.

—Закон катыланды. Салган килеш элексә министрларның да правасын алалар.

—Минем дә теләк юк. Телефоннан: «Син артык эчмә әле бүген!—дигәч, сезгә бик ачуым килгән иде. Әйтерсең лә, айнымас бер сәрхуш мени!

—Ну бераз салгалыйсың инде анысы. Беләм, гаиләң һаман көйләнмәгән. Өйләнгән килеш ялгыз тору синдәй ирләрне шактый сындырган. Хислимәне көтеп, уттан өзелмәгән компьютер кебек, көне-төне «в режиме ожидания»дә яшәр өчен юаныч кирәктер. Ну син эчмә, аракы белән юану—суицидның үзе инде ул.

—Җитте! Туйдым! Сез мине монда мораль укыр өчен чакырдыгызмы?!—Шәех Нур кием шкафына таба ашыккан иде, аны Нәфнәфнең кырыс әмере туктатты:

—Стоять! «Китәргә ярый!» дигән рөхсәт бирелмәде әле сиңа. Ишек ике яктан да менә шушы ачкыч белән генә ачыла.—Һәм Нәфнәф ачкыч бәйләмен кесәсенә салып куйды.

Зал уртасындагы кыска торыклы журнал өстәле артына килеп утырган Нәфнәф тәмәке кабызды. Үтә күренмәле, тирән эчле көлсавытта гел аның төпчекләре өелгән иде. Шунда гына Шәех Нур әлеге «күпбелгән»нең тозагына эләккәнен аңлап алды. Фатир түгел, яшерен очрашулар өчен сакланган явка камерасы икән лә бу.

—Сиңа Альянс Фәридуновичка охшаган фотоларны кем бирде? Һәм нинди максат белән?

—Бирмәде. Мин аны үзем сорап алдым... Бигрәк оперативно эшлисез икән!

—Белгән йә күргән нәрсәне генә сорап алып була. Димәк, сез күптән аралашып, кинәшеп, ә бәлки махсус оештырып бирәр провокация әзерлисездер!

—Сез нәрсә инде, ул хәтлек! 37нче елда яшәмибез ләбаса...

—37, 47, 57, 67нче ел булды ди...

—Шуннан ни?

—Юк, мин әле сиңа безнең җитәкчеләрнең туган елларын гына санадым.

—Ә быел 2007 бит инде! Сезнең оешма һаман исән-имин эшләп ятамы?

—Имин дип бик дөрес искәрттең. Дәүләт булган җирдә һәрвакыт иминлекне саклау кирәк. Димәк, без кирәк...

—Нинди дәүләт инде ул?! Безнең атауның бөтен җирен урман-суын мәскәүлеләр, инвесторлар, пайчылар сатып алып бетерде, җире булмагач, бернинди дәүләтебез дә юк дигән сүз ич инде.

—Эчке эшләр министрлыгы да, прокуратура, надзор, суд, ФСБ, УСБ, «Альфа», «Бетта», «Омега» ... һәм шул исәптән безнең оешма да—барыбыз да федераль дәүләт интересларын яклыйбыз... Хәер, сүзне читкә бормыйк әле, гражданин Шәехнуров. Төгәл сорауга төгәл җавабыңны язып бир дә, бар Сабан туеңа...

—Нәрсә язарга тиеш соң мин?

—«Игезәкләр кичәсе»ндә фотограф Микулай Седой белән танышуыңны, аннан двойник эзләп «Оптимист» бакчасына баруыгызны. Ул биргән фотоларны Седой кушуы буенча Глава кулына да тапшыруыңны.

—Уен гына, бер шаяртып Кияү Тарханның кәефен күтәрергә генә теләдем ич мин.

—Тапкансың шаяртыр кеше. Ышандылар ди сиңа.

—Ник ышанмаска? Наполеонның да, Ленинның да, Сталинның да, Гитлерның да двойнигы булган. Дипломатиядә үзеңә охшаган кешеләр белән интригалар оештыру элек-электән билгеле.

—Вәт именно—интрига оештыру... Димәк, Седой сиңа ул фотоларны ниндидер интригалар өчен тоттырган!

—Ник ул кушсын? Мин үзем ... мәзәк итеп.

—Юк, гражданин Шәехнуров, мин ничек әйтсәм шулай язасың. Телдән сөйләү бер хәл, ә язып бирү—бөтенләй башка нәрсә. Кәгазь—ул документ. Сөйләнеп кенә котылмакчы... Сезнең фамилиягә ышанмаска хакыбыз бар.

—Причем монда минем фамилия?

—Әтиең—Дияр Хафизулловичның ике хатыны картаеп үлгән. Бертуган абыең Габдулла, исән-сау килеш әсир төшеп, сугыш беткәннән соң да унбиш ел буе качып яткан, Молдованың Румыннар белән чиктәш бер шәһәрендә.

—Әйе, абыем аңын югалткан хәлдә, сез әйткәнчә исән-сау килеш әсир төшкән, Польшаның Гданьск шәһәрендә концлагерьда яткан. Сугыш бетәргә ярты ел кала концлагерьдан качканнар...

—Качканнармы, әллә чыгарып җибәргәннәрме?

—Ну, иртән уянып китсәләр, бөтен лагерь тып-тын ди. Эт тә өрми, полицейскийлар да сүгенми ди. Казарманың ишеген төртеп карыйлар—бикле түгел ди. Урамга чыгалар—дошман күренми. Олы капка төбенә хәтлек ачык ди. Фашистлар төнлә шулкадәр ашыгып чигенгәннәр, хәтта тоткыннарны юк итәрлек тә вакытлары калмаган... Ну алар бит бөтен лагерь белән исән котылганнар... Әйе, кайтышлый бер молдованка белән кавышып, Вулканешты бистәсендә яшәп калган. Туп-туры өйгә кайтып, «Сатлык җан» кушаматы белән яшәргә хурлангандыр. Җинүнең 40 еллыгы уңаеннан Германия сигез йөз илле дойч марка ярдәм бирде әле аңарга.

—Шәехнуров, бу легенда абыең сөйләгәннәрдән чыгып кына әвәләнгән.

Чынбарлыкта ни булганын беләсең килсә безнең архивка килеп документларын өйрәнерсең, рөхсәт итәрбез.

—Беләсем килми. Кабердәге кешенең җавап бирәсе юк.

—Үлгәннәр өчен исәннәр җавап тота... Менә кәгазь, менә ручка, Седойның сиңа нинди задание биргәнен аңлатып яз.

—Миннән башка да бөтенесен белеп торасыз икән, кәгазь күпертүнең нигә кирәге бар?

—Делога теркәр өчен.

—Нинди делога?!!

—Фотохәбәрче Седой белән күптән кызыксынабыз инде без. Азатлык мәйданындагы пикетларны, митингларны артык ярата ул, берсен-бер калдырмыйча өчәр фотоаппарат күтәреп чыга. Ачлык игълан иткән милләтчеләрнең фотокүргәзмәсен оештырганын да беләсеңдер—телевидениенең бәйсез каналлары бөтен дөньяга шаулатып Яңа Хөкүмәтне тәмам мыскыл итте.

—Димәк, мин, хәзер сезнең делога кәгазь кирәк өчен генә, матбугат ветераны өстеннән әләк язып бирергә тиешме?

—Син язганны беркем дә белмәс. Исемең урынына псевдоним куябыз: әйтик—«Муса». Бар иде Шәех Нур, юк Шәехнуров, эзләмәгез, табалмассыз аны, ул хәзер «Муса»!

—Тагын репрессия башландымы? Хөррият дибез, сүз иреге, ачык чикләр дибез, шушы булдымы Яңа чор?

—Син, Шәехнуров, базар демократиясе белән дәүләтчелекне саклау сәясәтен бутама. Җәмгыятьтә халык теләгәнчә генә иркле яшәү булалмый. Дәүләт гел үзенең каты куллы лидерын көтеп ята. Барыбер киләчәк ул тиран. Һәм шулчакны тагын бик күпләр җавап тотачак—аларның исемнәре күптән билгеле инде, җыеп аласы гына бар.

Шәех Нурның тәне куырылып килде. Кичәге тарихны кинолардан күреп, китаплардан-дәреслекләрдән укып кына түгел, иң газиз, иң ышанычлы кеше—әтисеннән ишетеп тә яхшы белә... Әлеге 37нче фатир да сталинизм чорыннан исән-имин качып калган, бөтен хәвефе белән сакланган җәза камерасыдыр. Менә бу тимер умырткалы, тирән калпаклы өстәл прожекторы, тәрәзәләрдәге корыч рәшәткәләр, тәнеңне өшетерлек шакмаклы таш җәелгән кытыршы идән, башыңны бәрсәләр дә күршеләр ишетмәслек калын кирпеч стена, чыелдап ачыла торган броняллы ишек... Әнә, түшәм почмагындагы ыргаклар да тәрәзә өстенә чигүле кашагалар эләр өчен түгелдер, кулларыңны артка каерып тарттырыр өчендер. Барысы да алдан ук уйланылган, хәтта аңа дигән кушаматның «Муса» булуы да... Шәех Нурның әле тырнак төпләренә, әле табан астына, әле йөрәк турысына камыт энәләре кадалгандай булды, сулардай һавасы югалып-югалып торды, плитә өстендәге корымлы чәйнекнең капкачын ачып йотлыга-йотлыга су эчәсе килде. Бер имза куясың да—син сексот, син—сатлык, син—үзең гаепле... Тагын кырык елдан гайбәтче архивлар үзләренең серен ача. Һәм «Муса» дигән әләкченең Шәех Нурлыгы бөтен нәселенә нәҗес булып кайта... Хәзер, әнә, 60-70нче еллардагы серләр сертотмас үрдәкләр кулында... Ул елларда имза куйган күпме әләкче үзенең кырыгын көтеп ятадыр...

—Мин язмыйм да, кул да куймыйм!

—Ну, утырасың инде алайса шушы бүлмәдә. Мин киттем, сәгать саен шалтыратып торырмын, язмый хәлең юк... Да, менә бу бланкка кул куй әле.

—Тагын нәрсә инде?

—Бүгенге әңгәмә турында кырык ел үткәнче беркемгә дә сөйләмәскә дигән расписка.

—Анысына ике дә уйламый кул куям.—Шәех Нур, имза куеп, авторучканы кесәсенә тыкты да кинәт торып басты.—Кайткач әтиемә сөйләргә туры килер. Төпчек улының хәлен белеп торсын.

—Ну, үзенә кара! За утечьку информации—син җаваплы хәзер. Ә чиста кәгазь өстәлдә кала, тизрәк язсаң—тизрәк чыгасың.

—Язмыйм!

Һәм Шәех Нур янадан өстәл артына утырырга теләмәде. Үзенең ни дәрәҗәдә гаеплелеген, әлеге очракта криминал бармы-юкмы икәнен беләсе килде аның. Менә ул хәзер каушамыйча гына, әкрен-әкрен атлап ишеккә юнәлә. Шкафтан пәлтәсен алып кия. Ишекне юри генә бикләгән булган Нәфнәф, этеп ача да бу рухи зинданнан ирекккә чыга. Әгәр Нәфнәф ташланса... Баш чүмечендәге чәчтән умырып тота алмас, Шәех Нурның модага ияреп тап-такыр итеп китәрелгән чагы. Кулны каерса... эченә тибәргәме? Юктыр, бу Нәфнәф махсус мәктәптә сугышчан әзерлек үткәндер. Хәер, беткән баш беткән, кире чигенү юк.

—Гражданин Шәехнуров! Кая киттең, ану-ка сидеть!—Ләкин Нәфнәф баскан җирендә калды, кычкыруы да бәйдән ычкынган этләә ерактан торып команда биргән ише генә, куркытыр өчен генә иде.

—Гаебем булса, повестка белән чакырырсыз!—диде Шәех Нур, сүгенүдән чак тыелып. Һәм аңа каяндыр, ишекне бик каты итеп ябарлык көч килгән иде инде.

***

«Чулман утлары» редакциясендә чираттагы дүшәмбе, ягъни газетага нигез салынганнан бирле бу көнне гел киңәшмә үткәрелә. Рәсми телдә «планерка» дип аталса да, хезмәткәрләр өчен ул «Иван Иваныч укулары» буларак телгә кергән, үз итеп, шаяртып, әлбәттә.

Иртәнге тугызда эш сәгате башлана, шуңа күрә редактор бүлмәсендә бөтенесе дә җыелып беткән булырга тиеш. Ләкин газетага нигез салынган көннән бирле бу планеркаларның бер генә тапкыр да үз вакытында башланганы юк. Һәркемнең соңга калдыра торган үз сәбәбе бар, һәр сәбәпнең тагаен беркетелгән үз хуҗасы бар. Айрат редакторның дачасында кар көри, Шаһбан инде унсигезенче тапкыр күршесен күмә, Ләләнең инде менә егерме ел була, һаман теге чакыртылган сантехнигы күренми.

Кодрәтеннән килсә, Иван Иваныч кояшны сейфына бикләп куяр иде дә үзенә кирәк чакта гына чыгарып торыр иде. Аның тәрәзәләре өйләгә чаклы яп-якты, чебен таеп егылырлык шома пеләше кояш батареена әверелеп, кабинетка кергән бөтен нурны үзенә җыеп тора. Ул, гадәттәгечә, кибет кульяулыгы белән маңгаен корыткан арада, «ыһым-ыһым!» дигән ымлык белән тамак кырып, киңәшмәгә тел ачкычы булырдай беренче сүзне эзли башлый, күңеленнән генә бизмәнгә салып, аның файдалы вә зыянлы ягын үлчәп өлгерә. Ул арада туган ялыктыргыч тынлыкны ике-өч кат «ыһым-ыһым!» бүлдерә. Сукбайлар арасына килеп эләккән бер психиатр әйткән имеш: ыһым-ыһым дип туктаусыз тамак кыру кешедә ике «мин»нең тартышуы, ягъни саранлык белән хөсетлектән яралган нерв өянәге дигән. Андый чир юмарт хәерчеләрне гупчым интектерми икән.

Иван Иваныч эзләгән теге сүз, хәрби дикторлар тавышы белән, көтелмәгән яңалык итеп җиткерелә. Ләкин, ни кызганыч, шаккатулы чырай белән: «Да?! Нужәли? Булмастыр ла!» дип тыңларга өйрәнгән хезмәттәшләр ул яңалыкны инде әллә кайчан белгән булып чыга. Аларның белгәнен редакторның белмәве киеренкелекне бушандыра, эчке пружиналар хәрәкәткә килә, чырайның көлә торган мускуллары тибенә, җитди хәбәрдән дә елмаю сирпелә башлый. Ләкин планеркада бүген редакторның үзеннән башка һичкем белмәгән яңалык та бар иде.

—Шушы арада Шәех Нур Шәехнуровны өлкә газетасына махсус хәбәрче итеп күчерәбез,—дип әйтүенә, хезмәттәшләр йөзендәге дәвамлы елмаю ут

сүнгәндәй кинәт юк булды.

—Ник мине?!. Журналистлар союзына алынып җитмәгән килеш...

—Беренчедән, чакырсалар үзем китәр идем әле спецкорр булып, чакырмыйлар. Аларга син кирәк. Икенчедән, сине союзга әгъза итү нигездә хәл ителгән инде: рекомендацияләрең бар, басылып чыккан фельетоннарың җитәрлек. Бүген-иртәгә җыясы идарә утырышында хәл ителер. Әгәр спецкорр булып китәргә теләмәсәң, район хакимиятенә милли мәсьәләләр буенча урынбасар итеп урнаштырам.

Шәех Нурның бөтенләй кәефе төште. Проблемалары кимеми, киресенчә, арта гына бара. Яшәгән фатиры җир белән күк арасында—әле һаман хосусыйлаштырылмаган. Кияү Тарханның рөхсәте юк. Әти-әнисе, карт көнендә малай ярдәменә өметләнеп яшәп ята. Инде эш урыны югалырга тора, бөтен матбугат чараларын акционерлаштырып куйдылар да баш редакторларның хезмәт хакын ун тапкырга күтәрделәр. Пенсиягә чыккач бер сәгать тә эшләмим дип йөргән Иван Иваныч, мин китсәм бетәсез бит сез, дип, кәнәфиенә контор келәе белән сыланган кебек, ябышып ята. Һәр өметле журналист, һичьюгы шәп получка өчен генә булса да аның урынына кызыгадыр дип коты оча. Шәехнуровны югарыга этәрергә тырышуы да гуманлык йөзеннән түгел, кәнәфидән ераграк җибәрү өчен генә... Хислимәне көтеп яшәү дә алжытты. Инде аннан бер ел соңрак кергән Франгизә дә укуын тәмамлап «Чулман утлары»на җаваплы секретарь булып кайтып утырды. «Кайчан кайта инде Хислимәң? Икегез ике җирдә никахлы буйдак булып күпме яшәрсез икән тагын?»—дип сорамый калган көне юк. Франгизә белән Кол Харис буш вакытларында шигъри SMSлар алыша—бер кабинетта янәшә утырган килеш. Әнисе ерак командировкаларга киткән чакта кыз аны өенә төшке ашка алып кайта. Шәех Нурны да чакыргандай итәләр—кызганып, күнеле булсын өчен генә, бармаслык итеп кенә...

«Җитәр, Шәех Нур,—диде ул үз-үзенә,—эчке дөньяңа күңел тынычлыгы керсен дисәң, тышкы дөньяңны тәртипкә салырга вакыт! Киләчәгеңне үзгәртергә теләсәң Хислимәдән башла, Нуриягә җавап язмый тор, эшеңнән китәргә ашыкма. Журналистлар союзына барып кайт. Үз аягы белән мәрхәмәт килгәнне көтеп ятма, хакыйкатьне яулап ал...»

***

Кинәшмә вакытында тавышы сүндерелгән кесә телефоныннан Хислимәнең хәбәрен күреп алды Шәех Нур: «Бәгырем, кайтып киләм. Өйдә бул» дигән. Алай да сакау пәпә кебек SMSларга ышанып ук бетмәде, каракаршы сөйләшергә булды. Тик сөйләшү чамасыз кыска килеп чыкты.

—Нихәл? Автобусыгыз кайсы тирәдә?

—Кыстыбый туктальшын үттек инде, матурым.

—Озаккамы? Берәр яңалык бармы әллә?

—Белмим әле. Яңалык шул—аспирантураны ташладым. Ярый, кайткач сөйләшербез. Монда кеше күп...

Дөресе шул—Хислимәнең кайтуын көтте Шәех Нур. Һәм менә көткәнен ишетте. Әмма күнелендә сөенеч артмады. Аспирантурасын ташлаганга күрә генә уйланылган күрешү бит бу. Аптырагач, бөтенләе белән Чулманга күчеп килергә дә ризадыр ул, бәлки. Телисеңме, теләмисеңме—законный кунак. Хатыныңны кочак җәеп каршы алырга гына кала. Килсен соң, әйдә. Зарлы бүлмәдә ялгызың йомылып ятканчы, кухня ягыннан «әү?!» дип торырлык иптәш—тормыш иптәше булыр шунда...

Шәех Нурның ныклы ниятен ишетеп болытлар таралды. Кояш ниһаять Иван Иванычның сейфыннан чыкты. Аяк астындагы иске кар шулпаланды. Мартның суыткычы ватылды. Җылы җилдә яз исе йөри.

Иң зур сәүдә үзәгенә кереп, артык сайланмыйча гына кирәк-яраклар җыя башлады. Буш вакытын булса әйбер алмаган килеш тә кибетләрдә көне буе йөрергә була. Ләкин Шәех Нурның вакыты юк. Хислимәне табадан төшкән ризык, тәм-том белән, шампаннар куеп, юк, коньяклы өстәл җәеп каршы алырга кирәк... «Постельное белье» бүлегеннән бер өем япма сатып алды—мендәр тышлыгына чаклы ромашка чәчәгеннән—нәкъ Шәмдәлнең ындыр артындагы тар урманлы аланы кебек. Ике төрле шампунь сайлаган иде, хатын-кызлар өчен дигәнен кире куйды, фатирына бичәләр оялаган, ахрысы, дип Хислимә көнләшергә мөмкин. Әйе-әйе, өй эчен җентекләп карап чыгасы булыр. Нуриянең хатлары эләкмәсен, яна фотоларны да яшерергә кирәк. Кол Харис белән Франгизә аулак өй эзләп килгәлиләр иде, сөлгеләре онытылып калган, аны да алып өлгерергә, диванга озын чәчләр ябышмаганмы, иннек таплары юкмы... Хәер, нигә дип шул тиклем тәтиләнергә әле, Шәех Нурның Хислимә тормышына ревизия ясаганы юк ич...

***

Табын артында ашап-эчү бик ашыгыч килеп чыкты. Әйтерсең лә алар поезд туктаган арада станция кафесына тамак ялгарга дип кенә кергәннәр. Хислимәне сагыну, ир уртасы яшенә җиткән Шәех Нурның хатын-кыз тәненә карата җыелган талымсыз сусавы белән кушылып, бүгенге вакыйгалардан ыгы-зыгы ясый, гел ашыктырып, дәртләндереп тора. Кайткач сөйләшербез дигән вәгъдәләр онытылды. Житди сүзгә күчсәң, көрешү комарлыгыннан пыран-заран киләсе билгеле бит инде...

—Әйдә, урын-жирне алыштырабыз. Мин яңа комплект алып кайттым. Җәеп куйыйк әле шуны.

Хислимә сүзсез-нисез генә уенга кушылды.

Алар, гомер буе икәүләшеп урын җәйгән парлар кебек, юрган-мендәрләргә чәчәкле күлмәк кидерделәр, простыняның бөтен кинлегенә диванны тараттылар. Хислимә мендәрләрне кабарткан арада Шәех Нурга күз төшереп алгач: «Абау, канатлана бу—дәртле чебеш!»—дип елмаеп куйды. Ләкин аның елмаюы үзе өчен түгел, Шәех Нур өчен генә иде.

Минутына күрә әйтелә торган ымлыкларны исәпкә алмаганда, уен һаман да сүзсез-нисез генә дәвам итте. Пәрдәне корып утын сүндергәч, бүлмә эчендә эңгер куерды. Ятасың, гүя кечке болында назланып, табигатьнең ике баласы, анадан тума килеш... Җил исми, кырмыска тешләми, черки таламый, дошман күзе төшми. Сулышына чәчәк бәйләме исе ияргә...

Гыйшык аланындагы ромашка бизәкләре сытылды, тәелде, бөгәрләнде...

Хислимә, юрган почмагы белән капланып, үкси-үкси елап алды. Шул арада ук, урыннан торып, халатын киде, битен-күзен сөртмичә генә юыну бүлмәсенә кереп китте. Сәер, үзенең керфекләреннән яшь тама, үзе елмая... «Абау!»—дигән арада, елаудан елмаюга күчеп өлгерер өчен ким дигәндә җилбәзәк йә чиксез бәхетле хатын булырга кирәк...

Шәех Нур юынып чыкканчы Хислимә инде урынны җыйган, диванны күтәргән, чәй янарткан иде.

Икейөзле гыйшык уены бетте, көрешүнең чын асылы калды. Күн ягы белән чөелгән көмеш тәнкә иләк ягы белән килеп төште. Кем гаепле, кайда, кайчан, ник?.. Көрешмичә үткән һәр көнең бер сорау бит ул.

—Син бөтенләйгәме?

Хислимә эндәшмәде, Шәех Нур аның: «Әйе, әйе, бөтенләйгә! Күп газапладык инде бер-беребезне, җитәр!»—дип өзгәләнүен көткән иде. Читтән торып укыдым, хатыным белән читтән торып яшим.

—Ә мин ... чит илгә китәргә булдым.

—Көтәләрме?

—Бәхетемне сынап карыйм әле, тагын бер тапкыр.

—Сыналган кадәрлесе дә житкәндер, бәлки? Инглиз телен дәреслекләрдән укыдым дип кенә англичанка була алмыйсың инде ул.

—Барыбер китәм. Бала карыйм, урам себерәм, гувернантка, хет отельгә горничная булып урнашам. Тик кире кайтмыйм...

—Авылга кайтып өйдәгеләренә әйттеңме соң әле?

—Юк. Әйтеп тормыйм, кинәшләрен беләм. Син дә минем әти-әни кебегрәк фикер йөртәсең. Алар нәсихәтен ишетәм.

—Алайса, кал Чулманда! Яшьлекнең калган өлешен кешечә дәвам итик. Монда кыен дисәң Азанга күчәрбез.

—Көчәнмә, матурым. Мине түгел, үзеңне кызган. Мирдән калган белән яши дип синнән көләчәкләр... Әтиең Дияр агайның күз карашыннан, әниең Нәсимәттәйнең каргышыннан куркам.

—Болар барысы да бүгенге халәтең генә. Хурлану, кимсенү, газаплану—яши-яши онытыла әле ул... Исенә төшер: без бит синең белән кечкенәдән сөешкән кешеләр. Бер салам белән икәүләшеп каен сулары эчтек, бер жир жиләген урталай тешләп каптык, ирengә-ирен килеп, сөенә-сөенә таңнар аттырдык—авылыбыз офыгында кояшның ничек туганын күрдек. Сине иң беренче үпкән егет ич мин! Яшьлек мәхәббәтенең иң газаплы минутларын, күрешү сөенечләрен, наз рәхәтен тойдык. Рәхәт иде бит безгә, Хислимә, рәхәт идеме, әйт?! Киләчәктә дә рәхәтләнеп яшәрбез.

—Рәхәтләнеп яшәрбез?!. Шәехнуров, рәхәтнең үткән заманы да юк, киләчәк заманы да булалмый. Рәхәт—ул хәзерге заман гына. Безнең бүгенгебез юк. Кыскасы, аерылышыр өчен кайттым. Шунсыз миңа чит илдә яшәргә рөхсәт итмәячәкләр. Ә гражданлык хокукы алу турында хыялланасы да юк... Озак эш түгел, баласыз парларны көн эчендә аералар. Син яшәгән районның ЗАГС бүлегенә икәү килеп, аерылышырга риза, дигән гариза язабыз да—вәссәләм!

—Сине үгетләүдән файда юк инде, Хислимә. Һәр яманлыкны яхшыга юрарга өйрәнеп киләм мин... Теләсәң, бүгеннән аерылдык дип исәплә. Кол Харисларга барып кунам.

—Кирәкми, матурым. Чулман буйлап шаулап йөрмә. Дуслар булып калыйк. Жырларда жырланганча: «Бүген безнең мәхәббәтнең соңгы төне...» Ашыйк, эчик, жыларбыз, жырларбыз. Сөеп кал, мин синеке әле бүген! Бу безнең аерылышу туе булыр.

—Алайса, аерылышу туена никахыбыз шаһитларын да чакырыйк: Франгизә белән Фәләх Сәмигуллинны... Жавап тотсын алар да!

—Вакланма, Шәехнуров, жәнжаллар куптарырлык вакыт калмады!

—Тәннәр тәнгә якынайган саен аралар ерагая...

Шулай итеп, Шәех Нурны тышаулап куйган жиде төенле чи каешның иң зур төене чишелде. Буйдак егетнең адымнары кинәйде, сулышы иркенәйде, гәүдәсе турайды...

## Унбер чәүкә

Чынбарлыкның асыл йөзе кичәге ялганны фаш иткәч кенә ачыла. Бүгенге дөреслекне турыдан-туры язар өчен әллә ничә патшаның тәхетеннән төшкәнен күтәргә, кыюлык белән ялган көрәшкәнне үз күзләрең белән күрергә, кичәге китапларның мәйданда янганын карап торырга кирәк. Власть белән власть, ялган белән ялган алышынган саен елъязмачылар да алышына һәм һәр чорның ялганы дөреслек булып яшәп ала.

Бүгенге дөреслекне яклар өчен бик озын гомерле булырга кирәк.

Журналистлар союзына әгъза итеп алганда аны идарәнең егерме бер кешесе мактап чыкты. Утырыш беркетмәсенә Шәехнуров, Шәех Нур псевдонимы

белән талантлы, перспективалы, принципиаль, актив, оригиналь журналист булып теркәлде. Өч рекомендация арасыннан сайлап, Иван Иваныч язганын кычкырып укып чыккач, егерме бер кеше алкышлады.

Ә яшерен тавыш бирү урнасын бушатып, «чәүкәләр»не саный башлагач, Шәех Нур үзен монафыйклыкның уртасында калгандай хис итте: ун кеше аның исемен сызып ташлаган иде, иҗат карьерасын тик бер «чәүкә» хәл иткән булып чыкты. Сүз һәм гамәл—икейөзленең ике ягы. Яшерен тавыш биреп дусларны санарга да, сынарга да була, ләкин таянып булмый.

Яшерен тавыш белән сайлау—куркак януслар уйлап тапкан демократия уены...

***

Иҗат дөньясында ифратлар да чисталык сөючән халык яши, алар һәр бүләк, уңыш, шатлыкны зурдан кубып юып тора. Союзга яңа алынган журналист, гасырлар буена сакланган күркәм йола кушканча, яңа билетны бик шәпләп юарга тиеш. Шәех Нур «Тал» кафесында егерме биш урынлык зал сөйләшеп куйды. Банкетка дәшеп, ул иң әвәл үзенә юллама биргән остазы Микулай Седойга шылтыратты. Ләкин кәефе юк чакка туры килде, фотохәбәрче агайның бакчадагы өен басканнар. Ишеген каерып кергәннәр, транзисторлы иске радиоалгычын, электрон сәгатьне, тагын шуның ише вак-төякне алып киткәннәр. Бала-чага эше дияр иден дә... Стенадагы электр чыбыкларын балта белән өзгәләп, караваттагы җаймаләргә, мендәрләргә түбә буярга дип алынган куе зәңгәр буяуны түгеп чыкканнар. Монысын үсмерләр явызлыгы диярсең... Ләкин агач тартмага тыгызлап тутырылган фотоларны туздырып негатив тасмаларын алып киткәннәр... Болары ни бала-чага, ни үсмерләр, ни очраклы караклар эше түгелдер...

Идарә рәисе Дәүләт җыелышына депутат булып сайланган кеше. Шуңа күрә дә Шәех Нур табынны олуг җитәкче күнеленә хуш килерлек итеп әзерләтте: кабымлыкларга акча кызганмады, зәһәр эчемлекләрнең дә «Арарат» коньягы белән «Двойной стандарт» аракысын гына куйдырды. Кунаклар аерым-аерым да килде, төркем-төркем дә җыелды. Килгән берсе Шәех Нурны тагын чын күңелдән котлап кулын кысты, аркасыннан сөйде...

«Арарат» бигүк әрмән коньягы булып җитмәде, ахрысы, күкләргә чөеп тостлар әйткәндә халык әкренләп грузин акцентына күчте. «Двойной стандарт» шешәләренә чират җитте...

Ни хикмәттер, Шәех Нурга бүген аракы үтмәде. Мәҗлес тамашасына җыелган идарәне ул яшерен тавыш бирү тәртибе белән барлап карады. «Кара чәүкә»ләрнең унысын кундырырлык унбиш, унсигез, егерме кеше тапты... Саннар арасында буталып бетте. Аннан соң ул үзен яклаучыларны санап карады—алары да унбер, унбиш, егермегә тулды... Болар арасында Нәфнәфнең «Мусалары» бар микән?... Шәех Нур сүз алырга дип әллә ничә талпынды, тик аны ишетмәделәр: мактадылар да мактадылар.

Билен өзәрдәй иттереп алъяпкыч путасын тарттырган официант кыз Шәех Нурның эчми утыруына каныкты. Ул, әлбәттә, банкетта журналистлар җыелганын алдан ук белгән, ләкин ни сәбәпле килгәннәрен һаман төшенми. Игътибар үзәгендә калган егетне, юбиляр булмагае дип, чамасыз кыстарга керәште.

—Ник бер дә эчмисез соң? Бүген бит сезнең бәйрәм,—дип беразга югалып тора да тагын килә.—Әле һаман эчми утырасызмы?! Үпкәләгән диярләр бит, күтәреп куегыз...

Тиз арада ул янә Шәех Нур янында пәйда була. Тагын кыстый башлый.

—Йөз граммнан, әллә шунда, сер бирмәссез. Ашап эчкәндә стрессны

әйбәт ала ул. Шатлыклы вакыйга кешене ыграк алҗыта... Кафе хезмәтенә шелтәгез юктыр ич, әчми торган юбиляр бик вакчыл була ул. Андыйлардан безнең директор бик курка.

Тәки җиңелде Шәех Нур, юкса бүген әчәргә бөтенләй дә теләге юк иде.

—Сеңлем,—диде ул официантның алъяпкыч итәгеннән чеметемләп,—сыйла, әйдә!

Шәех Нур рюмканы бушатуга кыз тутырып куя. Тагын бушата—тагын тутыра. Рәттән биш рюмка күтәргәч, кунаклар сыйлану шөгылен онытып, яңа әгъзадан яңа маҗара көтте. Шәех Нур буш кулы белән үрелеп зәйтүн җимеше капкан чакта да официант кызның алъяпкычын ычкындырмыйча торды.

—Их!—дип куйды ул—биш йотымга ияреп кергән сулышны берьюлы чыгаргандай уфтанып,—өйдә шушындый да үгетли-үгетли сыйлый торган хатының булса икән ул!

Официант кыз мәҗлестәгеләрне көлдерерлек дәрәҗәдә дөрес кеше булып чыкты:

—Өйдәгесен мин дә сыйламыйм шул!—диде.

Официант кыздан көлдеме халык, әллә Шәех Нурданмы—анысын төгәл әйтүе кыен. Ләкин Иван Иваныч үзенең тамада вазифасын дәвам итәрлек хәлдә иде әле.

—Хөрмәтле коллегалар!—диде ул, өч катлы кәгазь салфетка белән пеләшен корытып,—дустыбыз өлгереп пеште, тост әйтеренә чират җитте.

Шунысы сәер, моңарчы гел шаулашып утырган мәҗлес Шәех Нурны тыңлар өчен шым булды. Әйтерсең лә аңа хөкем залында соңгы сүз бирелә.

—«Периодическая печать» дигәнне безнең халык вакытлы матбугат дип бик белеп тәрҗемә иткән. Реформа башланган елларда «Дүртенче власть» дәрәҗәсенә җиткән журналистиканың вакыты бетеп бара. Сүз иреге, фикер төрлелеге, альтернатива, хөррият—болар барысы да базар әкиятләре генә. Нинди бәйсезлек ди ул?! Ике байраклы ил бәйсез була аламыни?!—Шәех Нур соңгы җөмләсен төбәп әйтердәй кеше эзләп як-ягына каранды, тик Иван Иванычтан арыны тапмагач, фикерен үзгәртте.—Бүгенге кризиста мин сезгә теләгән кадәр эчә алырдай саулык кына телим!...

## Каравылчы борчагы

«Тал» кафесыннан иң соңгы кунак булып Шәех Нур үзе чыкты. Чыкса—шәһәр урамы лампалар көненә күчкән. Анда-санда яшьләр авазы ишетелә—әллә әрләшәләр, әллә чукраклар барысы да—һәр әйтелгән сүзләре көчәеп, һавада эленеп тора сыман.

Ул үзәккә таба атлады, ләкин ни өчен шушы якка икәнен үзе дә белми. Ике миллион кешеле мәркәздә болай япа-ялгыз калганы юк иде әле. Шәһәрнең котылгысыз үги төне аның тәнен куырып тора. Такси туктатып әти-әнисе янына кайтырга була булуын. Шәмдәл авылы кырык чакрымда, Иван Иваныч әйтмешли, татар радиусында гына. Мин хәзер билетлы журналист дип кенә өйдәгеләрне сөендереп булмас. Әтисе хәл-әхвәлләрне сорашып торганчы, иң әвәл: «Йә, Шәехнур, алга таба нишләргә уйлыйсың инде?»—дип исәнләшер. Андый авыр сорауга җавап әзер түгел әле.

—Шәехнуров!—Таныш тавыш куып җитте. Борылып карамыйча да таныды ул аны. Доцент Фәләх Сәмигуллин бу.—Шәех Нур Диярович, бик ашыкмасагыз бергәрәк атлыйк,—диде ул, бәрхетле тембрны сакларга тырышып кына.

—Атлыйк соң. Кафедан расчет ясап чыкканчы кунаклар таралышып беткәндер дигән идем инде мин, каян килеп чыктыгыз болай?

—Махсус сезне көтеп тордым.

—Юатыргамы?

—Киңәш бирергә. Педагог... һәм дә идарә кешесе буларак.

—Аспирантурага керәсем юк, чит илгә китәргә теләмим. Хислимә белән аралар үзелде... Нинди киңәш бирә алырсыз икән миңа?

—Йә, Шәех Нур, алга таба нишләргә уйлыйсыз инде?

—Киңәш түгел бу, бу—әтидән дә яман допрос алу.

—Җавабың юк, алайса... Сиңа провинциаль шәһәрдән кайтырга кирәк... Каян шундый тост әйтергә башыңа килде бүген? Тост түгел—Ленинның броневик өстенә басып сөйләгән Апрель тезислары инде! Мондый настроение белән кечкенә шәһәрдә яшәргә ярамый. Чулман—ул бер аквариум кебек кенә, ничек яшәгәненне, ни ашаганыңны, кая сыенганыңны, кемгә ияргәнеңне төрле яктан карап торалар, качып котыла торган түгел... Ә мәркәз—диңгез кеби: теләсәң су өстенә сикер; куркыныч килгәндә төпкә чум; зур балыклар белән янәшәдә маймычлар да яши ала, аугa, кармакка, чуртанга эләкмәсәләр яшиләр посып кына.

—Сезнеңчә мин аквариум маймычы инде?!.

—Кит балыгы түгелсең бит әле. Мондый тостлар әйтеп йөрсәң, булалмассың да. Зур исемле журналистлар, филологлар, идарә члennары җыелган да акыллы чырай күрсәтеп утыралар, ә халыкка әйтер сүзләре юк дисең инде син, әйеме?

—Мин алай дип әйтмәдем...

—Әйттең, әйттең! Тостыңның мәгънәсе шул... Иҗат кешесе якты дөньяга туганда ук үҗәтлек, кирелеге белән килә. Син әйтергә теләгән фикерләр безнең бәгырьдә таш булып каткан инде. Әйе шул, моннан алты гасыр элек кенә Олуг Мөхәммәтебез Мәскәү кенәзләренә хан ярлыгы өләшкән, ясак җыйган. Ә бүген киресенчә... Егерме ел буе ике байраклы тәхеттә утырган Оныкь Мөхәммәт Мәскәү кенәзенә барып Ярлыгын алдырып кайтты... Моны без барыбыз да аңлыйбыз... Әйе шул, һәр илдә, һәр җөмһүрияттә тик бер генә дәүләт теле булырга тиеш... Икенең берсен сайла дисәләр, халык барыбер зуррагын, арзанрагын сайлап алачак. Әйе шул, егерме ел буе коммунистларны җитәкләгән хуҗабыз бүген үзе үк коммунистларга каршы...

—Минем Сезләрне мәйданда күргәнем юк.

—Әйе, түрәләрне яратырга, каршы дәшмәскә өйрәндек.

—Конституцион икейөзлелек була түгелме соң бу?! Карьера, дәрәҗә, мактаулы исемнәр алу өчен милләтне корбан итәбезме?

—Юк, сез дөрес әйтмисез. Ике конституция, ике байрак, ике гимн, халыкның икейөзлелеге—болар барысы да безнең илдәге тынычлык өчен кирәк. Яши-яши аңларсыз әле, Шәехнуров.

—Аңларга теләмәгәннәр демократия эзләп чит илгә чыгып качамы?

—Демократик илдә рәхәт яшәр өчен акча күп кирәк... Ярый, Шәехнуров, алга таба нишләргә уйлыйсыз инде? Чулманнан китәсеңме?

—Тагын эш эзлисе була... Тору урыны кирәк.

—Гел артистлар турында гына яза торган газеталар күп хәзер. Аларга цензура кереп җитмәде әле. Кайчакларда шактый гына кыю язмалары балкып ала. Теләсәң сөйләшеп куярмын... Баштагы мәлдә берәр бакчада яшәп торырсың. Бик күпләр шулай яши. Хәзерге законнар нигезендә дачаларга пропискага керергә дә була... Бүген кунарга урыныгыз бармы?

—Урын күп,—дигән булды Шәех Нур. Доцент алдында мескенләнеп торасы килмәде.—Азан каласы сагындырды, бераз урам әйләним дидем.

—Гафу итәрсез, үземә алып кайта алмыйм, хатын белән ике арада дипломатик сугыш бара... Ә сез нишләп Иван Иваныч машинасына утырып китмәдегез?

—Калдым әле. Авылга кереп өйдәгеләрнең хәлен беләсе бар. Әти белән дә киңәшәседер, бәлки.

Доцент белән пионерларча рапорт биргәнише генә саубуллашкач Шәех Нур үзен биләп алган баягы уйлары белән тагын бергә-бер калды. Бик теләсә

туганнан туган апаларына, күрше-күләнгә кайтып йөри торган дусларга, һич югы трактирга булса да кереп куна ала инде ул. Ләкин бүгенге фәлсәфи өермәләр аны этә-төртә һаман мажаралы сукмакка бора, тынгысызлап торган яна сорауларга жавап эзләргә куша иде.

Өлкәннәрнен, бала-чагаларнын йокы сәгате житкәндер дип тартынып тормыйча, Микулай Седойга шылтыратасы итте ул. Дөресрәге, фотографның бакчага күчеп яшәгәнен беләсе, шунда төн кунып кайтасы, югары эшелон тирәсендәге яңалыклардан хәбәрдар кешене тынлап карыйсы килгән иде. Ләкин бакча өен басканнан бирле аның «Оптимист»ка барганы юк икән. Бер кат юып, жыештырып-төзәткәләп киткән үзе. Ишегән бау белән генә боргычлаган, керәсе карак биген ватып йөрмәсен, янәсе... Кыскасы, туңа калсаң анда урын-жир житәрлек, теләгән кадәр яши аласың диде.

Вокзалга төшеп Киектау ягына баручы соңгы электричкага тәки өлгерде Шәех Нур...

***

«Оптимист» ширкәтеннән бакчачылар кача башлады..

Киектау урманы белән Азансу елгасы арасында житмеш гектарлы яшелчә жире бар иде. Яз житте исә, елга ярларыннан дулкын чыгып, яңгыр яуса урман эчендәге сазлыктан ташу төшеп, кырыкмаса-кырык ерганак ярган иде инде аны. Чалгы белән селтәнсәң түмгәккә кадалып, комбайн керсә батып, трактор керсә чумып интеккәнгә әлеге урынны болын, жир, яки кыр дип тә атамаганнар. Киектаулыларның жыелыш телендә ул «Кишерем басуы» дип кенә йөртелгән. Ел аралаш йә кәбестә, йә кишер чәчеп караганнар. Ләкин шушы чәчү әйләнешенә күнеккән жирле халык бер елны кәбестәсен урлап барган, икенче елны кишерен ташыган.

Алла каргаган «кишерем басуы»н тулаем мәйданы белән шәһәрнекеләр сорап килгәч, Киектау хакимияте сагаеп калган. Гади фермерлар гынамы— жәмгыятьнең колагы-күзе булып саналган дүртенче власть вәкилләре кызыксына икән—бу тикмәгә генә түгелдер... Берәр нинди төрле файдалы казылма табылгандыр, йә хәзинә-мазар күмелгәндер, Спартакиада һәм дә Олимпиада унаеннан туристлар базасы төзер өчен Мәскәү алып-сатарларының ошбу мәйданга күзе төшкән булырга да мөмкин. Ләкин муниципаллар күпме генә төпченеп, генпланнарны өйрәнеп, архивларны актарып, интернетта яшәп эзләнсәләр дә журналистларга «юк!» дип әйтерлек сәбәп тапмыйлар. Ахыр чиктә, килешүнең соңгы пункты итеп, ширкәт ун процент жирне Киектау халкына бүлеп бирергә тиеш, дигән йөкләмә өстәлә.

Ниһаять, жир матбугат зыялылары кулына күчкән. Һәркемгә мәгълүм, Рәсәй йөзем жимеше үстермәсә дә күбекле шәрабны Франциянең Шампан провинциясенә караганда ике йөз туксан тапкырга күбрәк житештерә. Шуңа күрәдер, йөз дә кырык биш миллион кеше Яңа елның беренче минутыннан шампан эчә башлый. Балаларын да кушып саныйбыз, чөнки алар өчен дә махсус күбекле шәраб чыгарыла.

Рәсәйдә шампан шәрабы ватылмыйча кораблар суга төшми, бөкеләр атылмыйча заводлар ачылмый, табышлы килешүләргә кул куйгач бокаллар чыңлый. Спортчылар жиңү яулагач бер-берсенә күбек сибә, тансык канизәкләр чыжылдап торган ваннага чумганда авызларында шоколад кисәге булыр... Хәтта кияү белән кәләшне кавыштырыр өчен дә яңа гаилә нигезендә дүрт-биш чиләк «Шампанское» коярга кирәк.

«Кишерем басуы» тапшырган көнне, совхоз директоры: «Бу бокалны мин кысыр жирдә гөлбакча үстерергә алынган оптимистлар өчен күтәрәм дигән.»

Бакчачылар ширкәтенең «Оптимист» булып калуы шуннан килә, имеш.

Кысыр жир турында декрет алып йөргән төркем «Оптимист»ның беренче

идарәсе булып сайланды. Мәгълүм ки, безнең илдә бер сайланганны гел сайларлар дигән Ходай. Инде егерме ел буе ширкәт белән шул ук кешеләр идарә итә иде...

Иде дими хәл юк—бакчадан нәкъ менә идарә составы кача башлады да инде.

Иң беренче булып Дәүләт советында яшәүче ике депутат китеп барды. Ширкәт чытырманлыгы җиләк-җимеш бирердәй гөлбакчага әверелгән арада алар инде дүртәр срокка сайланып, дүрт сутыйлы кишәрлеккә сыймастай алпавыт булып җитешкән иде. Депутатларнын кая күченгәнен карап кайтабыз дип киткән җирдән өч журналист белән ике баш редактор да юкка чыкты. «Оптимист»та чирәм җир күтәргән типография директорынын очлы түбәле өе янына бөркәүле «КамАЗ» килеп туктагач та бакчачылар гаҗәпләнмәде, Әтил ярында урын тапканнар, урынбасарын да үзе белән алсын, анда урын җитәрлек диделәр. Өен-мунчасын арзан хактан реелторга тапшырып, ширкәтнең баш бухгалтеры да Мәскәү юлы өстендәге Сослан кооперативына кергәнне белгәч, беркая да китәлмәстәй гади халык кыбырсый башлады.

Гадәттән тыш хәл рәвешендәрәк, гомуми җыелыш үткәрелде.

«Әллә безнең корабны су баса микән, күселәр качып бетте?»—дигән сорауга ширкәт рәисе Тегран җавап биреп карады:

—Менә мин качмыйм ич әле.

Ләкин аның җавабы җыелыштагыларны җылытмады, Тегран нинди дер фетнәдә катнашмаганы өчен биш балалы гаиләсе белән диаспорадан куылган. «Оптимист» аның соңгы тукталышы.

—Ашның өйрәсе өскә җыела. Байлар күчә торсын, ә без рәхәтләнеп яшик,—диде Нәгыйм.—Урам исемнәрен алыштырасы бар. Яңа идарә сайлыйк.

Нәгыйм ул элек... электрик иде. Өч тапкыр баганадан егылып төшеп, миен какшаткач, аны каравылчы итеп куйдылар. Оптимистлар бакчасында тугыз аллея бар, һәммәсе дә саннар белән теркәлгән. Ләкин бакчачылар аллеяларны Директор урамы, Депутатлар ягы, Казначей тыкрыгы диебрәк атап йөртә иде. Каравылчы Нәгыйм качкыннар урамына яңа исемнәр кушылырга тиеш дип әйтергә теләде. Чөнки халык судьясы Касыймнан бушаган урамда Нәгыймнең вагон тактасыннан корылган, рубероид түбәле үз өе бар иде.

Аллеяның түбән очындагылар җыелышка дип һаман килә. Кеше күбрәк җыела төшсен дигәндәй, каравылчы Нәгыйм сүз чиратын башкаларга бирми торды.

—Хөкүмәт йортында күрәзәче булып эшләүче хатын әйткән, зур комбинат салыначак, дигән. Спартакиадага килгән чит ил туристлары өчен, юан-юан калай торбалар аша, безнең урман һавасын мәркәзгә кудырачаклар икән. Ну, Башкалабызда саф һавага кытлык бит. Белмим, урманнарда саф һава бар микән ул хәзер? Элек бит халык утын ташып делянкаларны гел чистартып тора иде. Ипи мичләре генә түгел, авыл мунчалары да газга күчте лә. Сухостойлар аркылы-торкылы аунап, череп-кортлап ята. Элеккечә җиләк исләре, чәчәкләр хушы юк анда. Әнә, «Оптимист»ның урманга керә торган юлын кычыткан курасы басты, Киектаулыларга бүлеп бирелгән участоклар кебек кыргыйланып ята...

—Күрәзәче апаң тагын ниләр әйткән соң, Нәгыйм?—дип председатель аны канатландырып алды.

—Тагынмы? Мегаполисларда җир тетрәячәк ди.

—Без океан ярында яшәмибез лә...

—Океан монда нипричём. Хәтерлисезме, девон өстендә утырган районнарда җир тетрәде? Галимнәр язып чыкканые, өч миллиард тонна нефтьне суырып алгач, җир катламнары авышкан, дип. Зур шәһәрләрне дә шул язмыш көтә ди. Үзегез уйлап карагыз, йөз фатирлы бер йорт салып чыгар өчен дә ун мең тонна таш өеп куярга кирәк. Унҗиде, егерме биш катлы йортлар салу модасы

китте әнә! Азанда төзелеш өстенә төзелеш. Кояш төшәрдәй урамнары калмады, көн уртасы житкәч баш түбәсендә күренеп ала да, караңгылана. Шушы чаклы авырлыкны нинди жир катламы күтәреп тора алсын ди.

—Син бу күрәзәче хатын турында каян ишеттең соң?—дип гажәпләнде председатель Тегран.

—Кайдан булсын, рациядән. Милиция дулкынында ич ул. Төне буе тынлап чыгам. Жыелыш саен әйтелде, каравылчы йортына чыбыклы телефон кертергә дип. Эшкә тотынган кеше юк, баганалар утыртуы кыйбатка төшә, чыбыкларын кисеп урлarlар, имеш.

—Туктат, Нәгыйм, демагогиянне!—дип кырт кисмәкче иде Тегран, үз адресына тәнкыйть эләккәч, жыелган халык туктарга ирек бирмәде:

—Сөйлә, Нәгыйм! Сөйлә! Тагын ниләр ишеттең?

Халык сөйләргә кушты да шым булды, яналык көтә. Шул тиклем ялварулы күзләрен күргәч, каравылчының бигүк сөйләргә ярамаган серләре дә чишелде.

—Безнең Оныk Мөхәммәт ни... Ниткән... Кызыл диңгездә ялын тагын бер атнага озайткан ди...

Килердәйләр килеп беткәч шактый халык жыелган иде. Хәбәрне бик тиз эләктереп алып телдән-телгә күчерделәр.

«Кайчан?.. Кем сүзе?.. Хәбәр итмичә калмасларые!.. Әле кичә генә телевизордан күрсәттеләр, театр ложасында спектакль карап утырганын... Безнең балалар да интернеттан укыдык дигәннәр иде, ышанмадык кына, гайбәт оясы ла ул компьютер...»

—Дүшәмбе көн эшкә чыгарга тиеш булган, юк ди әле һаман...—Нәгыйм, тәмам рольгә кереп, матбугат үзәгенә әверелде.—Ялы ике атналык кына иде анын. Ә телевизордан иске язманы күрсәткәннәрдер, юри, халыкны тынычландырыр өчен. Интернет һәр гайбәт өчен жавап тота!

—Син, Нәгыйм, рациядән жыен юк-барны тыңлап ятканчы бакчаны әйбәтләп сакла. Фотограф Седойның өен талап чыктылармы? Чыктылар! Беркем бернәрсә күрми калган.

—Гафу, председатель. Бу хәл минем сменада түгел иде. Үзем өчен генә жавап бирә алам. Минем сменада гел тәртип булыр. За базар отвечаю!..

—Тәртип дисең, Судья урамындагы Солтан абыйны синең сменада урлап алып киткәннәрен онытма!

—Урламадылар аны. Дөрес, төн уртасында чия төсендәге «БМВ» килгән иде, капканы ачып үзем керттем. Тәрәзәләре чем кара. Кызлар төягәндер болар, кайсы өй кунаклары икән дип артларыннан бардым. Солтан абый министрлар янына чакырылгандай итеп киенгән, галстугын таккан. Өй түрендәге лампочкасы мин куйган заманнан бирле яна. Күрдем. Ул үз ирege белән чыгып утырды. Әле дә хужасыз өйгә күз-колак булып торам, түтәлләрендәге карачкылары шул килеш. Ну аның сәер кеше икәнен дә, кемгә охшаганлыгын да беләбез инде. Хатыны Солтан абыйның фотосын тотып милициядән эзләтмәк булган, гаризасын алмаганнар. Әле бүген иртән генә фотограф Седойның кунагы Солтан абыйның өй түрендә йөри иде. Махсус хәбәрче, ялгышмасам—Шәехнуров бугай. Сорауларына сезгә сөйләгәндәй жавап бирдем.

—Тагын, тагын нәрсәләр әйткән күрәзәче?

—Тагын егерме елдан Кытай президенты Ху-Цзинь-Сын булачак. Кореяныкы Кем-Чен-Сын, ә Мәскәүгә Ти-Мер-Сын куелачак ди.

—Тагын?

—Тиздән бик хәтәр йогышлы чир—акча вирусы таралачак ди. Күп итеп акча жыйган саран байлар котыру авыруыннан кырылып бетәчәк.

—Тагын, тагын?!—дип гайбәт газабына керде бакчачылар.—Әйтеп бетер! Бер башлагач инде...

—Федераллар сурәте белән почта маркалары чыгарыла ди. Хатлар

җибәргәндә артын ялап, йөзен сыйпап-сыйпап ябыштырырбыз...

—Нәгыйм!—Бу юлысы ширкәт председателенең тавышы җиңде.—Син боларны үз борчагыңнан шыттырасың бугай. Җәмәгать, җыелыш барып чыкмады инде бүген. Охранникның әкиятләрен тыңлап утырып помидорларга су сибәр вакыт җитте... Качып киткән идарә составына яңаларын уйлабрак килерсез. Бер атнадан нәкъ шушы урында җыйналырбыз.

Халык зарлана-зарлана таралышты да сыныкт түфли, ямаулы халат, балчыкка баткан эш бияләйләрен киеп тагын дүрт сутыйлы проблемаларына кереп батты... Күрәзәченең сәяси юрамышларына караганда түтәлдә пешкән каен җиләкләрен, ызанда эчкән суын, парникта үскән бәрәңгеләрен кадерлерәк лә!..

## Дияр сүрәсе

Көн үзе дә икейөзлеләнеп маташа.

Әле генә авылны болыт баскан иде. Әңгерлеккә ияләшүең була, һич уйламаган-көтмәгәндә кояш килә дә чыга. Менәтерәк, ныклап аязды бит тәки дигәндә күк йөзенең нуры сүнә дә куя. Эт кояшын сискәндереп яңгыр сибәләп ала, минуты белән туктый тагын үзе.

Җирдә генә түгел, инде Күктә дә җәй белән көз тартыша...

Нәсимәттәй өстәлдәге кояш нурына пыяла кәстрүл белән Болгар катыгы китереп куйды.

—Базданмы?—Дияр карт, агач кашыгын кулында калдырып, буш касәне Нәсимәттәйгә таба шудырды.

—Баздан булса пыяласы тирләп чыгарые. Күрмисеңмени—чоланнан алып кердем.

—Тагын карагат сыттыңмы? Күпме әйттем, саруны кайната дидем.

—Беләм. Шуңа күрә дә кызыл чөгендер удым.

—Барысын да беләсең тагы...

—Синең белән ике гомер яшәп инде.

—Хак әйтәсең. Үземнең гомерне әллә кайчан туздырып бетердем инде. Хәзер, әнә, башкалар гомере хисабына яши башладым бугай. Һаман-һаман пенсия алып ятарга оят, билләһи.

—Оят дип, төпчек улыбыз яшьләй шәһит китте. Аның калган гомерен Ходай сиңа бирсен...

—Юк! Тәүбә-тәүбә диген!—Дияр карт, йодрыкларын күз алдында йомарлап, утырган җиреннән капылт сикереп торды. Һич югы кырык яшькә генә яшьрәк чагы булса, өстәлгә сугасы, урталай сындырасы иде.—Тимичә тор әле син Шәехнурның өзелгән гомеренә, яме!

Нәсимәттәйнең дә куркак чакларында кия торган күлмәге тузган инде, Дияр картны җиненнән йолкып дигәндәй кире утыртты.

—Тәк томалдан көйсезләнеп, табыннан чүп эзләнеп ник бәргәләнгәнеңне беләм лә... Улыбызның җинаятьчеләре иректә йөргәнгә мин гаепләме? Гөнаһсызга рәнҗетергә әзерсен...

Болгар катыгын капкалый торгач, Дияр карт сабырлана төште.

—Борыңгылар чын ризык әзерли белгән. Шушы Болгар катыгын йогырт дип саталар бит хәзер, сироп болгаталар да...—Ул сөйләү тизлегенә чаклы киметте.—Син анда... чоланда чамалабрак йөре, үрдәкбикәм. Нух сандыгына абына күрмә.

—Тулмадымы әле ул?! Кайчаннан бирле казынасың, өйнең астын өскә китердең.

—Чүп-чар белән тутырасым килми.

—Киңәш йөзеннән генә соравым, әтисе, ниләр салдың соң?

—Сандык төбенә әвәл Сәләй әлифбасын яшердем, Рәмзия әлифбасы белән бергә. Карале, Нәсимә, ышанасыңмы, юкмы—Рәмзия дигәннән,

безнең тимерче Сәлимханның якташы икән бит ул, әй!

—Ышанмый ни, ярты халык Сәлимханга якташ ич бүген.

—Әлифба арасына хат кыстырдым.

—Хат?! Анысы кемгә атап тагын?

—Сәлимхан әйтмешли, бәй, кортка, кемгә дип, кыямәт көне узганнан соң минем сандыкны ачып караган беренче кешегә. Әлифба янына Коръән куйдым.

—Кайсысын, Дияркәчәем? Алар икәү бит хәзер.

—Икесен дә куйдым. Яңа халык таный алганын үзе сайлар. Берсен генә калдырыр идем дә... Кемнең дөреслеген кем белгән. Киләчәк буын алдында андый ук зур җаваплылыкны өстемә алыр хәлем юк.

—Үзең беләсеңдер инде...

—Иске җырлар язылган тәлинкәләрне күп итеп салдым, патефоны-ние белән. «Туган тел»не патефонда килеш калдырдым хәтта, сразы җырлатып карарлар. Катлаулылыгы юк. Яңа кешеләр Җирдә ялгалган маймыл хәлендә булсалар да, Игезәкләр йолдызлыгыннан кабат килгән гуманоидлар булса да бу нәмәрсәне җырлата алырлар. Ручкасын әйләндереп пружинасын борасы да, энәле радиосын тәлинкәгә бастырасы.

—Җыру дигәннән, карт, менә боларын да куш шунда, рәхәтләнеп тыңласыннар.—Нәсимәттәй Дияр агайның җавабын ишеткәнче бер кочак «сиди», «дивиди», «караокэ» ише дискларны алып килеп тә өлгерде.

—Син әллә анда, кыяматтән соң беренче көнне үк дискотека оештырырлар дип уйлыйсыңмы?! Күземә күрсәтмә шул шарманщикларыңны!—Ике намаз арасында Нәсимәттәйнең яратып тыңлый торган җырчылары барын исенә төшерепме, карт шундук юмагай телгә күчте.—Соң, үрдәккәем, магнит белән, ут белән генә язылган җырлар Туфан суында момент сүнеп бетәчәк бит. Бетмәсә дә гарасат яшеннәре моңын алачак аның. Ахыр чиктә инде, алар яңадан җыр уйнаткычлар уйлап тапканчы... Аннан, ни, ахырзаманның монысында японнар исән каламы, юкмы бит әле. Белеп тор шуны, Нәсимәттәй, мин ике генә җырчының тәлинкәләрен алдым: берсе Илһам энекәшнеке, икенчесе кем дисең?

—Салаватмы?!!

—Ашыкма! Салаватның хөкүмәттә үз кешесе бар. Ахырзаманда исән калачак ул. Динозаврлар арасында үзе җырлап йөрер.

—Алайса, кем соң икенчесе?

—Икенчесеме... Икенчесе—Фәридә сеңелкәш!

—Баядан бирле әйтә алмыйча торам, ник һәммәсен дә икешәрләп сайлыйсың соң аларның?..

—Нух пәйгамбәребез шулай кушкан. Табигатьтә җан ияләренең дә, җансыз җисемнәрнең дә, гүзәллек, батырлык, хәтта явызлыкның да капма-каршы ише булырга тиеш дигән.

Нәсимәттәйнең бәхәс куерта торган гадәте юк. Карты кушканча, кочагындагы җырларны янә комод тартмасына илтеп япты.

—Тагын нәрсәләр җибәрәсең теге дөньяга?

—Бәй, ник әле бусага аркылы атлап чыгарга иренеп торабыз? Әйдә чоланга, сандыкта ниләр барын үзең күр.

Сәлимхан ясап биргән кызыл сандык бикле булса да, ачкычы ишегендә калган иде. Карчыгы бервакытта да үз белдеге белән актарынып, Диярдән узынып тикшеренеп йөрмәде.

Сандыкны ачуга кулына беренче эләккән нәрсә гаилә альбомнары иде. Нәсимәттәйнең тагын кәефе кырылды.

—Әллә Ходаем, өйдәге фотоларның берсен бер калдырмыйча илтеп күмәсең инде?

—Ә нәрсәгә кирәк соң ул биш былтыр үлеп беткән әби-бабайлар, яшьлектә адашып калган сөйгән кызлар... Альбом актарган саен яшьлегеңне

сагынып елап, картлыгына көенеп йөрәк авырттырыргамы? Гомерне бик нык кыскарта торган зәхмәт ул фотолар... Альбом арасында ике түгәрәк көзгене күрәсеңме?

—Аларының нигә кирәге бар инде?

—Яңадан яралган кызлар альбомдагы рәсемнәрне изгеләр сурәте дип кабул итәр, үзләре белән чагыштырып карарлар.

—Бер көзге җитмәгәнме?

—Икәү кирәк. Көзгедәге чырайларын күргәч, беренче көзгене бәреп ватачак алар. Безнең кеби матур халык булыр өчен җирдә миллион ел яшәргә кирәк әле... Тәк, патефонны әйттем... Шәехнурның кыңгыраулы сәгатен салдым, батарые беткәнче йөрсен шунда.

—Истәлегенә тимәскә иде.

—Улыбыз югалганнан бирле бу сәгать вакытны дөрес санамый. Келт-келт итеп бәгырьне кисә... Ярар. Ә менә монысы...—Дияр карт сандыктан глобус чыгарды. Аны бәллүр шар тоткандай сакланып боргалады.—Менә монысы безнең Җир шары! Нинди күркәм, нинди сөйкемле! Саклыйсы да саклыйсы, яшисе дә яшисе шушы Җирдә!—Һәм Дияр карт глобусның Шәмдәл авылы тамгаланган төшен үбеп алды...—Галәм дигән чиксезлектә бу Җирнең икенчесе юк бүтән!!! Кыз чагындагы калфагың белән көмеш чулпыларың да китсен әле шунда. Сандыкны ачкач хәзинә таптык дип сөенерләр.

—Алтын балдагымны да салып биримме?—Нәсимәттәй, бәлкем, үртәргә теләп кенә әйткәндер дә, тик Дияр картның җавабы барыбер җитди иде.

—Яңа заман алтыннан азынмасын. Алтын әйләнешкә кергәч, илләр үзара сугыша башлаган. Без—көмешле халык!..

—Әгәр чишмәбез суын, каен җиләге вареньесын, юкә балы да салсак, ә, карт?

—Армиягә посылка җибәрәсең мәллә? Хәер, юкә балы бозылмаска мөмкин... Әйе, менә бу конвертта киләчәк заман кешесенә дип, бая әйткән хат.

—Яле, яле укып күрсәт. Теләсә нәрсә язып, анда адәм көлкесенә калмагаек.

—Бик теләсәң, үзең кычкырып укып кара.

Нәсимәттәй, күзлеген элеп, дога укыгандай көйле тавышка күчте.

*«Кыямәт мәхшәреннән соң яралган яңа кавемгә!*

*Сезнең кулга барып җитәсенә ихлас инанып язам.*

*Биниһая дәверләр буе Җир халкы белән идарә иткән, михнәт сөючән халык идек без. Бөтен дөнья безнең телдә сөйләшкән, дәүләтләребез утлы корал коймаган, иминлектә иген иккән, мал асраган, сәүдә иткән.*

*Бүген без—ике динле мәгыйшәт, ике кыйблалы сәясәт, икейөзле җитәкчелек, ике башлы бөркет корбаннары. Йөзәр мең данәле мәгърифәт басмаларыбыз бөлде, әбүнәчеләребез телсез калды, мәктүпләребез ябылды, яңа туган оныкларыбыз шайтан телендә сөйләшә башлады. Мәркәзебез дары заводы өстендә калды.*

*Белегез, ирегеи җуйган бөтен илләрне дә безнең язмыш көтә...*

*Хафизулла углы Дияр Шәехнуров.*

*Юлиан исәбе белән:*

*2 миллион 455 мең дә 502нче көн.»*

Нәсимәттәй, хатның азагын югалткандай, беравык исенә килә алмыйча торды.

—Халык акча колына әверелде, туган-тумачалык, әшнәлек дөньяны басты дип тә өстисең калган. Илләр-җирләр түрәләре белән сатылып бетте...

—Акча элек тә булган ул, мәгәр нәфесне тыя белгәннәр.

—Карале, карт, син бу хатны әлифбага түгел, Коръәннең соңгы битенә кыстырып куй. Дияр сүрәсе булып калсын...

—Шаярма, Нәсимә! Кулы кычыткан һәр шамакай Коръәнгә каләм тыга башласа изгелектән ни калыр?!.

## Шәех Нурның миллион елы

Өйләнәсе килә Шәех Нурның. Быел ук... Бүген... Хәзер үк!

Төн чыкканчы, әле туңып та өлгермәгән җир өстенә яңа аерткан куе каймак кебек җепшек кар катламы ягылган. Агач кашык белән каерып алып кабасы килә. Урамнан машиналар узмаган әле, кыл уртага тапталып кәкре-бөкре сукмак төшкән. Димәк, кар астындагы юлны эзләп, иң беренче булып Айнымас Ибрай үтеп киткән. Ул, пожаркада дежур торып, көн саен диярлек иртән авыш-түеш кайта. Ә халык, борылмалы-сырылмалы дими, гел бер эздән йөрергә ярата. Эри торган сукмак әле бу. Карның мулрагы, салкынрагы явар, яңа сукмак төшәр, туры эз салырдай дөрес кешесе дә табылыр.

Туган йорт эргәсенә жилкә терәп утыра Шәех Нур.

Өстендә мамык сүрүле куртка, башында йөнтәс кепка, аягында йон оек белән киелгән алты ярымлы ялтыравыклы галош.

Шундый кыен икән ул бер өйләнәсең килә башласа!

Жиләк-жимеш күп булган елны егетләрне интектерә торган витаминоз галәмәтедер инде. Үч иткәндәй, көзе дә ичмасам, Хислимә армиягә озаткан чактагыча алмалы килде. Чиләкләп тә, иләкләп тә саттылар, капчыклар да, әржәләр дә тулды, багалмасы бала-чага кулында, бәясе төшкәне мал-туар улагында.

Ибрай сукмагыннан тайпылмыйча, билләрен уйнаткалап кызлар үтә. Урамда бүген гел хатын-кыз гына, алмадан туенган күзләре мут. Дияр агайның төпчек малаена бүген нинди төшләр кергәнне беләбез диләр бугай. Әйе шул, Шәех Нур күргән төшләрне кешегә сөйләү түгел, искә төшерергә дә оят!

Шушындый минутларда Хислимә кайтып төшмәсә ярар иде. Гыйшык дәрте сынынны куырып алса ирләр күңеле йомшара бит ул. Әйдә, хатын, тагын кавышыйк, язылышыйк, туй ясыйк диярсең аннан соң! Алмалы ел килгән саен кабатланыр микән бу халәт?

Кесә телефоны мандолина кылы чиртелгән тавыш чыгарып алды.

Хажитарханнан MMS килгән—Нурияңең ике фотосы. Берсендә, жиңсез футболка белән балак очлары бәби итәкле шорт кигән килеш, баштанаяк төшкән. Икенчесендә студент чакта төзелеш отряды урнашкан лагерь аланы... «Сине сюрприз көтә» дигән язуы күп нокталы. Аларда әле һаман җәйге чиллә. Ләкин лагерь аланы буш инде, хужалык бинасы гына утырып калган. Кайчандыр палаткалар корылган урын да шәрә, шыксыз... Анда Франгизә дә юк, доцент Фәләх Сәмигуллин да, Хислимә дә юк... Ә Нурия бар!

Шәех Нурга кинәт яшәү дәрте, киләчәкне ашыктыру теләге өстәлгәндәй булды. Урамга малай-шалай чыкса ияреп уйнарга, Кар бабай ясарга, окоплар өяргә әзер иде ул хәзер. Ә малайлар юк, алар компьютер уйнап яңа яуган карны күрмичә калырлар.

Ә Шәех Нур урамда. Ул хәзер бер кадак май чаклы жылы карны йомарлап тәгәрәтер дә Кар бабай, юк ла инде, Кар кызы коеп куяр...

Өй түрендәге кар миниатюрный гына Кар кызы әвәләргә житте. Кесә телефоны белән рәсемгә төшереп, Шәех Нур аны шундук Нуриягә жибәрде. «Менә син!» дигән язу да өстәде. Үпкәләмәскә тиеш...

Капкадан чыгар-чыкмас кына Нәсимәттәй күренде, ул Шәех Нурны эзләп чыкканга охшый иде. Чәчәкле кызыл шәл яулык өстеннән Дияр агайның төлке бүреген кигән, плюш бишмәтенең төймәләрен каптырып өлгермәгән, өйдән үк эләктереп чыккан киез каталары белән капка төбендәге юеш карга басарга куркып тора.

—Улым, бездән качып кына кемнәрне уйлап елмаясың анда?

—Сезнең исәнлеккә сөенеп утырам әле.

—Тәмле телеңә рәхмәт, улым. Ата-анага миһербанлы баланың гомере озын, тормышы мул була... Мин ни дип чыкканыем, атаң мунчаны

булдырды. Газ мичен таннан торып кабызып куйганые. Бар, кереп чык, улым. Тарурманнан җыйган каен пиннеге дә, югары диләнкенен чыршы бәйләме дә пешерелгән. Суы шаулап тора, берүк сакланып кер, салкын су дигәне дә кайнарлангандыр инде...

Мунча ләүкәсенә менеп яткач, адәм баласы Җир белән Күк арасында эленеп кала... Кайда кыен—шунда рәхәт! Тәнен орынган урын өтеп-өтеп ала, чүл челләсеннән ун артык кызу һава сулышында иярә—үпкәнне пешекли, йөрәгенне каулый. Казандагы сунын шаулавы йокыны оета, буыннар майшыклана. Кулларынны баш астына куеп, күкрәгеннән вак-вак тир чишмәләре тибеп чыкканны күзәтеп ятасын, алар күбәеп бер-берсенә кушыла да гөрләвеккә әверелеп гаменне юа. Гәүдән җиңеләя, күк җисеменә әверелә. Сиңа сихәт иңә. Гомерең озынайганны тоеп ятасын... Яшәү сөенечкә әйләнә...

Әллә тән шулай нык кызган, әллә чыршы бәйләме артык пешкән—каен пиннеге белән алмаш-тилмәш чабына торгач, ылыс кадаганы да сизелмәде. Ләүкәдән төшкәч кенә аңлап алды Шәех Нур, җиз лаканга су таманлап куймаган лабаса. Казандагысы кайный, калай кисмәктәге салкынча дигәне кайнарланган. Ә коенырга кирәк...

Шәех Нурның озак уйлап торырлык хәле калмаган иде. Ул чыккан хутка трусигын киеп бәрәңге бакчасына ашыкты, ләкин ятып аунарлык урын таба алмады, җепшек кар көпшәк туфрак белән кушылып шулпаланган иде инде.

Ул атылып-бәрелеп капка төбенә йөгерде. Анда да җир ачылган, Кар кызы гына, ташкабактай кулы белән биленә таянып, кемнедер көтә.

Бу минутта Шәех Нурны күршедәге Бибиҗамал әбинен ян тәрәзәсе аша бөтен авыл халкы күзәтеп тора иде. Анысы иртәгә генә сүз булыр... Ә хәзер ул, Кар кызын күтәреп алып, мунча идәнендә кояштай балкып яткан җиз лаканга кертеп салды. Кар кызы кайнар суда эри барды—чүгә барды. Әллә лакандагы су инде суынган иде, аның эрүе әкренәя төште. Шәех Нур аптырап калмады, ике пиннек белән селтәнеп-селтәнеп чабындырырга тотынды. Кар кызы күзгә күренеп эреп бетте, лакандагы су идәнгә ташып чыкты, ул инде аякны чемердәтерлек салкын иде. Һәм Шәех Нур мөлдерәмә тулы карлы суны бүлеп-бүлеп башыннан койды, тагын чабынды, тагын коенды.

Мунча чарачасына чыгып сөртенгән арада Дияр агай килеп җиткән иде.

—Улым, син исәнме анда?—диде ул ишек аркылы гына эндәшеп.—Монда телефонынны тыяр хәл юк. Үзен белән алмагансын. Өзгәләнде берәү шалтыратып, экранында Хислимә сурәте иде. Мә, ишек өстеннән генә үрелеп ал.

Хәбәр бирүче кеше Хислимә түгел, Нурия иде. «Сине сюрприз көтә!»—дигәнен хәтерли әле Шәех Нур. Шуңа күрә тизрәк җавап бирергә ашыкты. Нурия үзләрендә әле һаман да почтада эшли. Күрәсең, ана эше буенча телефоннан бик күп сөйләшергә туры киләдер, тавышы нык, дикциясе чиста, сүзләре аермачык.

—Син миңа шалтыраткансын икән. Мунчада идем. Авылда.

—Әйе, әйе! Озак җавап бирмәгәч, әллә сөйләшергә теләми инде дип, котым очты. Озак юынма анда. Бүген кичкә сезнен Чулман пристанена килеп туктыйбыз. Абыем пароходствода эшли дип әйткәнем барые бит инде. Иранннан сезнен завод өчен җиһазлар кергән. Хаҗитархан таможнясында аларны абыем йөртә торган сухогрузга күчереп бушатканнар. Су юлы ябылганчы дип ашыктыралар ди. Чулманда өч көн булачакмын. Алло! Нәрсә булды анда, ник телсез калдын? Күрешәсен килмиме әллә?!

—Нурия, өч көнгә түгел, бөтенләйгә кил!

—Сине күреп кайтыр өчен ялынып-ялынып ял сорадым, ун көне юлда үтә.

—Анладым, Нурия! Каршы алырмын. Хәзер үк Чулманга китәм. Өлгерәм әле мин... Абыена сәлам әйтә тор!

Шәех Нурларның авылы Мәскәү белән Уфа арасындагы олы юлга урнашкан. Нәкъ шушы урында, ерак сәфәргә йөрүче фургоннар туктасын өчен, зур ашханә, заправка, ике катлы кунакханә, түләүле хаҗәтханәләргә тиклем салып куйдылар.

Алып-сатарларны ял иттерергә дип туктаган автобуска эләгер өчен шоферга ялынырга туры килде. Сәүдәгәрләр арасына очраклы пассажирлар алу бик нык тыелган нәрсә икән. Шәех Нур әле яңа гына алган журналист билетын күрсәтсә дә ык-мык иткәннәр иде, сөйгән кызымны каршы аласым бар, сонга калсам бөтенләйгә югалтам дигәч ризалаштылар тагы.

Автобустагылар юлда төн кичкәнгә охшаган, тукталыштан соң әлләни сөйләшеп-шаулашып, видеолар карап интектермәделәр, каңгыраеп йокы рәвешенә авыштылар. Шәех Нур, аларны уятып борчымас өчен, кесә телефонын сүндергәндә, «номер засекречен» дигән кешенең дүрт тапкыр җавапсыз калганын күреп алды. Нәфнәф эзли...

Юлда хәрәкәт шултиклем көчле, машиналар бер-берсенә тагылып йөргән кебек тезелгән, тизлекне арттырсаң, алдагысына тереләсен, киметсән—сиңа килеп төртеләләр, колонна үз җаена ияртеп алып бара. Юл җиле асфальт өстен корытып тора. Офыкларга тоташкан яшел көзлекләрдә ала-кола кар ятмалары күренгәли.

Йокысызлар тагын тәрәзәгә ябырылды. Бактың исә, бөтен кырларны үзенеке итеп, кызыл шар тәгәрәп йөри. Өреп кабарткач кына җебе өзелдеме икән, әллә махсус ирекккә җибәргәннәрме? Кызыл шардагы җылы сулыш бәйрәм истәлеге булып, гамьсезләргә сөенеч өләшеп йөри, хатирәләрне янарта, озын-озак балачакның берәр вакыйгасына килә дә керә... Октябрь бәйрәме житә ләбаса... Революцион бәйрәм мәктәпләргә көзге каникул алып килә иде. Чиреккнең соңгы дәресеннән «ура!» кычкырып кайтасың. Кулларда кызыл флагчыклар, кызларда кызыл шарлар... Мәктәп, клуб, кибет, сельсовет кыекларында кызыл лозунглар. Баганаларда кызыл фанерларга язылган өндәмәләр, телевизорда кызыл тамаша—аягында тора алган бөтен кеше демонстрациягә чыккан!.. Бәйрәмнәрнең дәрте сүнде хәзер, шатлыкларның кызыл төсе югалды...

***

Кайту белән ул туп-туры «Чулман утлары»на юнәлде. Караңгы төшкән иде инде. Эш көненең соңгы сәгате житкән. Хәер, иртәнге тугыздан кичке алтыга чаклы тоташтан иҗат эше белән шөгыльләнү мөмкин түгел, хатлар уку да ялыктыра, мәгълүмат алам дисән, сиңа кирәкле кешеләр йә объектларга тарала, йә юлда була. Журналист халкы да, күзне ял иттерәм, бераз һавада йөреп керәм, почтага сугыласым бар, реклама өчен заказлар эзлимише хәйләләр табып, берәр сәгать алдан кайту юлына юнәлә.

Редакциядә Франгизә генә калган: өстәл өстеннән кульязмаларны пөхтәләп жыеп алган, мониторы сүнгән. Шәех Нур кергәндә ул инде китап шүрлеге читендәге «А-3» форматлы кәгазь бите чаклы гына көзгегә тереләп, иннек белән ирен сурәтен төзәтеп маташа иде.

—Нихәл?.. Котлыйм, Иван Иванычтан ишеттем, унбергә ун белән жинденме? Иртәгә юарбыз! Иркенләп сөйләрсең. Мин бүген ашыгам... Махсус хәбәрче булып күчәсеңме соң?..

Ирен буяган арада бирелгән сорауларына җавапны бик кирәксенмәде Франгизә, ашыга иде ул. Аның ашыгуы әйбәт кенә, юкса Шәех Нурның җавап тотарлык чарасы юк. Франгизәнең Хислимә белән телефоннан сөйләшкәләп торганын белә ул. Шәех Нурның бүгенге вакыйгалары дус-

ишләргә, таныш-белешләргә, тегe-бу оешмаларга житкерер өчен түгел...

—Кол Харис бар идеме бүген?

—Иртәрәк китте. Кием алыштырып килә. Бүген әни өйгә чакырды. Ни өчен икәнен әйтмим... Эштәгеләр сизмәсен берүк.

—Юк инде. Син мине кем дип белден?! Үземнеке үземә житкән.

—Ярый. До завтра! Утны сүндерергә онытма...

Франгизә чыгып китүгә, Шәех Нур курткасын урындык аркасына элеп өстәл артына утырды. Берничә бит «снегурочка» кәгазе алды... Каләм—авторныкы, кәгазь—укучыныкы... Ап-ак билгесезлек синең фикереңне көтә. Бүген ул кәгазь синеке әле—ни теләсәң шуны яза аласың, ошамаса, ертып ташла. Ә иртәгә, синнән киткәч ул инде тарихи сәхифәгә әйләнә...

*«Кол Харис!*

*Мин югалып торам... Миллион елдан соң әйләнеп кайтырмын.*

*Әгәр редактор тавыш чыгара калса, син аңа минем эштән китүем турындагы гаризамны бир. Числосын үзең куй.*

*Шәех Нур.»*

Инде Нурия белән элемтәгә керергә кирәк иде. Шәех Нур мобильнигын уч төбендә уйнаткалап торды, өстәлдәге редакция телефонына үрелде, ләкин шылтыратырга кыймады—Нәфнәфнең ике алтын тешле елмаюы күз алдында эзәрлекләп тора. Тыңлый, ишетә, күзәтәдер ул кеше. Ул «Муса»ларның ярдәменә мохтаж... Причалда, артыннан ияреп йөрер дә, зарыгып көткән Нуриян басмадан төшеп кочагына авам дигәндә генә ике арага килеп керер... Тагын нинди сораулар әзерләп куйды икән? «Муса»лардан сорау алыр өчен генә яралган оешманы тагынниләр борчый икән? Шәех Нур эзәрлекләүдән котыла алмый, әйтерсең лә колак кикригенә ниндидер микрочип кереп оялаган да Нәфнәф тавышы белән гел пышылдап тора... «Син» житәкчеләргә карата чамасыз дустанә кыланасың... Кияү Тархан хакында да артык күп беләсең. Син бу уенның кагыйдәсен үзең кордың... Ике ут белән шаярасың. Журналист тикшеренүе үткәрергә хакың юк. Тыкшынма. Син бик хәтәр шаhит!»

Урамдагы таксофоннан сөйләшергә кирәк иде, ләкин аның өчен элемтә бүлегенәме, гипермаркет салонына керепме талон аласы була. Кеше күп йөри торган жирләрдә балкысаң, йә көрешергә ярамаган кешеләр очрар, кәефе кырылыр, бәйрәмеңнең көе китәр. Бөтенләй чит кешене туктатып ярдәм сораргадыр.

Көзге төн жәй жылысын жуйган hәдhәдләрне өйләренә куып керткән. Ара-тирә тәтәй кызларның чыркылдашуын, сирәк-мирәк машиналарның колак тондыргыч жырлар акыртып узуын hәм ресторан-кафелар тирәсендәге салютлар күкрәвен исәпләмәгәндә шәhәр эчен тын дияргә ярыйдыр.

Автобус тукталышына жайлашкан «24 сәгать»лек бутиктан бер шешә йөзем шәрабы белән яшь шагыйрьнең беренче китабы чаклы гына шоколад катыргысы алгач, ул баганадагы ут яктысына килде. Күн дипломатта урын житәрлек, теләсәң азык-төлек тутырырга була. Кул уңае гына, эчке бүлемәнә тыгылып, «Гознак»та басылган килеш, әле уртага да бөкләнмәгән яңа билетын тикшерде—урынында! Нуриягә күрсәтәсе бар аны...

Ул арада тукталышта өч егет пәйда булды, «24 сәгать» ягына каранып акча саныйлар. Кесәдән кесәгә кул тыгып саный торгач, кәгазь акчалары бетте, вак акчага күчтеләр, алай да житми иде, ахрысы, багана төбендә берьялгызы басып торган егетне күреп сөенделәр. Шәех Нур озак уйлап маташмады, егетләрнең соранып бәйләнгәнен көтмичә, кыюланып үзе килде.

—Егетләр, бер генә звонок ясыйсым бар, телефон биреп торыгыз әле. Минекенең аккумуляторы утырган.

—Ә күпме бирәсен?

—Илле сум... Ниме, син минем брат түгелме—мыегың, борының, буй сының, иягенә чаклы миңа охшаган?!—Шушы юк кына охшашлык белән



2.*

ике арадагы киеренкелекне йомшартырга иде Шәех Нурның исәбе.

—Илле?!. Ты чё, бәлки, син роуминг белән чыгарсың. Безгә откат калмый. Алай, братлар да булгач, күпсенеп торма.

—Ну... йөз сум алайса!

—Илле сум—сөйләшкән өчен, йөз илле сумың бонус, родной брат итеп.

Шунысы сәер, егетләрнең икесе телсез кебек ләм-мим басып тордылар. Ике йөз сумлык контрактны көзге пәлтәсенә якасыннан чумган, яланбашлы блондин килеште. Яланбаш егет, әйтер сүзен бүлеп, ирен чите белән генә салкын һава йотып ала, теше сызлый иде, ахрысы. Телефонын да ул бирде.

«Нурия! Кайчан килеп житәсең?!»

«Кая югалдың, Шәех Нур? Мин сине ярты көн буе эзлим бит инде! Номерың да үзгәргән...»

«Чит кеше телефоныннан сөйләшәм. Үземнекен сүндердем... ни... зарядкасы беткән иде. Чулманградка житәсезме әле?»

«Пассажир судносы булмагач, пристаньнарга кереп торасы юк икән. Графикны узып өч сәгатькә алдан килеп життек. Причал бушаганчы бер култыкта көтәбез. Әгәр син каршы алсаң, мине көймә белән чыгарып куялар.»

«Нурия! Көтәм! Жиргә төш тизрәк!..»

Алар өч минут сөйләште. Минутлары язмышка бәрабәр сөенеч! Тавышларның күрешүеннән канатланып, ул көндәлек вак-төякләрдән өч минутка арынып алды. Әйләнеп кайтса, яланбаш егет телефонын көтеп тора, ә ике сәрхүш белән бергә Шәех Нурның дипломаты юкка чыккан.

—Дусларың кая?! Дипломат кая?!

—Белмим мин аларны. Кибет төбендә күрештек тә... өч борынга керештек... Акчаны алдылар да кинули мине. Исемнәрен дә сорамадым,—дигән булды яланбашлы егет һәм китәргә ашыкты.

—Карале, агайне, болай ярамый ич инде. Минем анда өр-яңа билетым. Тукта, менә адресны язып калдырам, тегеләрне күрсәң әйт, китерсеннәр өйгә, түләрмен.—Шәехнур кесәсеннән беренче ияреп чыккан акчага үзенең адресын язды, биш йөз сумлык дип тормады, ялан башлыга сузды.—Вакытым юк, кирәксә тотам инде мин аларны, ну, бик ашыгам. Китерсеннәр, яме!

—Ярар, әйтермен!—дип ышандырды ул. Ә соныннан ыкы-мыкы килеп кенә өстәп куясы итте.—Күрсәм әйтермен...

Күрми ни, бутиктан ерак түгел йөз урынлы автостоянка бар. Тәүлек буе кизү торучы егетләргә янгыр-салкыннан ышыкланыр өчен калай вагон куелган. Әлеге яланбашлы егет ярты ел чамасы шул капкада шлагбаум күтәреп-төшереп торган. Аны таныйлар, шешә бушатырга дип иптәшләре белән килгәндә куып чыгармыйлар.

Теге ике сәрхүш вагон төбендә көтеп тора иде инде. Дипломатны әллә кайчан ачып караганнар, эчендәгесен жиргә селкегәннәр: шәрабы—баллы су, шоколады—конфет, журналист катыргысының кондукторга күрсәтерлек тә көче юк, алюминий билдәмәле каеш дипломаты модадан чыккан—сукыр бер тиенгә алмаячаклар... Эчендә акчасы да юк, ичмасам...

Икәүнең кәефе бик нык кырылган иде, яланбашлы дус кәләргә мәжбүр итте үзләрен. Өр-яңа катыргыны урталай бөкләп күкрәк кесәсенә салды да эшем кешеседәй китәргә әзерләнде:

—Билетны хужасына илтеп сатам.

—Ә каян табасың син аны?—диделәр тегеләр, көлүдән туктап.

—Ул минем телефоннан кемгәдер шалтыратты. Белешәбез хәзер.—Яланбашлы егет адрес язылган биш йөзлекне иптәшләренә күрсәтергә теләмәде, телефонын чыгарды.—Алё! Журналист?—Хатын-кыз тавышы жавап биргәч тә каушамады.—Барышня, әле яңа гына сезнең белән сөйләшкән

егетнең номеры кирәк иде... Мин аның билетын таптым, Тәк... Әкертен әйт, хәтеренә язып куям... Тәк, МТС икән... Соңгысы... 43-10-50... Синең.., Ну, сезнең янга ашыкты булса кирәк. Вәт-вәт... Күрешкәч, исенә төшерерсең...

Бөтенләйгә сүндерелгән телефоны өчен Нурия алдында ничек акланганддыр Шәех Нур, яланбашлы белән ул янадан элемтәгә кермәде.

Өч минутлык сөенеч белән башланган күрешү өч көнгә сузылды. Сухогруз дип бик коры гына аталса да, нәкъ өйдәгечә яшәп була икән үзендә. Юыну-йокы бүлемнәре дә житәрлек, каютькомпаниядә гел кайнар аш, төнге һавага чыгып урам әйләнеп керик дисәң—палубасы иркен. Капитанның алты кешелек командасы яшьләрне күрмәмешкә сабышты, бу өч көнлек бәйрәм әйтерсең лә Нурия язган сценарий буенча бара иде. Алар хәтта заводка китерелгән җиһазларның бушатылуын да, Хажитарханга алып кайтыр өчен төзелеш агачы төягәнне дә күреп өлгермәделәр... Сөендылар... Сөелделәр... Сөйләштеләр... Почта бүлегендә беренче күрешкәннән башлап, чыбылдык белән ерганаклардан балык тоту, сәяхәткә чыгып Хәзәр диңгезе утравыннан лотос чәчәкләре яшереп алып кайту дисеңме, лагерь белән саубуллашкан төндә атка атланган дала малайларының һөҗүм итүеме, хатлардан истә калган өзекләрне кабатлаумы, җыйнап кына әйткәндә, хәтердә ни барын—бөтенесен дә сөйләп, яңадан кичереп чыктылар. Өч көн бергә кушылды. Алар өчен гүя иртә юк, кич юк; көз юк, җәй юк, өйлә вакыты вә төн уртасы юк... Йокы бик-бик изрәткән мәлләрдә аерым каюталарга бикләнеп черем итеп алалар да, уянгач күрешеп тагын сөйләшәләр...

Шундый озак һәм бик тиз үтте ул өч көн!

Истәлек-хатирәләр кинәт бетте. Соңгы сүзне кемдер әйтергә тиеш иде. Дүртенче... кырыс көн башланды. Команда сухогрузны причалга богаулап куйган чылбырларны ычкындырырга әзер.

—Мин бит әле эштәге кеше. Редакциядә ни хәлләр бар икән? Беләсе иде.

Нурия дәшмәде. Җавап итеп Шәех Нурга телефонын сузды. Егет «Чулман утлары»ның хатлар бүлеген җыйгач, телефонны кире бирде.

—Син сөйләш, Нурия. Мөгаен, Франгизә алыр, Кол Харисны чакырт, ул гына аңлар мине. Тавышын катырак итеп куй. Штаттан тыш хәбәрче булып кылан.

—Исәнмесез, миңа Кол Харис кирәк иде,—дигәч, Франгизә берازга тынып калды.—Ә кем сорый соң аны?

—Апа, мин аңа фельетон җибәргән идем, алды микән?

—Сеңлем, соңрак, берәр атнадан, ямe. Юк әле ул монда.

—Ә кайчан була?

—Сеңлем, редакциябездә зур кайгы. Сотрудникгыбызны үтерделәр, Кол Харис прокуратурада йөри.

—Кемне үтерделәр?

—Шәех Нурны...

—Ничек инде?!!

—Подъезд ишеге төбендә көтеп торып ерткычларча кыйнаганнар. Исерек аунап ята дип милиция айныткычка алып киткән. Кесәсеннән журналист билеты чыккач кына кем икәнен белгәннәр. Больницага илткәндә инде соң булган. Өч көн узды инде, әле моргтан ала алмыйбыз.

—Апа, гафу итегез берүк...

Франгизәнең һич белмәгән-күрмәгән кеше белән шулай ачыктан-ачык сөйләшүе бик үк аңлашылып бетми. Шәех Нурның үлемендә редакциянең гаебе юк, эчүе башына житте дип әйтергә телиме ул. Әллә журналистларга кул күтәргән вәхшиләрне тизрәк тотсыннар, бу турыда күбрәк кеше белсен дип тырышамы?

Үзенең исән калуы өчен сөенсә дә, аның аркасында, һич гаепсезгә, ниндидер шук егетнең шәһит китүе газаплады аны. Димәк, яланбашлы егет

эзләп килгән. Шәех Нурны подъезд төбендә сагалап торганнар. Акылга утыртырга теләгәннәр. Артыгын мавыкканнар... Провинциянең тәрбия кануннары кырыс... Кесәсендә журналист билеты, Шәех Нурга охшашлыгы, фатир ишеге төбендә... Буташтырыр өчен бөтен шарты килгән. Моргка чакыртылган Кол Харис имгәтелгән чыраена күз сирпеп кенә аермалыкны җентекләп күреп өлгергәндер дисеңме? «Опознание»нең нәтиҗәсе сорауга җавап кына: «Шулмы? Шул. Таныдыңмы? Таныдым... Охшаган...»

Охшамый ни, кызгану, чиркану һәм курку кеше күңелен тиз инандыра. Бик теләсәң җиде диңгез аръягында үсә торган ананас та бездәге нарат әкәлиенә охшаган...

—Шәех Нур, син юк. Үлгән бит син!..—Нуриянең тавышында шаяртуның әсәре дә сизелми, киресенчә, куркынып калды хәтта.

—Мин юк икән—димәк, син дә юк.

—Бәлки, без төш күрәбездер?

—Алайса, уянмаска тырышыйк. Өндәге тормыш гел сагынудан тора иде.

—Йоклар алдыннан паспортыңны кесәңә салдыңмы соң, Шәех Нур?!

—Әйе. Военный билет белән бергә. Һөнәрем шулай куша.

—Киттекме Хаҗитарханга?! Икенче тормышка. Сиңа беразга булса да югалып торырга кирәк бит. Хәзәрстанның диңгезе киң, далалары очсызкырыйсыз. Бездә җәйләр бик кырыс, көздән килеп ияләшергә кирәк.

—Сайланырлык шарты булып, җиде-сигез тарафта ялварып чакырып торсалар да мин бүген барыбер сиңа иярер идем.

Чуен бүкәннән сүтелгән чылбыр богау палубага барып төште, аның һәр буыны чыгарылыш кичәсенә дәшкән җиз кыңгырауны хәтерләтеп чыңлап алды бугай. Кайтыр якка төбәлеп калган язмыш быргысы көчәнеп-көчәнеп ике кабат аваз салды. Чулманлы причал тыныч кына буйсынып, үзе китеп барды кебек. Мондый да йомшак итеп пароходлар гына кузгала белә. Ниһаять, сухогруз, кагыйдәсенә буйсынып, зур борылыш ясады да су юлына чыкты. Һәм җилкәнсез ак караб, агым уңаена ятып, Хәзәр диңгезенә таба ашыкты. Хәер, бигүк ак түгел иде ул караб... Тәбәнәк палубага төялгән яңа такта, борыс, сүтелгән бура өемнәре көзге кояшның мәрхәмәтле нурында алтынга манылгандай балкып бара иде...

Сау бул, тешсез җөмһүрият!

Бәхил бул, телсез халкым...

## Кышкы әкият

*Җимерәбез дә корабыз...*

*Корабыз да тагын җимерәбез...*

*Ком-ташлардан мегаполислар өябез...*

Урамнар иркенәйсен өчен озын-озын баракларны аягүрә бастырдык—коридорында лифт дигән калай читлекләр йөри. Нык булсынга корыч кабыргаларын бетон белән койдык, тышкы кыяфәтен кирпечкә төрдек. Чит илләргә күренсен дип түбәләрен җиде төскә буядык. Кояшы да, ае да шунда булыр дип кеше саен берәр тәрәзә уйдык.

Мегаполислар гигант магнит кебек кешеләрне үзенә тартып китерә. Зур шәһәрдә өметләр, хыяллар, мөмкинлекләр һәм ялгышлар да зуррак.

Франгизә белән Кол Харисның Азанга күчеп килеше...

Җаваплы секретарьның әнисе Малайзиядә ял иткән арада, Кол Харис, көннәрдән бер көнне төшке аш вакытына туры китереп, ярты гына сәгатькә дип аулак өйгә ияреп кайткан иде.

Өй эчендә Бразилия сериалларындагыча ак алъяпкыч япкан хезмәтче апа каршы алды. «Бигүк аулак өй түгел икән...»—дип уйлап өлгерде бугай Кол Харис. Франгизә аның бу уен шундук сизеп алды:

—Нәфига апа, син инде кайтып китсәң дә була. Кунакны үзем сыйлармын,—дип, олы яшьтәге ханымны тизрәк озату хәстәрен күрде.

Икәүдән-икәү калгач та Франгизә беркадәр генә ашыгуын яшерә алмады. Түгәрәк өстәл артындагы дүрт урындыкның икесен отыры читкә күчереп куйды. Шүрлегеннән салкын коньяк чыгаргач әллә суыткычның ишеген дә ябып бетермәде шунда... Стенадагы агач йөзле түгәрәк сәгатькә күз сирпеп алды... Кол Харис үзенә тәкъдим ителгән озын торыклы бәллүр бокалны кулына алып өлгердеме, юкмы, ул арада өй хуҗасы инде чигүле кулъяулыкларга охшаган кәгазь салфеткалар куеп маташа иде...

Франгизәнең тыелгысыз ашыгуы эшкә сонга калудан куркып түгел, һич юк. Төшке ялның кыскалыгындамы хикмәт?!. Аны—уку һәм урнашу мәшәкатьләре белән инде чирек гасыр гомер кичеп өлгергән кыз баланы гыйшык уты өтә, табигать ашыктыра иде.

Әкияттәге сихри ашъяулык булдымы—өстәл өстенә капланган эре шакмаклы эскәтерне ачып җибәрүгә Кол Харис үзен туй мәҗлесе түрендә утырган кияү хәлендә тойды. Кол Харисның бу табынга сокланганын сизде, сизде генә түгел, күрде хәтта, тик Франгизә инде үзен бик тыныч тотарга тырышты, әйтерсең лә төшке аш саен шушылай кәеф сафа корып алу аның өчен гадәти бер күренеш, яшәү рәвешенә әверелгән гамәл иде. Ләкин сыйлану артык күпкә китсә, салым инспекциясендә эшләүче инспекторларны да ялыктыра торгандыр... Франгизә Кол Харисны чәйгә алып кайтасын хезмәтче Нәфига апага һичшиксез алдан ук әйтеп куйган, ныклап әзерләнергә кушкан иде.

Йоткалап түгел, чәй кашыгы белән капкалап утырсаң да ике сәгать эчендә бер шешә коньяк бетә икән.

Хатын-кызның авызына чүт кенә хәмер тисә, аны тыеп, саклап тота торган пружиналары йомшара, күбрәк китсә ул ихтыярсыз өмет өеме булып синең хәлиткеч гамәленне көтә...

Ә нормальный ир кешенең, илле грамм җибәргәч, дус-ишләренә шылтыратып, никтер ул «мескеннәр»нең хәлен беләсе килә башлый. Йөз грамм җибәргәч, шылтыратасы кызлары исенә төшә... Йөз илле граммнан соң ул кызлар исемлеге зурая... Ә инде кырлы стакан тулырдайны сеңдерсә... аңа хәзер кемгә шылтыратса да барыбер: «Кил, әйдә!» дип чакыручы гына булсын... Абау, исеректән оят чыгып кача икән...

—Франгизә, минем сиңа шылтыратасым килә.

—Ярый искә төшердең әле, эштәгеләр югалтмасын, хәбәр итеп куясы бар.

—Кирәкмәс иде...—Кол Харисның сагаюын ишетеп өлгермәде Франгизә.

—Алё, Иван Иваныч, бәгърем, без... чәй эчеп утырабыз әле, Кол Харис белән... Кайда дип, өйдә!.. Тавышым үзгәргән? Минемме? Бер җирем дә үзгәрмәгән. Кичкә таба эшкә килеп китәбез әле... Нинди бәйрәм дип... Беребез өйләнмәгән егет... Икенчебез кияүгә чыгардай кыз... Шутки, Иван Иваныч, озакламабыз. Җуймагыз безне, яме!..

«Чулман утлары» бәләкәй генә авыл кебегрәк нәрсә инде ул. Редакция хезмәткәрләренә кагылган шәхси яңалыкларны сер итеп саклармар димә. Хәтта сер саклардай кешең баш редактор булса да. Хәтта Франгизә белән Кол Харис икесе генә белергә тиешле минутлар булса да—сизделәр... Ялдан кайткач Франгизәнең әнисе дә белде.

Тагын Кол Харисны чәйгә дәштеләр.

Бу юлысы хезмәтче апаны иртүк кайтарып җибәргәннәр иде. Франгизә кухняда савыт-саба юган арада әнисе тәрбия дәресе үткәреп алды.

«...Кызымның йокы булмәсен карагансың. Нишләп мендәрең икәү, дигәнсең... Редакциягә чаклы урам буйлап култыклашып баргансыз. Чулман

каласы үтә күренмәле шәһәр. Безнең һәр кылган гамәлебезне күреп-җыеп торалар... Менә шуннан ике мендәр булып куя инде ул... Язылышсагыз гайбәт үзеннән-үзе бетә. Өйләнергә ашыкмыйм әле дисәң, Чулманнан китәргә туры килер... Икегезгә дә... Бергә... Кулга-кул тотынышып...

Һәм Кол Харис белән Франгизәнең Азан каласына күчеп килеше...

Бер уйласан, шәһәрләр дә кешесыман икән: зурлары бар, кечкенәләре; яшь калалар була, була чал калалар; байлары, хәерчеләре; пайтәхетле мәркәзләре һәм шул мәркәзгә буйсына торганнары...

Кышның гыйнварлы-февральле мәле. Көннәр озынайган саен бураннар көчәя, бураннар тукталган арада салкыннар рәхимсезләнә.

Буйсынулы шәһәрләр баш иеп керсен өчен генә салынган ике чатлы «М» капканы бәс сарган. Юл буе йокымсырап килгән пассажирлар җанлана төште. Транзит автобуслар хәзер кунакларны багана төбе саен туктап чәчеп йөрми, аның бердәнбер һәм соңгы тукталышы автовокзал... Шуңадырмы һичкем кабаланмый, мәрттән кайткан Фәтхулла хәзрәт кеби әле бер якка бармак төртеп канатлана, әле икенче як тәрәзәгә сокланып бага.

—Безне өйдә көтәләр!—дигән булды Кол Харис, перронның таш идәненә сикереп төшкәч. Этеш-төртешкә бирешмәде, Франгизәне күтәреп диярлек алырга да онытмады ул.

Троллейбус тукталышына җитәрәк кыз алга чыкты, егетне әйдәкләп, көтеп-көтеп алды. Провинциаль шәһәрдән мегаполиска күчеп килгәч, үзен шушында туып-үскән һәм беркая да китмичә гел монда гына яшәгән күптәнге кеше итеп күрсәтергә теләде. Читтән килеп биш ел укыган һәр студент өчен таныш халәт бу.

Киң урамнарга сыймастай гөрелте ташкынында түбәсеннән кары көрәлмәгән машиналар күренеп китә. Тротуардагы кар күптән инде ләйсәнлеген югалтып асфальт төсенә кергән. Һәр кибет тирәсендә базар ыгы-зыгысы, көпчәк эзе төшкән түгәрәк түтәлләрдә шәмәхә тәпиләренә кар кундырмый гына күгәрченнәр мәрхәмәт эзләп йөри. Безне кисеп автостоянка ясарлар инде дигәндәй, «Никах паркы»ның исән калган чыршылары дерелдәп тора...

Кол Харис Франгизәгә ияреп кайтып бара—8нче март урамына. Кызның әнисе, кирәге чыга калса дип, ике бүлмәле аерым фатир сатып алган анда...

Туп-туры троллейбус тукталышына килеп бастылар, кереп тә утырдылар.

—Абыйларым тукталышында төшеп калырмын инде.—Зур калага килеп кергәч, ялгыш бәйләнгән дуслыктан бәйсезлек яулыйсы килә иде Кол Харисның.

—Әйе, жингән бик сөенер! Бөтенләйгә үк безгә күчеп кайттың мәллә, кайнигәчкәем? Бәлешебез суынгандыр инде, өч бүлмәле «хрущевка»да алты җан иясе син кайтканны гына көтеп утыра идек, дияр.

—Каян беләсең, Франгизә?

—Жинги дигән туганнарны белмәскә...

—Шәех Нурның әти-әнисен күреп кайтсам да әйбәт булыр иде. Берәр көн куныпи, картларны юатып, эчемне бушатып дигәндәй.

—Икәү бергә кайтып килербез.

—Икәүләшеп үк кайтып йөрергә...—«Иртәрәк әле безгә», дип өстәмәкче иде дә Кол Харис, тыелып калды. Дөресрәге, алга таба сүз көрәштерергә иренде ул. Шәһәрнең тыгыз атмосферасында йокы даруы бар иде—шул изә.

Ерак юлда автобустан җыелган җылы әкренләп сүрелде. Җитмәсә, тукталыш саен ишекләр ачылып, урам исемнәрен вата-җимерә игълан иткән арада троллейбус эче урамдагы һава белән тигезләнә, урыннан кузгалганда хәтта йөртүче кабинасы ягыннан тәмәкеле җил дә искән кебек.

Шулчак бер нәрсәгә игътибар итте Кол Харис, салондагы һәр кешенең сулышы күренеп тора. Алар үзара сөйләшкәндә сулышлары күз алларында болыттай кабара да ул болытлар төрле-төрле җанварлар, җансыз җисемнәр, әкияти сурәтләргә керә икән. Әлеге җанлы болытларга карап кемнең ни турында сөйләшеп барганын чамалап буладыр, шәт...

Шунысы рәхәт, хуҗасы бармы-юкмы, өйдәме-түгелме, шәһәр фатирлары гел ягылган, кайчан килеп керсәң җылы, сулары да әзер. Франгизә бу бүлмәләрне бик үк ятим итми, ахрысы: телевизор өстендә вакчыл кайнана бәйләнерлек тә тузан юк, чыбыклы телефоны уттан өзелмәгән. Эчендәге хәзинәләре белән мактанырга җаен көтеп ике камералы суыткыч эшләп тора. Ике мендәрле агач караватның урын-җире бүген иртән генә, дөресрәге, әле яна гына җыелган кебек, куен җылысы бөркелеп тора. Җәймә итеп капланган яшькелт-зәңгәр япманың парча дулкыннары үзенә ымсындыра: «Чум! Чум диңгезгә!»

Кол Харис колачын җәеп капланды. Диңгезнең тыгыз дулкыннары аны күтәреп алды, тибрәндерде, изрәтте...

Күнелендә һичбер шик калмаслык итеп, өйнең бөтенләй аулак икәненә инаныр өчен Кол Харис сорап куясы итте.

«Кемдер яши бугай монда?»

«Минем күләгәмдер инде. Җае килгәндә кергәлим.»

«Әйтәм аны, редакциядә югалып-югалып ала идең.»

«Хәбәрче кеше командировкага йөрмәсә ачтан үлә.»

«Район газетасыннан башкалага... командировка? Һе...»

«Алайга калса, башкаладан безгә еш килә ич—радиосы, телевидениесе, пресс-группалары. Үзеңне бел... кайтып кергәнең юк.»

«Ну, мин фотохәбәрче... Ә син җаваплы секретарь гына, утырып эшләргә тиешле кеше. Мин матурлык эзлим.»

«Кемгә?»

«Үземә.»

«Эзләмисең, җыясың! Туйгач туктарсың, бәлки.»

«Туктарга ни... Һәр җисемнең, һәр җан иясенең, һәр кешенең матурдан-матуры, аеруча матурлары бар, иренмичә эзлисе дә эзлисе.»

«Ничә ел буе бер түбә астында эшләдек. Ә синең әле мине фотога төшергәнең дә юк. Шулай ук ямьсезме мин?»

Каушады Кол Харис, һай коелып төште! Җылыга кергәч эленке-салынкы гына башланган сөйләшү бер борылышта менә шушылай мендәр өеменә килеп төртелер дип кем уйлаган?! Хәзер исә, Франгизәнең кичекмәстән җавап көтеп текәлгән күз карашыннан котыла алмыйча, тынлыкны сузарга азапланды Кол Харис, зур калага кайткач бөтенләй үзгәрде, тискәре ягы белән әйләнде бугай ул...

«Онытып торам икән, сумкадан фотоаппаратны алып, корырак җирдә җылытасы бар. Суыктан кергән килеш парланып тормасын.—Һәм ул кызның күз карашы әсирлегеннән котылганына сөенеп, кием шкафы янында калган сумкадан әйберләрне бушата башлады.—Мин бүген сине шундый матур итеп фотога төшерәм—сәхнә йолдызлары көнләшер.»

«Техниканны могҗизалары белән мактанма... Син минем рәсемемне телдән сөйләп кара.»

Тагын сүз өзеге килеп чыкты. Тик бу юлысы Франгизә җавап көтеп оеп тормады, күрше бүлмәгә кереп тиз арада кием алыштырып өлгерде. Әллә алдан ук уйланган ният белән, әллә егетне сынар өчен—путасын бәйләп өлгергәнче каршыга чыгып та басты. Каршыга дип әйтү бик ерагайту булыр, Кол Харисны аягүрә караватка кысрыклап йөзгә-йөз килеп басты. Көмеш туйлары җиткәнче парлашып яшәгән ир белән хатын да бер-берсенә ул чаклы якынаймый инде хәзер. Бик үк көтелмәгән яңалыктан Кол Харисның гәүдәсе чигенде, тераллде һәм караватка килеп ауды. Ләкин

ул әлеге тамашаны күрүдән мәхрүм калмас өчен ике терсәгенә таянып өлгерде, башын күтәрә төшеп һаман нидер көтте.

«Йә, ике объективлы фотоаппаратым? Рәсемемне укып бир.»

«Сары атлас халатыңа өч кенә чәчәк сыйган, аның да берсен пута белән уртага бүлгәнсең. Итәк өстендәге соңгы төймәсен юри каптырмагансың, мине алгысытыр өчен, ачылып-ачылып китә. Әгәр син «Чулман утлары»на шушы халатыңны киеп килсән, ирләребез газета чыгара алмыйча интегерләр иде.»

«Кол Харис, халат ул кибет әйберсе, салдым-аттым. Үземнең рәсемем ничегрәк?»

«Баштан-аякмы? Әллә паспорт фотосы хәтлесе дә җитәрме?»

«Җитмәсә, әйтермен.»

«Минем күзем каты түгел, буй-сыныңа карап өстенә әйтәм. Хәер, синең күз тиярлек жирең юк та... Аягыңдагы чүәгең акча янчыгы кебек... Путаң астында чат сөяген тырпаеп тора... Өстәрәк... халат астында ике сөт пакеты күпереп тора... Элеккеге заманнарда кибеттәге сөт савытлары пирамида кебек очлы түбәле иде, хәзергеләре полиэтилен капчык шул...»

Көтелмәгән тасвирлаудан Франгизәнең коты очты, күзләре күзлек пыяласы чаклы булды, ирен арасында тәмәке сыярлык ярык ачылды, үзе сулыш алудан туктады... Ә Кол Харис дәвам итте...

Агач муенын—яшь каен кәүсәсе кебек, сызык-сызык сипкелле. Интерчыраең—грузин борын, кытай бәбәк, япон күз. Шуңа күрә сине кияүгә алмаганнар... Минем ише берәр бозауны көтеп яткансың... Ә үзең болай бик тәҗрибәле хатынга охшаган. Әйт әле, син моңарчы бер дә кияүгә чыгып карамадыңмы? Яшермә, сөйлә!»

«Бар, Кол Харис, җиңелчә генә юынып кил, Душтан чыккач сөйләрмен.»

—Бар инде, Харис! Йокың куерганчы коенып чык. Алай бик ошаткач, шушы караватта йокларсың. Мин үземә күрше бүлмәдәге диванга җәйдем... Харис! Тор дим!!!

«И, Мәрхәмәтле Ходаем,—дип өзгәләнде Кол Харис, уянып китү уңаена пышылдап,—әле дә ярый төшемдә күргәннәрем өчен генә оялып утырам икән. Франгизә коенган арада аз гына хәл алып торыйм дигән җирдән оеп черем итеп алганмын лабаса!»

—Франгизә, мин йокы аралаш сөйләнеп ятмаганмындыр ич?

—Юктыр. Су тавышы белән ванна ишеге аркылы ишетелмәде. Никтер, куркып уянганга охшыйсың...

—Әйе шул...

«Сине күргәнием», дип чак ычкындырмады Кол Харис. Алай да көн саен, һәр иртә кичен, әнисеннән мактау-үсендерү сүзләре ишетергә күнеккән бу максатчан, үз сүзле, иркә, әмма тымызык кызга берәр кәлимә комплимент әйтергә кирәк иде.

—Провинциядә әрәм яткансың. Зур шәһәр килешә сиңа... Рәсемең матурайды... Әйт әле, Франгизә, шушы яшеңә... гафу ит, көнгә кадәр ничек кияүгә чыгарга теләмәдең соң син?

—Бар, коен. Душтан чыккач сөйләрмен.

—Душтан чыккач сөйләрмен?.. Бу сүзне бер ишеттем ич инде бүген...

—Миннәнме? Булмаганны...

—Төшемдә.

—Кичке төшләрне юрамыйлар бездә. Бар инде, бар, арыгансың. Телең көрмәкләнгән... Карале, душта минем күзлегем онытылып калган, көзге каршындагы пыяла шүрлектә. Төшереп вата күрмә, яме.

—Бар, алып кил үзең.

—Юк. Юынып чыккан мунчага кабат кермиләр бездә... Торсын шунда, күзлек киеп йокламыйм мин. Төшләремне болай да аермачык күрәм.

«Душтан чыккач сөйләрмен» дигән кыйсса таң атканчы дәвам итте. Февраль таңы атканчы... Алар ике яктан да келәм эленгән стена аркылы сөйләштеләр. Дөрес, бүлмәләрне берләштереп торган ишек ябылып бетмәгән—кыз белән егет арасында йозак эләрлек хәзинәләр, чикмән бөркәнерлек шик-шөбһәләр, куркынырлык фигыльләр калмаган иде инде... «Чулман утлары» аларны таныштырды, дуслаштырды, якынайтты, үз кешеләр итте. Ике арадагы дуслык сагыну-юксынулар белән сынамаса да эш сәгатьләре дип аталган вакыт үлчәмендә алар гел бер тирәдәрәк йөрде... Киңәшмәләрдә, бәйрәм мәрәкәләрендә урыннары янәшә булды, кабинеттагы әбәт чәйләре бергә үтте.

Кыз белән егет бер-берсенең биографиясен, хезмәт кенәгәсеннән күчереп алырдай «резюме»ларын, хәтта туган-тумачалары хакындагы күп кенә истәлекләрне дә яттан беләләр иде кебек. «Аулак өйдә» кич утырып кайтканнан соң да Франгизәдә әле Кол Харисны кызыксындырырлык сер яши икән. Ул сер гомер үткән саен ерагаясы, онытыласы урында, киресенчә, Шәех Нур, Хислимә исемнәре белән зурая барып, отыры авырая гына. Һәм кыз соңгы елларда шушы серне сөйли алырлык газиз тыңлаучысын эзләде. Тапты. Ләкин сөйләп бирә алмады.

Ишек ярыгы аша сер йөри... Төнге шәһәрдә дүрт яктагы күршеләрең ишетмәсен дигәндәй пышылдап кына йөри... Кыйссаның ымлыклары, өзек-өзек урыннары, дөресен әйтергә авыр булгач ялганламас өчен махсус төшереп калдырган җөмләләре бик күп. Тик Кол Харис һәр пышылдауны отып ала, бүлдерми, кайтарып сорамый.

Мендәр очындагы аяклы лампаны кабызмады егет. Ник дигәндә Франгизәнең күз-колактан саклап йөрткән серле кыйссасында төнге караңгы вакыйгалар күбрәк булырга тиеш иде.

Кол Харис сабыр гына көтә, Шәех Нур көндәлегенә сыймаган мәхәббәт маҗараларын Франгизәнең үз авызыннан ишетергә тели. Кыз әллә инде әйтер сүзен чиксез еракта башлады, әллә егет ни көткәнне белеп, хикәятеннән юри төшереп калдыра.

Сәгатьләр буе көтә торгач, Кол Харис ирексездән йокыга китә. Икенче, өченче... унынчы көнне тагын шул ук хәл. Бер ай булды дигәндә, Франгизә инде тәмам Шәһрезадәгә әверелә, егетне йоклатыр өчен уйлап чыгарылган әкиятләре озынайганнан озыная бара. Һәм ул әкиятләрне «Мең дә бер кич» буе, азагына чаклы тынлап ятсаң да сер томаны таралмаячак. Шәех Нурны көндәлек язарга мәҗбүр иткән «Хислимә-Сәмигуллин-Франгизә» мөнәсәбәте, «Бермуд өчпочмагы» кебек убылып, инде Кол Харисны да үзенә сөйри. Аннан котылыр өчен кичекмәстән хакыйкатьне кайтарырга кирәк.

Франгизәнең икенче йөзе ачылганын һаман да көтә әле ул... Белә торып. Моңарчы кылган хаталарын танысын, үзе ачылсын.

Чын Мәхәббәтнең йөзе бер генә!..

Авыл җирендә булса хатын-кыз ягында яшәгән иргә «йортка кергән» дип кушамат тагарлар иде. Зур шәһәрдә моңа исе киткән кеше юк. Кол Харис та фатирантлыгына ияләшә төште... Дөрес, әлеге янәшәлек—күршелекне ул гаилә кору дип түгел, торыр урын юклыктан килеп чыккан вакытлыча җайсызлык дип кенә кабул итәргә тырыша. Иртән чыгып китә, кич кайтып керә... Кибетләрдә йөреп ала... Ләкин үзе дә сизмәстән һаман саен әкрен-әкрен генә Франгизә җылысына ияләшә бара. Аңа ияреп иртән сөтсез кофе эчәргә өйрәнде, төшке ашка күбрәк яшелчә, ботка ишеләрне ала, кичке алтыдан соң бөтенләй ризык капмаска күнекте. Хәтта көнгә икешәр тапкыр—иртән һәм кич душ керергә дә гадәтләнде.

Әмма кальбендәге эзләнү халәтеннән котылырлыгы юк. Шушы өметне җиңә алмагач, ул компьютер артына килеп утырды.

Франгизәнең иркенләп кичке душка кереп киткән чагы иде. Ул

мониторның кабынганын түземсезлек белән көтеп алды. Ниһаять, танышу сайтын ачты. Файдаланучы буларак теркәлгәч, электрон пәрәвез Дөньякүләм челтәргә тоташтырды. Инде жанын теләгән, күнеленә хуш килгән, кечкенәдән хыялланган кешеңне эзләп табарга, сайлап алырга, һәм аның белән элемтәгә керергә була.

Кем кирәк, ничә яшьлек, ни өчен, кайдан эзләргә телисең дигән сорауларга Кол Харис күптән, бик күптән әзер иде инде. Буй-сынын, билен, күкрәген, чәч толымын сантиметргача төгәллек белән язгач: куе кара кашлы, зәп-зәңгәр кысык күзле, киң маңгайлы, озынча яңаклы, бит алмасының уң ягында коңгырт миңе булган, калын иренле бер кызның фоторoботы сурәтләште. Кол Харис өчен аның почык борынлысы, ирен читендә «мәхәббәт чокырлы» һәм солярийда чамасыз мавыккан көяз кебек кара тутлы булуы да бик мөһим иде.

Компьютер: «Кайдан эзләвебезне телисең?»—дип кайтарып сорагач, егетерактанрак башлады. Кысык күзле кызларның Япония, Корея, Вьетнам тирәсендәрәк булу ихтималын чамалап, Кол Харис, үзе дә сизмәстән виртуаль дөньяга кереп китте. Ерак һәм Якын Көнчыгыштан, Африка һәм Азия илләреннән гел бер төрле җавап килде: «Андый кыз юк...» Дөрес, Кытай иленнән Гуль-Ю-Зем исемле бер кыз табылган иде, ләкин ул мөслимә булып чыкмады... Житмәсә, кульяулык та чигә белми икән.

Аптырагач, Кол Харис виртуаль Рәсәйгә кереп карады. Мегаполисларны, провинциаль шәһәрләрне, Агыйделнең аръягын айкады. Икеләнеп, гайрәте чигеп, теләр-теләмәс кенә ахырына якынлашкан сәяхәт көтмәгәндә-уйламаганда сөенечле хәбәр житкерде: «Андый кыз бар!» Сәрия исемле. Буй-сыны, яше, төскә-биткә, хәтта тавышына чаклы Кол Харис эзләгән хыял! Монарчы әле беркемне дә шашып яратмаган, тапмаган-югалтмаган, тумышыннан бөтен килеш сакланган кыз бала!

Һәм ни хикмәттер, ул кыз Чулман каласында яши ди..

Кол Харис Сәрия дөньясында калды.

## Күчү чоры ләззәте

Әжәлгә дару бар диләр...

Юк сүздер, булса Хафизулла углы Дияр белер иде аны.

Картаеп үлгәнче эшләп, тәхеттән туп-туры ләхеткә кергән падишаһларның берсе дә үз халкыннан озаграк яши алмады. Миннән башка бетәсез бит сез, дия-дия мәңгелек власть өметләнгән шаһиншаһлар, ханнар, солтаннар, императорлар, юлбашчылар, генераль секретарьлар һәм дә күпме президент китеп барды бу фани дөньядан...

Ә халык һаман исән. Халык мәңгелек!

Ил башлыклары үлгәч: «Сездән башка ничек яшәрмен соң мин?!»—дип еламаска өйрәнде Дияр карт.

Оник Мөхәммәтнең Кызыл диңгез тарафларында тоткарлануы турындагы хәбәр яналыклар каналында янрамыйча гына бөтен мәмләкәткә таралып өлгерде. Кайсыдыр ки сабырсызы, имеш-мимешнең расланганын көтмичә, үзенең версиясен өлкә газетасында чыгарып өлгергән иде инде... «Диңгез пиратлары урлагандыр аны—берәр колониаль илгә юлбашчы кирәк булгандыр...»—имеш.

Әйе, зур житәкче алышынгач, телисеңме, теләмисеңме халыкның моңлы күңеле бераз иләсләнеп ала. Рәнжетелгәннәрнең кальбен канәгатьлек хисе били, ул барында шөкрана кылып яшәүчеләрне шом баса.

Бер уч туфрак ыргыткан чакта, гүр иясенә карата да миһербанлылык сорый китап: «Яхшы кеше иде...»—дип телдән әйтергә куша. Рәнжетелгәннәр дә, саклап килгән нәфрәтне чигереп, китап кушканны үтәргә мәжбүр була. Буйсынулы халыкның алдагы көн хакына язмышына күнеп яшәве инде бу... Киткән кеше урынына яхшырагы килгәне юк әле!

Карт хатынны ташлап яшь бичә куенына кергән ирләр жинел аңлар безне... Жиһазларны күчереп, комод-өстәлләрнең урынын алыштырып алсаң да иске фатир эченә яңалык кереп чыга. Озакка бармый үзе, кабат ялыктыра, мохит тагын үзгәреш сорый башлый...

Хакимият алышынгач та халык ничектер бер мәлгә азатлык яулагандай, үзен ирекә чыккан бәхетледәй хис итеп ала. Алдавыч, хыялый һәм дә тотрыксыз халәт бу...

Гади эшче пенсиягә-мазар китсә Гали урынына Вәлине куялар да—шуның белән вәссәләм, күрше цехтагылар үзгәрешне сизми дә кала... Әгәр инде зур түрә китеп барса чиновниклар армиясенең йокысы кача, әрсез алмашның өмете азына. Шеф урынына урынбасарын куярлармы? Урынбасар итеп бүлек мөдиренме? Мөдирлеккә тегенең малаен әзерлиләр иде, алайса бүлектә бер вакансия бушый... Бер түрә эшеннән китсә, ким дигәндә биш кеше үзенең яшәү шартын үзгәртә, бер баскычка өскә үрмәли... Киткән түрә зуррак булган саен кадрлар арасында урын алыштырулар күбрәк була.

Бу очракларда Кияү Тарханның Чулманда күренгәне юк, Азан Кирмәне тирәсендә бусагалар таптый диделәр. Онык Мөхәммәт тәхетенә берәрсен Мәскәүдән китереп куймаслар ич инде?!.

Иван Иванычның да тынычлыгы бетте, яна глава килсә аны эшеннән алмасмы?

Бәхет эзләргә дип Азан каласына киткән жирдән Кол Харис кире әйләнеп кайтты, редакторлыкка расларга кирәк булса Хакимият алдында Иван Иваныч аны яклап үз сүзен әйтер...

Кыскасы, эрләмәгән-сукмаган, Шаһи сина ыштанлык...

Кешегә барысы да табигать хозурыннан күчә.

Ел фасыллары берсен-берсе алыштырганда жиһандагы гүзәллекнең чамасы югала... Май ахыры белән июнь башында, жиләк-жимеш чәчәкләре дөньяны яулаганда, язгы табигатьнең кочагына керәсе килә башлый... Жәйнең бөтен горурлыгы—мул августның алтын көз белән кушылуында... Ноябрь белән декабрь тоташкан жирдә манзараның аклыгына сокланабыз... Февральдән мартка кергәндә, кыш белән яз ызанында кешелекне түбәләрдән тамган беренче тамчылар сискәндерә. Шул тамчылардан ук инде без елгалар ташуын, кошлар сайравын, жир жылысын тоябыз. Ел фасыллары алышынганда кешелек могжиза көтә. Күчү чоры—чынга ашмый калган хыяллар шашынуы ул!..

Онык Мөхәммәтнең тәхетенә кызыккан райбашлар шобага салыша иде инде. Кабинетларының юлбашчы портреты эленә торган стеналарын ремонтлатучылар да шулар. Гади халык та азына башлады: ул хәзер хезмәт хакын вакытында бирүләрен дәгъвалап начальнигының теңкәсенә тия; бушлай эшләргә кушсаң кирелән ә, орышкан чакта каршы дәшә, эшеннән куам дисәң... тәүбә, тәүбә, Аллам сакласын... прокуратурага язарга тотына, хәтта алимент сорап килгән приставларга «чыпчык борыны» («кәжә тоягы») күрсәтү очраклары да бар... Өстәгеләр булдыра алмагач, астагылар тик ятарга теләми һәм шуның аркасында мәмләкәттә революцион ситуация өлгереп килә иде.

Ниһаять, телевидение буталчык дөньяны тәртипкә салу эшенә керешә. Яңалыкларга Онык Мөхәммәтнең исеме кайтты, хәзер ул концертларда, спектакльләрдә, ат ярышларында күренә. Интервьюлар бирмичә, туры сөйләмгә кермичә, телекамераларга артык якын килмичә генә әкренләп үзенең барлыгын сиздерә башлады ул. Һәм жөмһүрият аның беркая да китмәвенә көннән-көн ныграк ышанды.

Парча төбәгенең Тагын Сала авылына хужалык алдынгылары белән семинарга барган жиреннән һәвәскәрләр оештырган Нәүрүз бәйрәмендә катнашмаган да булса...

Кунаклар, төялеп килгән лимузиннарын түбәсенә ике байрак кадалган контора янында калдырып, авыл капкасыннан чыкты. Үз аягында йөрердәй

бөтен җан иясе көтә иде аларны. Чем кара төрле чанага җигелгән атларның берсе «Мерседес» кушаматлы, икенчесе «Вольво». Оныкк Мөхәммәт хөкүмәт җитәкчесен үз янына утыртты, семинар өчен җаваплы министр чана табаны артына басып тарантас инсәсенә тотынды. Сәндерәдәге кучерның кем икәнен ни кунаклар белмәде, ни авыл халкы танымады.

—Әйдә, каула! Ә сез бездән калмагыз!—диде Оныкк Мөхәммәт, «шобагачы» хакимнәргә борылып.—Спартакиада елы җитә, йөгерергә өйрәнегез.

Пар ат ял иткән иде бугай, урыннан җитез кузгалды. Дистәдән артык хаким берсен берсе узарга маташып, чана эзе төшкән такыр юлдан элдерде, тик аларга гади халык иярмәде. Гади халык тамаша күрергә генә килгән иде... Ике багана арасы чаклы юл үткәч дилбегә Оныкк Мөхәммәт кулына күчте. Пар ат, кисәк кенә борылыш ясап, калын кар яткан басу өстенә сикерде. Быел тотылган кар «Мерседес» белән «Вольво»ның тезеннән генә булыр, мөгаен, ә шобагачылар аңа бот тиңентен килеп керде, керде дә, йөгерде дә. Моны бөтен авыл халкы күреп шаккатты: бакчи, түрәләрнең хәле дә без уйлаганча ук шикәр түгел икән... Шушы ат юлыннан йөгерергә теләмәсәң, югары постыңнан мәтәлеп төшәсенне көт тә тор! Йөгермәс өчен төрле чанада калырга кирәк...

Кар өстендә язны каршылап узышулар телевизион сюжетлардан киселгән иде. Аның каравы, Оныкк Мөхәммәтнең семинардагы тезисларын тулысынча бирделәр.

«Бүген кояш календаре буенча Яңа Ел башлана. Мөрәҗәгатем шул уңайдан.

Иптәшләр, без һаман да әле югарыдагылар кушканны гына үтәргә күнеккәнбез. Кушсалар һәр гектардан 68 центнер икмәк җыеп алабыз, кушсалар күперләр корабыз, җир асты юллары салабыз, миллиард тонналап нефть чыгарып бирәбез.

Кушмаганны эшләр вакыт җитте. Яшәү шартларының мөшкеллеге белән гади халык янә большевик булып калды. Рәсәйнең туксан биш процент кешесе җан асрар өчен очын-очка чак ялгап бара. Меньшевиклар биш процентын гына тәшкил итә. Гаделлекме шушы? Энергия чыганакларын: газны, нефтьне, электр станцияләрен, төсле металлар, бигрәк тә алтын, алмаз, никель, алюминий рудникларын шәхси куллардан алып кичекмәстән дәүләтнеке итәргә. СССР ник байый алмады дисезме? СССР—Африка, Азия, Латин Америкасы илләрен, социалистик лагерь җөмһүриятләрен туендырып-киендереп ятты. Без бу ялгышны бүтән кабатламабыз.

Пнимаете, хәзер бит Җир шары тоташ капитализм базарыннан гына тора. Үзебез бөергә таянып тендер, конкуренция, альтернатива дигән булабыз. Алайса, әйтегез мина, капитализмга альтернатива кайда?

Допустим, төзедек ди бер дәүләт, кабатлап әйтәм, допустим!.. Өч тиенлек трамвайлары, уналты тиенлек ипие, сигез тиенлек бензинны, бушлай уку, дәвалану, фатир алу, тугыз сумлык квартплаталары белән... Аңлыйм, сез мине хәзер утопиядә гаепләргә җыенасыз... И всё же, давайте подумаем...»

Дияр карт үз колагына үзе ышанмады—Оныкк Мөхәммәт сөйлиме соң боларны?! Әллә инде, чит илдән кергән фантастик фильмнарны өсте-өстенә карый торгач, колак саташа микән? Байлык диктатурасы ике башлы бөркет биләмәләрен йодрыкка төргән бер чорда, бу сүзләрне әйттерер өчен, вакыт машинасына утырып ким дигәндә йөз елга артка күчәргә кирәк! Дияр Хафизуллович телевизор тартмасын яннан да, артыннан да сыйпап карады, юк-юк, манифест укырдай коммунизм өрәге кереп ояламаган аның эченә! Хикмәт чыгыш ясаучының үзендә бугай... Ә тынлыйсы килә...

«Милли мәсьәләгә борын төртүчеләр күп, әмма кул тыгучылары юк. Әйе, согласен, заманында без Алтын Урда дәүләтенең глобусын төзегән халык. Бүген исә безне имән бармак белән санарлык, милләтебезнең, күп дигәндә, тагын ике переписьлек гомере калгандыр. Менә мин сорыйм сездән, пчему?!

Ник шулай? Чөнки яу белән берләшкән империяләр барыбер үзара сугыша-сугыша бүленеп бетә. Без илбасарлар түгел, без—сәүдәгәр халык, мөстәкыйль дәүләтебез юк. Ник? Чөнки аяк астындагы жиребез инвесторларга, Мәскәү кенәзләренә, банкларга сатылып беткән. Жире сатылып беткән урында нинди дәүләт төзеп булсын! Жирен юк икән—өен дә, илен дә юк дигән сүз!

Мин беренче очракта урак-чүкечле кызыл байракны үбеп ант иткән, әмма коммунизм төзелешен ташлап качкан унсигез миллион дезертирга мөрәжәгать итәм, кая сон сез?! Бәяләрне кайсыгыз туктата? Инфляция, эшсезлек, дефолт, кризис, коррупцияне безгә кем кертте?.. Әлбәттә, банклар! Коммунизм чорында нибарысы өч банк идарә итә иде, ну, Сбербанк, Промстройбанк, Внешторгбанк дип әйтик. Ә бүген алар ике мен ярым. Әйе, кризис аркасында пока мен ярымы бикле. Шулай да ул банкларда ярты миллионга якын кеше эшли. Аларнын күпме зарплата, бонус, дивиденд, премия алганын белсәме—Рәсәйдәге кырык миллион пенсионернын ярсудан йөрәге тотар иде. Банклар шул ук «МММ»нар кебек финанс пирамидалары инде ул. Син акча саласын, мин-ул сала. Банклар аны рәхәтләнеп туздыра. Син дә, мин дә, ул да берьюлы акчабызны сорап килсәк—банк Хөкүмәттән ярдәм сорый һәм аны да безгә бирми, үзе туздырып банкротлыкка чыга. Менә сиңа кризиснын башы...

Кыскасы, безнен милләт бетә, ә банклар кала.

Федераль университет галимнәре әйтсен әнә, без Туфан суы калыкканнан сон тагын күпләп үрчербезме? Әллә Игезәкләр йолдызлыгыннан Яна татар гуманоидлары килгәнне көтәбезме? Шуны онытмагыз, миллион ел элек тә чит планетадан күчеп килгән кавем инде без. Күптәнме бала йоклатканыгыз бар? Бишек тибрәнгәндә нарасыйлар күк жисеме булып ала, Жирнен тарту көчен жиңеп үз авырлыгын жуя. Архиборынгыдан килгән шартлы рефлекс бу. Бишек—галәм сәяхәтчесенен тренажеры...

Шагыйрь сүзләренә таянып төгәллисем килә: яши бездә хәзер ике «Мин», берсе анын гел байларны яклый, икенчесе каршы, суккин сын!..»

Гади халык өчен «Нәүрүз фетнәсе»нен сөенече озакка бармады. Атна узды дигәндә жөмһүрият житәкчелеген Мәскәү кенәзе үзенә чакыртты һәм хан ярлыгын, Онык Мөхәммәттән алып, түрле чанадагы икенче берәүгә тапшырды. Тагын күчеш чоры галәмәте башланды...

***

Нух пәйгамбәрнен сәгате сукты.

Дияр карт кызыл сандыкны күмәрдәй урын эзләп кайтты...

Бактын исә Шәмдәл кебек зур авылда хәзинә яшерерлек тә урын калмаган икән.

Кая карама—кеше күзе. «Котылдык» урамнары басу читләтеп кенә карурманга таба үсеп бара. Аулак чирәмлекләргә бозау арканлап, бакча башындагы болыннарга люцерна чәчеп, инеш ярларында машина юып, аулак чокырларга чүп-чар түгеп халык тирә-юньне биләмәләп алган.

Бакчи, әнә күрше житмеш хужалыклы Мукшурда тугыз сыерлы утыз йорт жан асрап ята—алары да Ижаудан әйләнеп кайткан яшь пенсионерлар. Ерып булмастай печәннәре чабылмыйча, чиләк-чиләк жиләкләре, тубал-тубал гөмбәләре жыелмыйча, шомыртлары коелмыйча кул тигәнне көтеп сабагында кибеп кала. Урманнары кыргыйланган, әрәмәлекләре чуалган. Өенһән чык та күм сандыгынны.

Кечкенә авыл дигәннән, кунакка кайткан чакларында кала мужиклары зарлана торганнар иде: бүлмәләрен күбрәк булган саен әйбер яшерүе кыен, ә менә бер бүлмәле фатирда хатыннардан яшергән акчаны да, шешәләне дә табам димә... Улы Шәехнурнын да укыган чакта шулай сөйләгәне бар.

Хислимә күрмәсен, кирәге чыгар әле бер дип ярты литрлы «Сусадский»ны унитазның су мичкәсенә чумдыра бу... Туалетка кереп чыккан булып кына чәркәләп бушата да, беткәч, яңа шешәне батырып куя. Хислимә Шәехнурның кич буе кызмача йөрүен күреп тора, кая яшергәнен генә белә алмый. Бер бүлмәле фатирда югалган нәрсәнне дә эзләп табам димә... Ахыр чиктә, хәрәм килеп барыбер малайның суыткычын фаш итә—су белән бергә ак сурәте төшерелгән шешә этикеткасы агып төшә...

Соңгы вакытларда улының хәмер белән дуслашуын сизеп тәмам хафага төште Дияр карт. Әти-әнисеннән ис яшергән булып кесә тутырып сагыз йөртсә дә сизелмимени соң?!. Бөтнекле сагыз җинә аламы ул явызны. Көндәлеген укыгач кына әлеге афәтнең сәбәбе аңлашыла кебек—күнелен алма корты кимергән дә, җанын-тәнен сәяси бет баскан ич аның...

Бәхетле ата улы янында картаерга тиеш. Бакыйлыкка китәр алдыннан нигезен мирас итеп, өендәге китапларын, чүпләмле сөлгегә төрелгән нәсел тарихын, ишек алды-абзар курадагы эш коралларын ышанычлы кулга тапшырып калдырырдай кешен бармы?.. Кызларын өчәү-бишәү-җидәү булсын. Тик барыбер малай кирәк. Бәхетле атаның җәсәде улы казыган ләхеткә инәргә тиеш... Баланың ата-анадан алда китәргә хакы юк!.. Кызыл сандык Шәехнуры кулына калырга тиеш иде.

Дияр карт урын карап кайтты...

Шәмдәлне ике мәхәлләгә бүлгән «төпсез канау» бар. Шул канау аша асылмалы күпер тартылган. Арба күчәре юанлык ике корыч аркан ике сөям киңлегендәге сайгакларны күтәреп тора. Бу—көндезге күпер. Малайлар монда мәктәпкә барышлый берсен-берсе уздырырга тырышып батырая, ян-якка чайпалдырып атына. Малайлар чыгып бетмичә кызлар аяк басмый ана... Иртәнге савымга ашыгучы терлекчеләр, сыер савучы дәү-дәү апалар да күперне кичкәнче бисмилланы теленнән төшермәс... Сәрхүшләрнең кермәве хәерлерәк—ел саен берәрсе мәтәлеп төшеп инвалидность алып менә.

Кояш баеды исә асылмалы күпернең җаны чыга. Ерганак төпкелендәге шомлы тынлык тирәнәеп, кара-кучкылланып үзенең корбанын сагалап тора башлый... Корыч аркан бәйләнгән имән субайлар тирәсендә чыпчык миләше котырып үскән... Дияр карт бик ошатты бу урынны. Кеше күп йөргән җирнең сере юк. Чыпчык әрәмәлеге Бөкмеш Табасының алпавыт нигезе түгел. Кырык ел үтсә үтәр, әмма шәмдәлләләр такыр сукмак читеннән хәзинә эзләп йөрмәс. Тагын Туфан суы калкыр. Кинәт түгел, көн саен сөямләп-сөямләп күтәрелер. Тау битендәге төпсез ерганак су белән тулыр. Гөнаһлы гавамны тәүбәгә китергәч, Туфанның әүхәте бетәр, килгән юлыннан кире китәр. Шәмдәлнең тау битендәге югары очы исән калыр. Асылмалы күпер тирәсендә өйләр артыр, урамнар тыгызланыр. Яңа нигез, йә капка баганасы, әллә баз казыгандамы—Дияр картның хәзинә сандыгы килеп чыгар. Туфан суыннан тәһарәтләнгән халык тагын яңа баштан яши башлар, телен яңартыр, рухына кайтыр... Әгәр инде ярсу дулкыннар актарып чыгарса, зур Идел аны диңгез ярындагы Хаҗитархан кирмәненә алып төшәр һәм ул анда үзенең яңа кавемен табар...

Дияр карт велосипед арбасын сөйрәп төнге урамга чыкты. Каеш кидерелгән зур кыршаулы көпчәк юлны уятмаска тырышып тын гына тәгәри, бөгәлҗәле тәртәсе кулга җайлы, күчәре майлы. Сырма өстенә салынган сандык арба калаена бәрелмәскә тырыша. Шалтырап бармасын дип ул кирәкне буш кулына тотты...

Күмү шартына туры китереп, ләхет уярга да өмете талпынып куйган иде, ләкин бу уе бик тиз үзгәрде, балчык бик күп чыгып чокыр тирәсенә җәелер, кеше күзенә чалыныр. Аннан соң, Дияр карт бит ул сандыкны җир куенында черетер өчен күмми. Ошбу әшәке еллар үткәч, бәгъзе ялган демократлар дөмеккәч, хәзинә янә өскә калкып, «күпчелек» дип ярлык

тагылган гади халык кулына без яшәгән чорның «кара ящигы» булып әйләнеп кайтырга тиеш.

Буш арбаны капкага сөяп өйгә керер алдыннан өс-башларның тузанын каккалаган арада Дияр картның эченә кату чыккандай булды. Йа, Хода, күмгән җирдә көрәге онытылып калган лабаса! Вәт, хәтерсез, вәт зиһен өянәге, аягүрә йоклап йөрсән—шул кирәк сиңа!

Дияр картның күптән, бик күптән инде болай тиз йөргәне юк иде. Таң беленер чак җитә, савымчылар уянганчы өлгерергә кирәк. Көрәге җәл түгел, хәзинәне актарып алып мыскыл итәрләр.

Килсә—балчык актарылган, чокыр буш. Сандыкны Дияр картның үз көрәге белән казып алганнар—анысы бер читтә ялтырап ята. Ни арада?!. Ерак китмәгәннәрдер... Ул бөтен тынлыкны янына җыярга теләгәндәй шым калды... Әнә, дөп-дөп иткән адымнар ерганак ярыннан үр төшә, табан шапылдавында авырлык бар.

Сәгать эчендә ике кат үр менгән, чокыр казып күмгән Дияр картның гайрәте бар иде әле. Баскан җиреннән кинәт ыргылам дигәндә сөрлегеп китте, тик егылмады. Аягына уралган нәрсәне кулына алгач ачуыннан икенче сулышы ачылгандай булды—бу бит Сәлимханныкы! Тәки арттан күзәтеп яшәгән икән, камчылы шымчы!

Тиз куып җитте Дияр карт, алай да уяулыгын җуймады. Тимерченең кесәсендә әллә нинди кораллары бардыр, гәүдәнне ерганак төбеннән эзләрләр аннан соң. Карак кулыннан шәһит киткәнче әҗәлне урын өстендә көтеп алуың хәерлерәк. Хәлдән килгәнчә этзәрлекләргә сабырлыгым бетсә, үз камчысы белән үзен ярам, кешелеген калдырмыйм.

Берәүнең ияргәнен сизде Сәлимхан, туктап-туктап тыңлап торды. Кемдер пырыш-пырыш борын тарта кебек иде. Ул туктаган чакта сукмак тына, авыл эчендәге әтәчләр генә таң сәгатен дөресләп кычкыргалап куя. Өскә ябырылырдай куркыныч сизелмәгәч, тагын кузгала. Тимер сандыкны җилкәдә тотуы җайсыз, ул алга таба бөкрәйгән һәм егылып китмәс өчен адымын тизләтергә мәҗбүр иде.

Дияр карт араны тигез тотты. Шакмаклы шәүлә артыннан калышмады, якынайса—әкренәйде, ерагайса ашыкты.

«Куып киләме, әллә узып китәргә шүрлиме?»—дигән ише шикләнүләре җилкәдәге йөкне һаман саен авырайта бара. Сәлимхан өенә туры кайтмыйча клуб ишегалдына керде. Борыны җебегәннәр үтеп киткәч, бакча артлатып качарга була. Сандык калак сөяген изә, каядыр куеп торырга иде үзен. Бөкре аяк астыннан арыны күрмәс, әнә, Шәмдәл клубының ике оялы бәдрәфе, бер ишеге ачык хәтта, кирәксә шунда яшереп торып әйләнә-тирәгә разведка ясап килергәдер. Әгәр шикләнердәй кемсә күренмәсә, тракторны кабызыргадыр, бәлки. Кая бармас, нәмә төямәс, кемнең ни эше бар?!. Гөнаһ шомлыгы—ачык дигән ишек бөтенләй юк икән, ә идәндәге оядан ике-өч яшьлек өрәңге үсеп чыккан. Соңгы сайлаулардан соң өч ел узды бугай... Икенче ишекне ачса—анысының оялы идәне гупчым юк. Сәлимханның сабырлыгы сыгылып төште, ул йөкне бәдрәф кырыендагы түмгәккә сөяде. Талчыккан җанны сөендереп сандык эчендә тәңкәләр шалтырады. Шунда гына абайлап алды—көн яктырып килә ләбаса! Өй түбәләре, урамнар аермачык, баганаларны санарлык, сандык йозагының ачкыч күзәнәгенә чаклы күренеп тора. Ашыгырга кирәк... Сәлимхан кесә төбеннән ачкыч кучерләсен эзләгән арада як-ягына карап алырга да онытмады. Шикләнерлек ни-нәрсә юк. Инде мәгәр берәрсе килеп чыкса төпсез бәдрәфкә атам сандыкны.

Кергәләп йөр, дип әйтеп әйтте ди йозак бер ачкычка... Ләкин бу йозак түгелдер ул—бусы ачкычны бөтенләй өнәми. Күзәнәгенә балчык тулганмы, дип камыл белән чокып карагач кына аңлады Сәлимхан, йозак эченә кургашын койганнар, алай гынамы, ишек ярыгына да эретеп сылаганнар,

утта янмас, суда батмас әрҗәгә әверелгән бу кызыл сандык.

Нәкъ шул мәлдә клуб урамында чыбыркы шартлады.

Сәлимханга хәбәр бу. Ул сандыкны түмгәге-ние белән кубарып алырга әзер иде: «Кулга төшкән малны күрәләтә калдырып китүчеләр без түгел, апаем!»

Чыбыркы шартлавы, туктаусыз эзәрлекләп, аны авылдан куып чыгарды. Сәлимхан олы юлдан ат юлына күчте—Бимә урманына кереп качарга иде, ахрысы, исәбе. Аның саен чыбыркы «шарт та шорт!» килеп каракның кайтыр юлын яралый, нәфесен телгәли, баш очында сызгырып-сызгырып чатный.

Ат юлыннан сарутлы сукмакка күчкәч, Дияр картка соңгы чара калды, узып каршысына чыгарга, туктатырга, кирәксә юлына аркылы ятып үткәрмәскә... Чөнки әлеге сукмак үләт базына алып бара.

Дияр картның аягы җирне тоймас булды, бөтен таң җиле бергә кушылып җилкәсеннән этте, йөрәге белән янәшәдә тагын бер йөрәк кабынды. Менә ул сукмак читенә чыгып Сәлимхан белән тигезләште. Узды... Инде аяк астында кыргый этләр, котырган төлкеләр үләт базыннан сөйрәп чыгарган мал-туар сөякләре күбәйде, алар күбәйгән саен баз аузыннан аңкыган җирәнгеч дарулы ис көчәйде...

Кинәт борылып, сукмак өстенә имән багана булып басты Дияр карт. Бер кулында көрәге, икенче кулында качкынның үз камчысы.

—Үләт базына якын киләсе түгел! Камчың белән күзеңне алам. Көрәк белән башыңны кисәм. Кузгалма! Әкрен генә җиргә куй. Әкрен генә! Аның эчендә шартлаткычы бар, баядан бирле сәгать тавышын ишетмисеңмени?!

Ике арадагы үле тынлыкта Шәех Нур сәгатенең текелдәве ишетелә башлады. Сәлимхан зур хәвефтән шүрләп, Дияр картның һәр әмеренә буйсынды. Үзе кинәт кенә атай-әсәенең күркәм телен оныткалап әле русча, әле башкортча, әле татарча сүгенергә тотынды. Сандыкны, дары мичкәсен иркәләгәндәй, әкертен генә җиргә куйды.

—Вәт, баштук шулай итәләр аны... Ә хәзер—кругом марш! Ике йөзле дусны югалту—берьюлы ике дошманыңнан котылу ул.

Иренеп кенә кайтыр юлга борылган Сәлимханның бәләкәй чакта атай каешы төшкәли торган урынын камчы кылы суеп үтте...

***

Дияр карт көмеш йөзле көрәген иңенә салып кайтып кергәндә Нәсимәттәйнең төшке ашы суынган иде инде.

Сәлимханның колач ярымлы камчысын бүтән күргән кеше юк, әллә карт аны үләт базына ыргыткан, әллә сандык тоткасына урап калдырган. Шулай ук сандыкның кая күмелгәнен дә беркем белми. Вә ләкин шунысы мәгълүм, Шәмдәл халкы, кызыл сандык малын үз күзләре белән күрергә теләгәндәй, Туфан суы калыкканны әле дә булса көтеп йөри...



*Борынгы бабаларыбызның кылганлы далаларда торып калган сынбалбаллары.*



*Болгар-йортка юл өзелмәс.*



*Казанны алу күренеше. XIX гасыр немец рәссамы В. И. Вениг эше.*



*Шәһит киткәннәргә—догалар.*




*Дәүләтчелек рухы сүнмәгән.*




*Тел бирмәк—ил бирмәк.*



*Мондый биналарны хәтерен җуймаган*
*халык кына күтәрер.*



Бикә
Рәхимова

# ДӨНЬЯ ТЫНЫП КАЛГАН АК ТЫНДА...

## Сайлап ал

**Энҗе кебек сүзләр тезәм ак кәгазьгә...**
**Җан иңдерә хәрефләргә галәм җиле...**
**Мин килгәнмен йолдызлардан—ераклардан,**
**Сагынып бер тартып алыр йолдыз җиле...**

**Сүзләр тезәм, йөрәгемне парә итеп,**
**Йолдыз нуры ук-кылычын төбәгәндә...**
**Мин чәчелдем, мин сибелдем чәчәк кебек,**
**Син сайлап ал—синең йөрәк теләгәнне...**

***

**Елга яры буйлап сукмак киткән—**
**Әрәмәгә илтә юлларым...**
**Гүзәл таң кызыдай йөзеп чыга**
**Әллә минем үткән елларым?..**

**Елга өсте көзгеләре җилдән**
**Чәрдәкләнеп китте, ватылып.**
**Кисәкләрдән нурлар очып үтте,**
**Кыйпылчыгы булып вакытның.**

**Эх, җыясы иде кисәкләрне,**
**Бөтен итеп милли тормышым...**
**Өлгергәнлек нуры—җиләк эзләп,**
**Әрәмәгә кереп барышым.**

Бикә РӘХИМОВА—*шагыйрә, публицист; «Сәрвиназ», «Иделләр казанында», «Мәрхәмәт» һ. б. китаплар авторы. Татарстан мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең А. Алиш премиясе лауреаты. Казанда яши.*

***

Әрнүләрем әремнәргә салсам,
Түзәр микән ачы әремнәр?..
Җаннарына таң яктысы койсам,
Бүзәрерме кара адәмнәр?...

Шытып чыгар, бәлки, таң гөлләре...
Күпме көткән халкым боегып!
...Хыялларын оныттырыр өчен,
Тугладылар йокы—оетты.

Әрнүләрем әремнәрдән түгел,
Миһербанлы алар, дәвачы.
Яңа гасыр килде, йотам, диеп,
Тырма тешле аузын дәү ачып...

***

...Хыял аланымны кемнәр басты[1]
Албастыга охшап бу мәлләрдә?
Төссез гөмбәз төште өсләремә,
Гүя утлар сүнде шәмдәлләрдә...

## Язмыш

Ачылмаган гөлләр бөре килеш
Шиңә тора. Шомга юра...
Ләкин кеше гайрәт-дәһшәт тели—
Күңелләрне силләр ера.

Яндырмасын мине дәһшәт диеп,
Арасына пәрдә элдек...
Чәбәләнепниләр теләгәндер,
Кеше китте. Без ни белдек?..

***

Бәргәләнде кышлар быел, бәргәләнде,
Җиңәр өчен һавадагы юеш газны,
Һәм, ниһаять, кардан ап-ак түшәк җәйде,
Бәхет диеп, шатланырга әллә азмы?

Яулап алды хокукларын, бурычларын,
Быелгы кыш безнең кышка охшаш тәмам:
Колак-борын, бит очларын чеметкәли,
Табигатьтә табигыйлек итә дәвам.

Юкса кышлар җуйган иде хокукларын,
Бурычларын—яудырасы карлар барын...
Җылы юрган ябынган да җирләр йоклый,
Өшетмичә татар җанын—уҗымнарын...

...Кыштан күреп, үз-үземне «бурычладым»,
Оныттың дип хокукларың, бурычларың...

---

[1] Россия мәгариф программасыннан милли компонент дигән бүлек алып ташлануга ишарә.

## Сугарасы...

Бу дөньяда кеше кадерләре
Үсә, диләр, кадәр[2] агачында:
Бердәй тансык, тәмле җимеш икән
Кояш баешында, чыгышында.

Сусый кеше җаны кадер көтеп,
Кадер көтү били тукны, ачны.
Тик нигәдер уйларына килми
Сугарасы, диеп, шул агачны.

## Көз—2009

*Һаман тынмаган Әфганстан,*
*Гыйрак, Кавказ сугышларын*
*уйлап...*

Алтын коя юлларыма көзем,
Бармы анда минем өлешем?
«Аһ, ашыкма!»—үрсәләнеп әйтә
Кулларымда булган көмешем.

Иркә назын сибә быелгы көз,
Юмарт, бик тә юмарт ул быел...
Күңелемә гел мәрхәмәт булып,
Кешелекле булып, көз, уел.

Бакчаларда ымсындырып бага
Алтын ягы көзге алманың.
Әллә нәрсә кулларымны тыйды,
Алтынымны учлап алмадым.

Аһ! быел да китек зур бер чите
Сум-алтыннар сипкән бу көзнең:
Кыйтталарда сугыш-үлем аһы
Елмаюын ала бу йөзнең...,

***

Сандугачлар, сайрап, риза!—диде,
Мәхәббәтнең таҗын кигәндә,
Ефәк җилләр, әйдәп, исеп торды,
Йөрәгемә угы тигәндә.

...Сусәргән таҗ күккә китеп ашты,
Асылташы купты, киткәндә...
Хәтер-ташны чайкап, суын эчәм,
Иреннәрем янып кипкәндә.

***

Янган утларымда ялгыз калып,
Тагын күпме түзәр бу тәнем?..
Мәхәббәтнең уты мәрхәмәтле,
Ләззәтләрнең белмим бүтәнен.

---

[2] Кадәр – язмыш.

Язмышымны ятим димәсеннәр,
Сөю суты миндә туп-тулы:
Челтерәвек җырын тыңлыйм әле,
Тормыш чишмәсе ул—җып-җылы...

## Бәс бизәге

Ак чәчәкләр аткан бар агачлар—
Ак урманнар туган дөньяга.
Гел аклыкка, сафлыкка өндәүче
Манзарасы Хакның тын ага.

Энҗе җептән челтәр чигеп элгән,
Чыбылдыгы сыман зөфафның.
Ак салкынның нәфислеген саклап,
Җил бикләгән үзе йозагын.

Җилләр исми, сихри тынлыкта бер
Туктап калган энҗеле дөнья.
Чуар төсләреннән гарык булып,
Көнләшер күк җылы як—көньяк...

***

Кәккүк кебек нигә моңлы башым?
Чит ояга күз дә салмадым.
Адаштырган серле юлларым юк,
Оя ватып өлеш алмадым.

Сүнгән—тынган учак тергезүне
Ходай насыйп итте юлымда:
Сәхабәдәй сыгынам Бөек көчкә,
Ай—Кояшның нурын юллый да.

Төнемдә дә мин Кояшны күрәм,
Моңлы икән Кояш ак төндә,
Кайтарылган нуры моңнар сибә,
Дөнья тынып калган ак тында.

***

Сызлыйсың син йөрәгемдә һаман,
Гел ачылып торган җөй булып,
Әрнүләрем, сыктауларым минем
Җилдә исә өзек көй булып.

Төнге җилләр таянычлы хәтер,
Бигрәк ятим булып исәләр,
Мәхәббәтнең ерак офыгында
Кызыл гөлнең утын кисәләр...

***

Эзләреңә ак томаннар төште,
Томан арты аяз булса да,
Күзләремнең яшен керфек тота,
Яшь болыты—көнгә бусага.

Болыт-болыт һәр керфегем саен
Эленгән дә тора күз яшем.
Маяк кебек ялгыз тоташ төндә,
Хәлем әйтеп, кемгә эндәшим?..



Зөлфәт
Хәким

# КАЙДА СИН, АТТИЛА?!.

ТАРИХИ ДРАМА-РОМАН

## Тарихка күз йөгертү

*Безнең эрага кадәр IV гасырдан алып Хуанхэ елгасының Зур Төньяк Борылышында (Монголия территориясендә) төркиләрнең борынгы бабалары—һуннар ыруының яшәгәне мәгълүм.*

*Б. э. к. III гасырда алар көчле дәүләт төзиләр. Мадә (Модэ яки Мао-Дун) шаньюй хакимлеге чорында һуннар дәүләте аеруча кодрәткә ия була. Бу чорда кытайлар һуннарга буйсынып салым түли башлыйлар.*

*Тора-бара һуннарның төньякка таба Байкал күленә кадәр 1 мең километрга, көнбатышта Арал диңгезенә тиклем 4 мең километрга сузылган дала империясе барлыкка килә.*

*150 ел буена кытайлар һуннардан котыла алмыйлар. Бер-бер артлы каты сугышлар була. Туктаусыз сугышлар, кытайларның хәйләле дипломатиясе, үзара ызгышлар—болар барысы да һун дәүләтен нык какшата һәм I гасырда һуннар икегә бүленәләр. Көньяк өлеше Хань империясенә кушыла, төньяктагылар күпмедер вакытка әле мөстәкыйль дәүләт булып сакланалар. Хыянәтче кланнар аркасында бу дәүләт тә тиздән таркала һәм һуннар Көнбатышка таба күчәргә мәҗбүр булалар.*

*II гасыр урталарында һуннар Идел-Урал буйларына килеп урнашалар һәм, угрылар белән кушылып, Җаектан алып Донга кадәр җәелгән империя туа.*

*IV гасырның 70нче елларында һуннар, угрылар, сарматлар белән бергәлектә, Көнбатышка юнәләләр. Герман кабиләләрен һәм башка бик күп ыруларны буйсындырып, һуннар юлда очраган илләрне яулап, Көнбатыш цивилизациясен котсыз калдырып, 400 нче елда Дунай буена, Рим империясенең чикләренә килеп җитәләр.*

---

Зөлфәт ХӘКИМ (1960)—*драматург, прозаик, шагыйрь, публицист; 3 томлык «Сайланма әсәрләр» һ. б. китаплар, театрларыбыз сәхнәсендә куелган күпсанлы пьесалар авторы. Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Биографик мәкалә

*(«Британика» энциклопедиясеннән. Вильям Бентон нәшрияты, 1968 ел, 2 том.)*

Аттила (?—453)—434 елдан алып 453 елга кадәр һуннар патшасы, Рим империясенә бәреп кергән варварларның иң атаклы, бөек юлбашчысы. Көнбатыш Европада аны «алла тарафыннан җибәрелгән афәт» дип атыйлар.

Беренче яуларын Аттила үзенең туганы Баладай (Бледа) белән башлый. Тарихчылар әйтүе буенча, аларның абыйлары Ругиладан калган һун империясе көнбатышта Алып тауларыннан Балтик диңгезенә, көнчыгышта Каспий диңгезенә (Һун диңгезе) кадәр җәелгән була.

Аттила белән Баладайның тарихи елъязмаларда беренче тапкыр телгә алынулары Көнчыгыш Рим империясенең идарәчесе белән Маргус шәһәрендә (Позаревак) төзелгән килешүләргә бәйле. Бу килешү буенча римлеләр салымны һуннарга икеләтә арттырып түләргә тиеш булалар, ягъни елына җиде йөз фунт алтын белән.

Аттиланың 435 нче елдан 439 нчы елга кадәре тормышы турында мәгълүматлар калмаган. Бу вакытта ул үз биләмәләренең төньягындагы һәм көнчыгыштагы варварларга каршы сугыш алып барган булса кирәк. Мөгаен, шул вакыйгалардан файдаланып, римлеләр Маргуста төзелгән килешүне инкарь итеп, еллык салымнарны түләми башлыйлар.

Аттиланың нәфрәте римлеләргә бик кыйммәткә төшә. 441 елда, вак-төяк рим гаскәрләрен тар-мар китереп, Дунай елгасы буйлап сузылган Рим империясенең чиген үтеп, Аттила Рим провинцияләренә бәреп керә һәм Виминациум (Костолак), Маргус, Сингидунум (Белград), Сирмиум (Метровика) һәм башка шәһәрләрне яулап ала, талый, җимерә. Ниһаять, римлеләр сугышны туктатуны ялварып үтенәләр һәм 442 нче елда солых килешүе төзүгә ирешәләр.

443 елны исә Аттила барыбер Көнчыгыш Рим империясенә бәреп керә. Беренче көннәрдә үк Дунай буендагы Ратиарий (Арчар) шәһәрен җимергәннән соң, Наис (Ниш), Сердика (София) шәһәрләрен яулап ала. Шуннан соң Аттила Константинопольне алырга ниятли. Юл уңаеннан ул Филлипополь шәһәрен ала. Римлеләрнең төп гаскәрен Аттила Аспәр янында юк итә һәм Константинопольне төньяктан да, көньяктан да саклаган диңгез буена килеп чыга.

Һуннар Константинопольне ала алмый. Аттила Галлиполи ярымутравына качкан рим гаскәренең калдыкларын куып җитеп, турап-кырып бетерә. Бу сугыштан соң килешү төзегәндә Аттила римлеләргә узган еллар өчен алты мең фунт алтын түләүләрен шарт итеп куя һәм еллык салымны ике мең бер йөз фунт алтын дип билгели.

445 нче елда Аттила үзенең туганы Баладайны үтергән дигән мәгълүмат бар. Ничек кенә булмасын, 445 нче елдан башлап ул һуннар белән берүзе идарә итә башлый.

Билгесез сәбәпләр буенча, 447 нче елда Аттила Рим империясенең көнчыгыш провинцияләренә тагын яу белән чыга. Төп һөҗүм Скиф дәүләтенең түбән провинцияләренә һәм Мезиягә туры килә. Шулай итеп, Аттила көнчыгышка таба элеккеге кампаниягә караганда тирәнрәк керә. Атус (Вид) елгасы буенда һуннар рим гаскәрен җиңәләр, ләкин үзләренең дә югалтулары зур була. Марцианополисны алганнан соң һәм Балкан провинцияләрен талап туйгач, Аттила көньякка—Грециягә юнәлеш тота. Бу кампаниянең дәвамы ничек булган—билгеле түгел. Шуннан соң өч ел буе Аттила белән Көнчыгыш Рим императоры Феодосий Икенче арасында дипломатик сөйләшүләр бара. Бу тарихи вакыйгалар Приск Паннийский язмаларында саклан-ган. Приск үзе 449 нчы елда Рим илчеләре белән бергә Аттиланың лагерында була. Ниһаять, яңа солых килешүе төзелә һәм ул 443 нче елгысына караганда да катырак булып чыга. Аттила Дунайның көньягындагы җирләрне сорый һәм коточкыч зур суммалы салым билгели.

451 елда Аттила Галлиягә бәреп керә. Анарчы ул Көнбатыш Рим империясенең императоры Валентиниан Өченченең гвардия командиры, аның опекуны, өч тапкыр консул—сәясәтче һәм сугышчы Аэций белән бик дустанә мөнәсәбәтләрдә була.

Елъязмаларда Аттиланың Галлиягә һөҗүм итүенең сәбәпләре сакланмаган. Башта Аттила башкаласы Толосия (Тулуза) шәһәре булган вестготлар иленә барам дип игълан итә һәм Көнбатыш Рим империясенең императоры Валентиниан Өченчегә бер дәгъвам юк дип белдерә. 450 елның язында Валентинианның сеңлесе Гонория кәчләп иргә бирүләреннән коткаруны үтенеп Аттилага хат яза һәм бүләккә йөзек җибәрә. Аттила Гонорияне үзенең хатыны дип игълан ясый һәм бирнәгә Көнбатыш Рим империясенең бер өлешен таләп итә.

Аттила Галлиягә бәреп кергәч, вестготлар короле Теодорих белән франклар Аэцийга ярдәм итәргә дип, һуннарга каршы гаскәр туплыйлар. Аннан соңгы вакыйгалар риваятьләр буларак кына сакланган. Аэцийның гаскәрләре килеп җиткәнче Аттила Аурелианиумны (Орлеан) алган булса кирәк. Аэций белән Теодорихның гаскәрләре һуннарны аннан бәреп чыгарганнар дигән версия бар. Хәлиткеч сугыш Каталаун кырында була. Бу коточкыч бәрелештә вестготлар короле һәлак була. Аттиланың гаскәре чигенә һәм Галлиядән китә.

452 елда һуннар Италиягә һөҗүм итәләр һәм Аквилея, Патавиум (Падуя), Верона, Бриксия (Брешиа), Бергамум (Бергамо), Медиоланум (Милан) шәһәрләрен җимереп, талап үтәләр. Бу юлысы Аэций һуннарга каршы торырлык көч туплый алмый. Ул елны Италиядә корылык аркасында ачлык булу һәм чума авыруы таралу сәбәпле, һуннар бу илдән чыгып китәргә ашыгалар.

Көнчыгыш Рим империясенең яңа императоры Марциан салымнарны түләүдән баш тарта. 453 елны Аттила һөҗүмгә әзерләнә башлый. Ләкин Илиркә (Ильдико) исемле кызга өйләнеп туй уздырганнан соң, һуннарның юлбашчысы яшь хатын кочагында үлә.

**Катнашалар:**

А т т и л а —һуннар ыруының илбашы, аннары барлык варварларның императоры. 50—60 яшьләрдә.

«Бу кеше җирдә яшәүчеләрне котсыз калдырырга яралгандыр. Аяк атлаулары, тишеп чыгардай күз карашы аның эчке куәтен, горурлыгын күрсәтә. Әйе, ул чын сугышчы иде, шул ук вакытта аңа сабырлык һәм үзен кулда тоту да хас иде. Киңәшләрне ул игътибар белән тыңлый белә, ялваручыларның хәленә керә, яклау эстәүчеләргә мәрхәмәтле иде. Ул тәбәнәк буйлы, киң җилкәле, олы башлы, агара башлаган сирәк сакаллы, җәйпәк борынлы һәм чыраеның төсе ерак бабаларыныкына хас чирканыч иде.»

*(Приск Панийский. Латинчадан тәрҗемә)*

А т а к а м —Итил буеннан Аттиланы эзләп Дунай ярларына килеп чыккан кам, 40—45 яшьләрдә. *(Атакам—Аттиланың материальләшкән җан газабы.)*

И л и р к ә (И л ь д и к о) —18—20 яшьләрдәге һун кызы. Аттиланың соңгы хатыны.

Ф е о д о с и й II —Көнчыгыш Рим империясенең (Византия) императоры, 47—50 яшьләрдә. Константинопольнең һуннардан сакланыр өчен корылган стенасы шушы император исеме белән аталган. Хәйран кыю, батыр йөрәкле, әмма Аттиладан коты алынып торган һәм аңа искиткеч зур суммалы салым түләгән. 450 елда аттан егылып төшеп үлә.

В и р г и л —Феодосий Икенченең атаклы тәрҗемәчесе, телләр белгече. 40-45 яшьләрдә. Сәясәтне яхшы аңлаганга, зирәк акыллы, хәйләкәр булганга күрә, дәүләт эшләрендә, илара интригаларда, дипломатик алыш-бирешләрдә актив катнаша.

*(Виргил—Аттиланың материальләшкән комсызлыгы һәм кансызлыгы.)*

Х р и с а н ф —Византия императоры Феодосий Икенченең камергеры, аның иң якын, иң кодрәтле чиновнигы. Бите балаларныкы төсле, гәүдә төзелеше дә сәер. 50 яшьләр тирәсендә. Куркыныч, тиз сатыла торган, шул ук вакытта гаҗәеп акыллы кеше. Империядәге барлык эшләрне контрольдә тота. Император Феодосий аның манипуляцияләре тәэсирендә яши, күп очракта аның сүзеннән чыкмый. Аттила белән килешүләр төзегәндә дә Хрисанф зур роль уйный. Аттиланы үтерергә маташучыларның берсе.

Валентиниан III—Көнбатыш Рим империясенең императоры, 30—35 яшьләрдә. Кыяфәте хатын-кызларныкына охшаган, йомшак, ихтыярсыз, кеше.

Аэций— мәһабәт гәүдәле, затлы римле. Император Валентинианның якын кешесе, кыйммәтле киңәшчесе, опекуны. 50—60 яшьләрдә. Рим империясенең иң атаклы шәхесләренең берсе. Өч тапкыр консул булган, империяне күп тапкыр саклап калган гаскәр башлыгы. Бала чакта һуннар илендә асрамада булган. Аэцийның Аттила белән дуслыгы аркасында римлеләр белән һуннар шактый вакыт тату яшиләр.

Гонория—Валентиниан Өченченең сеңлесе. Бик чибәр, төз гәүдәле, тәкәббер кыяфәтле. 25—30 яшьләрдә. Амбицияле, тәхеткә омтылучы. Булдыксыз, куркак абыйсының император булуы белән килешә алмый. Хәтта аңа каршы фетнә оештыруда катнаша. 450 елда ярдәм сорап Аттилага хат яза һәм аның хатыны булырга теләк белдереп, вәгъдә йөзеге җибәрә.

Орест—римле, Дунайның көньяк буендагы җирләр хуҗасы. 35—40 яшьләрдә. Җирләрен һуннар яулап алгач, Аттилага берсүзсез буйсына һәм тиз арада аның ихтирамын яулый. Бик бай, акыллы булганлыктан, Аттилага нык якыная.

Эдика—скириannar ыруының элекке юлбашчысы, аннары Аттиланың яудашы һәм аркадашы. 40—45 яшьләрдә. Яуларда үзен аямыйча батырлыклар күрсәткән каһарман.

Заркан (Зеркон)—искиткеч язмышлы, даны әллә кайларга таралган шамакай. Аны Ливиядән тотып алып кайталар һәм ул шактый вакыт Баладайда (Бледа) шамакай булып хезмәт итә. Бервакытны ул кача, ләкин аны тотып кире алып кайталар. Аны кичерәләр, хәтта хуҗасы аңа хатынлыкка бик чибәр кыз бүләк итә. Баладай үлгәннән соң Аттила аны Аэцийга бирә. Күпмедер вакыт узгач, ул янадан Аттила янына кайтарыла.

Иллек—Аттиланың өлкән улы, 28-30 яшьләрдә.

Дингиз—Аттиланың уртанчы улы, 25-27 яшьләрдә.

Ирнәк—Аттиланың кече улы, 20-25 яшьләрдә.

Алгыр—Илиркәнең Аттиладан тапкан улы, 16 яшьтә.

Гиацинтның шәүләсе—Гиацинт—Гонориянең шымчысы һәм ярдәмчесе, кайчандыр евнух булып хезмәт иткән, күпне күрә, күпне белә торган мәкерле кеше. Гонориянең хатын һәм вәгъдә йөзеген Аттилага илтеп тапшыручы. Римгә әйләнеп кайткач, аның башын чабып өзәләр.

Хезмәтчеләр, сакчылар, ясауллар, һун сугышчылары.

Римлеләр, һуннар һ. б.

# I

*449 ел башы. Көнчыгыш Рим империясенең (Византия) башкаласы Константинополь. Мега Палатион (Бөек Сарай.) Император Феодосий II шул сарайның Дафна дип аталган үз биләмәсендә хат укып утыра. Камергер Хрисанф керә.*

Хрисанф *(тавышсыз гына адымнар белән килеп).* Император! Мин килдем.

Феодосий *(кинәт башын күтәрә, беравык карап тора).* Ә-ә-ә, минем тугры камергерым. Уз әйдә, Хрисанф. Көнбатыш Рим империясенең императоры Валентиниан җибәргән хатны укысаң, акылдан язарсың.

Хрисанф *(император каршысына килеп утыра).* Син—Византия императоры—тилемсә кешенең ни язганына зур игътибар бирмә.

Феодосий *(хатны өстәлнең читенә куеп).* Тиле түгел ул. Иң коточкыч кыргый варварлар белән уртак тел таптылар да, тыныч кына яшәп яталар бит әле.

Хрисанф. Аттила белән Аэций бала чактан ук дуслар. Шуңа алар һуннар белән тату. Аннары, аларның империясенә ара ерак, ә безнең җирләр һуннарныкы белән чикләшә.

Феодосий. Кайчандыр дөнья-

ны уч төбендә тотып торган бөек Рим империясе шулай таркалыр дип Юлий Цезарьлар, Траяннар башларына да китермәгәннәрдер.

Хрисанф. Безгә монда Константинопольдә үзебезнең кайчандыр Римнән аерылган империя икәнебез турында түгел, киләчәкне уйларга кирәк.

Феодосий. Киләчәкне уйлый башласаң, күз алдына һуннар юлбашчысы Аттила килеп баса. *(Йөзе карангылана.)* Анардан ничек котылмак кирәк? Анардан котылмыйча нинди киләчәгебез булырга мөмкин? Тагын ана салым түләргә тиешбез—алтын белән, акчалата, мал белән. Ул әле тагын яна җирләр таләп итәчәк. *(Кызып.)* Теләкләре гел артып тора! Туймый! Һаман җитми!

Хрисанф *(пышылдап диярлек)*. Аны көн батышына яу белән барырга этәрергә иде.

Феодосий *(Хрисанфка карап тора)*. Син кайвакыт әллә нинди коточкыч сүзләр сөйләп ташлыйсың.

Хрисанф. Мин аптыраганнан гына әйтәм.

Феодосий *(урыныннан кузгала)*. Аптыраганнан... Куркыныч кеше син, Хрисанф. *(Хрисанф тирәли әйләнеп чыга.)* Император Феодосий Икенче үзенен камергеры Хрисанф манипуляциясе белән яши, бөтен эшләрне шул хәл итә, дигән имеш-мимешләр тикмәгә йөрми.

Хрисанф *(каушый)*. Бөек император...

Феодосий *(жикереп)*. Яп авызынны! Византия империясендә бөтен нәрсәне контрольдә тотасын, дип тикмәгә сөйләмиләр синен турыда. *(Паузадан сон.)* Дөресен әйткәндә, мин үзем дә синнән шүрли башладым.

*Хрисанф тезләнә.*

Феодосий *(кинәт йомшарып)*. Йә, йә, тор, Хрисанф. Син миңа тугры, мин беләм. *(Ике куллап камергерга торырга булыша.)* Көнбатыш Рим империясенә каршы котыртырга кирәк дисенме Аттиланы? Утыр әле, утыр. *(Хрисанфны көрсигә утырта. Үзе әрле-бирле йөри.)*

Хрисанф. Башка чарабыз юк.

Феодосий. Һуннарга каршы торырлыкмы сон алар? Ул җебек Валентиниан үзенең ана эткә әверелгән сенлесе Гонорияне дә җинә алмый бит әле. Янында Аэций булганга күрә генә исән әле ул үзе дә.

Хрисанф. Әйе, Аэций Римнең соңгы таянычы, актык өмете. Бигрәк тә, күптән түгел һуннар лагерына барып, Аттила белән яна килешү төзеп киткәч.

Феодосий. Аттиланын дөньяны яуларга омтылуын Аэций аңлыймы икән?

Хрисанф. Аңлыйдыр. Чөнки һуннарнын бөтен элитасы Аттиланы Аллага тин күрә башлады—бу бит әллә каян күренеп тора. Хәтта скириан кабиләләренен башлыгы Эдика да Аттиланы бердәнбер итеп күрәсе килә. Ә Эдика һуннар пехотасынын төп өлешен тәшкил итә.

Феодосий. Әй Хрисанф, һәркайда бер төрле үк кагыйдәләр—корольдән акчаны күбрәк алган саен, король шул кешегә яхшы булып күренә.

Хрисанф. Мин тикмәгә Эдиканы телгә алмадым. Беренчедән, ул Аттилага иң якын кешеләрнең берсе, икенчедән, ул һуннар кабиләсенә каны буенча бөтенләй якын түгел. Алтын өчен тугры булган кеше теләсә кайчан үзенен короленә хыянәт итә ала. Өченчедән, һуннар тарафыннан монда киләчәк делегациядә, һичшиксез, Эдика да булачак.

Феодосий. Мин сине аңладым. *(Пауза.)* Ләкин саклык белән генә, зинһар. Аттила—бүгенге көндә иң куркыныч кеше. Анын биләмәләре хәзер Һун дингезеннән алып Аквинкумга кадәр, Фракия җирләреннән төньяктагы дингезләргә кадәр сузылган. Ул хәзер безнең империягә каршы сугыш алып барыр хәлдә.

Хрисанф. Шуна күрә анын илчеләре тизрәк килсен иде. *(Чак кына ишетелерлек итеп.)* Аттиланы юк итү чарасын нәкъ менә хәзер табарга кирәк. Кара дингез буйларыннан акацирлар яный башлагач, Аттиланын хәле алай ук яхшылардан түгел, минемчә.

Феодосий *(көлемсерәп)*. Валентиниан ни дип яза бит—үзе Аттилага бирешмәскә өнди, үзе шундук ана каты бәрелмәскә тырышыгыз, ди.

Хрисанф. Аттила дигән исемне инде һәммәбез йоклаганда да хәтердә тотадыр.

Феодосий *(өстәл янына барып утыра, хатка күз ташлый)*. Валентиниан үзенең хатында нииндидер кам турында әйткән. Имеш, бездә Итил елгасы буеннан килгән кам яши. Шуны үзенен

янына җибәрүебезне сораган.

Х р и с а н ф *(авызын кыйшайтып).* Башкалалары Римнән Равеннага күчкәннән соң алар варварларның да әллә нинди шаманнары, камнары, им-томчылары белән ныклап торып мавыга башладылар. Мондый сугышлар, буталышлар шаукымында әллә ниләргә, әллә кемнәргә ышана башларсың.

Ф е о д о с и й. Нинди кам соң ул?

Х р и с а н ф. Димәк, син оныткансың, император. Күптән түгел һуннар Фракиягә бәреп кергәч, Константинопольгә таба качкыннар агылды. Шулар арасында Фракия җирләрендә дан казанган бер кам барлыгы ишетелде. Минем күзәтчеләрем аны табып монда алып килделәр. Аның исеме дә Атакам.

Ф е о д о с и й. Нәрсә белән дан казанган соң ул Итилдән Фракиягә кадәр килеп?

Х р и с а н ф. Күрәзәлек белән, кешеләрне дәвалап. Күк белән элемтәгә керә ала ди.

Ф е о д о с и й. Кайда соң ул хәзер?

Х р и с а н ф. Мин аны алыпсатарларның бер йортына урнаштырдым. Сакчылар куйдым. Ул үзе генә түгел иде. Аның белән бер бургунд кызы бар. Ул каты чирләгән, Кам аны гел дәвалап тора. Хәзер әкренләп аякка баса инде. Алар Фракиядән бергә качканнар.

Ф е о д о с и й. Валентинианга ук барып җиткән микәнни ул камның даны?

Х р и с а н ф. Күптән түгел, Аэцийның кешеләре килгәч, Атакамнан Рим империясенең киләчәге турында сораштылар. Империягез таркалачак, диде аларга Атакам. Сараегыздагы бер хатын-кыз илегезне җимерергә тиздән кискен адым ясаячак, дип өстәде. Шуны Равеннага кайтып әйткәннәрдер.

Ф е о д о с и й *(ачуланып).* Нишләп моны мин әле яңа гына ишетәм, Хрисанф!

Х р и с а н ф *(тыныч кына).* Күрәзәлеккә ышанмавынны белгәнгә күрә.

Ф е о д о с и й. Мондый вакытта әллә ниләргә ышана башларсың. *(Тыныч.)* Мин ишеткән идем бу хакта. Шулай да бу фактны синең миңа әйтмәвең начар. Чыннан да әллә кемнәргә, әллә ниләргә ышана башларсың. Бу Аттила элек ышанмаган нәрсәләргә дә табындыра хәзер. Атакам белән Аэцийның кешеләре Вигил ярдәмендә аралашканнар. Хәзер монда Вигил керә. Минем сезнең икегез белән берьюлы киңәшләшәсем килә. Вигил турында хәзерге вакытта нәрсә әйтә аласың?

Х р и с а н ф. Вигилны сез үзегез миңа караганда яхшырак беләсездер. Ул сезгә күптән хезмәт итә.

Ф е о д о с и й. Мин аны телләр белүче тылмач буларак кына яхшы беләм. Зур талант иясе, тылмач кына түгел, шул тылмачлык белән политикада яхшы йөзүен чамалыйм. Тик мине аның эчендә ни барлыгы кызыксындыра.

Х р и с а н ф. Вигил акча ярата. Комсыз, ләкин, дөрес әйттегез, талантлы, зирәк акыллы. Шул комсызлык телләр өйрәткән, хәйләкәрләткән аны.

Ф е о д о с и й. Аттиланың илчеләре килгәч, Вигил, тәрҗемәче буларак, зур роль уйнаячак, шуңа күрә... *(Аяк тавышлары ишетелгәч сүзен әйтеп бетерми, туктап кала.)*

*Вигил керә. Бераз бөгелебрәк тора. Чыраенда ялагай елмаю чагыла.*

Ф е о д о с и й. Кер, Вигил. Итилдән адашып монда килгән кам белән сез дуслар дип ишеттем?

В и г и л *(Феодосий белән Хрисанф арасында басып тора, әле берсенә, әле икенчесенә карый).* Мине аның янына тылмач итеп алып бардылар, ләкин ул кам үзе латинча шәп сиптерә. Латинча гына түгел, күп телдә сөйләшә ул.

Ф е о д о с и й. Нинди кеше ул?

В и г и л *(чырае тартылыбрак китә).* Ул миңа коточкыч тәэсир ясады.

Ф е о д о с и й *(чәнчүле итеп).* Телләрне синә караганда да күбрәк белгәнгәме әллә?

В и г и л. Аннан түгел...

Ф е о д о с и й. Ул Аттиланы эзләп килгән, имеш...

В и г и л. Әйе.

Ф е о д о с и й. Ник икән?

В и г и л. Белмим, тик... чамалыйм. Аттилага булдыра алган кадәре ярдәм итәр өчен бугай.

Х р и с а н ф. Аны үзебезнең якка аударып, Аттилага каршы файдаланып булмас микән?

В и г и л *(кистереп).* Юк!

Х р и с а н ф. Акчага, алтынга, малга сатылмаган кеше сирәк.

В и г и л. Мин соңрак аңлатырмын аның кем... дөресрәге, нәрсә икәнен...

Әлегә мин икеләнебрәк торам.

**Феодосий**. Валентиниан Атакамны үзе янына Равеннага җибәрүемне үтенгән.

**Вигил** *(ялварулы тавыш белән)*. Император! Кичектермичә җибәр, берүк тизрәк озат аны!

**Феодосий** *(сагаеп)*. Син бик сизгер, уяу кеше. Синең болай ачыргаланып Атакамны озатырга өндәвең сәер.

**Вигил**. Тиздән Аттиланың илчеләре килеп җитәчәк. Алар Атакам белән кызыксыначаклар. Аттила аларга Атакамны үзенә алып кайтырга кушкан дип беләм.

**Феодосий** *(гаҗәпләнеп)*. Әйе, күп күрәсең, күп беләсең син, Вигил.

**Хрисанф**. Вигил дөрес әйтә. Сиңа ачасы бер серемне әле генә Вигил ачып салды—Атакам турында Аттила да кызыксынган. Фракияне айкап йөргәндә аңа Итил буеннан килгән кам яшәве хакында, аның акылы, сәләте турында сөйләгәннәр. Һуннар тарафыннан кайткан кешеләребез ишеткән.

**Феодосий**. Нишләп моны әле яңа гына ишетәм мин, Хрисанф?!

**Хрисанф** *(тыныч)*. Сине—христиан диненә йөз тоткан императорны—камнар, шаманнар кызыксындырмагач, хәбәр итеп тормадым. *(Паузадан соң.)* Әле төп яңалыкны әйтмәдем. Аттилага Марс Кылычы күктән бирелгән дигән сүзне һуннарга шул Атакам хәбәр иткән.

**Феодосий** *(өстәл яныннан торып китә)*. Бөтенләй үтерден мине!

**Хрисанф** *(ялагайлык белән)*. Барлык яңалыкларны җиткереп торсак, башың ярылыр иде.

**Феодосий** *(камергер каршына килеп баса)*. Минем ул камны күрәсем килә!

*Сәхнә караңгылана. Сәхнә яктырганда Феодосий каршында Атакам басып тора.*

**Феодосий** *(көрсидә киерелеп утыра)*. Син кем?

**Атакам**. Кам.

**Феодосий**. Кайдан килден?

**Атакам**. Бик ерактан. Итил буеннан.

**Феодосий**. Латинча сөйләшергә кайда өйрәндең?

**Атакам**. Фракиядә яшәгәндә.

**Феодосий**. Фракиягә ник килдең?

**Атакам**. Дөньяны тетрәтүче һуннар юлбашчысы Аттиланы эзләп табар өчен.

**Феодосий**. Ник эзлисең аны? Аңардан ничек качып, ничек котылырга белмиләр, ә син аны эзләп йөрисең.

**Атакам**. Бүген барысы да Аттиланы эзлиләр. Аңардан ничек котылырга белмәүчеләр дә гел аны уйлыйлар. Кая гына барсам да: «Кайда син, Аттила?»—дип кычкырган тавышлар ишетәм. Аны яратучылар аңа якынаер өчен шулай дип кычкыралар. Аны күралмаучылар курыкканга шулай кычкыралар.

**Феодосий**. Син нинди ырудан?

**Атакам**. Мин кояш чыккан яктан килеп дөньяны тетрәткән ырудан.

**Феодосий**. Син һунга охшагансың. Итилдә дә һуннар калган дип ишеткән идем.

**Атакам**. Итил буендагы ыруларда да шул ук кан ага.

**Феодосий**. Һунча сөйләшәсеңме?

**Атакам**. Аттила телендәме? Сөйләшәм. Безнең телләрнең тамыры бер үк.

**Феодосий**. Синең турыда Аттила белә, диләр.

**Атакам**. Беләдер.

**Феодосий**. Сине эзләп табарга кушкан ди ул.

**Атакам** *(таләпчән тавыш белән)*. Җибәрегез мине аның янына!

**Феодосий**. Син Аттилага нинди ярдәм күрсәтергә телисең?

**Атакам**. Мин аның кире борылып бабалары үткән юлдан көн чыгышына кайтуын телим.

**Феодосий** *(елмаеп)*. О-о-о, мондый теләгең өчен Аттила сине казыкка утыртачак. Син кемне алдамакчы буласың? Моннан һуннар ягына ычкыныр өчен генә шулай дисең син. *(Ачу белән.)* Марс Кылычын Күк Аттилага билгеләгән дип һуннарны җилкендерүче син бит.

**Атакам** *(тыныч кына)*. Тәңре Кылычы турында әйтәсеңме? Әйе, Тәңре Кылычы Аттиланыкы. Шул кылычны ул көн чыгышына кайтып кулланасын иде.

**Феодосий** *(торып, камга якынрак килә)*. Ай-яй хәйләкәр син. Тәңре Кылычы үзенә тиеш дип ышанган Аттила Итил буена кайтып китәр дип уйлыйсыңмы? *(Беравык камга карап торганнан соң.)* Син ничек белдең, ничек

күрден Тәңре Кылычының Аттилага иңдерелүен?

Атакам. Мин бер үк төшне инде күп тапкырлар күрдем. Аттиланың даны Итил буйларына кадәр ишетелгәч үк керде ул миңа. Имеш, Аттила биләмәсендәге бер көтүче аксап йөрүче бозауны абайлап ала. Бозауның аякларын җентекләп караганнан соң да, көтүче яраның сәбәбенә төшенми. Шуннан көтүче бозауның канлы эзе буенча бара да, үлән арасында яткан кылычны таба. Бозау шул кылычка басып аягын җәрәхәтләгән булган. Көтүче кылычны кулына ала. Нишләргә белми. «Аттилага илтеп тапшыр»,—дигән авазны каяндыр җил алып килә. Мин шушында гел уяна идем. Чынлап ат Аттилага Тәңре Кылычы язган икән.

Феодосий. Византия империясе турында төш күргәнең юкмы?

Атакам. Юк. Ләкин аның киләчәген күрәм. Көн батышындагы Рим империясе таркалгач та, Византия империясе әле мең ел торачак. Көн чыгышыннан тагын давыл килгәнчегә кадәр.

Феодосий. Алай начарга юрамадың шикелле илемнең язмышын. *(Әкрен генә.)* Ә минем киләчәгемне күрәсеңме?

Атакам *(императорга туры карап)*. Киләсе елда син аттан егылып төшеп үләчәксең.

Феодосий *(эчке сискәнү тоя, камнан читкәрәк китә)*. Вакыт инде бик соң, бар, ял ит. Иртәгә мин сине чакыртырмын. *(Урынына барып утыра, уйга кала.)*

*Атакам чыгып китә. Караңгылыктан тып-тын гына Хрисанф пәйда була.*

Феодосий *(сискәнеп китә)*. Ә, Хрисанф. *(Тынгысыз.)* Син аңа ышанасыңмы?

Хрисанф. Мине Аттилага тапшырылган Марс Кылычы да, Атакамның һуннарга ярдәм итү-итмәве дә кызыксындырмый хәзер. Мине бу камның күрәзәчелеге куркыта.

Феодосий *(катгый итеп)*. Мин хәзер төгәл әйтә алам: Атакамны кичекмәстән Византия җиреннән Көнбатыш Рим иленә, Равеннаның үзенә озатырга кирәк.

## II

449 ел. Яз ае. Византия императоры Феодосий II Аттиланың илчеләрен кабул итә. Кабул итү Бөек Сарайның (Мега Палатион) колонналы залында бара.

Феодосий *(коры тавыш белән)*. Сез—Көнчыгыш Рим империясенә Аттиланың сүзләрен җиткерергә килгән илчеләр. Сезгә шуны әйтәсем килә... Аттиланың яңа сугыш юлына басканына ике ел вакыт узды. Аттила ясакны да азсынды, безнең ачык йөзебезне дә яратмады. Без һуннарның азгынлыгына түзеп киләбез. Безнең хәрәкәтне богаулар өчен, Аттила Дунайның бу ягына чыкты, елга флотыбызны үз кулына алды. Үзенең империясен киңәйтер өчен шәһәрләребезгә бәреп керде.

Орест. Шуны онытма, император, Аттила үз ыруларының сүзеннән чыкмый. Аттила сугыш юлына басты дип әйтү дөрес булмас. Һуннар яуга кузгалды. Һуннар теләге—Аттила өчен барысыннан да өстен.

Феодосий *(кызып)*. Без бит инде Аттила куйган шартларга таянып килешү төзедек. Әйе, сугышны туктатуны без үтендек. Аттила кушканча, качкыннарын кире аңа тапшырдык, үзебезнең тоткыннарны коткарыр өчен алтын белән түләдек. Салымны беркайчан бу кадәре беркемгә түләгәнебез юк иде. Мин, Феодосий Икенче, оялмыйча әйтәм: мине Аттила нык талады. Константинопольнең казнасы чиксез тирән дип уйлыйсызмы әллә! Аттила таләп иткән ясакны күтәрү мөмкин түгел. Чама кирәк.

Эдика *(кырыс)*. Аңлыйбыз. Сез исә шуны аңлагыз: бүгенге Аттила инде кичәге Аттила түгел. Аның тагы да күбрәккә кул сузарга мөмкинлеге бар. Ул хәзер император. Һуннар гына түгел, барлык варварлар аны үзләренең императоры итеп таныды. Дунайның бу ягындагы җирләр инде Аттиланыкы. Анда хәзер сезнең чирүләр юк. Балкан аша сезнең Константинопольгә юл ачыктан-ачык.

Хрисанф *(ямьсез тавыш белән)*. Константинополь сезгә ник кирәк? Ел

саен уздырылучы ярминкә инде Дунай ярларыннан монда таба Наис каласына күчте... Инде...

Орест *(чыраен сытып, Хрисанфның сүзен бүлә)*. Син күзенне ачыбрак кара! Фракия тулаем Аттилага буйсына. Аттила бик атаклы. Аның куәте коточкыч зур. Ул император!

Хрисанф. Кыргыйлар императоры үзенә күпме кирәкне алдан ук санап әйтә алмый микәнни? Көн саен теләкләре арта, үзгәрә.

Орест *(нәфрәтләнеп)*. Һуннарның илбашы Аттиланы кыргыйлар императоры дип атадың.

Феодосий *(елмаеп)*. Аттила биләмәсендә кыргыйлар да шактый, шуңа гына әйтте ул алай дип.

Эдика *(кычкырып)*. Аттила император! Иң көчле император!

Хрисанф *(чәрелдәп кычкыра)*. Феодосий иң олы император!

Феодосий *(кулын селти, ясалма көлү белән)*. Юк-бар бәхәс корып торырга без кыргыйлар түгел. *(Торып сарай буйлап атлый.)* Эчемлекләрне авыз итегез! Бөек сараебызда рәхәтләнеп ял итегез!

*Шуны гына көтеп торган хезмәтчеләр эчемлекләр китерәләр. Кунаклар кулларына тустаганнар тотып сарай буйлап атлыйлар.*

Феодосий *(Эдика янына якынаеп)*. Ялгышмасам, син—Эдика—скирианнар ыруының элекке башлыгы.

Эдика *(Феодосий каршысына атлый)*. Хәзер мин Аттиланың аркадашы.

Феодосий *(кызыл аракы йотып куя)*. Әйе, хәзер син Аттиланың иң якын кешеләренең берсе. Яу кырларында үзеңне батыр итеп күрсәтмәсән, сине Аттила болай ук яратмас иде.

Эдика. Аттила аркадашларын гына түгел, дошманнарын да бәяли, ярата торган император. *(Шәрабын авыз итеп куя.)*

Феодосий. Һем...император... Синең кебек тугрыларга чын император тагы да яхшырак карарга тиеш түгелме?

Эдика *(әңгәмәне ошатмый)*. Без монда Аттила турында кырын сүз сөйләшергә дип килмәдек.

Феодосий. Беләм, беләм. *(Орест янына килә.)* Син Орест бугай.

Орест. Әйе, мин Орест. *(Хезмәтчегә таба тустаганын суза, ана кызыл аракы салалар.)*

Феодосий. Ялгышмасам, бу делегациядә син икенче кеше. Син римле. Син бай, затлы кеше. Аттилага хезмәт итүеңне аңлый алмыйм.

Орест. Мин Дунайның бу ягындагы җирләр хуҗасы. Хәзер минем җирләр Аттила биләмәсенә керә.

Феодосий *(Эдика ишетелерлек итеп әйтә)*. Эдика Аттила өчен кан койган ир. Яуларда канын койган кеше белән бер үк санда булу ул ничек?

Орест *(үпкәләп)*. Бу инде Аттиладан тора. Без һуннар императорының илчеләре. Шуңа күрә чамалабрак...

Феодосий *(Орестка әйтеп бетерергә бирми)*. Бигрәк үпкәчел кешеләрне җибәргән мина Аттила, шулаймы, Эдика?

Эдика. Орестның җирләрен йә готлар ала, йә һуннар, аның җирләре әле Константинопольгә керә, әле Римнең үзенә. *(Көлемсерәп.)* Ул инде кемгә үпкәләргә дә белми.

Орест *(тустаганын хезмәтчегә бирә)*. Син минем турыда чеметтереп сөйләшәсең, Эдика. Мин Аттилага кайткач әйтәчәкмен.

Феодосий. Карагыз әле, бер делегациядә килеп, үзара талашалар. *(Көлә.)*

Орест. Дунайның бу ягындагы җирләрем сезнең илегез белән чикләшкәнгә күрә Аттила мине монда җибәрде.

Феодосий. Чикләшкәнгә? *(Күзләрен челәйтеп.)* Синең җирләрең ул инде хәзер чынлап торып безнең Византия территориясе түгелмени?

Орест. Император, син әле һаман чынбарлыкка ышанмыйсыңмыни?

Феодосий *(киеренкелек белән)*. Җимерелеп, буталып, чуалып бетте барысы да. Дөнья әллә нишләде. Рим империясе икегә бүленде. Хәзер Көнбатыш Рим империясе мескен хәлдә, ә Константинополь исән. Күпме илләр таркалды, затлы сарайлар җимерелде кыргый варварлар тарафыннан. Ә бу Мега Палатион—Византиянең Бөек сарае исән. Аттила бу хакта ни уйлый икән? *(Кулын өскә күтәреп.)* Алла үзе безне саклый, мине саклый.

Орест. Аттила башкачарак уйлый. Аттиланы Тәңре үзе саклый. Илегезнең

исән булуы өчен Аттилага баш иярргә тиешсез. Көн батышындагы Рим иленең әле дә сулыш алып ятуы да Аттиланың олы йөрәкле булуы билгесе.

Феодосий *(жикереп).* Син гади илче, болай ук кискен сөйләшергә тиеш түгелсең.

Орест *(һич кенә дә курыкмый).* Мин Аттиланың илчесе, шуңа шулай сөйләшәм.

Феодосий *(коры гына).* Аттила тарафыннан язылган хатны мин яңадан җентекләп укырмын, һәрбер сорауга җавап табарга тырышырбыз.

Орест. Дунай буендагы җирләр хакында сүз чыккач инде, шуны да әйтәсем килә: һуннар биләмәсенә кергән яңа җирләрдән бик күп җир эшкәртүчеләр сезнең якка таба кача. Аларны үзегезгә сыендыруны туктатып, Аттила лагерына тапшырырга тиешсез. Бу турыда хатта каты әйтелгәндер дип ышанам.

Эдика. Аннары, хатта әйтелгәндер, сез Аттила янына иң югары илче-магистратлардан торган делегация җибәрергә тиешсез.

Феодосий *(кырыс тавыш белән).* Тыныч ял телим сезгә.

*Феодосий, үзенең яраннарын ияртеп, җил-җил атлап китеп бара. Илчеләрнең кайберләре эчемлекләрдән исерәләр. Илчеләр йоклар алдыннан сарай ишегалдында йөрергә дип чыгып китәләр. Хрисанф үзенең бүлмәләре янында Эдиканы тоткарлый һәм, ым кагып, Вигилне дә калдыра.*

Хрисанф *(Вигил ягына ымлап).* Эдика, син Вигил белән танышмы?

Эдика. Ишеткәнем генә бар. Күп телләр белүче оста тылмач диләр.

Хрисанф. Вигил турында купшырак та әйтергә мөмкин. Безнең әңгәмәбезнең кайбер өлешендә аның ярдәме кирәк булыр. *(Кул ишарәсе белән.)* Эдика, сиңа бу бөек сарайның минем өлеше бигрәк тә ошады, шулаймы?

Эдика *(як-ягына каранып).* Искиткеч сарай. Бөек сарай. Сезләрне, византлыларны шушындый зур байлыклары белән котлыйм.

Хрисанф. Затлы кеше генә чын байлыкны, затлылыкны аңлый ала. Син, Эдика, һичшиксез, шундыйларның берсе.

Эдика *(кәефе күтәрелә).* Башка кешенең затлылыгын да үзе затлы булган кеше генә аңлый аладыр. Син, Хрисанф, нечкә күңелле, үткен күзле, кешеләрне яхшы аңлаучы затлы кеше. Византия синең кебек кешеләре белән һәм шул кешеләр тоткан затлы сарайлары белән горурланырга тиеш.

Хрисанф *(ягымлы).* Син, Эдика, безнең культураның асылын, кыйммәтен дөрес бәялисең. Син кыргыйлар ягында булырга тиеш түгелсең.

Эдика *(сагаеп).* Аңламадым?

Вигил. Хрисанфның тел төбендә башка мәгънә ята. Ул туп-туры әйтергә кыенсынды. Әгәр дә Византиягә хезмәт итсәң, син дә зур байлыкка ирешәчәксең, синең дә алтын түшәмле бүлмәләрең булачак.

Эдика. Сез үз акылыгыздамы?

Хрисанф *(пышылдап).* Син күбрәккә лаеклы. Барыбер сине Аттила тиешенчә бәяләми.

Эдика *(борчулы).* Сез минем авырткан җиремә басасыз. Аттиладан котылу мөмкин түгел. Аңа хезмәт итеп кенә исән булырга мөмкин.

Хрисанф. Нишләп аңардан котылу мөмкин түгел?..

Эдика. Качкан кешене ул барыбер тота. *(Хрисанфка текәлеп карый.)* Тиздән ул сезнең дә хуҗагыз булачак.

Вигил. Без—Византия. Безне христиан дине саклаячак!

Эдика. Барыбер Аттиладан башка бернишли алмыйсыз. Ул еракларак китсә дә, сез торымнан торымга: «Кайда син, Аттила?!»—дип кычкырачаксыз. Чөнки күздән югалса да, аның кайдадыр барлыгы котыгызны алып торачак.

Хрисанф *(күзләрен чекрәйтеп).* Синең күзләреңдә курку, Эдика. Аттиладан котылу мөмкин түгел дигән уй куркыта сине. Син Аттилага бик якын кеше. Бик якын булгач, ник куркасың соң алайса шулхәтле?

Эдика. Императорга нык якынаюның куркынычлыгын син, Хрисанф, аңламаган булып кыланасыңмы?

Хрисанф. Безнең император Феодосий кыргыйлар башлыгы Аттила түгел.

Эдика *(коры гына).* Әйе, сезнең император Аттила түгел.

Хрисанф. Якын кешесе буларак, син Аттила янына теләсә кайсы вакытта керә аласың, шулаймы?

Эдика. Әйе, мин хәтта Аттиланың

сакчылары, ясаулларына житәкчелек итәм.

Хрисанф. Берүзеңме?

Эдика. Без берничә кеше.

Хрисанф *(кулларын угалап)*. Әйдәгез, кичке ашны өчебез бергәләп ашыйк.

*Хрисанф кул ишарәсе белән хезмәтчеләргә дәшә. Шундук өстәлгә яңа эчемлекләр, ит тутырылган савытлар, җиләк-җимешле кәрҗиннәр китерәләр. Хрисанф, Вигил, Эдика өстәл янына урнашалар. Эчәләр. Пауза. Бер-берсенә карап утыралар.*

Хрисанф *(алгарак иелеп)*. Аттиланы үтергәннән соң, Константинопольгә кире киләсең. Сине монда бай, бәхетле тормыш көтәчәк.

Эдика *(басынкы тавыш белән)*. Минем үземә турыдан-туры буйсынучы сакчыларны сатып алырга акча кирәк булачак... Бик күп түгел—илле фунт алтын.

Вигил *(күзләрен акайтып)*. Бу бит өч мең алты йөз солид! Акчалата өч мең алты йөз!

Эдика. Әйе, шул сумма җитәчәк.

Хрисанф. Бик күп булмасмы соң?

Эдика. Ә үзеңнең яшәвеңне куркыныч астына куюу арзан бәяләнергә тиешмени?

Хрисанф. Ансы да дөрес.

Эдика *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Кайтып Аттила каршында илчелек турында җавап тотканда Орест та шунда булачак. Аттиланың һәрбер илчедән кем кемгә нинди бүләк биргәнен төпченә торган гадәте бар. Ул һәрберебездән сораячак. Илле фунт алтынны мин яшерә алмаячакмын.

Хрисанф. Бер серне ачыйм әле: Вигил сезнең белән барачак—Аттилага император җавабын Вигил җиткерәчәк.

Эдика. Юк, Вигил оста, ышанычлы кешегез булса да, җавапны зуррак урында утыручы магистрат алып барырга тиеш—Аттила шулай кушты.

Хрисанф. Ярар. Мин император белән сөйләшермен, һуннар белән сөйләшергә императорның таянычлы кешесе, аксөяк Максимин барыр. Ә син, Вигил, Эдика карамагына күчәсең.

Вигил *(карангыланып)*. Син миңа...

Хрисанф *(Вигилнең сүзен бүлә)*. Үпкәләмә, Вигил. Бу эшебез барып чыкса, алтынга күмеләчәкбез.

Эдика. Әйткәнемчә, илле фунт алтынны без яшерә алмаячакбыз. Делегациябездә бик сизгер кешеләр. Чак кына шик төшсә дә, Аттила башыбызны чабып этләргә ташлаячак. Болай итәрбез: килешү төзер алдыннан кайбер сораулар буенча киңәш кирәк дигән сылтау белән, Вигил Константинопольгә кире кайтыр. Кайткач, Аттиланы үтерер өчен билгеләнгән алтынны ничек һуннар лагерына алып килергә икәнне Вигил аңлатыр.

Хрисанф. Миңа бу уең ошады. Шулай итәрбез.

Вигил *(үпкәле)*. Мине Максиминнан түбәнрәк кеше дип саныйсыңмыни?

Хрисанф. Юк, Вигил, алай түгел. Шунсы да бар бит әле. Аттиланы үтергәннән соң, һуннар илендә императорыбызның зур магистраты калырга тиеш.

## III

450 ел. Көнбатыш Рим империясе. Равенна. Гонорияның сарае. Гонория озын балконда тирән сагышка бирелеп ары-бире йөри. Рим императоры Валентиниан керә.

Валентиниан *(йомшак тавыш белән)*. Хәлләрең ничек, Гонория?

Гонория *(башын читкә бора)*. Рим императоры булганыңа күрә генә җавап бирәм. Әйбәт.

Валентиниан. Ә император булмасам, миңа—бертуган абыеңа сүз дәшмәс идеңме?

Гонория. Мәңге сөйләшмәс идем. Син император исемен йөртәсең йөртүен, тик тирә-якка йогынтың гына юк. *(Абыйсына таба кинәт борылып.)* Синең аркада ыруыбызның затлы исеме—императорлар нәселе дигән исеме үз бәясен җуйды. Ә бит без Галла Пласидия белән Бөек Феодосий балалары.

Валентиниан *(тавышы калтырый).* Әйе, без аларның балалары. Мин моның белән нык горурланам. Сиңа нәрсә житми һаман? Син бала чактан ук рәхәттә яшәдең, сине миңа караганда өстенрәк күрделәр, ныграк яраттылар. Сиңа Августа дигән титул бирелде. Император сараенда үз резиденцияң бар...

Гонория *(кырт кисеп).* Боларга мин лаек түгелме?

Валентиниан *(тыныч булырга тырышып).* Лаек. Теләкләрнең чамасы булырга тиеш. Син миңа әле генә зур яра ясадың. Минем аркада ыруыбызның исеме төште, диден. Минем урында башка берәү булса, сине асып куярлар иде. *(Кайнарланып.)* Син—императорлар нәселенә тап төшерүче. Син! Син үзеннең мажордомың Евгений белән, шул пычрак сөяркәң белән миңа каршы фетнә оештырмакчы булдың! Мин сине кызгандым!

Гонория *(жикереп).* Ә Евгенийны үтерден!

Валентиниан. Аны хөкем иттеләр. Сине Константинопольгә олактырып чикләндем. Менә, хәзер монда кире кайттың. Бөтен малың кире кайтарылды. Ни житми сиңа?

Гонория *(авыз чите белән).* Син миңа тияргә куркасың. Анам исән чагында син миңа кагылмыйсың.

Валентиниан. Син анабызга охшагансың—амбицияле. Тик менә анабыз чама дигән нәрсәне белә, ә сиңа күп кирәк, сиңа император урыны кирәк.

Гонория. Әйе, дөрес әйттең! Чөнки минем империяне тотарлык куәтем дә, белемем дә, сәләтем дә бар. Ә син... Мин бит беләм ник минем яныма кергәненне.

Валентиниан *(тыныч).* Сенлемнең хәлен беләсем килде.

Гонория. Һи, үзенә каршы баш күтәргән сеңлеңнең хәлен беләсең килдеме?

Валентиниан. Мин сиңа яхшы ир тәкъдим итмәкче идем. Бер бай консулны.

Гонория *(кычкырып).* Кирәк түгел миңа бернинди консул!

Валентиниан. Исемен дә ишетәсең килмиме?

Гонория. Килми! Син минем яныма аптырагannan керден. Илдә сине санга сукмыйлар. Синең йомшак, томана, булдыксыз икәнене белмәүче калды микән!

Валентиниан. Көл миннән, әйдә, көл.

Гонория. Синең кызларга түгел, нечкә билле малайларга гыйшык тотуыңны да беләләр. Нәрсә житми, дисеңме? Империягә император житми!

Валентиниан *(тыныч булырга тырышып).* Империя хакында син уйларга тиеш түгел. Сине тагын берәр якка жибәрергә кирәк түгел микән? Сиңа бу Равенна тирәсендәге сазлыкларның һавасы начар йогынты ясый, ахрысы.

Гонория *(тирән сулап куя).* Мин беркая да китмим. Хәзер үк анам янына керәм.

Валентиниан. Ул авырып тора, борчып йөрмә. Империябезгә император житми дисеңме... Ә бүген кайсы илдә чын император бар? *(Мыскыллы елмаеп.)* Константинопольдә калтыранып утыручы Феодосий Икенчеме чын император?

Гонория. Рим империясенең чикләре артында иң кодрәтле, иң атаклы чын император бар. Тиздән ул вестготлар илен алырга жыена.

Валентиниан. Кем ул андый император?

Гонория. Һуннар башлыгы Аттила!

Валентиниан *(көлә).* О-о-о, пычрак, әшәке, хайваннарга тиң кыргыйларның атасын син дә император дип атыйсыңмы?

Гонория. Синең аның белән яу кырында да, аш табынында да очрашканың юк, ничек алай әйтә аласың?

Валентиниан. Мин кыргыйларның эшләгән явызлыкларын, алардан соң калган хәрабәләрне күргәнем бар. Аттиланың планнары хакында кемнән ишеттең?

Гонория. Аэций әйтте.

Валентиниан. Ярый. *(Пауза. Валентиниан китә башлый.)* Консулга чыгасыңмы?

Гонория *(тыныч кына).* Юк, миңа әлегә ир кирәкми. Барысын да... Барыгызны да күралмыйм. Син тәкъдим итәргә жыенган консулны да.

*Валентиниан кызу-кызу атлап чыгып китә. Гонория кычкырып елап жибәрә. Аның елавында ачу һәм нәфрәт яңгы-*

*рый. Кинәт елаудан туктый.*

*Аэций керә.*

Гонория *(тиз генә күз яшьләрен сөртә, чәчен төзәткәли).* Аэций! Мин сине күрүемә шат. Уз тизрәк, уз әйдә.

Аэций *(елмаеп).* Мин дә сине күрүемә шат, Гонория.

Гонория. Бу тинтәкләр арасыннан сине генә күрәсем килә.

Аэций. Арттырма инде, Гонория. Олы кешеләр күп империядә.

Гонория *(көлемсерәп).* Империя?! Әле генә император белән империя турында сөйләштек.

Аэций *(балконнан аска карап).* Нишләп Аттиланың планнары турында сина мин әйтте дип ялганладың?

Гонория *(бер дә югалып калмый).* Әйттем инде шунда. Көчле императорлардан үрнәк алсын иде ул. Ичмаса синнән дә бернәрсәгә өйрәнми бит. Син безнең иң көчле кешебез, Аэций. Син булганга гына Рим империясе исән.

Аэций. Мин үземнең бурычымны гына үтим. Хәзер инде императорның булдыксызлыгы да, кайберәүләребезнең булдыклыгы да нинди йогынты ясый ала соң? Империянең черүендә император Валентиниан гаепле түгел.

Гонория. Ул император урынында утыра, ул император исемен йөртә.

Аэций. Бу буталчык вакытта римлеләрнең интегүе сугыш афәтеннән дә яманрак, анысы белән килешәм. Империя таркалуының төп сәбәбе үзебездә, эчтә. Дошманнар исә шуннан файдаланалар.

Гонория. Йә, төп сәбәпне әйт әле.

Аэций *(кызып).* Илдә—уйнашлык, азгынлык. Тормышта да, политикада да. Законнарны кемдер үти, кемдер юк. Закон кем өчендер бар, кем өчендер юк. Закон бозучы бай, хәлле, яки зур урында утыручы булса, ул җаваплылыктан котыла. Җавапка исә ярлылар, прокурорларны сатып ала алмаучылар гына тартыла.

Гонория. Безнең законнар начар түгел. Гуманлыкка таянып салынган законнар бездә. Колларга да ирек алырга күп мөмкинлекләр бар.

Аэций *(ачырганланып).* Законнар әйбәт, ил төзелеше дә дөрес шикелле. Тик ил җитәкчеләре боза барысын да. Алар борынгылар тоткан кануннарга төкерәләр. Монарчы яшәгән тотрыклы культурабызны югалтып барабыз, моны күреп елыйбыз, ә кабихләр аның калдыкларын сатып ашап-эчеп бетереп киләләр. Илнең һәр катламында—бозыклык.

Гонория. Көчле император булмаганлыктан бит бу, Аэций!

Аэций. Магистратлар җингән илдә кемне император итсән дә тәртип булмаячак!

Гонория. Үзебезнең Рим магистратларын куралмаганга Аттила белән дуслыгынны югалтмыйсынмы әллә син?

Аэций *(елмаеп хәтирәләргә бирелә).* Без аның белән бала чактан ук танышлар, дуслар. Мине беркавым һуннар лагерында асрадылар, ә Аттиланы Римнең үзендә, император сараенда тоттылар. Без икебез дә бала чактан ук һуннар белән римлеләр арасындагы татулыкка өлеш керттек.

Гонория *(Аэцийнын беләгенә кагылып).* Нинди ул?

Аэций. Уртадан тәбәнәгрәк буйлы, кин җилкәле, кара чәчле, җәйпәк борынлы.

Гонория. Аның каршысында басып торучы һәрбер кеше калтырана ди, дөресме?

Аэций *(көлә).* Аның алдында гаебе булган кеше, әлбәттә, дер-дер килә. Аның кысык күзләре кыңгыр эш эшләгән кешене тишәр дәрәҗәгә җитә, анардан андый вакытта коточкыч көч бәреп тора.

Гонория. Ул бик данлы император хәзер, шулаймы?

Аэций. Ачуы килгәндә коточкыч җанвар, сугышта аяусыз батыр, шул ук вакытта үзенең кешеләренә якты күнелле ул. Һуннар аның сәләтенә, батырлыгына ышаналар, шуңа күрә дә Итилдән алып Рейнга кадәр барлык ырулар аңа буйсындылар. Бик күп римлеләр, греклар аның ягында хәзер, чөнки Рим түрәләренең цивилизацияләнгән комсызлыгыннан туйдылар. Безгә гөнаһларыбыз өчен җибәрелгән бу Аттила. Ходай безгә шундый афәт җибәргән.

Гонория *(Аэцийга текәлеп карый).* Аттила белән кызыксынуым сиңа сәер тоелмыймы?

Аэций. Аның белән барысы да кызыксына. Аны йә яраталар, йә куркалар

аңардан. Уртасы юк. Византия императоры Феодосий Икенче анын белән солых килешүе төзеде. Аттила аны түбән төшерде. Килешү төзесәләр дә, алар арасында дуслык булмаячак. Безгә исә Аттила белән тату булырга кирәк. Авыр чакларда Рим һуннарны ярдәмгә чакыра иде. Багаудларны да Аттила җибәргән чирү ярдәмендә генә җиндем мин—шуны да онытмаска кирәк.

Гонория *(кәефе күтәрелә).* Син Аттила турында гел яхшы сүзләр генә сөйлисең.

Аэций. Аның турында яман сүз сөйләргә сәбәп юк. Тик шунсы бар: ырулар юлбашчыга буйсына, шул ук вакытта юлбашчылар үз ыруларына котылгысыз буйсына. Илләр, ырулар тик торырга теләмәсәләр, гел ыргылып торсалар, юлбашчы шул дулкынга буйсынып әллә нинди адымнар ясый ала.

Гонория. Итил буеннан килеп олаккан Атакам турында беләсеңдер?

Аэций. Минем инде аны күргәнем дә бар.

Гонория. Ә Атакамның Аттиланы күргәне бар микән?

Аэций. Юктыр әле. Минемчә, аны Аттила янына җибәрергә кирәк. Аттила белән араларны бозарга ярамый. Камны һуннар императорына бүләк итеп тапшырырга кирәк.

Гонория. Син олы йөрәкле кеше, Аэций. *(Кинәт төсе үзгәрә.)* Шулай да сиңа бер соравым бар. Евгенийны син үтерергә куштыңмы?

Аэций *(туры карап).* Мин.

Гонория *(ияге дерелди).* Ул бит минем сөяркәм иде. Аны харап итеп, син мине дә яртылаш үтердең.

Аэций *(ачулы тавыш белән).* Син үзеңне үзең үтереп киләсең, Гонория. Евгений минем өчен иң элек императорга, империягә каршы баш күтәргән сатлыкҗан.

Гонория *(кинәт кызып).* Аны мин котырттым. Алайса, ник мине үтертмисең?

Аэций. Син императорның сеңлесе. Ә мин үземнең императорыма тугры кеше.

Гонория. Мин империяне саклап калырга телим. Минем абыемның хәленнән килми ул.

Аэций *(авыр сулап куя).* Сиңа акылга утырырга вакыт, Гонория.

Гонория *(балконнан еракка карап).* Син дә бер үк сүзләрне кабатлыйсың, Аэций. *(Кинәт борылып.)* Ничек уйлыйсың, ник болай бәхетсез мин?

Аэций. Гел бәхет турында уйлаганга!

Гонория *(көлеп җибәрә).* Синең җавапларың да, киңәшләрең дә үзең кебек дөрес, төгәл. Рәхмәт сиңа!

Аэций. Нәрсә өчен рәхмәт?

Гонория *(хәлсез тавыш белән).* Барысы өчен дә. Шушы хәлсез, ямьсез токымнар арасында барлыгың өчен рәхмәт. Синең кебекләр тота империяне.

*Аэций бер сүз әйтмичә чыгып китә. Гонория көлемсерәп тора.*

Гонория *(үзалдына).* Аттиладан син дә куркасың, Аэций. Син дә куркасың аңардан. Шуңа күрә аның белән мәңге дус булырга телисең син.

*Илиркә керә. Озын, калын чәчле. Башын ия.*

Гонория *(шатлана, шул ук вакытта үпкә белдерә).* Ильдико, мин сине күптән чакырттым, нишләп озак килми тордың?

Илиркә. Чәчемне югач бик озак кипмәде.

Гонория. Кил, утыр яныма.

*Илиркә Гонория янына килеп утыра.*

Гонория. Әйт әле, Ильдико, син һун кызы булгач, нишләп һуннар иленнән качып яшәдең?

Илиркә *(сагышлы тавыш белән).* Минем атам Байсан тархан Дунай буендагы җирләрнең хуҗасы иде. Аттила үзе бүләк иткән булган. Ә абыем Алмас Аттиланың яудашы, соңгы яуларда катнашкан меңбашы иде. Һуннардан качып, Дунайның аръягына чыгучыларны куып тотып үтерергә Аттила абыема куша. Абыем үзенең чирүе белән качкыннарны куып житә, әмма берсен дә үтерми, чөнки качучыларның каршы торырдай ирләре булмый, картлар, хатыннар, балалар гына була. Качкыннарны үтерергә кулым күтәрелмәде, дигәч, Аттила аңа: «Меңбашы булудан туктыйсың!»—ди. Аның белән генә чикләнми Аттила, атамның җирләрен тартып ала. Аның ачуы тагын да катыланыр дип куркып, бөтен нәселебез белән Дунайның аръягына—Панно-

ниягә качтык. Аннары башка качкыннар белән бергә Фракиягә киттек.

Гонория *(йотлыгып тыңлап утырганнан соң)*. Хәзер атан-анаң исәннәрме?

Илиркә. Алар Фракиядә калдылар. Мин Атакамга ияреп киттем. Атакам төшендә Аттилага Тәнре Кылычы индерелгәнне күргән. Аттилага шуны хәбәр итәргә дип абыем Алмас китте. Саклык турында да оныты, чөнки һуннар ил-көне өчен, Аттиланың үзе өчен борчылып, кайгырып яши торган кеше ул. Шуннан абыемның хәбәр-хәтере юк. Һуннар иленә барып аның язмышын беләсем килде. Шуңа күрә Атакамга ияреп киткән идем.

Гонория. Синең өчен Атакам кем ул?

Илиркә. Ул безнең ыруны чирдән коткаручы. Фракиягә һуннар бәреп кергәч, әле тегеннән, әле моннан качкыннар агылды. Төнлә йортыбызга бер юлчы керде—шушы Атакам. Ул бөтенләй хәлсез иде. Без аны тиз арада аякка бастырдык. Шул вакытта мин каты авырып киттем. Мин генә түгел, барыбыз да чирләдек. Атакам безне дәвалады.

Гонория. Безнең телдә сөйләшергә кайда өйрәнден?

Илиркә. Фракиядә качкын римлеләр белән бергә яшәдек, шулардан өйрәндем.

Гонория *(Илиркәнең битенә, чәченә бармаклары белән кагыла)*. Син бик күркәм. Чәчең таң калырлык. Кызганыч, минем чәчем синеке кебек матур түгел.

Илиркә *(оялып)*. Синең дә чәчең искиткеч купшы. Үзең дә бик чибәр.

Гонория. Чәчең тиз үсте синең. Нишләп монда килгәндә чәчең кыркылган иде?

Илиркә. Ирләр кызыкмасын өчен, чирле дип уйласыннар өчен, Атакам чәчемне гел кисеп торды. Һун кызы икәнемне дә яшерде. Ильдико дип исемемне үзгәртте. Мин бит Илиркә атлы.

Гонория. Сине монда кыерсытучы юкмы?

Илиркә. Юк.

Гонория. Күзләреңдә авыр сагыш...

Илиркә. Абыем исәнме-юкмы—белмим. Атам-анамны да бик сагынам.

Гонория. Теге көнне миңа жырлаган һун жырын жырлыйсыңмы?

Илиркә. Жырлыйм.

*Илиркә жырлый.*

Нинди хәбәр жылы сулыш өрде, дисен,
Нинди шатлык күнеленә инде, дисен.
Әйе, бүген бәгърем рәхәтләнеп жырлый,—
Дала жиле алып килде әрем исен.

Нинди газап күзләреңне томанлады,
Нинди кайгы болай сине басты, дисен.
Әйе, бәгърем тагын сулык-сулык жылый,—
Дала жиле алып килде әрем исен.

Дөньялыкта яшәр өчен алга таба
Далалардан бертуктамый жилләр иссен,
Жырларга да, рәхәтләнеп жыларга да
Миңа жилләр алып килсен әрем исен.

Гонория *(Илиркәне кочып)*. Тетрәндергеч жыр. Кызганыч, мин һунча аңламыйм, тик жырның ни турында икәнен төшендем бугай. Сез, һуннар, искиткеч батыр йөрәкле кешеләр, әллә кайсы яклардан чиксез далалар буйлап килеп чыккансыз бит Рим империясенең чикләренә. *(Читкәрәк китеп)*. Син мине чибәр диден. Ә мине Аттила ошатыр иде микән?

Илиркә *(аптырап)*. Белмим.

Гонория. Ә миңа Аттила ошар идеме, әгәр мин аның белән очрашсам?

Илиркә. Белмим. Августа Гонория, мондый уйлар сезгә ник кирәк?

Гонория. Болай гына. Мин мондый сорауларны монда беркемгә дә бирә алмыйм. Шуңа күрә синең белән киңәшләшәм. Синең аны якыннан күргәнен бармы?

Илиркә. Юк.

Гонория. Аның хатыннары бик күп диләр.

Илиркә. Әйе, шулай диләр.

Гонория. Хатыннары гүзәлләр микән?

Илиркә. Белмим. Аның хатыннары турында һуннар илендә сөйләшергә куркалар, атам белән абыемнын да ул турыда сүз катканнары юк. Эрекан исемле өлкән хатынын гына телгә алганнарын хәтерлим. Әмма чибәрме ул, юкмы—әйтмәннәре истә түгел.

Гонория *(киеренкелек белән)*. Эрекан, Эрекан. Яшь микән ул?

Илиркә *(көлеп жибәрә)*. Августа Гонория!

Гонория *(үзе дә елмаеп куя)*. Мин көлке хәлдә шул. *(Илиркә янына килә.)* Аттила янына барырга ничек курыкмыйча теләк белдерден?

Илиркә. Аттила сугышчы буларак явыз, әмма кеше буларак тыңлый белә, аңлый белә ди. Абыемны да кичерер дип ышанам.

Гонория. Шулайдыр да бит... Тик менә сезне монда китереп ташладылар шул. Моннан Аттила иленә бик ерак. Аны күрүгә ирешә алырсың микән?

Илиркә. Ирешермен дип ышанам. Атакам узган төнне төш күргән. Имеш, Аттила мине күтәреп яп-якты бүлмәгә кереп бара ди. Мин моны яхшыга юрадым—димәк, мин аның белән очрашачакмын, димәк, ул минем теләгемне кире какмас, абыемны азат итәр.

Гонория *(кинәт усаллана)*. Атакам шундый төш күргәнме? Аның төшләре чынга аша ди бугай... *(Илиркәгә сәер караш белән карап тора.)* Бигрәк чибәр шул син. Чәчен... Теге жырны тагын жырла әле.

*Илиркә жырлый башлагач, Гонория яшертен генә үткен пычак белән килә. Арттан килеп Илиркәнең чәчен кисеп ташлый. Илиркә тораташ булып катып кала. Гонория кулындагы пычагын төшереп жибәрә.*

Илиркә. Нишләвен бу, Августа Гонория?!

Гонория *(калтыранып)*. Монда килгәндә син шушындый идең. Шул кыяфәттә күрәсем килә сине. *(Кинәт елый-елый Илиркә алдында тезләнә.)* Кичер мине, Ильдико!

Илиркә *(аны күтәрмәкче була)*. Тор, тезләнмә.

Гонория. Әллә нишләп киттем, аным томаланды. Ничек кискәнемне сизми дә калдым. Моның өчен ничек, нәрсә түлим? *(Елый.)*

Илиркә *(тавышын күтәреп)*. Атакамны һуннар иленә, Аттила янына жибәрергә ярдәм ит.

Гонория *(елаудан туктап)*. Ә үзең?

Илиркә. Мин монда калам. Син мине барыбер моннан жибәрмәячәксен.

Гонория *(Илиркәне кочаклап тагын еларга тотына)*. Ачуланма мине. Каргама мине.

Илиркә. Тынычлан, зинһар, тынычлан.

Гонория *(елаудан туктый, шундук тынычлана)*. Син күп нәрсәне белмисең, анламыйсын. Монда алып килгәч, Атакам белән сине үтерергә тиешләр иде. Мин алып калдым сезне, мин коткардым. *(Пауза. Илиркә котсыз калып тора.)* Бар, иртәгә көндезге ашка минем янга килерсен.

*Илиркә баш иеп чыгып китә.*

Гонория *(карангылыкка кычкырып)*. Гиацинт!

*Арткы яктан кара шәүлә пәйда була.*

Гонория. Гиацинт, яшертен генә монда теге Константинопольдән кителгән камны чакырт! Беркем белмәсен!

*Карангылык. Сәхнә яктыра. Атакам керә.*

Гонория. Син төш күргәнсең: имеш, Аттиланың көтүчесе Тәңре кылычын тапкан да, аны Аттилага тапшырган.

Атакам. Әйе. Мин инде йөз тапкыр күргән төш иде ул.

Гонория. Илиркәнең абыйсын шул хәбәр белән Аттила лагерына жибәргәнсең.

Атакам. Әйе.

Гонория. Нишләп ул хәбәр белән үзең бармадың Аттила янына?

Атакам. Мин авырдым. Аннары Илиркә чирләде. Өстәвенә мине барысы да эзли дигән хәбәр ишеттем. Мине күбрәк Аттиланың дошманнары эзләде. Качып йөрдем. Һуннар иленә барып житәргә исә бернинди мөмкинлегем булмады.

Гонория. Илиркәнең абыйсы синең төшеңне барып сөйләгән...

Атакам. Әйе. Алмас Аттилага Тәңре кылычы язган дигән сүземне житкергән.

Гонория *(әсәрләнеп)*. Ишетүемчә, синең төшең чынга ашкан. Чынлап та көтүче аксак бозау эзеннән барып затлы кылыч тапкан. Аны Аттилага тапшырган...

Атакам. Әйе, минем төшем чынга ашкан—Аттила Тәңре кылычын тапкан. Ә менә Илиркәнең абыйсы ни хәлдә—билгесез. Аяныч, бик аяныч.

Гонория. Син Аттиланы эзләп Итилдән үк килденме?

Атакам. Әйе. Мин Аттиланы бабалары үткән юлдан кире кайтырга өндәргә телим.

Гонория. Тәңре Кылычы аңарда булгач, нишләп ул кире кайтырга тиеш?

Атакам. Ул Итил буйларына кайтып китсә, сезгә яхшырак булыр бит?

Гонория. Кемгә, минамы?

Атакам. Рим империясенә.

Гонория. Әгәр син анын янына барып житә алсаң, әгәр ул кире кайтырга теләмәсә, син үз иленә кайтып китәрсеңме?

Атакам. Юк, мин Аттила янында калыр идем. Мин анын янында булырга тиеш.

Гонория. Сине анын янына моннан җибәрмәячәкләр.

Атакам. Аңладым инде.

Гонория *(әкрен тавыш белән).* Сине моннан коткарсам, үтенечемне үтәрсеңме?

Атакам *(жанланып).* Теләсә нинди үтенечеңне үтәрмен.

Гонория. Мин сине азат итәргә булышырмын, ә син шуның өчен Аттиланы Көнбатышка таба яу белән килергә өндәрсең. Шуннан соң да кире Итил буйларына кайтып була бит.

Атакам *(паузадан соң).* Мин риза.

Гонория. Бар, тиздән янына минем кешеләрем керер.

*Атакам чыгып китә.*

Гонория *(караңгылыкка эндәшә).* Гиацинт!

*Шәүлә керә.*

Гонория *(дулкынланып).* Гиацинт, син минем ин тугры кешем. Евнухлар арасында тугрылар сирәк була. Син бит беләсең мина монда ничек тынчу икәнне, син бит минем ничек бәхетсез икәнемне аңлыйсың. *(Кайнарланып.)* Мин куралмыйм мондый тормышны! Мин куралмыйм императорыбызны! Мин аны туганым дип тә әйтә алмыйм. Монда миңа барысы да чит-ят. Минем үч аласым килә барысыннан да. *(Пышылдауга күчә.)* Минем хыялларым бүген Аттила турында гына. Мин анын белән саташам. Мин аны, бер тапкыр күрмәсәм дә, яратам. *(Нәфрәт белән.)* Мин Валентинианны, аның тирәсендәге хәшәрәтләрне Аттила ярдәме белән таптыйсым, сытасым килә. Гиацинт! Мин сине һуннар иленә җибәрәм. *(Сандыктан хат белән йөзек ала.)* Менә бу хатны Аттилага тапшырырсың. Менә бу йөзекне мин аңа бүләк итәм. Бүген үк төнлә юлга кузгал. Аттила күптән инде Итил камын эзли—Атакамны. Син аңа әйт: Атакамны Валентиниан белән Аэций урлаганнар иде, диген. Мин аны Валентиниан тоткынлыгыннан коткарып, озакламый Аттилага җибәрермен. Бар, Гиацинт, тапшыр хат белән йөзекне.

*Хат белән йөзекне алып, шәүлә чыгып китә.*

Гонория *(ярсып).* Аттила! Кайда син? Коткар мине! Кайда син, Аттила?!

## IV

*Рим императоры Валентиниан III резиденциясе. Валентиниан кин көрсигә кырын яткан. Янында биллән шәрә яшүсмер егетләр виноград ашап утыралар. Аэций керә.*

Валентиниан *(егетләргә).* Барыгыз. *(Үсмерләр тиз генә чыгып китәләр.)*

Аэций *(чыгып китүчеләр ягына җирәнгеч караш ташлап).* Вакытсыз керүем өчен ачуланма.

Валентиниан *(торып утыра).* Юк, юк, Аэций, синең керүең беркайчан һичничек вакытсыз булалмый. Ашыгыч йомышың бардыр?

Аэций. Атакамны Аттилага озатырга кирәк. Ул аны тынычландырачак. Мин инде кам белән сөйләштем. Ул Аттила янында булса яхшырак.

Валентиниан. Атакамның үзе белән сөйләшәсем килә.

Аэций. Ул монда. *(Ишек катына бара.)* Кер!

*Атакам керә.*

Валентиниан. Әйт әле, Рим империясенә якын киләчәктә сугыш яныймы?

Атакам. Әйе.

Валентиниан. Кемнәр белән сугыш булачак?

Атакам. Кояш чыккан яктан килүчеләр белән.

Валентиниан. Һуннарга каршымы?

Атакам. Анда һуннар гына булмаячак, күп ырулар катнашачак.

Аэций. Мин моңа ышанмыйм да, шул ук вакытта ышанам да.

Валентиниан. Без бит Аттила

белән әле күптән түгел татулыкка килешү төзедек.

Атакам. Килешүләр төзеп кешеләрнең сугышмый торганнары бармы соң?

Валентиниан. Кем җиңәчәк ул сугышта?

Аэций. Беркем дә җинмәячәк.

Валентиниан. Аттила исән калачакмы?

Атакам. Ул мәңге яшәячәк.

Валентиниан *(кызыксыну белән)*. Бигрәк нык яратасың икән Аттиланы.

Атакам. Аны барыгыз да яратасыз. Чөнки ул сездән көчлерәк. Аттила сезгә кирәк. Чөнки ул бар! Минем исә аны яратуымның сәбәбе үзгә—безнең тамырлар бер, каннарыбыз да бердер, ахрысы.

Валентиниан. Син коточкыч ерак ара үтеп, гомереңне кызганмыйча Аттиланы эзләп йөргәнсең. Мин сине аның янына озата алам. Белүемчә, син Аттиланың көн чыгышына кайтып китүен телисең?

Атакам. Шулай.

Валентиниан. Ул синең сүзеңә колак салыр. Син аны шуңа күндер. Көнбатышка яңа яу белән килсә, ул харап булачак—шуны аңлат син аңа.

Аэций. Аттила безгә каршы яу белән килер микәнни?

Валентиниан. Атакам шулай ди бит.

Атакам. Чыннан да җибәрегез мине Аттила янына. Моннан сезгә зыян булмас.

Валентиниан *(чыраен сытып)*. Уф, күңелем болгана—әллә һава тынчу, әллә һуннар турында сөйләшкәнгә.

*Валентиниан чыгып китә. Аэций белән Атакам читкәрәк китәләр.*

Атакам. Мин чынлап та һуннар иленә китәчәкменме?

Аэций. Әйе. Ләкин минем сиңа шуны әйтәсем килә: Аттилага көн чыгышына таба, Итил буйларына китү ярамый. Валентинианны тыңлама.

Атакам. Ул бит императорыгыз...

Аэций. Тс-с-с, кычкырып сөйләшмә. Син дөрес әйтәсең, Аттила безгә кирәк. Ул минем дустым. Күптән түгел мин аның янында булып кайттым. Без аның белән һәрвакыт уртак тел табачакбыз. Син Аттила янында бул, аны тынычландырып тор. Соңгы вакытта ул бик кызу канлы. Аның көтмәгәндә борыныннан кан китә. Көн чыгышына борылып китсә, аны ниләр көтүе—билгесез.

Атакам. Ярар, мин аны Итилгә кайтырга үгетләмәм. Шунын өчен бер үтенечемне үтә.

Аэций. Нинди?

Атакам. Илиркә минем белән барсын.

Аэций *(беравык уйланып тора)*. Ильдикомы... Барсын.

Атакам. Гонория безне озатмасын. Юлга кайчан чыгасыбызны да әйтмәгез аңа.

Аэций. Килештек. Син теләгәнчә булыр.

*Чыгып китәләр. Аһ-ваһ килеп Валентиниан керә, көрсигә кырын ята. Гонория керә.*

Гонория *(кулларын сузып килә)*. Валентиниан ! Туганым минем!

Валентиниан *(торып Гонория каршына килә)*. Гонория! Сеңлем минем! *(Бер-берсенең кулларын кысалар.)*

Гонория *(еламсык тавыш белән)*. Син мине кичер.

Валентиниан *(күңеле тулуын көчкә тыеп)*. Гонория, сине инде кичердек, калганы үзеңнән тора.

Гонория. Барысы өчен дә кичерәсенме? Сиңа каршы көрәшкәнем өчен дәме?

Валентиниан. Син ялгышларынны аңлагансыңдыр, акылыңа инде килгәнсеңдер, шулай булгач, сеңлем, тату булыйк, бергә булыйк.

Гонория *(елый)*. Рәхмәт, император! *(Икесе дә елый-елый кочаклашалар.)*

*Түрдәге кәнәфигә кара-каршы утыралар.*

Валентиниан. Тынычлан, сеңлем!

Гонория. Мин инде тыныч, Валентиниан.

*Пауза.*

Валентиниан. Ничек уйлыйсың, Атакамны Аттила янына җибәрү дөрес микән?

Гонория *(шомланып)*. Барсын. Тик... чак кына соңрак озатырга кирәк аны.

Валентиниан. Ник?

Гонория. Күнелем шулай сизә.

Валентиниан. Аларны озаттык бит инде без.

Гонория *(сискәнеп)*. Кемнәрне?

Валентиниан. Атакам белән ана юлдаш кызны.

Гонория *(кызып китә)*. Ильдико минем янда кала дигәннәр иде.

Валентиниан. Нәрсәгә ул сиңа?

Гонория (кинәт нәфрәтләнеп). Аның миңа кирәкме-юкмылыгында түгел хикмәт. *(Сикереп тора.)* Һәрбер эштә миңа каршы нәрсә дә булса эшләнми калмый!

## V

*Константинопольдән чыгып киткән Аттила илчеләре һәм византлылар ике атна эчендә 300 чакрым юл үтеп Сердикага (София) килеп житкәннәр. Ялга туктап чатырлар корганнар. Бер якта Аттила илчеләре, икенче якта Феодосий Икенченең делегациясе урнашкан. Ниндидер киеренкелек сизелә.*

Беренче һун. Без һуннар жирендә инде.

Беренче византлы. Бу жирләр дә һуннарныкымы?

Беренче һун. Һуннарныкы.

Икенче һун. Аттиланың яңа биләмәләре бу.

Икенче византлы. Без византиялеләр сезгә, Аттила илчеләренә, кичке аш хәзерләдек.

*Тустаганнарга эчемлекләр салалар.*

Беренче һун. Император өчен!

Икенче һун. Аттила өчен! Кояш астында иң бөек кеше өчен. Ул жирләргә генә түгел, инде күкләргә дә хужа.

Вигил *(Икенче һунга ачуланып карый)*. Авызыннан бигрәк мәнсез сүз чыкты.

Эдика *(Вигилга пышылдый)*. Ник кызасың? Тыныч бул!

Икенче һун. Сиңа нәрсә ошамады?

Вигил. Кешене Аллага тиңләргә ярамый.

Орест *(Вигилга ямьсез караш ташлый)*. Нәрсә дидең?

Вигил. Кешене Аллага тиңләргә ярамый, дидем.

Орест. Аттила—Алла!

Вигил. Феодосий Алла. Аттила—кеше.

Орест *(кыжрап)*. Аттила гади кеше, дисеңме?!

*Һуннар сикереп торып кылычларын кыннарыннан чыгаралар.*

Орест *(тыныч кына)*. Нәрсә, Вигил, син Аттиланың көче Тәңре Кылычыннан икәнне белмисеңмени? Ул алла булмаса, бүгенге көндә шушындый уңышларга ирешер идемени?

Эдика *(бәхәсчеләр арасына керә)*. Белә, белә. Вигил барысын да дөрес аңлый. Вигил византлылар делегациясенең башлыгы булып барырга хыялланган, ә аны минем ярдәмчем итеп жибәрделәр. Шуңа гына эче поша аның, шуңа кайнарлана. *(Елмаеп.)* Вигил, бигрәк минминле кеше булып чыктың син. *(Барысы да көләләр.)* Шулаймы, Вигил?

*Эдика Вигилне читкә алып китә.*

Эдика. Син бөтен эшне харап итәсең бит, шуның белән үзебезне дә харап итәчәксең. Һәр әйткән сүзгә игътибар итмә. Ник кайнарланасың?

*Ызгышның тәмамлану билгесе итеп, византлылар һуннар чатыры алдына затлы келәмнәр, алтын йөгертелгән савытлар китереп куялар. Шулай да киеренкелек саклана.*

Икенче византлы. Бәхәскә дә, ызгышка да урын юк.

Беренче византлы. Сүз дә юк, Аттила Марс Кылычын тапкан.

Һуннар тавышы. Тәңре Кылычын!

Һуннар тавышы. Тәңре Кылычын!

Икенче византлы *(эчемлек салынган тустаганын күтәреп)*. Без озакламый һуннар короле Аттила каршына килеп басачакбыз.

Беренче һун. Һуннарныкы гына

түгел. Ул император! Ул иң олы император!

Беренче византлы. Шулай булсын. Әйдәгез, Император Аттила саулыгы өчен тустаганнарны күтәрик!

*Барысы да тустаганнарны күтәреп эчеп куялар. Кинәт Вигил сискәнеп китә—ул читтәрәк таныш шәүләне абайлый. Барысы да ул караган якка карыйлар.*

Вигил. Кемнәр болар?

*Һуннар берничә кешене алып киләләр. Илчеләр каршына Атакам, Илиркә һәм аларны озата баручылар килеп басалар. Илиркәне танырлык түгел—озын кара кием кигән, башына кара шәл чорнаган.*

Атакам. Безне тоткарламагыз. Без һуннар иленә аяк бастык. Безне Аттила үзе көтә.

Орест. Кемнәр соң сез?

Атакам. Аэцийның ышанычлы кешеләре.

Эдика. Сез Равеннадан ук киләсезмени?

Атакам. Әйе.

Вигил *(арттан килеп чыга).* Кайчаннан бирле Итил буеннан килгән шаман Аэцийның ышанычлысына әверелде икән?

Атакам *(тыныч).* Мин теләсә кемнең ышанычлысы була алам.

Эдика. Вигил, кем бу?

Вигил *(авызын кыйшайтып).* Аты тирә-якка таралган Атакам.

Орест. Әйдәгез, безнең белән утырыгыз, ял итегез. Аттила лагерына бергәләп барып керербез.

Атакам. Юк, без ашыгабыз. Безнең берничә юлдашыбыз—һуннар—алданрак чаптылар. Минем киләсемне Аттилага хәбәр итәргә дип.

Вигил *(усал итеп елмая).* Ник Аттила янына ашыкканыңны белә-ә-м. Яхшы ният белән түгел.

Орест *(юлдашларына).* Аттила Атакамны озак эзләде. Үз теләге белән бара икән, аны хәзер үк җибәрегез!

Вигил *(йөгереп барып Эдикага пышылдый).* Аны үзебездән алдан җибәрергә ярамый. Аны бөтенләй юк итәргә кирәк.

Эдика. Ник?

Вигил. Аннары аңлатырмын. Аны исән калдыру ярамый. Алачак алтыныбыздан колак какмагаек.

Эдика. Аттила көтеп яткан камны ничек үтермәк кирәк?

Вигил *(гасабиланып).* Соңга калмагаек.

*Атакам китеп бара. Вигил аны куып житә.*

Вигил. Тукта! *(Илиркәгә күрсәтеп.)* Теге кем ул?

Атакам. Сиңа нигә ул?

Вигил. Мин аны таныдым. Ул—һун кызы Илиркә. Ильдикога үзгәртеп йөри исемен.

Атакам. Шуннан?

Вигил. Юк, болай гына. *(Атакамның күзләренә карап.)* Мин беләм синең кем икәнеңне.

Атакам *(шулай ук туп-туры карап).* Мин дә синең кем икәнеңне беләм.

Вигил. Аттилага мин керәгрәк хәзер. Мин аның күнеленә хуш киләчәкмен.

Атакам. Мине менә шунсы куркыта да. Мине тынычландырганы шул: минем күнелем синекенә караганда сизгеррәк. Күңел газабы комсызлык белән кансызлыкка караганда ераграк күрә.

Вигил. Киләчәк күрсәтер!

*Вигил үзенең чатырына таба китә. Атакам аның артыннан карап кала.*

Атакам *(үзалдына, көлемсерәп).* Мин бит синең һуннар иленә нинди ният белән баруыңны күрәм—шуны да сизмәдең бит син, сукыр!

*Атакам үзенең юлдашлары белән китеп бара. Вигил үзен кая куярга белми.*

Эдика *(Вигилга).* Сез күптәнге танышлар бугай?

Вигил *(тынгысызланып).* Күптәнге. Кешеләр яралганнан бирле. Аны бәйләп ташларга кирәк иде.

Эдика. Син аның белән әрләштең. Аннары, синең кыбырсуың мине дә кaушата. Орест безгә кырын карый хәзер. Сизенми микән?

*Вигил читкә барып утыра. Аның янына Орест килә.*

Орест *(Вигилгә иелебрәк).* Шулай да, мин сезгә ачулымын. Константинопольдә Мега Палатионда Эдиканы кичке ашка чакырдыгыз, ә мине юк. Бәлки моның берәр зур сәбәбе бардыр, ә?

Вигил *(каушавын яшереп).* Нинди сәбәп булсын! Императорның күнеленә Эдика хуш килгәч...

*Орест китеп бара. Вигил куырылып кала. Башкалар чатырларга кереп киткәч, Вигил янына Эдика килә.*

Эдика. Орест нәрсә ди?
Вигил. Бездән шикләнә.
Эдика. Әйтәм бит.

*Эдика читкә китә.*

Эдика *(үзалдына).* Орест үзенең шикләнүен Аттилага әйтсә, бетте баш!

Вигил *(үзалдына).* Миңа шик төшәргә тиеш түгел. Мин тылмач буларак кына барам. Эдика курка, ләкин Аттиланы үтерү эшенә алынуыбызны әйтмәячәк, чөнки аның үзен шундук сатлыкжан диячәкләр. *(Йодрыгын төйнәп.)* Атакам бар шул, Атакам!

*Вигил сикереп торып Эдиканы куып житә.*

Вигил *(еш-еш сулап).* Атакамнан алданрак барып житәргә кирәк!

Эдика. Нигә?

Вигил. Без эшлисене ул эшләргә мөмкин. Ул Аттиланы үтерә ала. Ул йә аңа ярдәм итәчәк, йә үтерәчәк—ничек булса да безгә кулай түгел. Аласы алтыныбыздан колак кагачакбыз.

Эдика. Ни сөйлисең? Тынычлан.

Вигил. Тыңла мине! Юлга кузгалыйк!

Эдика. Әйдә, жыеныйк.

Вигил *(акыра).* Торыгыз, кузгалабыз!

*Барысы да чатырлардан чыгалар.*

## VI

*Дунай буе. Һуннар лагеры. Аттиланың бурадан корылган сарае. Сәхнәдә ярым караңгылык. Түрдә кемнеңдер утырганы шәйләнә. Отыры ул тараф яктыра һәм үзенең биек, киң итеп ясалган агач тәхетендә Аттиланың утырганы күренә. Бераздан аның артындарак торган ясауллар абайлана, алар читтәрәк, бер хәрәкәтсез басып торалар. Идәнгә келәмнәр жәелгән. Уртада ит кыздыра торган корылмалы учак. Бер кырыйда өстәл, шул өстәлдә төрле шаманнарның нәни сыннары. Аттила уйга баткан. Эдика керә.*

Эдика *(башын ия).* Тәнре Кылычы иясе! Тиңе булмаган көнег! Һуннарның, шул һуннарга буйсынганнарның императоры! Мин—синең тугры аркадашың—һуннарны үземнең туган ыруым дип санаучы скириан Эдика, баш иеп, хәбәр итәм: Византиядән илчеләр килеп житте.

Аттила *(бик озак, аңламагандай, Эдикага карап тора).* Кемнәр килде?

Эдика. Көнчыгыш Рим империясенең башкаласы Константинопольдән илчеләр килде. Менә без дә шулар белән кайтып життек.

Аттила. Яхшы булган.

Эдика. Мин сиңа бер коточкыч серне ачарга тиешмен. Византия императоры Феодосийның камергеры Хрисанф сине үтерү эшен оештырып ята.

Аттила *(исе китми).* Аның бүтән эше юк микәнни?

Эдика. Монда илчеләр белән килүчеләр арасында Вигил атлы кеше бар.

Аттила. Мин ишетеп беләм аны.

Эдика. Хрисанф сине юк итәргә өндәде, күп итеп алтын түләрмен, диде. Ул алтынны беркадәр вакыттан соң монда Константинопольдән Вигил алып килергә тиеш булачак.

Аттила *(усал итеп көлемсери).* Ник моны миңа сөйлисең? Мине үтерергә идегез дә, алтында коеныр идегез.

Эдика *(куркып).* Мин сиңа тугры кеше.

Аттила. Тугрылыкның монда катнашы юк. Син мине үтерә алмыйсың. Мине үтерә алырдай булсаң, мин сине янымда тотмас идем, минем казанымнан бер генә кисәк ит тә ашамас идең.

Эдика. Мин алар оештырган кара эшкә юри ризалык бирдем. Вигилне монда алып килер өчен.

Аттила. Ярый. Әлегә моны белмәмешкә салышырмын. Мине үтерергә дип бирелгән алтынны ул монда алып килсен.

Эдика. Аңладым.

Аттила. Керсеннәр теге Византиянең ач этләре.

Эдика *(кычкырып).* Илчеләр керсен!

*Илчеләр керәләр. Барысы да баш иярләр. Берсе Аттилага хат тапшыра.*

Вигил *(алга таба бөгелеп).* Һун теле-ндә сөйләшүче буларак, миңа сүз бирегез. Бу хат Византия императоры Феодосий Икенчедән. Ул һуннар императоры Аттиланың уңышлары өчен, аның якыннарының, яудашларының, бөтен ыруының исәнлекләре өчен көн саен аллага ялвара.

Аттила *(Вигилгә җирәнеп карый).* Ә синең үзеңнең теләгең нинди?

Вигил. Кемнең?

Аттила. Менә синең үзеңнең?

Вигил *(тагы да алгарак иелеп).* Минем дә теләкләрем шундый ук.

Аттила. Син миңа чынында ни телисең, синең үзеңә дә шул булачак. *(Кинәт ярсып.)* Син, оятсыз, пычрак дуңгыз, ничек читенсенмичә минем каршыма килеп баса алдың? Кем син минем алдымда император исеменнән сүз катарга? Ә сез, калганнар, беләсезме, соңгы килешүдә ничек сөйләшкән идек? Миннән качкан барлык кешеләр миңа кайтарылган очракта гына минем яныма илчеләр килә ала.

Вигил *(мыгырдап).* Барлык качкыннарын сиңа кайтарылды... *(Калтырана башлый.)*

Аттила. Тынынны да чыгарма! Сездә әле бик күп миннән качкан кешеләр. *(Вигилгә бармагы белән төртеп күрсәтә.)* Син минем кешеләрем белән бергәләп качкыннарны монда алып киләчәксең. Миндә тоткынлыкта ятучы кешеләрегезне шул вакытта гына алачаксыз. Аеруча мине бер кеше кызыксындыра. Миннән качып йөрүче Атакамны Константинопольдән Равеннага озатканнар. Атакамны миңа табып китерергә боерам! Моны Феодосийга җиткерегез. *(Барысы да бер-берсенә карашалар.)*

*Пауза. Шомлы тынлык.*

Аттила. Феодосий Икенче ачыктан-ачык сөйләшергә дә, ачык кырда сугышырга да өйрәнмәгән король. Ул һаман ничек тә булса хәйләләргә, астыртынлык белән алдырырга маташа. Шул ук Феодосий минем һуннарымны кыргыйлар дип атый. Мине дә кыргый ди икән ул. *(Кинәт ярсып.)* Мин—күзгә күз сөйләшеп, уртага салып эш итүче Илбашы кыргыймы, әллә вак этлекләр ярдәмендә нәрсәгәдер ирешергә тырышучы Феодосиймы? Беләсегез килсә, сезнең латинча дипломатия дип атала торган нәрсәгездән дә пычраграк күренеш юктыр. Бу кадәре ялагайлык, алдашу, хәйләләү, сатлыкҗанлык сезнең дипломатия дип аталаган нәрсәгездә генә бар. Сезнең дипломатиягездәге кебек кыргыйлыкның дала ыруларында беркайчан булганы юк.

Илчеләрнең берсе *(кыюсыз гына).* Дипломатия ул кайвакыт каршы якның ачуын китермәс өчен шулай хәйләле була инде.

Аттила. Каршы якта кемнең басып торганын күзне ачып карага кирәк башта. *(Тынычлана.)* Ярый. Ни дисәң дә, сез илчеләр. Сезгә мин якты чырай да күрсәтергә тиешмен. Сезгә ял итәргә бөтен нәрсә әзер: аш-су, мунча, хатын-кыз... Барыгыз.

*Византлылар әкренләп чыга башлыйлар.*

Вигил *(һаман калтыранып).* Үткәнендә ул бик тыныч иде, бик әйбәт сөйләшкән иде.

Илчеләрнең берсе. Ул синең: «Феодосий—Алла, ә Аттила—кеше,»—дигәнеңне берәрсеннән ишеткәндер.

Вигил. Шулайдыр, ахрысы.

Эдика *(Вигилне куып җитә).* Тиз арада Константинопольгә кайт та, монда алтынны алып кил. Мин Аттиланы үтерәсе кешеләрне әзерләп куярмын.

Вигил. Ярар. *(Күкрәген угалап.)* Ул миңа кычкыра башлагач чак кына йөрәгем ярылмады.

Эдика. Каушама.

## VII

*Аттиланың сарае. Аттила читлектәге кошка текәлеп карап утыра. Атакам керә. Атакам исәнләшер өчен авызын да ачалмый кала, Аттила сүз башлый.*

Аттила. Менә бу кошчык ирек турында хыяллана, пырых-пырых килә, читлек эчендә бәргәләнә. Иреккә чыгаргач, ул үләчәк—шуны аңламый.

Атакам. Читлеккә бикләп куйсалар, үзең дә үләргә булса да иреккә чыгарга иде дип хыялланачаксың.

Аттила. Дөрес әйттең. Бала чакта, Римдә торганда мин даланы сагынып, һуннарның шул дала буйлап атларда чабуларын бер күрәсем килеп, үземнең дә җилләрне узып очуымны күз алдыма

китереп үләр дәрәҗәгә җиткән идем. Бала чакта үләсе килми—котылу, качу юлларын эзләдем. Хәзер андый хәлдә калсам, бәлки, чынлап та ирек өчен үлемгә дә риза булыр идем. Мине римлеләр асраганда һуннар илендә минем урында Аэций торкын булып торган иде. Менә шулай римлеләр белән һуннар арасында ызгыш-сугыш булмый торды. Аэцийга җиңелрәк булгандыр чит-ят кешеләр арасында тоткынлыкта яшәү. Ул дала баласы түгел, ул туып-үскән таш нигезле Рим—үзе төрмә.

Атакам. Аэцийдан сина ин яхшы теләкләр алып килдем.

Аттила *(ниһаять, Атакамга карый, аны җентекләп күзәтә).* Мин сине кайчаннан бирле эзләтәм. Нишләп качып йөрдең миннән?

Атакам. Мин үзем сине эзләп табуга ярты гомеремне багышладым. Мин Итилдән килеп, адашып, хәлләрдән таеп, мең тапкыр үлеп, мең тапкыр терелеп сине бер күрер өчен йөргән кеше. Сине эзләү бик авыр. Сине табу бик кыен. Чөнки адым саен сине йә яраталар, йә дошман итәләр. Сине белергә теләмәүчеләрне бер дә очратмадым. Шуңа күрә юлым сиңа таба бик озын-озак булды.

Аттила. Күчмә кош сыман әле Фракиядә син, әле Константинопольдә, әле Равеннаның үзендә...

Атакам. Дошманнарың мине еракларак олактырырга тырышалар, дусларың сиңа таба килергә булышалар.

Аттила. Тәңре Кылычын табачагымны миңа син хәбәр иттеңме?

Атакам. Әйе, мин. Алмас батыр аша хәбәр иттем.

Аттила *(күзләрен кысып).* Батырмыни ул? *(Пауза.)* Син үзең ышанасынмы соң төшеңдә күргәненә?

Атакам. Ышанмасам монда басып торыр идеммени?

Аттила *(текәлеп карап тора).* Синме соң ул Атакам?

Атакам. Мин.

Аттила. Мине төрле ысуллар белән үтерергә маташалар. Бу турыда ни уйлыйсын?

Атакам. Һәрбер илбашының үлемен телиләр. Синекен бигрәк тә. Синнән куркалар, сине яраталар, сине кураллмыйлар, сине бернишләтә алмыйлар. Сиңа берсе дә битараф түгел.

Аттила. Шулай да, кем кулыннан үләчәкмен мин?

Атакам. Сине әшәкелеген, комсызлыгын үтермәкче була. Әмма син газаптан, бәгырен сызлаудан үләчәксен.

Аттила *(нык гаҗәпләнә).* Яу кырында түгелмени?

Атакам. Юк. Якты уй-ниятләрдән, сагыштан, татлы кайгыдан үләчәксең. Татлы үлем көтә сине.

Аттила. Татлы үлем? Кайгыдан үлү татлы үлем дип аталамы?

Атакам. Нәрсә турында кайгырасың бит.

Аттила. Кайчан үтерергә маташачаклар мине? Минем явызлыгым үзе мине буарга маташачакмы, әллә берәрсенең кулы беләнме?

Атакам. Монда Константинопольдән килгән илчеләр арасында берәү бар...

Аттила *(кинәт).* Кем ул?

Атакам. Белмисенмени?

Аттила. Син соңрак килеп җитсәң дә, юлга бергә чыккансындыр аның белән?

Атакам. Кем белән?

Аттила. Вигил белән. Вигил белән бергәләп килмәдегезмени?

Атакам. Итил буйларыннан монда кадәр мин сине үтерергә дип киләммени инде!

Аттила. Ник эзләдең мине?

Атакам. Итил буйларында тәртип юк. Кан кими, сыегая. Ырулар бутала, нәселләр югала. Һуннар каны анда тәмам бетмәгәе. Аттила дигән сүз әрем исле дала җиле белән килеп ишетелгәч, мин тетрәнү кичердем. Шул көнне төш күрдем—ерактан бер бөек җайдак мине үзенә таба чакырды. Икенче көнне мин юлга чыктым.

Аттила. Син миннән ярдәм сорап килденме?

Атакам. Мин сине Итил буйларына бабаннар килгән юлдан кире кайтырга чакырам.

Аттила. Беркемнең дә беркайчан гомере узган юлдан кире кайтканы юк әле.

Атакам. Сүз бит бер кеше турында гына бармый. Ил-көн, ыруны саклап калу, эреп-таралып юкка чыкмаска тырышу турында бара сүз. Тамырлар анда калды бит.

Аттила. Кайсы агачның тамырларына таба ботаклары үскәнен күргәнең бар? Тамырлар алар шунда аста, артта, төптә, ә ботаклар югарыга, күккә омтылалар.

Атакам. Ыруынны саклап каласың килсә, кирегә борыл, Аттила. Син донь-

яны тетрәндерден, ләкин син бит үзең дә читлектә. Тик ул читлекнең урыны гына зур. Бер якта Византия, икенче якта Рим иле, тегендә готлар, анда акацирлар.

Аттила. Мин Рим империясенең котын алдым, Византияне тезләндердем, күпме илләр, ырулар миңа буйсынды! Хәзер мин тамырларымны барларга кайтып китәргә тиешме?

Атакам. Юк. Улларың, улларыңның уллары да сиңа тиң булсын өчен кирәк үткәннәрне барларга, үткәннәр белән элемтәне өзмәскә, һуннарның бөек илен төзергә. Үзеңнең исемең мәңге яңгырасын өчен.

Аттила. Ырулар императорсыз яши алмыйлар. Шулай ук император үз ыруларыннан башка бернишли алмый. Мин һуннарга хәзер Итил буйларына кайтып ил төзик дисәм, миңа буйсынудан туктаячаклар. Алар тыныч кына ятарга теләмиләр, тып-тын ил булып кына яшәргә омтылмыйлар, аларга хәрәкәт, күчену, сугыш, буталыш кирәк. Ә нишләп син миңа Итил буена кайтырга кушасың? Нишләп арырак кайтырга өндәмисең?

Атакам. Мин үзем Итил буеннан.

Аттила. Үземнең ерак бабаларымның тарихын белмим дип уйлыйсыңмы әллә? Мин беләм. Ә менә халыкка ул тарихны белү кирәкми.

Атакам. Ялгышасың.

Аттила. Бөек кешеләрне телгә алганда, аларның нинди нәселдән икәне кызыксындырмый.

Атакам. Ә үзең өчен кирәкме нинди нәселдән икәнеңне белү?

Аттила *(кызып-кызып сөйли).* Кирәк! Үзең өчен генә. Моннан бик күп еллар элек һуннар Мадә житәкчелегендә бөтен тирә-якны дер селкетеп торган. Хань илен тар-мар китергән. Әмма һуннар, чиннар белән тарткалашып, дүрткә бүленә—бер өлеше тарала, икенчесе буйсына, өченчесе кырылып бетә. Бер өлеше көн батышына китеп бара. Без башкалар үтә алмаслык олы юл үткән ыру. Һуннар туган җирләреннән китә. Сяньбилар аларны куып баралар. Арттарак калганнарны турап, таптап эзәрлеклиләр. Ул коточкыч авыр юлда хатын-кыз күп үлә. Исән калган һуннар соңрак хатынлыкка угыр кызларын алалар. Бу бәлане, моңдый мескенлекне алдагы буыннар белмәсен өчен, ул ерак вакыйгаларны ыру онытырга тиеш. Минем атам Мундзук та шулай уйлый иде. Ә мин үзем яшертен, караларга ишеттермичә, белгертмичә генә ерак бабаларыбызның җырларын да тыңладым, хәзер дә тыңлыйм, үткәннәрне сагынам. Минем якыннарым да шулай. Ә бөтен ыруга бабаларның язмышын белү кирәкми. Шуңа күрә мин хәтта үземне көнег яки хан дип атарга кушмыйм. Император дигән сүз охшаганга түгел.

*Аттила кинәт ике кулы белән башын кысып тота. Ыңгыраша. Аттиланың борыныннан кан китә. Барып ятакка чалкан ята. Ике ясаул шундук ятак янына килеп басалар һәм Атакамның һәр хәрәкәтен күзәтеп торалар. Атакам Аттила янына килә.*

Атакам. Күптәнме бу синең?

Аттила *(борыныннан аккан канны чүпрәк кисәге белән сөртеп).* Һуннар башлыгы булганнан бирле.

Атакам. Каның кайный. Кирәгеннән артык кайный. Һуннарның илбашы булганнан бирле өстеңдә авыр йөк. Илкөнеңне саклар-яклар өчен гел эчең пошып тора.

Аттила. Болай да эчемдә тынгылык юк иде. Нинди кеше соң син—иң авырткан җирләремә басасың.

Атакам. Мин кеше түгел, мин синең газабың.

Аттила. Син, никтер, бик таныш тоеласың миңа.

Атакам. Мин бит синеке.

Аттила. Ник һаман мине ташламыйсың соң син?

Атакам. Сине ташлап кая барыйм мин?

Аттила. Тәңре Кылычын син миңа юлладыңмы, әллә ул Тәңренең үзеннәнме?

Атакам. Мин үзем—Тәңренең үзеннән.

Аттила *(торып утыра).* Сине мин күрәм икән, димәк, мин сине юк итә алам.

Атакам. Мин синең газабың, хәзер бу тәнне үтерсәң дә исән калачакмын.

Аттила. Ник соң син күрәзәче булып, кам булып, дәвалаучы булып йөрисең?

Атакам. Мин газап. Аларның да һәрберсенә хас.

Аттила. Әйтәм җирле, мин сиңа иң тирәнтен серләремне ачтым. Димәк, син минем газабым? Кам—минем газабыммы?

Атакам. Синең рухың—синең газабың.

Аттила. Бер урында озаграк торыл-

ды. Шуңа каным кайный, ахрысы, шуңа газапланам бугай. *(Торып утыра.)*

Атакам. Ай-һай, белмим.

Аттила *(шаманарның нәни сыннары басып торган өстәлдән хат белән йөзек алып килә).* Күрәсенме—йөзек. Император Валентинианның сеңлесе Гонория миңа бүләк җибәргән. Менә аның миңа язган хаты. «Бөтен дөньяны дер селкетүче һуннар императорының хатыны буласым килә,—дип яза ул.—Вәгъдә итеп йөзек җибәрәм, килеп коткар мине, Аттилла! Кайда син, Аттила? Мин бары тик сиңа табынам!» Гонория мине көн батышындагы Рим империясенә бәреп керергә чакыра. Ул минем хатыным булырга теләгәч, мин римлеләрнең ярты империясен тартып алырга хаклы булачакмын. Уйлап кара, ничек мин хәзер атымны кире юлга борырга тиеш? Мине, һуннарны, һуннарга тугры ыруларны сугыш көтә, олы табыш көтә. Аларның күпмесе генә үткәннәр турында, ерак бабаларыбыз турында уйлыйлар икән? Минем кебек уйга батып газапланучылар бардыр, ләкин алар аз.

Атакам. Гонория үзенең эчке нәфрәте, күңел фаҗигасе өчен башкалардан үч алмакчы була. Гонория үзенең абыйсыннан үч алырга тели. Синең ярдәмең белән. Синең хатының булып, Гонория Рим тәхетенә менә алмаса да, Галлиянең илбашы булырга хыяллана.

Аттила. Мин ил-көн өчен, ыруым өчен Римгә барырга тиеш. Шулай гына исән калачакбыз. Шулай гына бездән куркачаклар, алдыбызда баш иячәкләр. Башкача булмый.

*Пауза.*

Атакам. Сиңа Тәңре Кылычының индерелүе хакында хәбәрне Алмас аша тапшырдым. Аның сеңлесе минем белән килде. Алмасның язмышы өчен икебез дә борчылабыз.

Аттила. Синнән хәбәр алып килгәч, мин аны тоткын итеп сак астына куйган идем. Үзенең аркадашлары ярдәмендә ул качкан. Ике көннән соң Тәңре Кылычы табылды. Качмаган булса, Тәңре Кылычы индерелү шатлыгыннан бәлки мин аны кичергән булыр идем. Качкан бит. Аның сеңлесен күрәсем килә.

Атакам. Монда ул.

Аттила. Керсен.

*Илиркә курка-курка гына керә.*

Аттила. Исемең ничек?

Илиркә. Илиркә.

Аттила. Куркасыңмы миннән?

Илиркә. Куркам.

Аттила. Соңгы вакытта мин дә үз-үземнән куркам. Син абыеңны эзләп килдеңме?

Илиркә. Әйе, бөек көнег.

Аттила. Абыең тагын качты.

Илиркә. Тәңре Кылычы турында хәбәрне монда ул алып килде. Аны кичерә алмассыңмы икән, бөек император?

Аттила. Тәңре Кылычы табылган хөрмәткә бәлки кичерер идем. Тагын качты бит.

Илиркә. Тотылса нишләтәсең?

Аттила. Казыкка утыртам.

Илиркә. Шундый яхшы хәбәр алып килгән кешенеме?

Аттила. Миннән качучыларны кичерә алмыйм мин. Сатлыкҗаннардан мин яудагы дошманнардан да күбрәк зыян күрәм.

Илиркә *(өзгәләнеп).* Безнең нәселебездә сатлыкҗаннар булмады, буласы да юк, бөек император.

Аттила *(уйга кала).* Сезнең нәсел борынгы һун җырларын хәтерләүче, оста итеп башкаручы нәсел, шулаймы? Атаң Байсанның да күп тапкырлар миңа җырлаганы бар иде. *(Илиркәгә карап тора.)* Үзең дә матур җырлыйсыңдыр син. Берәр җыру әйт әле миңа.

*Илиркә җырлый. Аттила таң калып тыңлап утыра.*

Барып җитәр җирем һич күренми,
Ерагайды миннән кай ара?
Ничек чабыйм узган көн артыннан,—
Атым кайтыр якка каера.

Кайтып җитәр җирем ерагая,
Кайтыр сукмакларым онытыла...
Җилгә ияреп кайтып китә алмыйм,—
Атым, никтер, алга омтыла.

Кай якларга гына талпынсаң да,
Язмыш үзе йөртә, юк чара.
Атым туктап башын аска игән,—
Минем хәлне аңлый бичара.

*Җыр тәмамлангач, барып Илиркәне кочагына ала һәм бик озак кочаклап тора.*

Аттила. Үтерден мине, үтердең, гүзәл кыз! Күңелем ташу булып ага хәзер.

*Аттила жыр шаукымы белән канатланып китә, күнеле кинәя.*

Аттила *(кычкырып).* Барыгызны да кичке ашка чакырам! Византия илчеләрен дә кичке ашыма чакырыгыз!

## VIII

*Аттила сараенда кичке аш. Түрдә Аттила утыра. Бер ягында улы Иллек, икенче ягында яраткан улы Ирнәк урнашкан. Чак кына алгарак улы Дингиз утыра. Арттарак кечкенә ятак, аннан арырак житен һәм ефәк пәрдәләр белән капланган зур ятак. Стеналар буйлап утыргычлар куелган. Һәр утыргыч артында хезмәтче басып тора. Аттиланың уң ягында якын кешеләре утыра. Римлеләр һәм византлылар Аттиланың сул ягында утыралар. Кунаклар алдында мул ризык, кымыз, арпа сырасы, Римнән кайтарылган төрле исерткеч эчемлекләр. Табын инде шактый кызган, ашыйлар, эчәләр.*

*—Аттила—корольләрнең короле!*

*—Бөек император Аттила саулыгы өчен эчәбез!*

*—Мең яшә тиңе булмаган император!*

*Аттила кулын чак кына калкыта. Барысы да шым калалар. Тынлык урнаша.*

Аттила. Минем гомерем озын булырга охшый. Чөнки минем дәвамым бар. Менә минем өлкән улым Иллек. Мин аны акацирларга илбашы итеп җибәрәм. Һуннар иленнән көчлерәк ил бармы, улым?

Иллек *(торып баса).* Юк, атам.

Аттила. Менә минем уртанчы улым Дингиз. Әйт әле, улым, кунакларга—ни өчен без барлык илләрне, барлык ыруларны тезләндерә алдык?

Дингиз *(торып баса).* Чөнки безне Тәнре үзе йөртә, чөнки Тәнре Кылычы сиңа язган, атам.

Ирнәк. Кече улым, Ирнәк, безгә күпме гомер бирелгән, ни уйлыйсың?

Ирнәк *(торып баса).* Һуннар иле мәңгелек, атам!

Аттила *(гөрселдәүле тавыш белән, барысын да сискәндереп).* Күрәсезме, ишетәсезме? Бу минем улларым. Бу—Аттиланың уллары!

—Аттиланың уллары өчен эчәбез!

—Аттиланың уллары өчен!

*Аттила чак кына кулын калкыта. Тагын тынлык урнаша.*

Аттила. Монда илчеләр бар чагында әйтәм: кайберәүләр Аттиланы җиңү мөмкин дигән пычрак хыял белән яши. Мин аларны күрәм, мин аларны беләм. Барчагызының гомере һәм үлеме миннән тора, шуны тәгаен аңлар вакыт! *(Кычкырып.)* Дөнья минем кулда!

—Дөньяда иң бөек император Аттила!

—Аның тиңе юк!

—Аттила өчен эчәбез!

Ирнәк *(Аттилага таба сузылып).* Хәлең ничек, атам?

Аттила *(елмаеп).* Син янәшә булганда яхшы минем хәлем, улым. Шаманнар һуннарның иле таркалачак, дигәнрәк сүзләр әйтәләр кайвакыт. Улым, һуннар иленең җимерелүенә син юл куймаячаксың, шулай бит?

Ирнәк. Әйе, атам. Караңгы уйлардан башыңны арындыр. Без ил-көнне саклаячакбыз.

Аттила. Жырчылар керсен!

*Ике жырчы керә. Уен коралларында уйнап үзләре язган жырны жырлыйлар.*

Күпме тапкыр мине саклап калды
Кылыч белән тыгыз калканым,
Күпме тапкыр аттан йолкып алды
Хыянәтче дуслар арканы.

Атым сизгер, атым абайлаган
Атып килгән таңның ал канын,
Нигә сулап булмый икән дисәм,—
Муенымда—дошман арканы.

Арынырмын барча дус-дошманнан,
Юл тузаны саклар аркамны...
... Ә шулай да һаман тыным кабар,—
Муенымда—язмыш арканы.

*Жырчылардан соң биюче чыга. Бию.*

Аттила. Заркан кайда?

*Атаклы шамакай Заркан—коточкыч, иләмсез кыяфәтле гарип—аксак, борынсыз, бөкре кәрлә. Аны беренче күрүчеләр котсыз калып карап утыралар.*

Заркан *(Аттиланың каршысына ук*

*килеп).* Монда мин, Аттила. Миннән башка һич яши алмыйсың, ә. Сине мәңгелек дигән булалар. Мине берничә көн күрми торсаң, сагыштан үләчәксең бит син. *(Барысы да Аттила ни әйтер дип куркып утыралар. Аттила исә рәхәтләнеп көлә.)*

Аттила. Заркан, кунакларны күрәсеңме?

*Заркан, тилемсә кыяфәтен тагы да шөкәтсезләтеп, илчеләр утырган якка бара.*

Заркан *(пырдымсыз хәрәкәтләр белән, сикергәли-сикергәли).* О-о-о, болар Византиянең үзеннән килгән илчеләр бит! Византлылар гына болай күп ашыйлар. *(Кунаклар ашаудан туктыйлар.)* Аттила салымны күп салгач, сез анда үзегездә хәзер ачтан интегәсездер. *(Һуннар Аттилага кушылып көләләр. Илчеләрнең йөзләре караңгы.)* Тиздән Аттила ел саен уздырыла торган ярминкәне Константинопольнең үзендә уздырырга боерачак. Шул чагында тамагыгызны ныклап туйдырырбыз.

*Илчеләрнең берсе сикереп тора да, Заркангa ташланмакчы була, әмма аны кырыенда утыручы иптәше жиненнән тартып урынына утырта. Заркан исә, кылана-кылана, Византия илчеләрен һаман мыскыл итә.*

Заркан. Византия императоры итеп Феодосий Икенче урынына мине куярлар, ахрысы. Һуннар императоры булырга миңа язмаган инде, чөнки Аттила ул—мәңгелек. *(Ташланырга теләгән илче каршысына килеп.)* Син миңа бик ямьсез карыйсың! Минем сезнең императорыгыз булачагымнан куркасыңмы?

*Илче тагын торырга талпынып карый, әмма юлдашлары аны тыялар, торырыга ирек бирмиләр.*

Аттила. Күп илләргә король кирәк. Нәрсә син гел Византия турында гына хыялланасың? Әнә көн батышындагы Рим империясенә дә яхшы илбашы кирәк, шунда император булып барасың килмиме?

*Аттиланың сүзеннән соң барысы да тып-тын калалар һәм Заркanның җавабын көтәләр. Заркан Аттила каршына йөгереп бара.*

Заркан. Юк, Аттила, бармыйм мин анда! Башкалалары Римнән Равеннага күчкән империягә император булып баралмыйм. Римдә мин рәхәтләнеп тәхеттә утырыр идем. Ә Равенна—сазлыклар арасында. Миңа андый һава ошамый. Анары, анда Аэций атлы кеше бар. Император Валентиниан урынына ул идарә итә анда. Анда тәхеткә менеп, Аэций белән тарткалашып, талашып утырыр хәлем юк әле. *(Аттила янынннан китә.)* Өстәвенә, Аэций Аттиланың дусты. Аттилага каршы сугышмагач, нинди император булам инде мин?! Аэций мине беркайчан Аттилага каршы сугыштырмаячак.

*Аттила көлә. Ул көлгәч, аның барлык яраннары рәхәтләнеп көләләр. Илчеләрнең генә кәефе төшенкe.*

Аттила. Теге биюеңне бие, Заркан!

*Барабанлы музыка яңгырый. Заркан кискен-кискен хәрәкәтләр белән биергә тотына.*

## IX

*Равенна. Император сарае каршындагы бакча.*
*Император Валентиниан ниндидер хат укып утыра. Аэций атылып килә.*

Аэций *(ерактан ук кычкырып).* Император! Оят, хурлык! Тагын нинди бәлаләргә тарырбыз синең сеңлең аркасында?!

Валентиниан *(сикереп тора).* Нәрсә булды?

Аэций. Күзәтчеләрем хәбәр иттеләр: Гонория үзенең ярдәмчесе Гиацинтны, хат тоттырып, Аттилага юллаган, аның хатыны булырга ризалык билгесе итеп йөзек җибәргән.

Валентиниан *(өнсез калып тора).* Тот та шушында егылып үл—чыннан да нинди хурлык!

Аэций. Инде Византия императоры Феодосийдан чапкын килеп житте—аларга да бу хәбәр ишетелгән.

Валентиниан. Феодосий ни әйткән бу хәбәрне ишеткәч?

Аэций. Аның сүзе шаккатырлык. Ул әйткән: «Аттиланың ачуын китерү ярамый, Гонорияне аңа хатынлыкка биреп котылу яхшырак булыр.»—дигән.

Валентиниан. Феодосий акылдан яза башлаганмы әллә! Минем абруема, Рим империясенә андый пычрак ягылуын һич кенә дә булдырырга ярамый.

Аэций. Мин Аттиланы яхшы беләм. Гонориягә өйләнә калса, Аттила һичшиксез империябезнең яртысын үзенә сораячак, ә бәлки бөтенләй үзе императорыбыз булырга теләк белдерәчәк.

Валентиниан. Феодосийның әйткән сүзе акылга сыймый.

Аэций. Аны аңламассың. Ул бәлки һуннарның Көнбатышка яу белән барулары телидер. Гонорияне Аттилага бирсәң, Аттила безнең җирләргә ташланачак, ул да моны аңлыйдыр.

Валентиниан. Әгәр һуннар безнең империягә ташлансалар, иң алдан алар Галлиягә бәреп керәчәкләр. *(Башын чайкый-чайкый ары-бире йөри.)* Ай, Гонория, Гонория! Бөтен гаеп синә төшәчәк бит, Гонория. Мәңге юылмаслык гаеп аласың бит үз өстенә, Гонория!

Аэций *(уйга батып торганнан соң).* Гонорияга әлегә тимәскә кирәк. Белмәмешкә салышыйк. Гиацинтның кайтканын көтик. *(Тешләрен шыгырдатып.)* Аның башын үзем чабып өзәрмен.

Валентиниан. Һуннар готлар түгел. Коточкыч сугыш булуы ихтимал. Бу варварлардан мәңге котыла алмас микәнни Рим империясе? *(Паузадан соң.)* Һуннар кайчан килеп чыкканнар әле?

Аэций. Моннан житмеш-сиксән еллар элек Дунай буйларында беренче тапкыр күренгәннәр. Әйтерсең лә Рим империясенең хәлсезлеген сизгәннәр.

Валентиниан. Мин сина ышанам, Аэций, Аттила белән синең арадагы күп еллык дуслык безне яңа афәттән коткарыр.

Аэций. Аттила мина караганда дала җиле белән татурак. Безнең дипломатия дигән чүбек чәйнәүгә караганда ул ачык кырда кылыч болгап сөйләшергә ярата.

Валентиниан. Шулай да, мин сиңа сокланам, Аэций—иң кыргый варвар белән уртак тел таба алуына.

Аэций. Аттиланы башка корольләрдән кыргыйрак дип саныйсыңмы? Ул син күзаллаганча кыргый булса, мин аның белән тату булыр идемме?

Валентиниан. Аэций, кадерлем! Зинһар, ачулана күрмә. Сине үпкәләтәсем килмәгән иде.

Аэций. Һуннар бик күп кыргыйлыкларга римлеләрдән өйрәнделәр.

Валентиниан. Аэций!

Аэций. Үпкәләмә, император! Мин һуннарны бала чактан ук якыннан беләм. Хөкем ителгәннәрне җәзалау ысулларын алар бездән—римлеләрдән өйрәнделәр. Миңа Аттиланың атасы Мундзук сөйләгән иде: һуннар римлеләрнең җәзалау төрләренең күплегенә шаккаткан булганнар. Бездә казыкка утыртканда, кеше озак интексен өчен, бавырына, йөрәгенә тигезмичә казык инбашыннан чыгарлык итеп утыртырга остардылар. Аттила да моны белеп гаҗәпләнгән. Алдашу, сүздә тормау, яшәү асылын алтында, малда күрү—болар элегрәк һуннарга хас түгел иде. Алар бездән ота башладылар алтын белән малга табынуны. Һуннар башка ыру, үзгә ыру. Римлеләр һуннарны кыргыйлар дип атыйлар. Ә һуннарның шәһәрләребездәге әшәкелеккә, пычраклыкка, фәхешлеккә исләре китә. Кем кыргый—безме, алармы? Аларга безнең таш шәһәрләребез чит-ят, аңлашылмый торган корылмалар. Шуңа алар шәһәрләрне җимерәләр. Һуннар таш йортта ничек бикләнеп яшәп ятарга мөмкин икән дип аптырыйлар. Алар өчен кыргый тормыш кайный безнең таш сарайларыбызда. Кем кыргый—һуннармы, безме?

*Аэций кызу-кызу атлап чыгып китә. Валентиниан үзен кая куярга белми, әрле-бирле йөренә.*

## X

*Аттила сараеның ишегалды. Сакчылар, Аттиланың яраннары басып торалар. Авызын ерып, ялагай елмаю белән Вигил килеп җитә. Аның юлдашлары алтын тулы капчыклар тоткан. Каршы алучыларны күргәч, Вигил сөенә.*

Вигил. Һуннар короле мине шушылай зурлап каршы алуга чиксез шатмын. Менә, килеп җиттек. Константинопольдән монда килеп җитүнең авырлыкларын

барыгыз да беләдер.

Берничә тавыш. Беләбез, беләбез.

*Каяндыр карангылыктан Аттила килеп чыга. Яман усал кыяфәттә. Атилла килеп чыгу белән Вигилнең кулларын каералар, тентергә тотыналар. Капчыкларны алып Аттила каршына ташлыйлар.*

Аттила. Бу алтын кемгә—минамы, әллә тагын башка кешеләргәме?

Вигил *(Аттиланың күз карашыннан котсыз калып).* Бу алтын... мин... Тоткын византлыларның туганнары үтенәләр... Шулар җыеп җибәрделәр. Тоткыннарны азат итүенне сорыйлар.

Аттила. Коткарыласылары коткарылды инде. Син үзеңне үзең саттың. Син илче. Сине хәзер тотып кулга алдылар, тентеделәр. Син аптырашта калып, каршы торырга тиешсең. Константинопольдәге хуҗаңа кайтып зарланырга тиешсең. Шуның урынына син ык-мык килеп ялганламакчы буласың, үзеңне акларга маташасың. Дуңгыз син!

Вигил *(тезләнә).* Бөек Аттила! Мин ялганламыйм! *(Тезләнгән килеш Аттилага якынлаша. Бер сакчы аның бугазына пычак китерә.)*

Аттила. Дөресен әйт!

Вигил *(дер-дер килеп).* Мин дөресен сөйләрмен. Константинопольдә чакта Хрисанф, Эдика, мин, император Феодосий ризалыгы белән, сине үтерергә сөйләштек, күпме акча кирәклеген билгеләдек.

Аттила. Әйе, син хәзер дөресен әйттең. *(Җирәнеп карый.)* Мине үтермәкче булдыгызмы?

Вигил *(кинәт курыкмый башлый).* Әйе!

Аттила. Минем үлемем сиңа ник кирәк?

Вигил *(торып баса).* Ә мин сиңа ник кирәк?

Аттила. Аңламадым.

Вигил *(куркуның әсәре дә калмый, кыю тавыш белән).* Мин синеке!

Аттила. Син куркудан теләсә ни әйтә башладың. *(Елмаеп.)* Сине ничек үтерергә, нинди үлем күнеләңә хуш?

Вигил *(Аттилага туры карап).* Син мине үтерә алмыйсың. Минем Вигил дигән кабыгымны гына юк итә аласың. Мин—синең холкыңның бер чагылышы. Мин син үлгәч кенә үләчәкмен.

Аттила *(аптырабрак).* Аңламадым. *(Кычкырып.)* Атакамны чакырыгыз!

*Шундук Атакам пәйда була.*

Аттила. Атакам, кем бу?

Атакам *(Вигилгә караган килеш).* Аттила, бу Вигил атлы кешенең эчке чыны—синең комсызлыгың, әшәкелегең, явызлыгың.

Аттила. Алай икән.

Вигил *(көлемсерәп).* Сиңа барыбер түгелмени—мин башыңа җитәмме, әллә Атакаммы? Сиңа үзеңнең күнел газабыннан үлү, яки әшәкелектән үлү барыбер түгелмени?

Аттила *(беркавым ни әйтергә белми тора).* Миңа үләргә иртә әле. Әле дөнья тәгаен яуланмаган.

*Сакчылар кылычларын әзерлиләр. Аттила аларны кул ишарәсе белән туктата.*

Аттила *(берсенә дә карамаска тырышып).* Мин берегезне дә үтермим. Мин сезгә яшәү бүләк итәм.

Вигил. Атакам барыбер синең янында калачакмы?

Аттила *(Вигилгә карамыйча).* Әйе. Ул миңа кадерлерәк.

Вигил *(көлә).* Ха-ха, газап кадерлерәкме?

Аттила *(Атакамга карап).* Ул миңа Итил буйларыннан ук килгән. Тәңре Кылычы миңа газабым өчен бирелгән. Мин йомшак та була беләм. *(Каядыр Вигилнең баш өстеннән еракка карап.)* Сине, Вигил, үтермим. Минем тоткыным булырсың. Сине коткарыр өчен Феодосий тагын илле фунт алтын җибәрсен. Син, дуңгыз, горурланырга тиешсең, гади илче өчен үземне үтертергә бирелгән акча кадәре генә сорыйм.

Атакам *(Вигилгә).* Феодосий—затлы ата улы булып санала. Аттила, һуннар императоры, Мундзукның улы. Аттила үз нәселенең затлылыгын саклады, ә Феодосий юк. Кайсысы кыргый, кайсысы варвар, ә? Аттиламы, Феодосиймы?

Вигил *(мыгырдап).* Феодосий белән Аттила барыбер татулашырга тиешләр.

Аттила *(җикереп).* Юк! Камергерыгыз Хрисанфны миңа тапшырыгыз башта!

Вигил. Феодосий сиңа һаман түли дә түли. Мин ышанам—ул мине дә коткарачак, Хрисанфны да сиңа бирмәячәк.

Сиңа шундый күп алтын түләячәк ул. Шунда син Дунайның бу ягыннан китәчәксең, Византиянең барлык тоткыннарын азат итәчәксең. Хәтта үзеңнең качкын һуннарыңны да кичерәчәксең.

Аттила. Карарбыз, бәдбәхет. *(Елмаеп.)* Ошый башладың әле син миңа.

Вигил *(ялагайларча елмая)*. Мин бит синеке.

Аттила. Алып китегез!

*Сакчылар Вигилны алып китәләр. Аттила белән Атакам калалар.*

Аттила. Константинополь белән монда лыжырдап ятканчы, барыбер көнбатышындагы Рим империясенә ташлану миңа җинелрәк булачак.

Атакам. Бернишли алмыйм. Мин үз сүземне әйттем. Хәзер инде син үзеңнең бәгыреңдәге яхшылык авазына да, начарлык тавышына да колак салмыйсың.

Аттила. Рим империясе көчкә аягында басып тора. Минем гаскәремне күргәч, ул, котсыз калып, коелып иңәчәк.

*Аттила китеп бара. Сакчылары, яраннары, ярдәмчеләре аңа ияреп китәләр.*

*Музыка. Атакам борынгы рухлар белән сөйләшә башлый.*

## XI

*Атакам борынгы рухлар белән сөйләшүен дәвам итә. Аннары экстазга кереп бии башлый.*

*Бию тәмамлангач, Аттила керә.*

Аттила. Мин Византиядән канәгать. Теләгәнемчә умырып алдым. Минем карашым хәзер көн батышына төбәлгән. Рим белән мин инде унбиш ел тату яшим. Һуннар белән римлеләрнең дуслыгы өчен Валентиниан Аэцийга рәхмәт укысын. Их, Аэций, Аэций! Без синең белән дуслар идек... Хәер, без хәзер дә дуслар. Тик миңа табыш кирәк, яңа байлыклар кирәк—минем илемне, ыруымны, гаскәремне туйдырасым бар. Көн батышына таба кузгалудан Аэций дустым да туктата алмас инде мине. Мине беркем, бернәрсә туктатмаячак.

Атакам. Рим бик каты орлык. Аны сыта алмаячаксың.

Аттила. Шулайдыр. Әмма Рим империясенең Галлиясен алырга мөмкинлегем бар.

Атакам. Тәңре Кылычын сиңа буласын әйткән камга ышан—барма Рим империясенә яу белән.

Аттила. Тәңре Кылычын инде кулыма төшергәч, нинди дер камның сүзенә колак салуның кирәге юк. *(Көлә.)*

Атакам. Туп-туры Галлиягә таба кузгалсаң, Равеннада ыгы-зыгы кубачак. Аэций белән шундук араларың бозылачак.

Аттила. Яу белән анда бармасам, монда үләчәкмен. Син минем үлемемне телисеңме?

Атакам. Мин синең үлемне җиңүеңне телим.

Аттила *(канатланып сөйли)*. Готлар безнең генә түгел, римлеләрнең дә дошманнары. Миңа буйсынудан качкан готларны акылга утыртырга теләгән булып барачакмын мин анда. Ә готларның короле Теодорихка хат язам: минем дошманым син түгел, минем дошманым Рим, дип. Валентинианга исә Рим империясенә бер ачуым да юк, дип язачакмын. Уяулыкларын югалтсыннар. Ха-ха-ха.

*Аттиланың Чапкыны атылып килеп керә.*

Чапкын *(көчкә сулыш алып)*. Һуннарның, барлык варварларның императоры Аттила! Мин, синең Чапкының, Константинопольдән кайтып життем. Византия императоры Феодосий аттан егылып төшеп үлде. Хәзер көн чыгышындагы Рим империясенең императоры итеп Фракиядән сенатор Марциан сайланды.

Аттила *(шомланыбрак кала)*. Минем ул кеше турында ишеткәнем бар. Очрашканым юк.

Чапкын. Марциан: «Феодосий түләргә тиешле ясакларны Аттилага түләмим,—ди.—Мин исән чагында Константинополь Аттилага баш имәячәк»,—ди.

Аттила *(уйга кала)*. Менә ничек... Ул минем көн батышына яу белән барырга җыенуымны сизенгәндер, шуңа койрыгын күтәрәдер. Фракия ишәге! *(Чапкынга.)* Бар, чык.

*Чапкын чыгып китә.*

Атакам. Бәлки, Рим җирләренә барудан хәзер баш тартырсың?

Аттила *(тагын җанлана)*. Хәзер инде бигрәк тә баш тарта алмыйм. Византия белән сугышу өчен күбрәк көч кирәк. Мин көн батышындагы Рим империясенең Галлиясен булса да алырга тиеш. Шуннан соң Византияне таптаячакмын. Халыкка нинди дә булса җиңү кирәк, аннары шул шаукым белән җинелмәстәйләрне дә җиңеп була. Ә син мине Итил буйларына кайтып китәргә өндисең.

Атакам. Галлиягә кергәнең өчен бөтен Рим империясе өстеңә ташланса?

Аттила. Сугышу турында гына уйларга кирәкми. Килешеп тә була бит әле. Миндә Гонориянең вәгъдә йөзеге бар. Ул минем хатыным булырга тели. Гонория инде күптән үзенең булдыксыз абыйсы белән бергә император урынын бүлешергә тиеш.

Атакам. Алар Гонорияне юк итәчәкләр, шуның белән—бетте-китте.

Аттила. Гонориягә беркем дә кагылырга тиеш түгел. Әгәр дә Гонориягә үзләренең скипетр дигән нәрсәләрен бирмәсәләр, мин бик каты үч алачакмын.

Атакам. Гонориягә кем бирсен ди аны?! Рим империясе башында ир кеше генә тора ала.

Аттила *(кычкырып көлә)*. Валентиниан ир кешеме? Ха-ха-ха. Күкәйсез кәҗә тәкәсе. Марциан миңа каршы хәрәкәт башлаганчы, мин Галлияне алырга тиеш *(Нәфрәт белән.)* Мин боерачакмын: «Гонория минем хатыным, шуңа күрә ярты империя минеке булырга тиеш!» Валентинианга хат белән Чапкын җибәрәчәкмен—хуҗаң Аттилага затлы сарай әзерләп куй, дип.

## XII

*451 елда Каталаун кырында Аттиланың гаскәрләре һәм Аэций гаскәрләре арасында коточкыч сугыш була.*

*452 елда Аттила Италиягә яу белән бара.*

*Сугышчылар биюе. Кылычлар чыжлавы, уклар сызгыруы, сөңгеләр сынган тавышлар. Ат тояклары тавышы, кычкыру, ыңгырашу кебек авазлар. Биюдән соң тынлык урнаша.*

*Сәхнәнең бер ягында Аэций, икенче ягында Аттила. Икесе дә үзалдына берберсе белән күңелләрендә сөйләшәләр.*

Аэций. Их, Аттила, Аттила! Безне язмыш бер-беребездән һич аермый. Йә туганнарча дус без, йә канга батып сугышабыз.

Аттила. Минем башка чарам булмады, Аэций.

Аэций. Шунсы аяныч, мин үземнең балачактан белгән, яраткан кешеләремә каршы сугышырга тиеш булдым. Кырык елдан артык элек, һуннар илендә асрамада чагымда синең белән кайчан да булса кара-каршы сугышырбыз дигән уй башыма да килмәс иде.

Аттила. Ник соң син миңа каршы легионнар җыйдың?

Аэций. Син көн батышындагы Рим империясенең җирләренә бәреп кердең. Юлларында очраган илләрне тар-мар итеп Аурелианиумга кадәр барып җиттең. Аурелианиумны да алган булыр идең. Әмма мин анда алданрак барып җиттем, сиңа калаhistoire бирмәдем.

Аттила. Минем башка чарам юк иде. Һуннар сугышны теләде. Кайсы якка яу чыгарга белми аптырадылар. Мин аларга бер юнәлеш бирүче генә булдым.

Аэций. Минем дә башка чарам юк иде. Әйе, бу юлысы сугышка корольләр үз ыруларын кумады, ә киресенчә, ырулар үз корольләрен яуга куды.

Аттила. Син Орлеанга миннән алданрак барып җиттең. Каталаун кырына мин Аурелианиумны алырга курыкканнан чигенмәдем. Минем сине ачык кырда тизрәк тар-мар итәсем килде.

Аэций. Минем когорталарым өчен бик җайлы урын булып чыкты Каталаун кыры. Коточкыч һәм сәер сугыш булды ул. Синең якта скирлар, остроготлар, геруллардан башка римлеләр, франклар, бургундалр, антлар, тюринглар катнашты.

Аттила. Ә синең чирүеңдә римлеләреңнән тыш элек Рим белән мәңге тынышмаган вестготлар бар иде, аланнар,

саксларл, шул ук франклар, бургундлар.

Аэций. Әйе, барысы да буталып бетте. Без үзебезгә каршы үзебез сугышабыз түгелме?

Аттила. Юк, мин төгәлрәк әйтәм: һәрбер кеше үзенә каршы үзе сугыша. Моны беләсеңме кайчан аңладым мин? Каталаун кырында сугыш тынгач. Мин чигендем. Ләкин җиңелеп түгел. Рим империясенә яңа сугыш башларга әзерләнергә мин шундук карар кылдым. Синең Каталаун кырында миңа каршы сугышуың—синең үз-үзеңә каршы сугышу булып чыкмадымыни?

Аэций. Син чигендең, ә мин сине эзәрлекләмәдем.

Аттила. Хәлең бар идеме соң эзәрлекләргә? Эзәрлекләргә идең. Юу-у-ук, син мине эзәрлекләргә курыктың. Чөнки син мине бала чагымнан ук беләсең.

Аэций. Әйе, Каталаун кырындагы сугыштан соң бер ел узгач, син Рим империясенә тагын бәреп кердең. Син Италиядә талаган байлык тагын бетәчәк. Күпме шулай дәвам итәр икән?

Аттила. Белмим, Аэций. Ул байлык минем үземә кирәкми. Ил-көннең көн саен тамагы тук булырга тиеш. Син бит беләсең, мин агач савыттан ашыйм, катыда йоклыйм, алтын-көмешкә исем китми. Яулар белән барып уңыш җыймасам, мине тәхеттә тотмаячаклар. Җиңелүчеләрне генә түгел, җиңмәүчеләрне дә тәхеттән тиз бәреп төшерәләр.

Аэций. Моның ахыры булырга тиеш бит.

Аттила. Сезнең атаклы калагыз Аквилеяны алгач, мин По үзәнлеген таладым. Медиолан белән Павия бирелеп котылдылар. Беләсеңме, мин нинди бәхет кичердем шул вакытларда. Үзем өчен түгел. Һуннар тагын кодрәт сулышы алганга канатландым мин. Син бит—Рим империясенең ышанычлысы, таянычы, саклаучысы—миңа каршы торырлык көч туплый алмадың. Валентинианыгыз миннән сугышны туктатуны елап сорады. Яхшы түләмәгән булсагыз, җирләрегездән китмәгән булыр идем.

Аэций. Мин белгән Аттила түгел син хәзер.

Аттила. Үзем белгән Аттила да түгел инде мин хәзер.

Аэций. Алга таба нишләргә җыенасың?

Аттила. Белмим. Сиңа сер итеп әйтәм: алны-артны карамыйча атыма атланып дала буйлап чабасым килә. Кояш чыккан якка таба.

## XIII

*Аттила башын аска иеп утыра. Атакам керә.*

Аттила. Озак күренмәден.

Атакам. Озак чакыртмый тордың.

Аттила. Син бит инде чакырмыйча да килергә тиеш.

Атакам. Рим җирендә йоккан үләт чиреннән халык кырыла, эшем күп.

Аттила. Нишләп яхшы, тугры кешеләрем күбрәк үлә, бер нәрсәгә яраксызлары исән, яшиләр, минем тирәдә кыймылдыйлар?

Атакам. Бәлки син үлгән кешеләрнең кадерен генә аңлыйсыңдыр.

Аттила. Юу-у-ук. Алай түгел. Хәзер мин соңгы вакыттагы куркуымның сәбәбен әйтәм. Без көчле кебек, әмма ил-көннең тәртибе юк. Тарханнарым, биләрем урлаша. Хәтта янәшәмдәге яраннар сатыла. Мин инде болай да һуннар империясе затлы булсын өчен, яудашларыма, җир хуҗаларына, алыпсатарларга яңадан яңа мөмкинлекләр ачам, яхшы түлим. Күбрәк түләгән саен күбрәк сорыйлар. Ил идарәсендәгеләр майларына чыдый алмыйлар. Соңгы вакытта гына аңлый башладым: илнең, ырумның тамагын туйдырыйм дип мин нинди бер катламның бүксәсен генә туйдырам икән бит. Шуңа күрә мине киләчәк куркыта башлады. Малга, алтынга, татлы ризыкка күнеккән, муллыкка чумып яшәгән ыру кайчан да булса бер җиңелә ул.

Атакам. Син хаклы. Рим империясен дә шул чир екты бит.

Аттила. Мин яуда дошманның бугазын ерта алам, бирелмәстәй шәһәрләрне яулыйм, буйсынмаслык ыруларны тезләндерәм. Әмма мин үз ил-көнемдәге ришвәтчелекне, сатлыкҗанлыкны, комсызлыкны, мал хакына хыянәт итүне беркайчан да җиңә алмам, ахрысы. Минем аркадашларым бик аз калды. Чикләре хәттин ашкан илемдә таяныр-

лык кешеләрем бик аз минем. Ә күпмесенә мин тәмле калҗа бирүче буларак кына кирәк?!

Атакам. Илбашы беркайчан да үзүзенә буйсынмый инде ул. Аның яраннары, ярдәмчеләре тулаем алганда илбашының үзенә караганда көчлерәк була. Ил-көнендә ришвәт, сатылу, урлау җәелгән икән, монда син гаепле, чөнки син—Илбашы, син Ил—Атасы, син—Аттила!

Аттила. Алайса, ник мин һаман дөньяны яулап алырга омтылам? Үзем өченме? Әллә минем казнадан акча чумырып зур-зур түрә булып утыручылар өченме? Мин егылсам, алар шул ук көнне илне, малны бүлгәләргә тотыначак бит. Улларым нишләр? Алар өчесе өч төрле холыклы. Миннән соң тота алырлармы ил-көнне? Киләчәктән курка башлагач, кирәк микән дөньяны яуларга омтылу? Мөмкинме соң ул бүгенге халәтебездә дөньяны яулап алу? Беләсеңме, кайчан бөтен дөньяны яулап аласымда шик туды?

Атакам. Каталаун кырындагы сугыштан соң, Галлиядән чигенгәндәме?

Аттила. Юк. Каталаун кырына барганда. Гаскәремә шакаллар көтүе ияреп барды. Сугыш алдыннан алар гел якын тирәдә тиздән сыйланачакларын сизенеп йөриләр. Ә бу юлысы аз гына да курыкмыйча, янәшә бардылар. Шунда мин аларга карап уйладым: көтеп кенә торалар бит, егылганыңны көтеп кенә торалар. Нинди дөньяны яулау, хәтта бу шакалларны да мин беркайчан бетерә алмаячакмын бит. Атакам! Көн батышына барсам да, көн чыгышына кайтсам да, ил-көнемдә ач этләр булачак, ач шакаллар артымнан ияреп йөриячәк. Дөньяны куркытып торам дип уйласам да, үземә гел куркыныч янап торачак.

Атакам. Картаясың, Аттила. Яшьрәк чагыңда мондый уйлар килер идемени башыңа?! Язмышыңнан беркая китә алмаячаксың. Атаң Мундзук олыгайган саен шушы уйлар белән бимазалангандыр. Атаңның атасы Улдан картайган көнендә синең кебек кайгырмагандыр дисеңме! Бабаңның атасы Торды Күккә очар алдыннан киләчәк өчен газапланмаган дисеңме!

Аттила. Мин ничек үләчәкмен дигән идең әле?

Атакам. Татлы үлем белән.

Аттила. Ошамый башладың әле син миңа.

Атакам. Чөнки мин синә комачаулый башладым.

Аттила. Ышанасыңмы, юкмы, мин хәзер чынлап нык куркам.

Атакам. Беләм нәрсәдән курыкканыңны. Болай озак дәвам итмәячәген аңладың. Нәселеңнең, ыруыңның, халкыңның каны буталып бара, бетүгә таба бара.

Аттила. Ә римлеләрнең, византылыларның, башкаларның каны буталмыймы?

Атакам. Алар хәтерне бетермиләр. Алар бүгенгене ташка баса. Киләчәктә синең турыдагы риваятьләрне дә шуларның хәтере аркасында сөйләячәкләр. Бәлки шуңа уйга калгансыңдыр әле син?

Аттила *(сикереп тора, акыра).* Мин аларның барысыннан да көчлерәк!

*Кинәт аның борыныннан кан китә— өянәге башлана. Атакам аны ятакка яткыра. Ясауллар ыгы-згы киләләр.*

Аттила *(чак кына башын калкытып, Атакамга эндәшә).* Кайлардан килеп чыктың син? Мин бит сине чакырмаган идем.

Атакам. Мин—синең газабың. Чакырып килә торган нәрсә түгел мин. Газапсыз яшәмәкче идеңме? Юк, алай булмый. Иң ерак бабаңны да хәтерлим әле мин синең.

*Аттила ыңгырашып башын мендәргә куя.*

Атакам *(сакчыларга).* Минем кызым Илиркәне чакырыгыз!

*Илиркә керә.*

Атакам. Җырла, Илиркә.

*Илиркә җырлый.*

Алдый күзне алтын-көмеш ялтыравы,
Бернәрсә дә алыштырмас көн балкышын.
Нинди генә тәмле ризык бирсәләр дә
Тар читлектә яши алмас дала кошы.

Һәркем китә, һәрбер нәрсә җиргә инә,
Җылы биргән учакларның кала көле.
Алып кайтып утыртмагыз түрегезгә,
Таш сарайда бик тиз шинә дала гөле.

Бу дөньядан төк тә алып китеп булмый,
Җимерелсә ил-көннәре, кала җире.
Гөлләр сула, кошлар үлә, байлык бетә,
Барсыннан да озак яшәр дала җиле.

*Аттила, торып, әкрен генә килә һәм Илиркә алдында тезләнә. Аның тезләнүен күреп барысы да таң калалар.*

Аттила. Белсәң иде бу жырның миңа ничек якынлыгын.

Илиркә. Тор, бөек император. Син кояш астындагы барлык илләрне тетрәндерүче.

Аттила. Мин әле генә тыңлаган жыр алдында тезләнәм.

Илиркә. Абыем монда кире кайтып, син аңа тимәдең, яуларда катнаштырдың, үз урынына билгеләдең. Шуның өчен мин тезләнәм синең алдыңда.

*Илиркә тезләнмәкче була. Аттила аны ике куллап тота һәм тезләндерми.*

Аттила. Син—Илиркә. Син илнең иркәсе булырга тиеш. Синнән дә гүзәлрәк кыз күргәнем юк минем.

Илиркә *(елмаеп)*. Синең берсеннән берсе матуррак кырыктан артык хатының бар.

Аттила. Синең шикеллесе юк. Мин туйдым барысыннан да. Миңа син генә кирәк. Бүгеннән син—минем хатыным. *(Кычкырып игълан итә.)* Туй!

## XIV

*Еракта туй авазлары яңгырап тора. Йокы бүлмәсенә Аттила Илиркәне күтәреп алып керә. Аттила бераз исерек.*

Илиркә. Хужам, әллә син исерек инде?

Аттила. Безнең кымыз болай исертми. Римлеләрнең эчемлеге башны болгата.

Илиркә *(көлә)*. Синең кебек бөек императорның да башы болганамыни?

Аттила. Юк ла, сәбәп аракыда түгел. Мин янадан яши башладым шикелле. Бүгенге төннән соң өр-яңа яшәвем башланачак. Бөтен нәрсә үзгәрәчәк. Дөнья үзгәрәчәк.

Илиркә. Дөнья үзгәрсә яхшы булыр иде. Без үзгәрсәк кенә үзгәрер шул ул.

Аттила. Без үзгәреп кенә үзгәрер микән соң? Безнең бу беренче төнебез. Баш катырып уйлана торган төн түгел. Без синең белән бербөтенгә әверелә торган төн бу.

Илиркә. Әйе, хужам...

*Илиркә сүзләрен әйтеп бетерә алмый, Аттила аны кайнар итеп үбәргә тотына. Шуннан соң урын өстенә яталар. Карангылык. Музыка. Сәхнәгә бераз яктылык төшә.*

Илиркә *(куркып кына)*. Мин ошадыммы сиңа?

Аттила *(яткан килеш кочаклап)*. Сине нәрсә белән дә чагыштырырга белмим! Татлы син, татлы, татлы, татлы!

*Аттила торып чүлмәктән тустаганга эчемлек сала. Йотлыгып эчә. Кинәт аның борыныннан кан китә.*

Аттила. Тагын борынымнан кан килә. *(Башын өскә күтәреп тора.)*

Илиркә. Кил, ятып тор.

*Аттила Илиркә янына килеп ята. Кинәт Аттиланың гәүдәсе кәкрәя, ул гырылдый башлый. Илиркә нишләргә белми. Аттила үлә. Илиркә кычкырып читкә тайпыла. Шәмдәлне аудара, ут сүнә. Карангыда ыгы-зыгы куба. Аттиланың кешеләре атылып килеп керәләр, кулларында факеллар. Аттиланы әйләндергәләп карыйлар. Атакам пәйда була. Атакам шул ыгы-зыгыда Илиркәне алып чыгып китә.*

Бер тавыш. Илиркә кая югалды? Кая юкка чыкты ул?

Икенче тавыш. Атакам да күренде. Ул кайда?

*Атакам бөтенләй икенче яктан килеп чыга.*

Атакам. Монда мин.

*Аны күргәч барысы да читкәрәк китәләр. Атакам тынсыз ятучы Аттиланың күкрәгенә колагын куеп тыңлап карый.*

Атакам *(әкрен генә алга атлап)*. Аттила очты. Аттила очмакта.

*Барысы да тораташ булып катып калалар.*

## XV

*Уналты ел вакыт узган. 469 ел. Днестр буе. Көнчыгышка таба качып баручы һуннарның кечкенә бер төркеме урнашкан лагерь.*

*Илиркә урын өстендә ята. Аның янында улы Алгыр утыра.*

Илиркә *(иреннәрен көчкә кыймылдатып).* Алгыр, улым, мин инде бүтән торалмам. Бу чир мине инде җинде бугай. Син, улым, кояш чыккан якка бар да, бар. Кайт син шул якка таба. Монда, Днестр буенда озак ятарга ярамый. Һуннарны эзәрлеклиләр.

Алгыр. Һуннар төркем-төркем булып көн чыгышына агылалар. Мин дә шул якка юл тотармын.

Илиркә. Һуннарның калдыклары кайтканга түгел, ә атаң гомере буена көн чыгышы ягына борылырга хыялланып яшәгәнгә кайтырга тиеш син анда таба. Синең атаң ул хыялын барысыннан да яшереп яшәгән кеше.

Алгыр. Син барыбер минем атам кем булганны әйтмәдең. Төрлечә ялганладың, тик дөресен әйтмәдең.

Илиркә. Мин сиңа хәзер аны әйтәм.

Алгыр *(якынрак килеп).* Әйт, анам, әйт.

Илиркә *(улына шактый вакыт карап торгач).* Синең атаң—Аттила.

Алгыр *(өнсез калып).* Аттила?!

Илиркә. Әйе, син—Аттиланың улы.

*Алгыр сикереп тора, аннары анасы алдында иелә. Илиркә Алгырның кочагында үлә.*

*Сәхнә карангылана. Сәхнә яктырганда Алгыр белән Атакам учак янында утыралар.*

Атакам. Атаң үлгәннән соң, бер ел эчендә һуннар иле таркалды. Шул ук елны Рим императоры Валентиниан Аэцийны үз сараенда чәнчеп үтергән. Озакламый Валентинианның үзен дә үтергәннәр. Гонорияне бер консулга хатынлыкка бирделәр дә, бөтенләй ил-көн эшләреннән ерагайттылар. Аттила үлгәч, Рим империясе өчен иң куркыныч кеше юкка чыкты кебек. Ләкин Рим империясе таркалуын, җимерелүен һаман дәвам итә. Аттиланың хәтта кайда күмелгәнен дә белмиләр, ә шулай да аның йогынтысын яшерен кабер чикләре тотып торалмый. Аттила барыбер әле һаман да Көнбатыш Рим империясен котылгысыз җимерелүгә этәрүче вакыйгаларда катнаша бирә.

Алгыр. Син миңа абыйларым—Аттиланың уллары турында сөйлә.

Атакам. Абыйларың һуннар илен сакларга тырышып бар көчләрен куйдылар. Тик илне яңадан җыйнау мөмкин түгел иде. Иллек абыең баш күтәргән ыруларны буйсындырганда һәлак булды. Ирнәк белән Диңгиз абыйларың моннан өч ел элек чирүләрен берләштереп, Константинопольне һуннарга буйсындырырга маташтылар. Әмма византлылар баш имәделәр. Аннары Диңгиз готлар җиренә керде. Готлар һуннарны җиңделәр. Диңгизнең башын чабып Константинопольгә озаттылар. Ирнәк абыеңның язмышы беркемгә билгеле түгел. Ә инде исән калган һуннарның көн чыгышына таба качуларын беләсең—үзең дә шулар арасында.

Алгыр. Кем иде минем атам? Кем иде ул Аттила?

Атакам. Бөек иде ул. Шул ук вакытта кол иде. Ыруларны, илләрне тезләндергән кеше иде ул. Шул ук вакытта ыруларның, илләрнең язмышыннан беркая киталмаган чыңбарлыкның бер колы иде.

Алгыр. Син минем анам Илиркәне коткарган кеше. Мин сиңа бурычлы.

Атакам. Синең миңа бер бурычың да юк.

Алгыр. Без синең белән бергә китәбезме?

Атакам. Юк. Минем башта Аттиланың рухы белән очрашасым бар.

Алгыр. Син минем атама үлгәч тә тынгылык бирмәскә булдыңмы?

Атакам. Аттилага инде мәңгелек тынгысызлык язган. Чөнки бу дөньяда тирән эз калдырган кешеләр һәрвакыт кирәк, аларны гел эзләп, барлап торачаклар. Мин—аның газабы—дөньялыкка мәңге эндәшеп торырмын. Шуна күрә: «Кайда син, Аттила?!»—дип киләчәктә дә әллә кемнәр кычкырачак. Исән калган һуннар көн чыга торган якка кайталар. Бәлки, абыең Ирнәк инде Итил буйларына җиткәндер. Син дә шул якка бар. Беркемгә дә Аттиланың улы икәнеңне әйтмә. *(Туктап тора.)* Юк, бу киңәшемә колак салма. Үзенә кара. Мин дә соңрак шунда юл тотармын.

*Алгыр китә.*

## XVI

*Атакам учак янында ерак бабаларнын рухлары белән сөйләшә башлый. Атакам экстазга кергәндә, аның янына Аттиланың рухы килә. Аттила ап-ак киемнән, ул яланаяк һәм коралсыз. Атакам аңа текәлеп карап тора.*

Аттила. Мин котылдым синнән.

Атакам. Кемнән?

Аттила. Синнән—бәгырем газабыннан. Шуны гына аңлый алмыйм—ничек син минем үзәгемнән чыгып әллә кайларда йөри алдың—Константинопольдә, Римдә, тагын әллә кайларда?

Атакам. Синең газабыңны белсеннәр өчен.

Аттила. Аны болай да беләләр иде. Хәзер котылдым инде. Мин үзем дә хәзер теләсә кайда йөрим—мин ирекле.

Атакам. Аттила, тукта!

*Аттила бер мәлгә югала.*

Атакам. Аттила, кайда син?

*Атакам үзенең шаман хәрәкәтләрен ясый. Тагын Аттила пәйда була.*

Аттила. Күп еллар узгач та: «Кайда син, Аттила?!»—дип оран салучы ырулар булачак әле.

Атакам. Моны мин сиңа әйткән идем. Минем сүзләремне кабатладың.

Аттила. Соңгы вакытта мин синең сүзеңнән чыкмадым. Кайт дип гел газабыма кайтырга өндәгәненне хәзер генә аңлыйм.

Атакам. Ничек уйлыйсың, сине мин үтергәнне белерләр микән?

Аттила. Татлы үлем белән үләчәксен, дигән идең. Киләчәктә шулай санаячаклар. Минем үзәгемдә газап яшәгән дип уйламаслар. Иң нык газапланган кол идем мин.

Атакам. Чын кеше өчен, бөек кеше өчен жан газабыннан үлүдән дә татлырак үлем бар микән?!

Аттила. Белмим.

*Аттила китеп бара. Атакам Аттила киткән тарафка карап торганда, бераз бөкрәебрәк, куркыныч күзләрен елтыратып, кап-кара киемнән Вигил килә.*

Атакам *(Вигилгә карамаска тырышып).* Мин сине чакырмадым.

Вигил. Холыкның начар өлеше дә чакырып килми, ул үзе килә. Син—газап—рухият, сагыну, киләчәк белән үткәннәрне уйлау өчен жавап бирәсең. Мин—әшәкелек—кешедәге комсызлык белән кансызлык исеменнән йөрим бу дөньяда. Беребез дә чакырып килмибез, үзебез киләбез. Аттила беребезне дә чакырмады. Үзебез аңа таба омтылдык. Әмма син өлгеррәк булып чыктың. Син башына җиттең Аттиланың, мин түгел.

Атакам. Минем синең белән сөйләшәсем килми. Хәтта көрәсем дә килми! *(Пычагын чыгара.)*

Вигил *(пычак чыгарып).* Без синең белән мәңге сугышачакбыз, ләкин беребез дә җиңмәячәк. Каталаун кырында беркем беркемне җиңмәгән кебек.

Атакам. Бер сугышта да беркем беркемне җиңми.

Вигил. Шул без синең белән—яхшылык белән әшәкелек бер-беребезне җиңә алмаганга бит ул.

*Пычакларын алга сузып бер-берсенә кыжрап торалар. Ләкин сугышмыйлар. Вигил әкрен генә китеп бара. Илиркәнен һун жырын жырлаганы ишетелә. Атакам пычагын яшерә.*

*Атакам Илиркә жырлаган көйгә үзенең кам биюен бии.*

Жил жыруын жылый-жылый жырлый,
Без барасы якка ул ага.
Барыр юллар якты булсын өчен,
Ай яктысы төшкән далага.

Жил жыруын жылый-жылый жырлый,
Охшаган ул жырлы йолага.
Барыр юлдан кире кайтмаслар дип,
Моң яктысы ингән далага.

*Зур экранда Аттила, атка атланып, Кояш чыккан якка чаба.*

*Тәмам.*

*2008 ел.*



Гарифҗан
Мөхәммәтшин

## КӨТ КЕНӘ ГОМЕР ЯЗЫМДА...

***

**Үзем җирдә, күңелем күктә минем,**
**Тәңрем җиргә шулай яраткан,**
**Туганда ук керсез күзләремне**
**Зәңгәр күкләренә караткан.**

**Әллә шуңа гомер гомерләп тә**
**Сабыйлыгын җуймый күңелем,**
**Төнлә йолдыз, көндез былбылларны**
**Учларыма алам үрелеп.**

**Шушы җирне җылытырга теләп**
**Күпме түктем йөрәк җылысын,**
**Гел елмайдым дөнья елмайсын дип,**
**Килгәндә дә үксеп елыйсым.**

**Үзем җирдә, күңелем күктә минем,**
**Язмышыма шулай язылган—**
**Бәхет бит ул бик зур була алмый,**
**Мәхрүм калдырмасын азыннан.**

***

**Мин бәхетне туган җирдән таптым—**
**Куеныннан ургып чишмә булып актым,**
**Инеш булып еракларга киттем,**
**Яңгыр булып кабат шунда кайттым.**

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН (1941) – *шагыйрь, публицист; «Килегез, дусларым», «Керим әле урманнарга», «Робагыйлар бакчасы» һ. б. китаплар авторы. «Татнефть»нең С. Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Балтачта яши.*

Гел вакытында гына явалмадым,
Йә иртәрәк яудым, йә соңардым,
Тик барыбер шушы изге җирне—
Туган җирне генә сугардым.

***

Җаныңның иң өзгәләнгән,
Юксынган мизгелендә
Килеп җитәрмен яныңа
Мәхәббәт тизлегендә.

Канатлы хыялларымның
Тотмамын тезгенен дә,
Килеп җитәрмен яныңа
Мәхәббәт тизлегендә.

Очып килермен яныңа
Мәхәббәт тизлегендә—
Көт кенә гомер язымда,
Калдырма көзлегемә.

***

Чишмәдән кайталар яшь кызлар
Чиләккә шаян җыр тутырып,
Чиләкнең читенә тезелеп
Тамчылар кайталар утырып.

Тамчылар кайталар шаярып,
Кояшның нурларын чеметеп,
Кызлар күк елмая тамчылар
Җемелдәп, җем-җем-җем итеп.

***

Күбәләк тә түгел түгелен,
Тик гел утка тарта күңелем,
Уйламый да янып үләсен,
Кемнәрнеңдер сөенеп көләсен—
Уттан яралгандыр, күрәсең.

Яшеренми кемдер артына
Омтыла ул һаман яктыга,
Арынырга теләп карадан,
Яңа туган кебек анадан
Яши башлау өчен яңадан.

Аклык җитми бүген җаннарга
Изге хисләр белән янарга—
Уңнан-сулдан ачы зар алып,
Түбән ваклыкларга уралып
Дөнья бара тоташ каралып.

Күбәләк тә түгел түгелен,
Утка тарта һаман күңелем—
Таратыйм, дип дөнья карасын
Килә бер шәм булып янасым,
Якты булып җирдә каласым!...

***

Өзгәләнеп язны көтәм—
Каршы барырмын кебек,
Карлар киткәнне дә көтми
Яфрак ярырмын кебек.

Үлән булып юлларына
Дәррәү шытармын кебек,
Кыраулар үткәнне көтми
Чәчәк атармын кебек.

Нигә икән?
Әллә бу яз
Китмәс өчен киләме,
Әллә инде соңгы язым
Миннән шулай көләме?!

***

Килә бик авызлыклыйсым
Язмышның явызлыгын—
Инде тезгенлим, дигәндә
Табалмыйм авызлыгын.

Китим, дим ерак-еракка
Язмышның шуклыгыннан,
Тик... менәр атым югалган
Сикереп утлыгыннан.

Качам язмыш тырнагыннан
Бер чара белән генә—
Кыйнаса да, шаярса да
Елмаеп көләм генә!

***

Ике йөрәк омтылганда кара-каршы
Кырыс акыл ашыкма, дип килә каршы,
Матәм көе яулап ала күңелләрне
Яңгырыйсы чакта татлы сөю маршы

Гашыйк жаннар гомер кичә исәр булып,
Акыллылар—акылына әсир булып,
Акыл дигән кырыс патша эргәсендә
Башын игән тугрылыклы вәзир булып.

***

Кешеләргә аңлашырга һай күп кирәк,
Бере-берен җиңел аңлый ике йөрәк,
Тик язмышнщ иң хәлиткеч мизгелендә
Йөрәк сүзен тыңлаучылар җирдә сирәк.

Андый чакта йөрәк һаман читтә кала,
Йөрәктәге хисләр тимер биктә кала,
Биктә калган изге хисләр кеше җанын
Гомер буе сүнми торган утка сала.

## Сәҗдә

Иелдем дә сәҗдә кылдым—
«Сөбханә раббил әгълә»,
Күңелемдәге вәсвәсәләр
Эреп югалды мәллә...

Иелдем дә сәҗдә кылдым—
«Сөбханә раббил әгълә»,
Изгелекнең изге куенына
Иңде җаным бу мәлдә...

Җаным минем былбыл булып
Очып китәр бер хәлдә,
Иелдем дә сәҗдә кылдым—
«Сөбханә раббил әгълә»,
«Сөбханә раббил әгълә»,
«Сөбханә раббил әгълә».



Җәүдәт
Дәрзаман

# АП-АК КАРЛАР ЯВА...

ПОЭМА

**Ап-ак карлар ява бурап-бурап,**
**Ак бөртекләр оча урап-урап.**
**Әллә томан шунда, әллә буран,**
**Оеп, уйга калган кышкы урам.**

**Нинди хисләр соң бу, нинди халәт,**
**Керфекләргә куна ак күбәләк.**
**Бөтен хәят чумган сихри акка,**
**Яңа елга кереп барган чакта.**

**Пакьлек сирпеп тора бар агачлар,**
**Ак күбеккә баткан алмагачлар.**
**Әйтерсең лә алар чәчәк аткан,**
**Атмаганы гүя ак шәл япкан.**

**Бар тарафта аклык, пакьлек кенә,**
**Күңелләрдә керсез шатлык кына.**
**Куеннарга салкын җил керсә дә,**
**Бу мизгеле җанның шундый садә!**

**Ап-ак карлар ява бурап-бурап,**
**Ак бөртекләр оча урап-урап.**
**Әллә томан шунда, әллә буран,**
**Сихерләнеп, шуңа карап торам...**

Җәүдәт ДӘРЗАМАН (1945)—*шагыйрь, прозаик, публицист; «Безнең әлифба», «Кузле кычыткан», «Җир авазы», «Чорлар кайтавазы» һ. б. егермегә якын китап авторы. Татарстан мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең А. Алиш, «Татнефть»нең С. Сөләйманова исемендәге премияләре лауреаты. Казанда яши.*

***

Кар болытын җилләр сүтеп бара,
Ел арты ел шулай үтеп бара,
Уралса да уйлар ак хыялга,
Уза гомер, уза, атлый алга...

Ярдан дулкын каккан көймә кебек,
Бер ел чикте дисбе төймә кебек.
Чигәләргә сылап карның агын,
Бер ел гомер узып китте тагын...

Ап-ак карлар ява бурап-бурап,
Уй-гамьнәрем кайта урап-урап,—
Урап кайта бәхет көткәннәргә,
Китеп бара ерак үткәннәргә...

Тукай искә төшә ничәнче кат,
Искә төшә мескен теләнче карт.
Гасыр түгел, бары еллар санап,
Тукай язган ул карт кайткан кабат.

Таңкә көткән учка тик кар төшә,
Салкын кардан картның учы пешә.
Ялварулы багып уңга-сулга,
Кереп бара ул да... Яңа елга.

Кемнәр аңлар хәлен, кемнәр җайлар,
Ярлы хәлен белми яңа байлар.
Сыңар тиен төшми кулларыннан,
Тик җил исә йөргән юлларыннан.

Искә төшә инде ничәнче кат
Тукай язган мескен теләнче карт.
Һәм каршыга шул карт килеп баса,
Ул биш гасыр гомер кичкән ләса!

Димәк, әле дәрт бар, дәрман да бар,
Тезләнмәс ул, булыр—ярдәм табар.
Алмыш сыман кабат торып басар,
Үз йортында үзе бәйрәм ясар!

...Ап-ак карлар ява бурап-бурап,
Ак бөртекләр оча урап-урап.
Әллә томан шунда, әллә буран,
Оеп, уйга талган кышкы урам.

Нинди хисләр соң бу, нинди халәт,
Керфекләргә куна ак күбәләк,
Һәм нигәдер шунда күңел тулып,
Эленә ул аннан энҗе булып.

* * *

Карлар ява, ап-ак карлар ява,
Аклыклары күңелләргә дәва.
Пакьлекләре шифа йөрәкләргә,
Ак нур иңә изге теләкләргә:

«Имин булсын килер еллар гына,
Язсын тигез, имин юллар гына.
Ходай бездән бәхет кызганмасын,
Көнчелектән дошман сызланмасын!

Куәт бирсен безгә, гомер бирсен,
Җилдә көйрәр кайнар күмер бирсен.
Җаннар тыныч булыр безнең ул чак—
Давылда да сүнмәс безнең учак!»

Ул давыллар юкса була тора,
Дәрьяларга ташлар тула тора,
Хәрабәләр ясый калаларны,
Үксез итә ятим балаларны.

Һәм шул мизгел Такташ искә төшә,
Шагыйрь шигырь яза тирли-пешә:
«Чемберленның сатыйм анасын,—дип,
Тупка тоткан Мәккә каласын!»—дип...

Яза шагыйрь каләм сындырганчы,
Бунтарь җанын тәмам тындырганчы.
Мисал эзлим бугай бик ерактан,
Гыйбрәт алмыйк әле ник Гыйрактан?!

Ул Гыйрак соң бездән еракмыни,
Туп астында калыр Гыйракмыни?!
Бу вәхшәтне ничек атарга соң,
Клинтонның кемен сатарга соң?!

Тәүбә, тәүбә! Инде бу заманда,
Гөнаһ җыймыйк изге Рамазанда.
Читтә торып торсын эчкер, рия—
Тик күңелдән китми... Ичкерия.

Күпме йортлар ауган, җиргә чүккән,
Үзебез үк безнең канны түккән,
Һәлак иткән вәйран күпме җанны,
Аттырмыйча калган күпме таңны...

Йа бер Хода, инде Яңа елда,
Чыгар безне изге, яңа юлга.
Кадере булмас алтын, гәүһәрләрнең,
Гомерен киссәң яңа Җәүһәрләрнең.

...Ап-ак карлар ява бурап-бурап,
Ак бөртекләр төшә урап-урап.
Әллә томан шунда, әллә буран,
Таңга калып, шуңа карап торам.

Нинди хәят соң бу, нинди кичләр,
Тынгы бирми җанга нинди хисләр?
Үзе рәхәт, авыр, үзе моңсу,
Дулкынлана күңел, күзләр дымсу...

* * *

Ап-ак карлар ява бурап-бурап,
Килер елга байлык, муллык юрап.
Алса да җил кайчак дулап-дулап,
Бар табигать йоклый иркен сулап.

Салкыннардан уйга калган килеш,
Боз астында ага талгын инеш.
Үзенә бер рәхәт, тынлык тоеп,
Йокы килеп китә оеп-оеп...

Әйтерсең лә җәйге кайнар рәшә
Югарыга сине, күккә дәшә.
Тынычланып калган сыман булып,
Ул тарала җиргә томан булып.

Уйлар—томан. Тылсымланган сыман,
Әйтерсең лә мин тәнемнән чыгам.
Авырлыгым кимеп югалуга,
Томырылам күккә, югарыга.

Һай, җәмәгать, рәхәт биеклектә,
Даһилык та монда, бөеклек тә.
Бер татысаң аның ямь-тәмнәрен,
Тарала да бетә уй-гамьнәрең!

Анда—күктә—сиңа балык та юк,
Ярдәм көткән фәкыйрь халык та юк,—
Менә кайда сиңа ул чын бәхет—
Үзең патша монда, үзең тәхет.

Ихлас шулай, әгәр тәмен тапсаң,
Тагын үрлим, диеп, өскә баксаң...
Адәм булсаң ләкин,—кендек җирдә,
Һәм җирдәдер бәхет асыл иргә.

...Күңел тагын иләс. Уйлар—болыт.
Якынаям җиргә болыт булып.
Кыйтгаларны бер кат урап чыгам,
Халыкларның хәлен сорап чыгам.

Күп илләрдә: «Шөкер, имин!»—диләр,
Йөзләр көлә, күзләр җемелдиләр.
Кайберендә: «Сездәгечә,—диләр,—
Кыргый байлар канны эчә!—диләр.—
Җимеш тә юк безнең, бакча да юк,
Хәләл эшкә тигән акча да юк...
Изелүдән арган, хәлдән тайган,
Яшәп ятыш шунда, мисле хайван...
Ризык кайгыртуда бөтен гамәл,
Табылырмы моннан чыгар әмәл?!»

* * *

Ап-ак карлар ява бурап-бурап,
Ак бөртекләр оча урап-урап.
Әллә томан шунда, әллә буран,
Ниндидер бер сәер хәлдә торам.

Җил карлардан ак биләүләр үрә,
Төш күрәмме әллә аягүрә?
Бар икән соң тагын ни күрәсем?
Сурәт булып туды шундый рәсем:

Борис патша, имеш, тау башында,
Зур җәнлеккә чыккан ау башында.
Ике башлы бөркет иңбашында,
Әмер көтеп баккан илбашына.

Каршы якка елгыр Барыс баскан,
Як-ягына көмеш калкан аскан.
Ак канатлар әзер талпынырга,
Бөркет тырнагыннан тайпылырга.

Булмасын дип һөҗүм башка төштән,
Алга күтәрелеп баса төшкән...
Шундый рәсем: елгыр Барыс тора,
Каршы якта патша Борис тора.

Нинди уйлар икән илбашында,
Ике башлы бөркет иңбашында...

Бурап-бурап ап-ак карлар ява,
Аклыклары күңелләргә дәва.
Пакьлекләре шифа йөрәкләргә,
Ак нур иңә изге теләкләргә:

«Имин булсын килер еллар гына,
Язсын тигез, имин юллар гына.
Раббы бездән бәхет кызганмасын,
Көнчелектән дошман сызланмасын.

Куәт бирсен безгә, гомер бирсен,
Ялкын сүнсә, кайнар күмер бирсен,
Давылы да хәвеф булмас ул чак,
Ут тергезер кабат безнең учак!»

Марат Әмирханов

# ИХ, МАТЬ ЯКАСЫН, ЧЕРЧИЛЕГЕЗНЕҢ САТЫЙМ КАРГАСЫН...

САТИРИК ХИКӘЯ

Әбелмәлих колак очларын чеметтерерлек итеп эссе салдырды да озын ләүкәгә сузылып ятты. Кибәндәй олы гәүдәсе тәмам изрәп, майлары эрер хәлгә җиткәч, көл тырнап бакырган үгез тавышы белән:

—Башлан, их, мать якасын,—дип әмер бирде.

Әйләндерә-тулгандыра, купшак тәне чөгендер төсенә кергәнче чаптылар хуҗаны. Үзенең дә күнеле булды, күрәсең, мунчачыларга «чәйлек»не дә мулдан тамызды.

—Абзагыз исәнлегенә бераз түбәтәй астын җылытып алырсыз,—диде.

Кунак бүлмәсендә, һәрвакыттагыча, барысы да әзер иде. Табын ул дигәнчә корылган. Өстәлнең нәкъ урта бер җирендә чиркәү гөмбәзедәй Акбаш балкып утыра. Мәрхүм атасы урман каравылчысы, бригадир ише йомышы төшәрдәй дәрәҗәле адәмнәрне генә сыйлый иде мондый хәмер белән. Дөрес, шешәнең тышкы кыяфәте генә «Акбаш»ны хәтерләтә, эчендәге зәм-зәм суының исә, ачуым килмәгәе, бер-бер тамчысы өч-дүрт «мәскәуский»га бәрабәр.

Экраны бөтен стенаны биләп торган тилетартма да кабызулы. Ягъни дә кымыз, кубыз бар, шайтан юлдашының өченчесе генә җитми. Хәер, Симсим кодрәте белән генә, әнә, каршыдагы зур ишек тә ачылып китте...

И һәм дә, әлгаязе билла, ишек уемында бал калагына салып йотардай чибәрдән-чибәр бер туташ пәйда булды. Тач хур кызы. Кием дигәне дә учка сыеп бетәрлек нечкә биленә уралган үтә тар кызыл тасмадан гына гыйбарәт.

Кул-аяклары, буй-сыны белән ниндидер ымсындыргыч хәрәкәтләр ясый-ясый сылукай Әбелмәлихка якынайды, сарылмак итте. Ләкин хуҗа кабул итмәде, күн диван тарафына төртеп җибәрде дә, Акбашны ачып, касәләргә хәмер тутырды.

—Их, мать якасын, әйдә, салып куй, Сафура,—диде.

—Миссамира,—дип, төзәтте чибәркәй.

—Мин әйткәч, Сафура булырсың, и баста!

Әбелмәлих кикереп җибәрде. Бу кикерек белән мул гәүдәсе кәнәфигә тәмам тулышты. Дулкын-дулкын булып рәхәтлек килде.

Безгә дөнья кармазин,
Их, мать якасын...

—Кичә кымын куймадым, шәп ял иттем,—дип мактанды Әбелмәлих иртән кулдашы Муллыйга.

Тегесенең юка иреннәре керәндил рәвешенә кереп бөжраланды.

—Ирнең ире ком өемен тау итә,—дип, Муллый нигәдер сырт җонын кабартты.

—Нәмә, әллә мин ком өемен тау итмәдемме?—дип, үз чиратында Әбелмәлих та кызып китте,—атайдан калган егерме сутый бәрәңге җирен мең мәртәбә арттырганымны белә торып, ничек шундай сүз сүләргә авызың ачыладыр, аңламаем. Алпаутларың бер якта торсын бит, исәр. Ишшу да...

—Мин бу турыда әйтмим,—диде Муллый,—бик беләсең килсә, кәеф-сафа коруыңның рәте-чираты юк, ничу кеше көлдерергә. Хаҗәте булмагач, ул Миссамираларны нигә дип чакыртырга инде, җә? Синнән ялкынсынып чыгалар да, шуфирларыңның кочагына атылалар...

—Үртәмә мине, биленне сугып сындырырга да күп сорамам.

—Сындырасың килә икән, сындыр, әмма дә ләкин...

Әбелмәлихның тар маңгаендагы җыерчыклары елан тумышлары кереп ятарлык булып тирәнәйде, өченче ияге гөнаһ алмасы астында кереп югалды. Димәк, башына уй килде. Мондый чакта аны бимазаларга ярамый. Муллый вак-вак кына баскалап, ишек катына юыртты. Ләкин чыгып китәргә өлгермәде, буш мичкә эченнән ишетелгәндәй Әбелмәлихның калын тавышы яңгырады.

—Әкүл, бүген нәмәгәдер гел кирегә саплап торасың әле, бер-бер яңалыгың бар ахыры, әйт, тыңлаем,—диде.

—Тагын әкүл?—дип күзләрен чекрәйтте Муллый.

—Ә-ә, ошамыймы,—диде Әбелмәлих кәефе килеп,—бер утыруда бер сарык ите ашап бетергән бирән икәнеңне бөтен кеше белә ләбаса. Тәнеңдә тотарлык нәмә дә юк, ә мөкелдәтүгә дисәң сине куш.

—Бәхәс хакына гына булды ич ул.

—Тыңлаем, сүлә,—дип, Әбелмәлих сүзне элекке эзенә төшерде.

Муллый күзләрен челт-челт йомгалап, фикерләрен рәткә китерде дә ният дәфтәренең тәүге сәхифәсен ачты.

—Абрамович әнә яхта сатып алган,—диде,—хәтта Англия корольләренең дә мондый зиннәтле карабы булмаган. Аның данын «Челси» футбол командасы түгел, нәкъ менә әлеге яхта җиһанга таратты. Вексельберг атлы икенче яһүд олигархы Фаберже күкәйләрен илгә кайтарып танылу алды.

—Ниемә миңа синең күкәйләрең?

—Бетте-бетте, әйттем исә кайттым,—диде Муллый.—Танылу өчен мал-мөлкәт кенә җитми, бай абзый, дөньяны шаккаттырырдай бер-бер хикмәт зарур. Татарны халыкара мәйданга чыгаруны Ходай Әбелмәлих өлүфмәнгә насыйп иткәндер, бәлки? Форсатны кулдан ычкындырырга ярамый.

—Ә ничек?

—Менә монысын бераз авыз чылатмыйча шәрехләп булмый инде, коры кашык авыз ерта, ди.

—Киттек утрауга, мать якасын.

Кама сусаклагычы төзелү белән бергә, күп кенә эреле-ваклы экзотик утраулар да хасил булды. Хәлле кешеләр арасында аларга чын мәгънәсендә ау башланды. Әбелмәлих та кушылды бу көрәшкә һәм иң зур утрауны үз исеменә рәсмиләштереп тә куйды. Ул анда нәселле ат көтүе тота. Уйнап кына башланган эш шактый керемле булып чыкты. Ял итү өчен дә сахра: кымыз, балык, җиләк-җимеш, яшелчә—һәммәсе бар.

Әшнәләр көнне шунда үткәрделәр. Күбенгәнче кымыз эчтеләр, күңелләре булганчы ат менеп чаптылар. Бу аларның иң яраткан шөгыле. Авыл малае туганда ук иярле ат өстендә туа ич инде ул. Арып-алҗып ялга туктагач, су дәрьясына карап хозурландылар.

—Үзебезнең Сөнгә житмәй инде, малай, аның суы ук икенче бит,—диде Әбелмәлих,—яңа сауган сөт кебек, жылы, парлы, пакь...

—Үз илең—Гөлстан, кеше иле—гүрстан,—диде Муллый,—зимагурлар жырындагыча:

Чит-чит, дидем, чит жир, дидем,
Чит иде теләкләрем...

—Кеше авыл турында жан ата, ә ул ишәктәй акыра,—дип кашын жимерде Әбелмәлих.

—Бер дә харап, мин ишәк булсам, син алаша, Сабир саран малае икәнеңне онытма.

Муллый бу сүзләрне кычкырып әйтмәде, фәкать уеннан гына уздырды. Әле уеннан уздырганда да айнып китте, чөнки Әбелмәлихның атасына сүз тигезгән кеше аның кан дошманына әйләнә.

Сабир саранның тарихы болай. Жәмәгате Хөллибану саулыкка туймый башлагач, умарта торгызырга ният иттеләр. Күрше авылдагы бер таныш хатын бал ашап кына аякка баскан, имеш.

Кирәк тирәкне ега ди, озакка сузмый гына Сабиржан авылда бердән-бер корт тотучы агачаяк Мәндинең ишеген какты.

Умартачы түр сәкегә жәелеп, өзек тезенә агач аягын ялгап маташа иде.

—Мин корт белән сату итмим, әнәтрәк,—диде йомышчының гозерен тыңлагач,—кул китә, аннан болай, сез наданнаргамы соң корт белән эш итү? Юкка баш ватып йөрмә, әнәтрәк.

Сабиржанның да дәлиле бар иде, шуңа хут бирде.

—Мәндимөхәммәт абзый, Хөллибануның нәселдәшең икәнен истән чыгарма, туган хакы—Алла хакы ди.

—Андый чыбык очларыннан гарык инде мин, әнәтрәк...

—Мәндимөхәммәт абзый, үзеңә гөнаһ алма...

—Әйдә, ярар, яхшылык ит тә суга сал ди, бирәм мин сезгә оя, көчлесен бирәм, үрчемлесен,—дип нигәдер тиз генә кайтып төште Мәнди.—Ә, хәзер, әнәтрәк, бар, кибеткә йөгер, ныгытып юылмаган килешү тиз өзелүчән...

Сабиржан берара ишек төбендә угаланып торды.

—Ни көтәсең, жәтрәк кыймылда,—диде Мәнди түземсезләнеп.

—Шайтан суына акча әрәм итәргә, теге, без черегән бай түгел лә,—дип мыгырданды тегесе.

—Сатулашма, беләм мин сезнең шүрлегегезнең буш түгел икәнен, әнәтрәк, юри, сынар өчен генә әйткән идем, кирәкми, бар, ычкын күземә күренмә.

Мәнди ачуыннан агач аягын Сабиржанга тондырды, ләкин ул чыгып өлгергән иде инде, аяк ишеккә килеп сугылды.

—Саран тәре...

Сабиржанның башын исә бу вакытта бөтенләй башка уй бораулый иде инде, хәтта йомышын да онытты, колак төбендә һаман шул бер сүз яңгырый: беләм, беләм, беләм...

Ничек белергә мөмкин агачаяк бу хакта? Әллә атасы кызмача килеш артыграк сөйләшеп ташлаганмы? Юк, мең тапкыр юк! Улы Сабиржанны да, әнә, өйрәнмәс борын, салган бәндәнең теле озынаяя дип, хәмердән биздерде. Адым саен: «Килер вакыт, дөньяның артына тибеп яшәрсең»,—дип тукыды.

Сабиржан кайта-кайтышка ишек-капкаларны кеше ачмаслык итеп бикләп куйды, этнең чылбырын сарай янынарак күчереп беркетте. Сарбайдан узып берәү дә анда борын тыкмаячак. Ә Сарбай тешенә юлыгырга язмасын, каба—өзә.

Күрер күзгә такта-токтадан әмәлләнгән абзарны гына хәтерләтсә дә сарай

эчендә имән буралы келәт тә бар. Ишеге—тимер, бигe—богау йозак. Ә келәт астында янган кирпеч белән тышланган тирән баз. Шул базның идән астында корыч сандык яшерелгән. Сандык эчендә... нәкъ әкияттәгечә...

Сабирҗан намаз ниятенә кергән мәчет картыдай сандык алдына килеп тезләнде. Иң элек мәгъшукасын назлаган карт гашыйк сыман сандыкны сыпыргалап-сыйпаштыргалап торды. Аннан соң сабыена үрелгән яшь ана хәрәкәтләре белән сак кына сандыкның капкачын күтәрде.

Аһ, бу ләззәтле минутлар! Ошбу хәләтне берни белән дә чагыштырып булмый. Мөгаен, адәм баласы оҗмахта гына шушындый тойгы кичерәдер. Менә бит алар, атларым-йөгәннәрем, кызыл бөрлегәннәрем; тайларым-колыннарым; гөр-гөр күгәрченнәрем...

Сабирҗан алтын-көмештән коелган муенса, балдак, йөзек, алка, медальон, брошка ише бизәнү әйберләрен, берсеннән берсе гүзәлрәк асылташларны учына алып хозурланды, иснәде, кайберләрен авызына кабып, тәмнәрен татып карады.

Аның әлегәчә беркайчан да баз-бункерга болай кабалана-кабалана көпә-көндез төшкәне булмады. Җиде төн уртасында, кешеләр йокыга талып, авыл тынычлангач кына хаҗ сәяхәте кыла иде ул монда. Мәндинең авызын былчайтып, мәкерле кыяфәттә «беләм» дип астыртын гына елмаюы бөтен чөйләрен какшатты да җибәрде. Нервылар беткән, сабакы, дип тәшвишләнде Сабирҗан соңыннан.

Бу хәзинә—атасы Малигәҗәр солдат мирасы. Ә Малигәҗәрнең үзенә әлеге алтын-көмеш сугыштан кергән ганимәт. Җиңү әҗере. Кызык бит ул сугыш. Элек-электән орыш сәргаскәриләргә байлык китергән, ә кече гаскәриләр шулар өчен гомерен корбан иткән. Тик тормыш булгач, ихатага чит сарык кергән чаклар да булгалый. Гади әрмис Малигәҗәргә дә елмайды андый бәхет.

...Берлинны алгач та кайбер СС отрядлары мылтыкларын ташламады, бәрелешләр дәвам итте. Берсендә шәһәр читендәге бай йортка бәреп керделәр. Шунда бүлмәдән-бүлмәгә йөргәндә Малигәҗәр бер карчыкка тап булды. Кулында ниндидер шкатулка. Мина хәстәрли, кабих, дип гөманлады ул һәм ике дә уйлап тормый, автоматын зеңгелдәтеп алды. Минаны зарарсызландырырга дип шкатулканы ачса, итит-митит, анда алтын-көмешләр җемелдәшә...

Форсатны кулыннан ычкындырмады фронтовик, башкалар алман түтәйләренең чүпрәк-чапракларын җыеп йөргәндә, кесәсен зиннәтле мал белән тутырды. Кайтышлый ук Мәскәүдә сәмәнгә әйләндерергә омтылып караган иде дә, элмәк борынлы яһүд көмешчесе үзен зур куркуга салды.

—Солдат,—диде калын кысалы күзлегенең өстеннән генә карап,—минем мондый кыйммәтле эшләнмәләрне алырлык акчам юк, булса да җөрьәт итмәс идем. Ник дисәң, дөньяның мәдәни каталогына кертелгән фамильный әйберләр бу. Эзенә төшсәләр, конфискация, каторга. Ашыкма, уңайлы вакыт җиткәнче ераккарак яшереп куй.

Уңайлы вакытны көтә-көтә Малигәҗәр солдат гүр иясе булды. Улы Сабирҗан гомерен «саран» кушаматы белән төгәлләде. Монысы агачаяк Мәнди эше. Дөрес, теге чакта хатыны Хөллибану хакына бер оя корт бирде ул аларга. Ләкин ике атна дигәндә күч умартасын ташлап качты.

—Малны таба белмәгән тота да белмәс, ул саран тәре аркасында кулым китте,—дип сөйләп йөрде Мәнди.

Егерменче гасырның Ельцин, Кравченко, Шушкевич атлы соңгы бунтарлары Белобеж урманы ешкынлыгында кача-поса СССР диган суперкаганатка ясин чыккан көнне җырладылар Сабир саранны. Әбелмәлих теләр-теләмәс кенә агрономлыкка укып йөри иде, атасы вафатыннан соң бөтенләй ташлап кайтты, әмма авылда озак тоткарланмады, дәшми-тынмый гына каядыр чыгып шылды.

Янә туган-үскән якларда пәйда булганда танырлык та түгел иде егетне. Биле билтәк бишле айгыр алтысында ат булыр ди. Ат кынамы, чын тулпар. Азамат. Кызлар карап кына торырлык: буе озын, йөзе шома. Үзе энәдән-җептән киенгән. Болары, кем әйтмешли, кабык кына, мәнен күр син аның, мәнен! Өй саен кереп, бүләк өләшеп йөргән кешене монарчы күргәннәре юк иде әле авылда. Менә сиңа Сабир саран малае!

—Чын Вәли нигъмәт икәнсен, улым, Ходай үзенә бише белән кайтарсын,—дип мулла да рәхмәтен җиткерде.

Беркөнне Хисаметдин телмәр:

—Әбелмәлих мунча бурарлык акча бирде,—дип, кош тоткандай бөтен кешегә күрсәтеп йөрде.

—Бернәрсәсезгәме?

—Бернәрсәсезгәме дип, нииндидер кәгазьгә кул куйдырды, шуның белән вәссәлам.

Юмартның күләгәсе киң бит аның, агылды авыл гыйбаты игелек иясенә. Көртлек маена буялганнарын аңлаганда соң иде инде, пай җирләре яңа мал көясенә күчкән иде. Акрынлап бөтен тирә-як шушы язмышка дучар булды. Тора-бара иген игү, эшкәртү, сату бизнесына чын хуҗаларча борын тыкты Әбелмәлих.

Карт солдатның мирасы ул үзе башына да китермәгәнчә мул шытым бирде. Мәрхәмәтле онык бабасының да, атасының да якты истәлекләрен яд итәргә тырышты. Алар хөрмәтенә авыл читендә ак таштан бинаһая зур мәчет салдырды. Ихатасын челтәрле тимер койма белән әйләндереп алдылар. Аны илнең баш мөфтиен чакыртып, күптин-күп дәрәҗәле кунаклар катнашында тантаналы төстә ачтылар.

Тик, гөнаһ шомлыгына, әлеге мәчеткә гыйбадәткә йөрергә тиешле авыл халкы өмә ясап, элекке аллаһ йорты урынында бүрәнәдән тыйнак кына үз мәчетен корып куйды. Җомга намазына шунда йөриләр. Акча хакына куштаннарны кодалап та караганнар иде,максатларына гына ирешә алмадылар.

—Хәрәм акчага корылган мәчеткә аяк бассагыз, Аллаһының каһәре төшәр,—дип куркытты авылдашларын иң тәүге кеше булып Әбелмәлих тозагына эләккән Хисаметдин телмәр.

Малигәҗәр-Сабир мәчете мәхәлләсез калды, хәзрәте дә бар, югыйсә, ә мәхәлләсе юк. Авыл читендә Бабил манарасыдай кукраеп утыра, хәтта чәүкәләр дә кунмый.

* * *

—Әкүл, вәземләбрәк аңлат әле, зинһар, кичәгедән соң баш та түнебрәк тора,—диде Әбелмәлих сүрән генә.

Муллый күңелне ярсытып торган үрдәк томшыгыдай киң борынлы коньяк шешәсен, касәләрне өстәл читенә сыпырып куйды да, каты итеп сөтле чәй ясады. Сүзсез генә эчтеләр.

—Җә,—диде Әбелмәлих,—сүлә, ниткән Черчилль ул?

—Черчилльне дә белмәскә теге, ун класс бетергән кеше ләбаса син.

—Бөгештермә,—диде Әбелмәлих ачусыз гына,—сүлә!

—Черчилль Англиянең сугыш елларындагы Премьер-министры. Кайнар сугышны салкын сугышка әйләндергән шамакай. Балта мае ялаган адәм. Бик фартовай, дөя шикелле, бер төз җире дә юк. Дуңгыз урынына ашаган, сыер урынына әрмән коньягы эчкән, авызыннан Куба сигарасы төшмәгән. Хәрәкәтләнергә яратмаган. Безнең заман табибларының фаразы буенча туганчы ук үләргә тиешле бәндә. Ә ул туксан берне тутыра...

—Менә, менә,—дип күтәреп алды Әбелмәлих дустының сүзен,—кыланып утырма, әнә, Черчиленнән үрнәк ал.

Коньяк янә өстәл уртасына кайтты. Әңгәмә кузгә күренеп җанланды.

—Менә шул Черчилльнең тутый кошы әле һаман исән икән,—дип дәвам итте сүзен Муллый,—үзенә йөз дә ун яшь ди.

—Абрамович яхтасының монда ни катнашы бар?

—Абрамович дөньяга яһүдләрне танытты, син татарны таныт. Фәрштейн?

—Ничек итеп?

—Черчилльнең ошбу әкияти тутый кошын сатып алырга киңәш итәм. Уначаксың. Туристлар баллы күмәчкә кунган чебен өере кебек ишелеп киләчәк. Акча су урынына агачак...

Әбелмәлихның күзләре хамельон кошыныкы кебек үз күчәре тирәсендә тулы әйләнеш ясады. Нидер әйтергә теләде, ләкин әйтергә теләгән сүзе тамагына утырып калды:

—Дык...

Муллый дәвам итте:

—Син ни өчен хөкүмәт пачкалап-пачкалап, миллионнар түгеп, карткорыларның авызыннан өзеп, озын ботлы һәм кара, һәм соры чырайлы туп тибүчеләр, алка тәгәрәтүчеләр җыя дип уйлыйсың? Белмәсәң бел: Татарстанның, татарның исемен бөтен Җир шарына таныту өчен. Ә минем проект һәммәсен бәреп егачак. Бу проектның дөньяда тиңе юк. Абрамовичның, һәм дә үзебезнекеләрнең көнләшүдән корсаклары шартлап ярылачак әле. Ник дигәндә, берьюлы ике куянның койрыгыннан эләктерәбез бит. Фәрштейн?

—Их, мать якасын, тәвәккәлләдек,—дип кулы белән һаваны ярды Әбелмәлих,—Лондонга кеше җибәр, үзебез соңрак кузгалырбыз.

Бераз уйланып торгач, янә дә өстәде:

—Расхут күп булырга охшап тора монда, хуҗалыкларга хәбәр сал, вакытлыча премия-бонуслар түләү туктатыла, хезмәт хакы егерме-утыз процентка киселә.

* * *

Лондонга алар кичкырын килеп төштеләр. Көн матур иде, яңгыр да пыскымый, томан да юк. Иркенләп-җайлап кына урнаштылар да ресторанга киттеләр. Урыннарны Мәскәүдән үк белешеп, мая акчасын электрон почта аша түләп тә куйганнар иде.

—Алтын-көмеш салып пешерәләр микән әллә бу тәгамнәргә, бер-берсе сыер бәһасе бит, дурәк,—дип мыгырданып алды Әбелмәлих.

—Керәстиән баласы икәнеңне онытинде, пажалсты, өлүфмән ләбаса син,—диде Муллый,—без бер тиен өчен кара тиргә батып сатулашучы инглиз сәләмәләренең исен-акылын алырга тиеш.

Ресторанда кунакларны икенде күләгәседәй озын буйлы, баштан-аяк акка төренгән негр егете каршы алды.

—Сэр Әбелмәлих, сэр Муллый әфәнделәр, хуш киләсез, рәхим итегез, бу кичкә мин сезнең колыгыз,—дип утыз өч тешен дә күрсәтеп елмайды официант,—исемем Хөсәен.

Бик өлгер булып чыкты Африка мөселманы, үзе күренми дә, ә кирәк чакта көлеп-елмаеп янында басып тора, әйтерсең лә, җен шикелле шешәдән генә чыга.

—Бик шапырынган идең дә, безгә карап исен югалтучылар күренмәй әле монда,—диде Әбелмәлих як-ягына карангалап.

—Бәй...

—Күрсәтәм мин аларга хәзер татар өлүфмәненең кем икәнлеген, у-хх!

Әбелмәлих бер ыргым белән сикереп өстәл өстенә менеп басты да: «Татар барда хәтәр бар, их, мать якасын»,—дип оран салды. Аннан соң аякларын тыпырдата-тыпырдата касәне авызына бушатты.

Вәйт хикмәт, янә илтифат юк... Хөсәен генә шул ук кин елмаю белән өстәлдән төшәргә ярдәм итте. Шулай да эзсез калмаган икән аның батырлыгы, кайтырга җыенгач, Әбелмәлихны идарә бүлмәсенә чакыртып алдылар.

—Сэр, ашъяулыкны пычраткан өчен сездән 100 фунт стерлинг акча тиеш,—диде идарәче.

Өстәл өстенә менеп биегән өчен түгел, ә ашъяулыкны таплаган өчен. Менә бу демократия ичмасам.

Черчилльнең «Черчил»е турында караутасма төшергәннәр икән, иртәнгә кадәр шуны әйләндерделәр.

—Карга ич бу, мать якасын,—дип Әбелмәлих ризасызлыгын белдерде,—ничу монын белән мәшәләнергә.

Дөрестән дә, тутый кошның каурыйлары шактый шәлперәйгән иде. Бәйләп куелгандай йокымсырап утыра. Буяулары да уңган мескенкәйнең. Үзе уянып киткәндә нindидер авазлар да чыгармак иткән була. Ләкин, ләкин... туе узган, туны тузган дигәндәй, ай-һай, оттырмагайлары.

—Сандугач түгел, әйе, комы коела төшкән, әйе, әмма дә ләкин ул мәшһүр Уинстон Черчилльнең тутый кошы!—дип үзенекен тукыды Муллый,—бу—Дөлдел күкәе табу белән бер.

Әңгәмә шушы урында өзелде, бүлмәгә төсе киткән менеджер килеп керде.

—Күнелсез хәбәр җиткереп күрексез буласым килмәсә дә, вазифам мәҗбүр итә,—диде ул кыенсынып кына,—ничек башларга да белмим хәтта...

—Сузма!—дип акырды Әбелмәлих.

—Шеф, «Черчилль йорты» компаниясе әле генә рәсми рәвештә белдерде: без эш йөртә торган Мәскәү банкы бөлгән...

—Ничек бөлгән?—дип Әбелмәлих менеджерның изүеннән эләктереп алды,—сүзеңне үлчәп сөйлә, ач күз...

—Кризис...

—Рәсәйгә кризис янамай, аңладыңмы, ач күз, илбашы әйтте: «Россия Федерациясе үз юлы белән үсә, ул океан арты кризисларына бирешмәй»,—диде.

—Телнең сөяге юк...

—Шуннан ни әйтмәк буласың?

—Сез... туесть без... сез... кыскасы, барча фининс бәйләнешләры да туктатыла, чөнки дә компаниябез неплатежноспособный...

Бүлмәдә кабер тынлыгы урнашты. Бу тынлыкта Әбелмәлихның тыгылган борын аша пыш-пыш сулавы иске паровоз тавышлары чыгара иде.

—Страхфондны кая куясың,—диде ул, ниһаять,—нигә аны кулланмаска?

—Сез ни сөйлисез, шеф, рәзе аңа тияргә ярый, НЗ ич ул... запас...

—Исең китмәсен,—дип ярдәмгә килде Муллый,—безгә әлеге чыгым йөзе-меңе белән кайтачак.

—Бәхәсләшмә, сделканы рәсмиләштер,—дип әмер бирде хуҗа.

Аэропортка алар Берлинны алган гәскәриләрдәй җиңүчеләр кыяфәтендә килделәр. Борын югары, йөзләр тәкәббер. Шулай булмыйча, култык астында—көмеш читлек. Ә анда дөньяның иң дәрәҗәле хәзинәсе саналган тутый кош—Черчилль!

Кемнәр генә уйлап тапты икән ул каһәрле «ләкин» сүзен, агач мылтык белән атасы иде шушы бәндәне. Барысы да җайлы гына хәл ителгән иде ич инде. Билет сатучы, шар күзле инглиз маржасы, шул «ләкин»е белән секунд эчендә кәефне бозды да куйды. «Туда и обратно»га тәгаенләнгән билетларның «обратно»сына акча күчмәгән булып чыкты.

Хәер, бу «ләкин» генә түгел, бу фаҗига иде. Олы фаҗига!

Әшнәләр ник туганнарына үкенгәндәй шактый ара башларын

салындырып, сүзсез утырдылар.

—«Черчилль»не сатарга туры килер,—диде менеджер бераздан,—башка юл юк.

—Не смей!—дип кычкырды Муллый,—шту син?—Янә тынып калдылар.

—Пажалый,—диде Әбелмәлих ярты сәгатьләр узганнан соң,—пажалый..

Ни хикмәт, «Черчилль» хәлне бик тиз төшенеп алды, хуҗаларына ярдәмгә ашыкты. Теле ачылды—сибә генә.

—Ай лове вай.

—Бонжур, мадам.

—Гутен таг.

—Әссәламегаләйкем.

Бу тутый кош бик күп хуҗаларны алыштырган икән инде, дип уйлап куйды менеджер эченнән генә, тәҗрибәсе бар, авантюристның авантюристы, кушбугаз.

Телмэрлеге хәттин ашса да, тутый кошның күрке товар таләпләренә җавап бирми иде шул. Күп акча югалтып, юк бәягә генә сатып җибәрергә туры килде үзен.

Менеджерны билет юнәтергә җибәрделәр.

—Уф, эчем-тышым яна, бер кырлы стакан белән йөрәкне басасы иде, туйдым ул уймакларыннан,—диде Әбелмәлих аэропортка килгәч.

Муллый иснәнергә китеп барды. Озак та үтми, тулган ай кебек балкып, әйләнеп тә килде.

—Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына ди, бу мәрхәмәтсез илдә дә үзебезнең искепүләннәр бар икән ләбаса,—диде ул шатлыгыннан нишләргә белмичә,—бер урыс белән таныштым, итәк астыннан гына безнең ише егет кәмәшләренә Акбашны да, стаканнарын да, милли кабымлыкларны да тәкъдим итә. Хакы хаклы, әлбәттә...

—Алапа корма,—дип бүлде аны түземлеге төкәнгән Әбелмәлих,—җәт кенә берәр аулак урын тап.

—Эзләп тә интегәсе юк, иң җайлысы әбрәкәй,—диде Муллый.

Икесе бер кабинага кереп бикләнделәр.

—Менә бу үзебезчә,—дип, зур канәгатьләнү белән кикереп җибәрде Әбелмәлих мөлдерәмә стаканны каплап куйганнан соң,—күр, тозлы кыярына кадәр бар, ә? Маладис.

Әүвәл пышылдашып кына сөйләшсәләр дә, тора-бара артлары кызды әшнәләрнең, саклану чаралары онытылды. Муллый яраткан зимагур җырын да сузып җибәрде:

...Чит иде теләкләрем,<br>
Инде хәзер чит җирләрдә<br>
Өзелә үзәкләрем...

Бөекбританиянең кадими җанатарлары әбрәкәйдәге хәлләр турында кирәк җиргә ирештереп өлгергәннәр иде инде, күрәсең. Ажгырып-талпынып табак битле әзмәвердәй полицайлар килеп тә җиттеләр, кулларына богау салып, мазасыз эшкуарларыбызны участокка алып та киттеләр.

Куллар богауда булса да, тел иректә бит. Әбелмәлих шушы хокукыннан файдаланып калырга, әләкче инглизләргә карата үзенең каттый мөнәсәбәтен белдерергә ашыкты—халыкара Хитроу аэропортында бозык Баламишкин көенә татар такмагы янгырады:

Их, мать якасын,<br>
Черчилегезнең сатыйм каргасын...

*Яшьләр иҗаты*



Рүзәл Мөхәммәтшин

# НӘТИҖӘЛӘР ЧЫГАРЫР ЧАК ҖИТТЕ

## Бүре каны

**Кыр киң. Төн тын. Тавыш бир тынлыктан—
Кемнәр үле күптән, кем тере?
Ярты-йортыларга ау башлыйм мин...
Миндә бүре каны!.. Мин—бүре!**

**Чирле гавәм ютәлләвен тыеп,
Йоклый инде...
Ярар, йокласын.
Иртән кояш күккә сибелгәндә
Хәтфә үләннәрне чык басып,
Җир чистарыр... Һава—лаекларга
Күбрәк калыр...
Бүген Мин дәшәм:
«Сиңа—җитте, яшәмә син!—диеп,—
Синең өчен,—диеп,—ул яшәр...»**

**Горабалар!
Алар, имеш, көн дә
Дөнья сөйри... Өскә, югары!..
Бәй, карагыз инде: аркагызда
Бөкре генә, бөкре нибары!—
Тураерга вакыт!..
Кил янымa,
Татлы бугазыңа үрелим...
Күзләремә кара—күрәсеңме?—
Миндә бүре каны!.. Бүре мин!..**

**Кыр киң. Төн тын. Тавыш бир (биралсаң!)—
Кемнәр исән һаман, кем—үле?
Нәтиҗәләр чыгарыр чак җитте—
Ярымайның тулып килүе...**

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН—*яшь шагыйрь, КIТДУ студенты; «Каралама» исемле китап авторы. Казанда яши.*

***

*Хәтер мин!..*
Л. Гыйбадуллина

**Кыйммәтрәкме тарих шалканлык бәядән?—**
**Ямыйсы—ямалган, бәйлисе—бәйләнгән,**
**Тотарлык җире юк! Тик җавап көттерми:**
**Ирекле идек без—**
**Үткәннәр хәтерли...**

**Таныйрлармы сине йөзеңне капласаң?**
**Ачуланма «Мин шат»,—дип беркөн алдасам.**
**Ачуланма елап җибәрсәм дә бераз:**
**Без бөек тә идек—**
**Хакыйкать алдатмас!**

**Ни булды, милләтем, күзләрең сагышлы?**
**Бу җырны мин сиңа, тик сиңа багышлыйм,**
**Исемен тапмыйча борчулы хисемә...—**
**Ирекле идек без!**
**Исемдә... Исемдә...**

***

*Газинур һәм Ркаил абыйларга*

**Шау-шуыннан дөнья тынып калгач,**
**Ак кәгазьгә каләм эзе сеңеп...**
**—Күпме иҗат!—дип уйланыр кемдер,**
**Кемдер: «Чүп ич...»—дияр, усал көлеп.**

**Җөмлә-җөмлә кереп китә барып**
**Тыныш билгеләре сихеренә...**
**Кемдер, бәлки: «Шигырь!»—дип сокланыр.**
**Кемдер әйтер: «Бу бит—шигырь генә...»**

**Һәм бар фикерләрен мөмкин кадәр**
**Ихласлыгы белән иш сугарып,**
**Кемдер: «Шагыйрь ул!»—дип сөрән салыр!**
**Кем төзәтер: «Бары—шагыйрь, шагыйрь бары...»**

**...Бер тынлыкта, моңсулыкта калып**
**Дөнья мәшәкатен уйлый-уйлый:**
**—Нинди моң бу?—дип сискәнәм, ә ул—**
**Мыштым гына әдәбият елый...**

****

**Син зәңгәрсу төтен куенында...**
**Хисләреңә нокта куя тор:**
**Безнең вакыт кимеп бара бугай...**
**Казан. Кабан күле. Театр.—**

**Бу—сиңа аш, сиңа илһам, тәхет.**
**Бу—шифаң да синең, чирең дә...**
**Каләмдәшләр**
**Шигырь сөйләп йөргән биредә.**
**Син монда шат, ахры... Син канәгать,**
**Син килмисең монда—кайтасың.**

Син монда—юк, әмма булган вакыт
Ике тапкыр ешрак тартасың—
Син яңадан төтен куенында...
Җыена тор, берни калмасын...
Күпме ящик тагын?
Җавабымны
Үпкәң белән тоя аласың...

Мин кем сиңа? Без кем? Кулагәләр...
Ут сүнде дә, кабат кавыштык...
Казан. Кабан күле. Спектакль бара...
Һәм җанөзгеч ютәл тавышы...

***

Мин—үсемлек...
Су сибегез миңа...
Юкса сулам... Корыйм... Корыйм ич!
Җылы кирәк миңа... Якты кирәк!..
Туфрак кебек дымсыз, коры кич...

Мин—үсемлек...
Туфрак кебек дымсыз,
Туфрак кебек коры бу кичен
Таптамагыз мине!.. Утамагыз...
Мин яшәргә хаклы... Яшимче!

Мин—үсемлек...

***

Мин—бер шагыйрь, Дәрдемәнд...
Җай чыкканда
Язган булам—кәгазь бите буйыйм...
Һәм, нигездә, сүгәм һәммәсен дә...
Бездә бүген башкача булмый...

Безнең бүген күзләр тонык,
Хисләр
Йөрәк кысаларын тарсына.
Түбәтәйне салып ыргыттык та
Хуҗабызның аяк астына,
Якты чырай өмет итеп аннан,
Кан суынды, тындык, сүнде дәрт.
Чиркәү кыңгыравы тәэсирендә
Махмыр авыр икән, Дәрдемәнд...

Кичә генә әле яз иде дә,
Җан пакь иде, җан ап-ак иде—
Бу иблиси сүзләремне кичер...
Чоры нинди—шундый шагыйре...

Мин дә—шагыйрь... Мин дә иҗат итәм...
Минем каләмдә дә хаклык бар!
...Әмма ничек ярдәм итим, Дәрдемәнд,
Шигырь укып арган халыкка?!

Дамир
Исхаков

# ТАТАР ЮЛЫ ТАКЫР ТҮГЕЛ...

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЭТНИК ТАРИХЫ, ХАЛЫКНЫ ИСӘПКӘ АЛУ ҺӘМ СӘЯСӘТ

### III бүлек
### ГОМУММИЛЛИ ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ ФОРМАЛАШУ

Мәгълүм ки, мәдәният ике «катламнан» тора—аның берсе традицион яки халык мәдәнияте, икенчесе—профессионаллар тарафыннан тудырылучы «югары» мәдәният. Милләт оешкан чорда мәдәниятнең бу ике катламы арасында катлаулы үзара бәйлелек, тәэсир күзәтелгән, шул нигездә традицион мәдәният үзгәргән, югары мәдәният исә төп урынны били башлаган. Тулаем алганда шуны әйтергә кирәк: татарларнын халык мәдәниятендә XIX-XX гасырларның чикләренә кадәр локаль үзенчәлекләр сакланса да, алар белән беррәттән эре мәдәни «диалектлар» (төгәлрәге—өлкәләр) да барлыкка килде, ягъни вак-төяк үзенчәлекләр бетә барды. Бу процесс татарларның авыллардан шәһәргә күчүе белән стимуллаштырылды.

XIX йөзнең икенче яртысындагы—XX йөзнең башларындагы индустрияләштерү дәверендә көчәйгән миграция элгәре чордан сакланган шәһәр мәдәнияте урынына яна, «гомумиләштерелгән» татар шәһәр мәдәнияте барлыкка килүгә этәрде. Бу соңгы төр мәдәният шәһәрләрдә төрле мәдәни традицияле авылдан күчеп килүчеләрнең мәдәни яктан «кушылулары» нигезендә генә түгел, мәдәниятнең шартлы-традицион, икенче төрле әйткәндә гомумиләштерелгән, шул исәптән, элгәреге һәм читтән алынган үрнәкләргә таянып барлыкка китерелгән формаларына таянып оешты. Мисал итеп бу процессның иң ачык чагылган бер өлкәсен—кием-салымның үзгәрүен китерергә була: 1860нчы еллар—XX гасырның башында Идел-Урал татарларында территориаль яктан аермалары булган авыл хатын-кызлары костюмы гына түгел, Казан татарлары традициясенә нигезләнгән шәһәр халкы өчен уртак костюмның да булганлыгы мәгълүм (аның элементлары: калфаклар, чулпылар, груша формалы алкалар, изүләр, ярым ай рәвешендәге хаситәләр, яка чылбырлары, муенсалар һ.б.). Тирән тарихи тамырлары булган Казан татарларына хас шәһәр хатын-кыз костюмының кайбер элементлары милли чорда символик мәгънә алалар, әйтик, калфаклар. Бу ирләр киеменә дә хас була (мәсәлән, каләпүш гомуми баш киеменә әйләнә). Бу төр баш киемнәренең, кайбер бизәнү әйберләренең шәһәр костюмынын үзенә күрә аерым бер миллилек күрсәткечен ә әверелүе аларны престижлы итте, шуна күрә XIX йөзнең икенче яртысында алар элек Казан татарлары яшәмәгән урыннарга да таралдылар. Бу процесс күбесенчә югары катлам вәкилләренең

*Дәвамы. Башы узган санда.*

әйтелгән үрнәкләрне кабул итүе аркылы барды.

Шунын өстенә, зәргәрләрнең (ювелирлар) читтәге төбәкләргә күчеп китүе нәтиҗәсендә, анда «икенчел» Казан-татар традицияле бизәнү әйберләре житештерү учаклары барлыкка килүе аркылы, аерым төр ювелир әйберләренең таралыш чикләре киңәйде.

Милли чорда татар шәһәр мәдәниятенең шартлы-традицион төс алуының тагы бер чыганагы—шул дәвердәге рус шәһәр мәдәниятенең йогынтысы. Үз вакытында күренекле галим—этнограф Н.И.Воробьев билгеләп үткәнчә, бу йогынты кием-салымда ачык күренә. Аерым алганда, XIX гасырның икенче яртысыннан башлап шәһәр көнкүрешендә билле, арткы яктан бөрмәле хатын-кыз күлмәге таралу, аның фикеренчә, руслардан кергән. Ә соңгылары, үз чиратларында, Аурупа модасы тәэсирен тойганнар. Мондый яңалыклар тагын да бар. Мәсәлән, XX йөз башларында татарларда ул вакытта модада булган, шәһәр сапожкилары үрнәгендә эшләнгән читекләр тарала (алар биек үкчәле хатын-кыз ботинкалары төсле дә булганнар).

Ә инде акрынлап шәһәргә кергән кием-салым төрләре авыл халкына да йогынты ясаган. Нәтиҗәдә авылдагы киемнәр бераз үзгәрә төшкән һәм шәһәрдәге үрнәкләргә охшый башлаган. Шундый күренеш шәһәр архитектурасында да күзәтелгән: әйтик, Казан мәчетләрендә рус бароккосы, классицизм стиле билгеләре чагыла. Кинрәк караганда бу, билгеле, Аурупа архитектурасына якынаю. Әмма, шуна да карамастан, урта гасыр чорына барып тоташучы җирле мәчет архитектурасы үзенчәлекләре дә сакланган.

Татарларда «икенчел» мәдәни формалар барлыкка килү шәһәр белән генә чикләнмәгән, хәлбуки, аларда шәһәр мәдәният үсү белән тыгыз бәйләнгән булса да. Шушы уңайдан XX гасырның беренче дистәләрендә, бигрәк тә совет чорында, элек Казан татарларына гына хас булган, үзгәргән Сабан туе бәйрәменең башка, аны элек бәйрәм итмәгән төркемнәргә дә таралуын күрсәтү кирәк. Авыл күләмендә генә үткәрелгән бу бәйрәм акрынлап, «гомумиләштерү» нәтиҗәсендә, барлык татарларга да хас булган гомуммилли бәйрәмгә әйләнде. Дөрес, 20нче елларда бу процесс әле башланган гына иде. Моның ише аерым мәдәният элементына «гомумтатар» мәгънәсен бирү нигезендә мәдәниятнең «икенчел» формаларын барлыкка китерүнең башка мисалларын да күрсәтеп була: басма рәвештә чыгару һәм тарату нәтиҗәсендә элек тар төбәктә генә билгеле булган фольклор әсәрләренең гомумэтник күренешкә әйләнүе; локаль үзенчәлекләрне «берләштерү» юлы белән милли кухняны булдыру (шул исәптән «татар ашлары» китаплары чыгару аркылы да).

Күренгәнчә, XIX йөзнең икенче яртысыннан башлап татарларда «гомумилләштерелгән» мәдәни формалар барлыкка килү интенсивлашты. XX йөзнең башларында мондый процесс дәвам итте. Һичшиксез, татарларда элекке-традицион мәдәният катламыннан шактый нык аерылып торган яңа мәдәният катламы барлыкка килү турыдан-туры милли «югары», ягъни, шәһәр мәдәнияте барлыкка килүнең нәтиҗәсе булды. Хәзер шушы яңа мәдәниятнең формалашуына күчик.

Урта гасыр татар мәдәниятенең үзәген ислам тәшкил иткән, шунлыктан, традицион мәдәниятка теләсә-нинди үзгәреш кертү башта шушы «үзәккә» үзгәреш кертүне таләп иткән. Шунлыктан, татарларда иҗтимагый реформаларның элгәресе дини реформа булды.

Мәгълүм ки, Көнбатышта мәдәниятне диннән «чистарту» (аеру дип әйтсәң дә була) аерым этаплап—Реформация чорыннан Мәгърифәтчелек чорына күчү аркылы барган. Көнчыгышта исә, шул исәптән татарларда да, мондый эзлеклелек күзәтелми: монда бер этапның икенчесе белән буталуы булган. Шулай да, татарларда да реформаның башлангыч чоры ислам кысаларында барган һәм дини яңарыш юлы эзләү белән бәйле булган. 1770нче елларда эш иткән, яңарыш кертергә омтылган Морат мулладан башлап санаганда (аның турында тәгаен мәгълүматлар бик аз), XX йөзнең башларына кадәр татар җәмгыятендә дүрт буын ислам реформаторлары алмашты. Аларның бер гасыр ярым чор эчендәге эшчәнлегенең төп нәтиҗәсе булып татарларның XIX-XX йөзләрнең чикләрендә заманага яраклаштырылган «чистартылгын» исламга күчүе булды. Сүз, беренче чиратта, традиционализмнан

чистарыну турында бара. Татарларның Ауропадагы географик халәтен истә тотсак—чынлыкта алар Ауропада мөселман динен тотучы җирле халык—һәм татар җәмгыятенен гомуми үсеш юнәлешеннән чыгып эш итсәк, бу реформалаштырылган динне ауроислам дип атарга була. Бу төр ислам күбрәк җәдитче дин белгечләренең хезмәтләрендә яшәсә дә, җәдит мәктәпләре һәм мәдрәсәләре аркылы аның халык массаларына тирән үтеп керүе дә бәхәссез. Шуны да онытырга ярамый—1917 елга Диния назәрәте үзе дә җәдитче ислам эшлеклеләре кулына күчте. Ә инде соңгы буын ислам реформаторларының эшчәнлеге татар җәмгыятендә мәдәни реформалык җәелгән чорга туры килеп, алар тарафыннан ислам XIX-XX йөзләрнең чикләрендә милли мәдәният кысаларында каралды. Нәкъ шушы буын ислам белгечләре, бигрәк тә аларның радикаль өлеше, татар-мөселман өммәтенең секуляр юнәлештә хәрәкәт итүен дә тәэмин итте.

Татар җәмгыятендә XVIII-XIX гасырның чикләрендә үк башланган мәдәнияттәге структур үзгәрешләр 1920нче елларга кадәр дәвам итте. Ахыр чиктә «югары» мәдәният тудыруга юнәлдерелгән бу эшчәнлек төрле сфераларда барып, гел берберсе белән параллель бармаса да, эчке яктан үзара бәйле булды.

*Әдәби телне реформалау.* Беренче чиратта татар җәмгыяте каршында иске татар әдәби телен, ягъни урта гасырдан калган төрки, Идел буе төркие дип йөртелгән телне реформалау кирәк иде. Чөнки төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә бу тел киң халык массаларына аерым әзерлексез аңлашылмыйча, тар даирәләрдә—галимнәр, язучылар, дин һәм дәүләт (дипломатия өлкәсендә) эшлеклеләре арасында гына кулланылды. XIX йөз урталарына кайбер татар зыялылары яңа әдәби тел кирәклеген аңлый башладылар. Әмма аны булдыру өчен зур кыенлыклар аркылы үтәргә кирәк иде: телне гарәп һәм фарсы алынмаларыннан арындыру, конкурент булган башка әдәби телләр—бу очракта, госманлы төрек һәм аңа бик якын булган И. Гаспралы кулланган телләр күз алдында тотыла—йогынтысыннан котылу, киң спектрдагы терминология булдыру (фәнни-техник, иҗтимагый тормышка караган һ.б.), алфавитны туган телебез таләпләренә якынлаштыру һ.б. Татар телен реформалауда берничә этапны күрсәтергә була: XIX йөзнең икенче яртысыннан 1905 елга кадәр; 1905-1917 еллар; 1920нче еллар. Беренче этапта татар әдәби теле сөйләм теле белән якынайса да, зыялылар арасында госманлы төрек һәм гарәп әдәби телләренең шактый зур йогынтысы сакланды. 1905-1907 еллардагы революциядән соң татарларда тел өлкәсендәге үзгәрешләр тиз рәвештә тирәнәя барып, 10нчы елларга «татарчылар», ягъни әдәби телне татар теленең үз нигезенә үстерүне яклаучылар җиңеп чыктылар һәм хәзерге татар әдәби теле вакытлы матбугатта һәм мәктәпләрдә ныклап урнашты. Татарлар, хәтта төрекләрдән дә алда, милли терминологиягә күчеп, 1917 елга татар теле нигезендә эшләнгән күп санлы яңа техник һәм фәнни төшенчәләр куллана башладылар. Фактик яктан караганда 20нче еллар башларына татар телендә, бөтенләй үк камил булмаса да, күп төрле төшенчәләрнең бай җыелмасы булдырылды. Димәк, фикерләүне татар әдәби телендә тиешле югарылыкта кору өчен мөмкинлекләр булдырылды.

Татарда хәзерге әдәби тел аякка басуда алфавитны реформалау һәм орфографияне үзгәртү дә зур әһәмияткә ия булды. Бу мәсьәлә 1890 нчы елларда үк күтәрелә башлады—ул вакытта гарәп графикасына (иске имля) корылган татар алфавитын һәм орфографияне камилләштерергә тәкъдим итүчеләр барлыкка килде. XX йөз башына алфавит һәм орфография тирәсендәге дискуссияләр көчәйде һәм ахыр чиктә иске алфавитны чама белән үзгәртергә теләүче урта имлячылар җиңеп чыкты; алар шулай ук татар теленең урта (Казан татарлары) диалектына таянуны хуп күрделәр. Ләкин язмадагы үзгәрешләрне закон нигезендә беркетү фәкать тик милли дәүләтчелек булдырылгач кына, ягъни Татарстан АССР төзелгәч кенә мөмкин булды (Татарстан АССР ХКС 1920 елның 19 декабрендә кабул ителгән «Алфавит һәм орфография» турындагы 27нче декретын карагыз). Моның белән әле татар телендә язманы реформалау тәгәлләнмәде, чөнки 20нче елларның урталарыннан татарларда латин графикасына күчү теләге көчәя башлады. Бу яңа хәрәкәт түгел иде—инде 1910нчы елларда ук татар җәмәгатьчелеге арасында латинны күтәреп чыгучылар булды. Әмма, 20нче елларда бу эшне партия органнары да яклагач, «милли» коммунистларның

бер өлеше бик нык каршы торса да, Татарстан АССР ХКС 1927 елның 3 июлендә кабул ителгән карары нигезендә латин алфавиты татар теле өчен рәсми алфавит дип игълан ителде. Шул ук елны татар теленең үзенчәлекләренә яраклаштырылган яна алфавит кулланышка да кертелде. 1928-1933 елларда латин графикасында язуның орфографик кагыйдәләре дә эшләнде. Шулай итеп, XIX йөзнең икенче яртысы-XX йөзнең беренче дистәләрендә хәзерге татар әдәби теле формалашты һәм анда язу мәсьәләләре хәл ителде.

Татарда милли мәгариф системасы оешу. Бу системаның оешуы озак вакыт дәвам итте: XIX йөзнең икенче яртысыннан башлап, 1930нчы елларның башларына кадәр. Мәгариф өлкәсендәге реформаларны башлап җибәрү алдыннан татарда XVIII-XX йөзнең башларынача төп урынны алып торган дини укыту үзәкләре (мәктәп-мәдрәсәләр) генә бар иде. Алар да халыкның үз хисабына (шул исәптән, бай татарларның акчасына) тотылдылар. Татар җәмгыяте каршында торган белем бирү өлкәсендәге бурыч түбәндәгечә торды: дәүләт кулында булган, татар телендә укытучы массакүләм дөньяви мәктәп булдыру. Бу бурычны үтәү бик тә катлаулы иде. Беренчедән, XVIII-XX йөзләрнең башларында татарлар дәүләт органнарына якын җибәрелмәү сәбәпле, Россия империясендә мәгариф өлкәсендә алып барылган сәясәткә (ә ул сәясәт 1917 елга кадәр үзенең төп нигезләре буенча империячел булды, дөрес, 1905-1907 елгы революциядән соң бераз үзгәрсә дә) йогынты ясый алмадылар; икенчедән, татар җәмгыяте акрын үсү сәбәпле, татарда милли мәгарифкә күчү өчен эчке шартлар 1860нчы еллардан соң гына житлегә башлады (хәзерге әдәби тел формалашу; мәктәп һәм иҗтимагый тәрәккыят арасындагы бәйлелекне аңлау; белем бирүнең дөньяви якларына игътибарның көчәюе һ.б.). Шунлыктан, татарлар конфессиональ мәктәпләр системасын реформалау юлы белән киттеләр. Бу процессның өч этабын күрсәтеп була: 1890-1910 еллар; 1910-1917 еллар (Октябрь революциясенә кадәр); 1917 елның октябреннән башлап 1930нчы елларга чаклы. Беренче этапның төп эчтәлеге булып конфессиональ мәктәпләрне гомуми мәктәпләргә әйләндерергә тырышу булды. Икенче этапта яңа тип (җәдит) мәктәпләренең җиңүе белән бергә аларны дәүләти гомуми белем бирү системасына кертү өчен көрәш башланды. А.-А. Рорлих фикеренчә, 1917 елга Идел-Урал татарларының мәгариф системасы үзенең «ислам характерын... саклаcа да, милли мәктәп буларак үсеп, торган саен дөньяви төс ала барды». Милли мәгариф эчендә әле 1917 елга кадәр үк махсус урта белем бирүче уку йортларына якын типтагы кайбер мәдрәсәләр формалаштылар. Ләкин шунысын да кистереп әйтергә кирәк: татарда дөньяви югары белем бирүче уку йортлары булмады, беренче чиратта, үз дәүләтчелекләре булмау сәбәпле. Өченче этапта, 1917-1918 еллардагы драматик көрәштән соң, конфессиональ мәктәпләр системасы акрынлап юкка чыгарылды, алар урынына массакүләм эшләүче татар совет мәктәбе килде. Ул мәктәп бер ягы белән—туган телдә укыту буенча—милли мәктәп булып торса да, икенче билгеләреннән чыгып карасаң—аерым алганда белемнең эчтәлек өлешенең тулаем дәүләт контролендә булуын һәм коммунистик идеология белән сугарылуын истә тотсак—бу әһәмиятле күрсәткеч ягыннан мондый мәктәп берничек тә милли була алмый. Шушы планда, инде күрсәтелгәнчә, чын милли мәктәпкә 1917 елга кадәр яшәп килгән конфессиональ уку йортлары якын булган. Ләкин алар да советкача чорда башлангыч белем бирү дәрәҗәсендә булса да тулаем барлык балаларны да укытырлык итеп эшли алмаганнар. Нәтиҗәдә, Идел-Урал татарларының сәвәтлелек (грамоталылык) дәрәҗәсе түбәндәгечә булган: 1897 елга—20,8, 1926 елга—30,6 процент. Дөрес, бу чорда Россиядә башка халыкларның (русларны да кертеп) да күрсәткечләре шул чама булган. XIX йөзнең икенче яртысында-XX йөзнең башларында татарларның халык мәгариф системасының икенче зур кимчелеге—аларда ана телендә эшләүче югары уку йортларының булмавы. Бу кимчелектән совет чорында да арынып булмады, хәлбуки, 1920-1930 елларда әйтелгән юнәлеш буенча аерым адымнар ясалса да (югары уку йортлары каршында эшләүче татар телле рабфаклар һ.б.).

Милли-мәдәни мәгълүмат челтәре. Югары мәдәниятнең иң әһәмиятле чылбыры булып торган бу өлкә татарда кайбер юнәлешләр буенча XVIII гасыр ахырларында

ук үсә башлый (китап басу), башка тармакларда (периодик басмалар чыгару), сәяси чикләүләр булу сәбәпле, үсү 1905 елдан соң гына башлана.

Әгәр китап басуны алсак, ул өлкәнең үсешендә мондый этапларны күрәбез: XVIII гасыр—милли китап нәшер итүнең башланып китүе; 1800-1850 еллар—татар китапларын массакүләм чыгара башлау; 1860-1900 еллар—татар китапларын нәшер итүнең көчәюе һәм басма продукциянең сыйфат составы үзгәрү; 1901-1917 еллар—милли китап басу эше оешуның тәгәлләнүе. Соңгы ике чорда, татарча китап басу эшенең интенсив рәвештә оешу дәверендә мондый күрсәткечләр күзәтелгән: 1851-1890 елларда 3,2-3,3 мең исемдәге татар китабы чыгарылып, аларның гомуми тиражы 23,5-29,9 млн данә булган, 1901-1917 елларда 6,2-7 мең китап басылып, гомуми тираж 41,3-47 млн данәгә житкән. Китап тиражы буенча татарлар 1913 елга Россиядә икенче урынга чыгып, фәкать тик руслардан гына калышканнар (чыккан китапларның саны буенча өченче урында торганнар). XX йөз башына, империячел цензура бик тискәре йогынты ясаса да, милли китап чыгару тармагы инде тәмам оешып житкән була.

Милли вакытлы матбугат чыгару эше күпкә авыррак шартларда барды. Татар периодик басмасын нәшер итүнең беренче омтылышы 1808 елга карася да, бу мәсьәләдә дәүләти чикләүләр сәясәте 1905 елга кадәр Идел-Урал татарларына периодик басма чыгару эшен практик яссылыкка куярга мөмкинлек бирмәде (1883 елдан башлап Кырым татары И. Гаспралының «Тәржемән» газетасын исәпкә алмаганда). Әмма, 1905 елдан башлап, беренче чын татар газетасы чыга башлаганнан соң, империя сәяси даирәләренең татар басмаларының санын 3-5 тирәсендә тоту планнарына карамастан, Идел-Урал татарлары тиз рәвештә тулы канлы, тармакланган, туган телдә чыгучы периодик басмалар челтәрен булдырдылар. 1905-1917 елларда бу челтәргә 100гә якын басма кереп, аерым елларда гадәттә 20 чамасы газета һәм журнал нәшер ителгән (шуларның унысы өзлексез чыгып торды). Татар периодикасы барлыкка килү XX йөзнең беренче дистәләрендә татар милли-мәгълүмати челтәренең (ул башкорт халкын да 1920 нче елларга кадәр мәгълүмат белән тәэмин итеп торган) тәмам формалашып бетүенә китерде.

Татар теленең статусы мәсьәләсе. Россия империясендә татар теленең статусы мәсьәләсе татарларда «югары» мәдәниятнең массакүләм мәктәбе һәм милли-мәгълүмати система кебек сегментлары оешып бетә бару белән катлаулана башлады. Әмма 1917 елга кадәр бу империядә татар теленең рәсми статусын тану турында сүз дә булу мөмкин түгел иде. Татарларның туган телләренең хокукый яктан яңа статусын беркетү өчен көрәшүенең беренче этабы 1917 елгы Февраль революциясеннән соң башланды.

Идел-Урал төбәгендә 1917 елның апрель аенда үткән беренче губерна мөселман съездларында ук (14-17 апрельдә—Уфа, 23-24 апрельда Казан губернасында) мөселманнар яшәгән районнарда дәүләт учреждениеләрендә татар телен рәсми тел итеп тану, мәктәпләрдә укыту теле буларак куллану өчен тавыш бирелде. Шулай итеп, сүз татар теленә региональ дәүләт теле статусы бирү турында барды. Россиядә татар теленең статусы буенча татарларның позициясе 1917 елның 22 июлендә (яңа стиль белән 4 августта) Казанда эчке Русия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни мохтариятен игълан итүдән соң ахыргача ачыкланды: «төрки» тел, ягъни татар әдәби теле (әйтелгәнчә, ул башкортларга да хезмәт итте), рус теле белән тигез дип игълан ителде. Бу тел барлык административ учреждениеләрдә һәм «төрки-татар» халкы яшәгән жирләрдә мәктәпләрдә дә кулланылырга тиеш иде. Рус теленең элекке статусы инкарь ителмәде—татар теле икенче дәүләт (рәсми) теле буларак күзалланды.

Татар теленең дәүләти статусын тормышка ашыруның икенче этабы Татарстан АССР төзелгәннән соң башланды. «Татар Социалистик Совет Республикасы турындагы положение»дә үк (1920 елның 28 февраленнән дә соң түгел) «дәүләт учреждениеләрендә рус теле белән беррәттән официаль тел булып татар теле тора» дигән пункт бар иде. Әмма 1920 елның 27 маенда дөнья күргән «Автоном Татар Социалистик Республикасы» турындагы ВЦИК декретында мондый пункт юк, ахрысы, бу большевикларның татар теленең дәүләти статусын беркетеп куярга

теләмәгәнлеге турында сөйли. Шулай да, 1921 елның 25 июнендә дөнья күргән Татарстан АССР БҮБК һәм ХКС декреты тарафыннан татар теле «барлык дәүләт совет учреждениеләрендә мәҗбүри» дип игълан ителде, ягъни ул дәүләт теле буларак беркетелде. Рус теле исә үзенең рәсми хәлен саклады, чөнки ул «татар теле белән бер дәрәҗәдә дәүләт теле» булып калды.

1921-1925 елларда татар теленең дәүләти статусын тормышка ашыру буенча шактый гына документлар кабул ителде. Ике дәүләт (официаль) теле турындагы урын 1925 елның 25 июненнән дә соңга калмыйча эшләнгән Татарстан АССР Конституциясе проектында (аны Мәскәү расламый) да булган. 1920 нче елларның урталарына кадәр Татарстанда татар теленең ике дәүләт теленең берсе буларак үсүе аның функцияләренең шактый киңәюенә китерде. Ләкин татар теленең хокукый статусын тормышка ашыру буенча эшләнгән эшләр шактый чикләнгән булып, 20нче еллар ахырыннан бу өлкәдә алып барылган сәясәт юк дәрәҗәдә калдырылды. Нәтиҗәдә XX йөзнең беренче дистәләрендә татар теленең дәүләти статусын конституцион беркетүнең ныгып урнашуына Татарстан эчендә дә ирешеп булмады, ә инде 1921-1925 елларда кабул ителгән документлар нигезендә билгеләнгән бурычларны тормышка ашыру буенча алып барылган уңышлы сәясәт турында әйтеп тә торасы юк.

Башкортстан АССР кысасында татар теленең хәле шактый үзенчәлекле булып чыкты: ул анда дәүләт теле булып танылмаса да, de facto аның статусы 1920-1930 елларда шундый статуска якын иде.

Ә инде РСФСРның башка төбәкләрендә һәм СССРның башка республикаларында татар теле 20нче елларда рәсми статуска да ия булмады, халык мәгарифе (мәктәптә) һәм периодик басмаларда, өлешчә суд өлкәсендә (җирле судларда) генә кулланышта булды.

Шулай итеп, Идел-Урал төбәгендә татарлар төрле республикалар һәм өлкәләрнең чикләре белән бүлгәләнеп, үз телләренең хокукый статусын XX йөзнең беренче дистәләрендә дәүләти дәрәҗәдә фәкать тик Татарстанда гына беркетә алдылар.

Милли мәдәниятнең башка элементлары (татар театры, академик фән h.б.), шулай ук милли этапта барлыкка килсәләр дә, монда аерым каралмаячаклар. Ләкин шуны әйтеп китәргә кирәк: театр һәм гуманитар фән шулай ук татар әдәби теленнән башка яши алмаслар иде, ягъни мондый тел аларның алшартлары булып тора.

***

Шулай итеп, XVIII йөзнең ахырларында ук оеша башлаган татар милли «югары» мәдәнияте, Россиядәге сәяси һәм социаль-икътисади шартлар нәтиҗәсендә чагыштырмача тиз рәвештә XIX йөзнең икенче яртысыннан соң гына үсә башлады. 1860-1920 елларда татарларда шактый югары үскән милли мәдәният барлыкка килеп, аның үзеген «югары» мәдәният тәшкил итте. Шуны да искәртү кирәк: өлешчә бу мәдәният үзенең формалашуының логик тәмамлануына совет чорында гына иреште. Ләкин Советлар Союзы кысаларында 1920нче елларда да империячел сәясәтнең нигезләре саклану сәбәпле, татарларга үзләренең «югары» мәдәниятләренең үсешен тәгәлләү өчен шартлар булмады. Шулай да, бөтенләй үк формалашып бетмәгән милли мәдәният булдыру да XX йөз башларына татар милләтенең аякка басуын күрсәтүче әһәмиятле бер индикатор булып тора.

### IV бүлек
## ТАТАРДА МИЛЛИ АҢ БАРЛЫККА КИЛҮ

Безнең замандашларыбызның күбесе соңгы вакытларга кадәр паспортларда һәм кайбер башка документларда күрсәтелеп килгән этноним—гомуммилли үзатамабыз—һәрвакыт булган дип саныйлар. Әмма аларның бу фикере белән килешеп булмый—милли үзаң фәкать тик милли берлек формалашкан заманда гына барлыкка килә, әле анда да үзеннән-үзе түгел, күбрәк зыялыларның тырышлыгы нәтиҗәсендә. Бу процесс бер халыкта да гади генә бармаган, чөнки милли үзаң тусын өчен элекке җирле, конфессиональ, сословие белән бәйле h.б. атамалардан

баш тартырга, яна үзатамага күнегергә кирәк.

Еш кына милли берлек вәкилләренең үзаннары бернечә «катлы» (иерархияле) була—гомуммилли атама белән бергә иске жирле исемнәр, кайбер очракта дин белән бәйле атамалар (конфессионим) да сакланып кала. Милли чорда татар идентитеты мәсьәләсе, житәрлек өйрәнелмәгән булу сәбәпле, мифлаштырылган килеш кала килде. Аерым алганда, бу «татар» дигән гомуммилли этнонимның ныгып урнашу мәсьәләсенә карый. Татарларны болгардан килеп чыккан дип санаучы кайбер авторлар, «татар» этнонимын бездә «ялгыш«, «табигый булмаган» һәм ахыргача фәкать тик XX йөз башларында гына кабул ителгән узатама дип санап килделәр. Соңгы елларда шуңа охшаган карашны америкалы тарихчы А.Франк та алга сөрде: аның докторлык диссертацясендә татар милли идентетлыгының массакүләм төс алып таралуы совет чорында гына булган дигән караш әйтелә; имеш, Идел-Урал буе мөселманнарының күбесе өчен 1920нче елларга кадәр болгар үзаңы хас булган. Тыштан караганда, бездә язучы һәм күрсәтелгән чит ил галименең фикерләре бер төсле булып тоелса да, алар арасында аерма бар һәм чынлыкта кайбер татар галимнәренең карашлары А.Франк тора торган позициядән нык кына аерыла. Безнең үзебездә эшләгән бу төркем галимнәр ышануынча, «татар» этнонимын безгә рус таккан (мәсәлән, Ә.Г. Кәримуллин ул турыда түбәндәгечә язды: «... болгарга («татар» атамасы—Д.И.) царизмның милли-колониаль сәясәте тарафыннан көчләп тагылган». Ә менә А. Франк бөтенләй башка позициядән чыгып эш итә—аның фикеренчә, Идел-Урал буе мөселманнарына болгар идентетлыгын XVIII йөзнең урталарында мөселман руханилары таккан. Сәбәбе—төбәктәге мөселман өммәтен берләштерү. Моны эшләгәндә алар мөселман жәмәгатьләрендә (общиналарында) инде яшәп килгән урта гасыр Болгар дәүләте белән бәйлелек турындагы тарихи традицияләрне файдаланганнар.

Гомумтеоретик планда караганда, милли үзаңның ике чыганагын күрсәтергә кирәк: 1) феодаль халыкчык дәверендә үк барлыкка килгән этник аң (халык үзаңы), 2) интеллигенция тарафыннан кертелгән этник үзаңның яңа катламы. Һичшиксез, яңа идентитет эшләп чыгаручы зыялылар бу процесс вакытында урта гасырлар катламнарыннан «чистартылган» иске этник атамаларны да кулланганнар—алар бу очракта гомуммилли этноним өчен үзләре иң кулай дип санаган атамаларны сайлап алганнар. Билгеле, монда кирәк дип санаган яисә фаразланган оештырылучы милли берлекнең этник чикләреннән чыгып эшләнгән конструкцияләү элементлары да булырга мөмкин. Әмма халык массалары милли идеяләрне пассив рәвештә үзләштерүчеләр генә булмаганлыктан, милли үзаң барлыкка килү процессына реаль йогынты бик күп факторларга бәйле була, бигрәк тә социаль үзгәрешләр темпына (шул исәптән этно-мәдәни үзгәрешләргә дә).

Милли зыялыларыбыз тарафыннан милли идентитетлыкны формалаштыруда ике төп этапны күрсәтергә була: XVIII-XIX йөз урталары—«мөселман идентитетлыгы» нигезендә барган үсеш чоры; XIX йөзнең икенче яртысы—XX йөзнең беренче дистәләре—этниклыкка нигезләнгән милли үзаң аякка басу чоры. Инде беренче чорда ук мөселман руханилары йөзендә татар идеологлары тарафыннан төбәктәге мөселан халкының идентитетлыгын булдыруга татарларда тарихи аң барлыкка килү процессына йогынты ясау аша күзгә күренерлек тәэсир итү булды. Ләкин, XVIII-XIX йөзләр урталарында алар әле яңа типтагы, урта гасырдан мирас булып калган, дини һәм үзенә аерым этник компонетларның аерылгысыз бәйлелеге белән характерланган үзаннан аерылып торучы этник үзаңны максатчан рәвештә формалаштыруны бурыч итеп куймаганнар. Аның иң ачык билгесе—ул вакытларда татарларда «мөселман» конфессионимының актив кулланышта булуы. Икенче чорның башында (XIX йөзнең икенче яртысында) татар идеологлары тар төбәкчелек һәм сословие белән бәйле атамаларны, шулай ук «мөселман» конфессионимын чын «этник» этноним белән алыштырырга омтылалар. Ә XX йөзнең беренче дистәләрендә милләтебезгә башка этнонимнар—алар тарихи сәбәпләр нәтижәсендә сакланмадылар—«ябыштыру» омтылышлары да ясалды. Ахыр чиктә нәкъ менә «татар» атамасы, аның тарихи яктан тамырланган һәм «интеграль» булуы сәбәпле, гомуммилли этноним булып кала.

Бу чорда нәрсә булганын карап үтик. Ләкин анарчы XIX йөзнең урталарына кадәр татарларга хас үзанның нинди булганлыгын күздән кичереп үтү кирәк булыр. Инде әйтелгәнчә, бу дәвер өчен аерым «мөселман» үзаңы (ул татар һәм башкорт өчен уртак булган) турында сүз алып барырга кирәк. Төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә ул үзаң «мөселман» конфессионимы кыяфәтендә аеруча тотрыклы булып чыкты. XVIII-XIX йөзләрнең урталарында Идел-Урал төбәгендә ул үзанның киң таралуы монда XVIII йөздән башлап мөстәкыйль «мөселман» милләте формалашуга бәйле булды.

XIX йөзнең икенче яртысына Идел-Урал буйларындагы мөселман берлегендә яна күренешләр күренеп, ул «этно-мәдәни» милләткә әйләнә башлагач, Идел-Урал татарларының идентитетлыгы турындагы сорау аермачык кискенләшкәч, идеологлар өчен икенче бер типтагы идентитетлыкка көчү кирәклеге торган саен ачыграк була башлады. Андый күчеш проблемасын иң анык рәвештә куючы—оешып килүче татар милләтенең иң күренекле идеологларыннан булган һәм милләт «төзүнең» икенче «чиратын» беркадәр алдан сизгән, ул эштә катнашкан Ш. Мәрҗани (1818-1889) иде. Татар идентитетлыгы турындагы үз идеяләрен ул, әле күптән түгел генә безнең милләттәшебез, Ю. Шамил угълы (Америка тарихчысы) тарафыннан «Казан (ягъни, Идел-Урал—Д.И.) татарларының беренче заманча тарихы» дип аталган, «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле зур тарихи әсәрендә (беренче томы 1889 елны нәшер ителде, икенчесе—1900 елда) язып чыкты. Идел-Урал буе татарлары тарихын тасвирлаганда, Ш. Мәрҗани «татар» этнонимын куллануны максатка яраклы дип таба. Ю. Шамил угълы фикеренчә, шушы этноним аркылы ул үз дәверендәге «Казан» (Идел-Урал) татарлары һәм Идел буе болгарлары арасындагы бәйлелекне Казан ханлыгы һәм Алтын Урда аркылы барган тарихи дәвамчанлык буларак билгеләргә омтылган. Бу анлатма әһәмиятле, әмма, житәрлек түгел. Мәсьәләнең тагы бер ягына америкалы тарихчы А.Франк тукталды.

Аның фикеренчә, Мәрҗани элегрәк барлыкка килгән кайбер «образларны»—бу очракта—«болгар» идентитетлыгын—«сүтү» белән мәшгуль булган. Чөнки, аның уенча, Идел-Урал мөселманнары берлеген этник бергәлекнең (Идел-Урал төркиләре) сәяси организм (Алтын Урда дәүләте) белән кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән «татарлар» тәшкил иткән. Бу автор уйлавынча, Мәрҗани өчен татар милләте оешуда этник һәм сәяси факторлар—беренчел, ә дини фактор икенчел булып торган. Ш. Мәрҗани фикерен тәнкыйтьләп, Ә. Франк хәтта болай дип белдерде: «аерым индивидлар тарафыннан ирекле рәвештә кабул ителгән исламга нигезләнгән болгар идентетлыгы, хәзерге заман, ирекле рәвештә сайлау мөмкинлеге азрак булган, күбрәк этник һәм генетик детерменизмга нигезләнгән татар милли идентитетлыгы идеологиясенә альтернатива буларак үзенчә әһәмиятле». Күренгәнчә, бу тарихчы Ш.Мәрҗанине Идел-Урал төбәгендәге өмматкә «татар» этнонимын көчләп «тагуда» гаепли. Ләкин Мәрҗанинын бу этнонимны сайлап алуы күпкә катлаулырак сәбәпләр комплексы белән бәйле.

Аларны тикшерүгә күчкәнче татар тарихчысы хезмәтеннән аның фикер агымын ачып бирүче кайбер урыннарны китерү кирәк. Мәсәлән, ул болай дип яза: «... чиктән тыш наданлыклары аркасында, Мавәраэннәһередә (ягъни Амударья һәм Сырдарья арасында—Д.И.) яшәүче сарт халкына карап, дөреслеккә каршы килеп үзләренә «нугай» исемен алып, үз араларындагы сөйләшү-утырышларда шул исемне йөртеп һәм үзләрен шул халыктан дип санасалар да... ». Бу язмадан күренгәнчә, монда әһәмиятле бер факт—Урта Азия төркиләре тарафыннан татарларны «нугай» дип атау традициясе тасвирлана һәм кайбер татарларның шул исемне кабул итүе күренә. Ләкин татарларның яна идентитеты проблемасының күпкә авырырак икенче ягы да бар иде—ул иске «мөселман» идентитетлыгының нык булуы. Реформатор-галим татарлар арасында кайберәүләрнең «рус халкының аларны кимсетү, хурлау рәвешендә татар дип әйтүләреннән ... татар булуны бер кимчелек санап, ул исемнән чирканып, без татар түгел, без «мөселман» дип тавыш-җәнҗәл чыгаруларын да аерым күрсәтеп үтте. Әмма Мәрҗани этнонимны конфессионим белән алмаштыруга кискен каршы чыкты һәм түбәндәгечә белдерде: «Нинди кызганыч хәл, бу исемнәр (татар белән мөселман) арасында Нил белән Ефрат елгалары арасындагы

ераклык кадәр зур аерма бар бит! И мескен! Әгәр синең «мөселман»нан башка бер исеменне дин һәм милләтен дошманы белмәсә иде, сине, әлбәттә, «мөселман» дип дошман күрерләр иде». Һәм ул болай дип өстәп куя: «Татар булмасаң, ... инде кем булырсың?» Анлашылса кирәк, Ш. Мәрҗани инде заманча, этниклыкка нигезләнгән идентитетны сайлап алган була.

Әгәр дә тарихчыны шушы юлга этәрүче сәбәпләргә килсәк, минем фикеремчә, алар түбәндәгеләр. Беренчедән, Мәрҗани заманында татарлар арасында әле төбәкчелек үзатамалары һәм башка исемнәр таралган булган (алар арасында читтән «кертелгән» нугай атамасын да күрсәтү кирәк, чөнки Урта Азия белән аралашу көчәйгән дәвердә бу әһәмиятле факторга әйләнгән). Татар тарихының атасы булган идеолог «татар» этнонимы кебек киң таралган һәм берләштерүче атаманы якламыйча булдыра алмаган. Аның бу этнонимны сайлап алуында бабаларының элекке бөеклеген хәтерләгән (ул турыда руслар да онытмаганнар, моны Мәрҗани төшенгән) йомышлы татарларның тарихи хәтере дә, ахрысы, соңгы роль уйнамагандыр. Икенчедән, «татар» идентитетлыгына каршы торучы «мөселман» идентитетлыгы, үзенең «чиксез» булуы белән, милли бергәлекнең нигезен алга таба ул заманда торган саен этник төс алган милли мәдәният тәшкил итәчәген аңлаган Мәрҗанины канәгатьләндерә алмаган. Өченчедән, Мәрҗани карашларының ахыргача формалашуына татарларны Алтын Урдадан килүче кыргыйларның (ул вакыттагы рус тарих фәненең Алтын Урда халкын бәяләве шундый булган) варислары итеп күрсәтергә теләүче миссионерлар да йогынты ясаган булса кирәк. Шушы караш белән көрәшү өчен Мәрҗани төрле төрки дәүләтләр белән соңгы чор татарлар арасындагы бәйлелекне расларга тырышкан. Димәк, милли тарих фәненә нигез салучы империя идеологлары торгызган корылмаларга каршы чыгып, инде эшләнгән татар милли идентетлыгы юнәлешен бозуны булдырмаска тырышкан. Дүртенчедән, татарда хәзерге этнонимның ныгып урнашуында рус мохитенең (шул исәптән, рус администрациясенең дә) ролен да танымыйча булмый. Бу факторны Ш. Мәрҗани, һичшиксез, исәпкә алган. Ул аның халык турындагы «дин һәм милләт дошманының» күзаллавыннан беркая да китеп булмавы турындагы сүзләреннән һәм аның шул вакытта «татар» этнонимын монгол яулап алучыларыннан аерып карарга теләвеннән күренә. Бишенчедән, карала торган проблеманың гел фәнни ягын да онытырга ярамый: татар тарихында «татар» компонентының (Алтын Урда төркиләренең) үз урынын танымыйча торып Идел-Урал татарларының этник үсеше проблемасын хәл итеп булмас иде, ә бу үз чиратында Ш. Мәрҗанигә төзек милли тарихны язарга мөмкинлек бирмәс иде. Мәгълүм ки, галим буларак Мәрҗани ул вакыттагы тарихи белем дәрәҗәсендә бу бурычны уңышлы үти.

Мәрҗани дәверендә яна идентитетлык әле формалаша гына башлаган була, чөнки аның табигый нигезе булган «югары мәдәният» барлыкка килү һәм аның йогынтысы нәтиҗәсендә үзгәрүче мәдәниятнең традицион-халык катламының трансформацияләнүе нәтиҗәсендә үсүче милли этник мәдәният әле оешып кына килгән. Шуңа күрә крестьяннар массасы арасында, бигрәк тә Казан татарлары тупланып яшәгән районнарда, иске идентитетлар, бигрәк тә «мөселман» конфессионимы, яшәп килгән. Ул турыда вәисовчылар хәрәкәте белән бәйле материаллар сөйли (хәрәкәтнең башлануы 1860 нчы елларга карый). Хәрәкәткә нигез салучы Бәһаветдин Вәисов (1819-1893) үзен «төрки сословиесендә» торучы «иске диндәге мөселман» дип санаган. Аның тарафдарлары 1890нчы елларда үзләрен «болгарлы Вәисов алла полкының иске диндәге мөселман җәмгыяте» дип исемләп, «татар-крәстиәннәр» икәнлекләрен танырга теләмәгәннәр, «татарлар белән бернинди дә уртаклыгыбыз юк»,—дип белдергәннәр. Алар фикеренчә, «татарлар калимишәргатькә ышаналар (ягъни мөселман теологиясенә—Д.И.), вино эчәләр, тәмәке тарталар, ә аларның хатыннары зина кылалар». Алардан аермалы буларак, «иске диндәге мөселманнар боларны эшләмиләр, алар изге Исламга, изге Шәригатькә һәм изге Коръәнгә ... ышаналар». Вәисовчылар крәстиәннәрдән һәм вак мещаннардан торганлыктан, моның ише рухның һәм үзенчәлекле «мөселман» үзаңының XIX йөзнең икенче яртысында халык массаларында таралган булганлыгын танырга кирәк. Моны Ш.Мәрҗани да таный—ул аның татарларның бер өлешенең

үзенең «татарлыгын» инкаръ итеп «мөселман» булуларын күрсәтүләре турындагы сүзләреннән бик ачык күренә. Татар мәгърифәтчесе К.Насыйриның (1824-1902) XIX йөзнең соңгы чирегенә караган сүзләрен дә шулай ук аңлатып була. Аның берсе бу рәвешле яңгырый: «... милләтебез халкын татар тәслия кылсам, яратмадылар, татар теле дисәм, яратмадылар...». Бу галим тарафыннан конкретлаштырылмаган «татар» этнонимын кабул итмәүче «яратмаучылар» «мөселман» конфессионимы тарафдарлары булган булса кирәк.

Теге яки бу төркем зыялыларының үзләре формалаштырырга омтылган этник бергәлекнең чикләрен ничек үткәрергә тырышуларына бәйле рәвештә, XX йөзнең беренче дистәләрендә татарлар өчен башка этнонимнар да «ясап» каралды. Шуңа күрә гомуммилли этноним тирәсендә бәхәсләр бу заманда да булды. Юкка гына Г.Ибраһимов үзенең «Без—татарлар» (1911 ел) дип аталган мәкаләсендә түбәндәгечә язмады: «Татарлар нишләптер бу исемнән (татар этнонимыннан—Д.И.) читләшәләр». Ә моның сәбәпләре берничә була. Иң башлап, билгеле, эш монда Идел-Урал татарлары арасында «мөселман» идентитетының нык булуында. Мәсәлән, күренекле татар этнографы һәм тарихчысы Г.Әхмәров (1864-1911), татарларның болгардан барлыкка килүе турындагы теория тарафдары, үзенең «Болгар тарихы» (1909 ел) исемле китабында, замандашлары—Казан татарларының «Казан мөселманнары» һәм «Казан төркиләре» дип эндәшкәнне кулайрак күрүләре турында яза. Җәмгыятьтә «татар» этнонимына каршылык тууның башка сәбәпләре дә булган. Алар арасында зыялыларның самодержавиегә каршы бөтен төрки һәм мөселман халыкларның бердәм хәрәкәте зарурлыгын истә тотуларын аерып күрсәтү кирәк. Шуңа күрә дә XX йөзнең башында татарлар арасында квазиэтноним булган «төрек», «төрк» атамалары әйләнешкә керә. Мәсәлән, татар язучысы Ф.Кәрими 1914 елны мондый сүзләр язган: «без төркиләрме, әллә татарлармы дип тикшерәбез һәм мөмкин булганча үзебезнең татар булганлыгыбызны исбат итәргә тырышабыз». Алга таба ул болай дип яза: «Безнең асылыбыз, тамырыбыз, рухыбыз һәм фикеребез төрек түгелме?» Мондый татарны төрек (төрк) дип карауның объектив нигезләре дә була—тарихи һәм лингвистик тикшерүләр төрки халыкларның туганлыгын, аларның тарихларының уртаклыгын исбат иттеләр. Бу турыда күренекле татар зыялысы Җ. Вәлиди түбәндәгечә язды: «... Безнең үткәнне өйрәнгән тарихчылар безне төркиләр дип атыйлар...». Чынлап та, Г.Әхмәров кебек болгар теориясе тарафдары да, Казан татарларына карата «болгар» этнонимын гына түгел, ә «төрки-болгар халкы» атамасын да кулланган. Шулай ук, актуаль сәяси вәзгыять өчен бик кулай булган «мөселман» конфессионимы саклану «төрк» (төрек) квазиэтнонимы кулланучылар тарафыннан да ныгытылган, чөнки Россиядә яшәүче төрки халыкларының күпчелеге мөселман булганнар. Ләкин татар зыялыларының «татар» этнонимы чикләреннән чыгарга тырышуының тагын бер өстәмә сәбәбе дә булды: бу—төньяк-көнбатыш башкортларының татарлар белән ассоциацияләнгән булуы. Татар зыялылары арасында татарлар белән башкортлар бер этник бергәлек тәшкил итәләр дигән караш таралган булган. Аны бик төгәл итеп Җ. Вәлиди әйтеп бирде: «... мишәрләрне һәм башкортларны татар дип санап буламы дигән сорау бирү тулаем мәгънәсез һәм урынсыз булыр иде», чөнки «бер халыкны икенчесеннән аеручы—телдәге аерма, ләкин мишәрләр һәм башкортлар теле белән Казан татарлары теле арасында әллә ни аерма юк». Мондый фикернең яшәве 1917 елга кадәр Идел-Урал татарларында формалашкан «югары» мәдәниятнең башкортларга да хезмәт итүе белән дә бәйле.

Әмма, татар зыялылары арасында гомуммилли этнонимны сайлау буенча төрле карашлар таралган булса да, төп юнәлеш булып акрынлап бу сыйфатта «татар» этнонимның позициясе ныгу торган. XX йөз башларындагы эре фикер иясе булган Җ. Вәлиди бик нечкә рәвештә ул турыда мондый сүзләр язып калдырган: «... безнең әдәбиятчыларыбыз, шагыйрьләребез һәм *яшьләребезнең* (безнең курсив—Д.И.) зур өлеше безне татар дип атый». Чынлап та, татар җәмгыятенең яшьрәк өлеше һәм бигрәк тә киң мәгънәдә әдәбиятчылар (журналистларны да кертеп), берсүзсез «татар» этнонимын яклыйлар. Г. Ибрагимов, мәсәлән, «төрки» дигән ялган атамадан «читләшү» өчен, болай дип яза: «славян булганнар рус булган төсле ... төркиләр дә татар була ала». Г. Тукай үзенең «Халык әдәбияты» (1910 ел) дигән мәкаләсендә

«без татарлар һәм без татар булып калдык»,—дип язган. Ә инде талантлы шагыйрь һәм алтын приискаларының хуҗасы З. Рәмиев (Дәрдемәнд) мондый рәвешле итеп әйткән үз фикерен:

*Татарлыктан татар һич гарь итәрме,*
*Кеше үз исмене инкяр итәрме.*
*Татарлыкта татар углы татармын,*
*Татар түгел димә—башың ватармын.*

Нәкъ менә шушы бәхәсләргә ясалган бер күзәтүдә («Шура» журналы, 1912 ел) болай диелә: «...«татар» дип йөртелүчеләргә багышланган мәкаләләргә күп урын бирелә: бер яктан, татарлар белән бөтен төрки миллиятчелеге арасындагы тугандашлык мөнәсәбәтләре ачыкланса, икенче яктан, аерым төрки кабиләләргә мөнәсәбәт тикшерелә һәм татар атамасын мишәр, башкорт һәм хәтта казакъ-кыргыз атамасына карата куллану әле бетмәгән».

1910нчы еллардагы документлардан күренгәнчә, татарларда милли үзаңны үстерүдә татар зыялылары һәм татар буржуазиясе иң зур активлык күрсәткән. Крәстиәннәр бу процесста катнашмасалар да, милли идеология йогынтысы астында аларда да этник аң тиз рәвештә үзгәргән. Революция алдыннан татарлар тарафыннан гомуми рәвештә караганда яңа тип идентитетлыкны үзләштерү турында Казан губернаторы П.М. Боярский бик тулы итеп әйтте. Ул күрсәтеп үткәнчә, «элек «син нинди милләттән»,—дигән сорауга татар «мөселман» дип җавап бирсә», хәзер Казан губернасында «мөселманнарның дини фанатизмга тартылышы кимеп, халыкчылыкны күтәрүгә, татар милләтчелеген үзләштерүгә һәм мөстәкыйль мөселман мәдәнияте булдыруга омтылыш көчәя».

Шулай да, формалашып килүче милли анга ахыргача оешып җитү процессында берникадәр үзгәрешләр кертү юнәлешендә йогынты ясап була иде әле. Мондый «конструктивистик» рухтагы омтылыш татар идеологлары тарафыннан татар «сәяси» милләте «төзү» дәверендә ясалды.

1917 елның җәендә «Эчке Русия мөселманарының милли-мәдәни мохтарияте нигезләре» дип исемләнгән документ проектында либераль буржуазия идеологлары «төзергә» тырышкан этно-сәяси бергәлекне (милләтне) анлатучы берничә төшенчә барлыкка килде. Бу, бер яктан, «эчке Русия һәм Сибирия мөселманнары» төшенчәсе (аның кыска варианты—«Эчке Русия мөселманнары»). Текстта ул кыскача «мөселман», «мөселманнар» дип тә бирелә. Анлашылса кирәк, бу төшенчә безгә таныш булган традицион «мөселман» конфессионимы. Ул документ та 1917-1918 еллар башларындагы сәяси процессларда әһәмиятле роль уйнаган руханилар йогынтысыннан тыш барлыкка килмәгәндер. Мондый нәтиҗәне мөфти Р. Фәхретдиновның фикере дә ныгыта—ул әле 1925 елны да «мөселманнар» исеме астында татарларны, башкортларны, мишәрләрне һәм типтәрләрне бер «милләт» дип санаган. Әмма, икенче яктан, югарыда аталган документта «төрки-татар» төшенчәсе, ягъни милли үзаң үсүдәге «төрекчеләр» һәм «татарчыларның» карашларын берләштерүче термин зуррак әһәмияткә ия булып тора. Бу документтагы өченче төшенчә—«төрки тел». Ул хәзерге татар әдәби телен белдереп, «төрки-татар» этнонимының үз составына Идел-Урал (шул исәптән, Әстерхан) һәм Себер татарларын, шулай ук башкортларны да керткән «сәяси» милләтне анлатканлыгын күрсәткән (барлык бу төркемнәр дә ул чорда бер әдәби тел кулланганнар). «Мөселман» конфессионимы чынлыкта шул ук мәгънәгә ия булган. Шунын өстенә, Милли-мәдәни мохтарият Конституциясе (1918 елның 16 гыйнваре) «сәяси» милләтнең исемен «төрки-татар» формасында гына түгел, ә «Эчке Русия һәм Сибирия төрки-татар мөселманнары» рәвешендә дә бирә, димәк, аларның синонимнар булуын раслый. Игътибар итегез, бу очракта Себер татарларының милли «проектка» кертелгәнлеге аермачык күренә.

Идел-Урал штаты проектына алмашка Татар-Башкорт Совет Республикасы төзү проекты килгәч, татар интеллигенциясе иҗтимагый аңда башка атаманы—«татар-башкорт» атамасын ныгытырга тырышып карады. Бу, ахыр чиктә, идеологларның аерым территориаль форма алырлык милләтне «конструкцияләү» омтылышы белән бәйле иде. Әйтелгән очракта татар идеологлары кайбер объектив факторларны (Урал

буеның төньяк-көнбатышындагы татар һәм башкортларның этно-мәдәни берлеге) исәпкә алып эш итсәләр дә, алар тәкъдим иткән позиция артык кин булып чыкты. Башкортларның идеологлары инде 1917 елның июль-август айларында үзләрен «Идел мөселманнарына» (татарларга) каршы куеп, үз территориаль автономияләрен— «Башкортстан штатын» (сүз «Кече Башкортстан» кысаларындагы башкорт «сәяси» милләте турында бара) төзергә теләүләрен белдерделәр. 1920 елны «татар-башкорт» атамасы турындагы сорау тагы өскә калыкты. 1920 елның 17 гыйнварында ясалган белдерүдә Башкорт республикасы лидерлары «ана (ягъни—Татар Башкорт Совет Республикасына—Д.И.) «Татар-Башкорт Республикасы» исемен бирүгә каршы булуларын», «татар-башкорт теле», «татар-башкорт әдәбияты», «татар-башкорт армиясе» кебек терминнар куллануга да риза түгеллекләрен белдерделәр.

Нәтиҗәдә татар лидерларына акланырга туры килде: алар без яңа республикага ике өлештән торган исемне «прозелитлыктан түгел, ә Совет Башкортстаны чикләреннән тышта калган һәм Татар республикасы составына кергән (төгәлрәге—кертелергә планлаштырылган—Д.И.) башкортлар бу республиканың татар милләте исеме астында йөрүенә каршы килерләр дип, *саклыктан* (безнең тарафтан аерып бирелде—Д.И.) бирелгән»,—дип күрсәттеләр. Уфа губернасын Башкортстан АССРга (1922 ел) китереп кушкач, татар идеологларының «конструкцияләүгә» омтылышына чик куелды. Шулай да 1920нче елларда татар-совет элитасы вәкилләренең кайбер әйтелгән сүзләрендә яшерен рәвештә «төрки-татар» милләтенең шәүләсе чагыла иде. Ә сәяси эмигрантлар өчен «төрки-татар» анлатмасы төп термин булып калды. Аның шулай икәнлеген Г. Исхакыйның «Идел-Урал штаты» исемле әсәре раслый (Париж, 1933 ел). Башкортстан ҮБК VIII чакырылыш, 3 сессиясендә (1932 ел) кабул ителгән карарындагы «башкортларга карата алып барылган татар бөекдержавачылык сәясәте» турындагы сүзләрне очраклы дип булмый. Чөнки бу карарда Башкортстан мәгариф комиссариатына «башкорт телен укытуны татар теле укыту белән алмаштыруны тулысынча бетерү өчен адымнар ясау» кирәклеге турында әйтелә. Димәк, бу республикада татар белән башкортның бер-берсенә «береккәнлеге» (төньяк-көнбатыш районнарда) яшәвен дәвам иткән.

* * *

Шулай итеп, 1917-1920 елларда милли идентитетлыкның барлыкка килүе процессына татар идеологларының йогынты ясау теләге унышлы төгәлләнмәде. Бу башкорт элитасының каршы торуы белән дә һәм гомумән 1917-1920 елларда татар «сәяси» милләтен кин этник һәм территориаль кысаларда төзү турындагы татар милли хәрәкәтенең сәяси проекты җимерелүе белән дә бәйле. Ләкин бер планда татар идеологларының тырышлыклары бушка китмәде: 1920нче елларга татарларның күпчелеге гомуммилли үзатама буларак «татар» этнонимын үзләштерде.

Ләкин Урал буеның төньяк-көнбатышында татар телле халыкның тулаем «татар» һәм «башкортка» аерылуы күзәтелмәде—күпчелек очракта бу мөмкин булмаганлыктан шулай булды. Димәк, XX йөзнең беренче дистәләрендә милләтнең төрлечә аталуы вариантларын алга сөргән татар идеологлары үзләренең конкрет милләт «төзү» турындагы идеологик омтылышларыннан чыгып кына түгел, ә этник процессларның объектив логикасына ярашлы рәвештә эш итәргә тырышканнар дип уйларга урын бар. Нәкъ менә шул этник процесслар аларга үзләре тарафыннан тәкъдим ителгән милли идентитетлык яшәсен өчен территориаль һәм этник чикләрне мәҗбүри «билгеләгән». Шуңа күрә, Урал буеның төньяк-көнбатышы, «бүленмәгән» идентитет зонасы буларак, фактик яктан татар һәм башкорт идеологлары арасында алга таба этник яктан конкретланган үзатамаларны ныгыту өчен көрәш кыры булып калды.

Нәтиҗә итеп шуны әйтергә була: гомуммилли этноним татар милли бергәлеге барлыкка килүнең ахыргы нәтиҗәсе һәм аның артында бөтен милли мәдәният тора. «Татар» этнонимы—күп санлы татар зыялыларының берничә буын дәвамында эшләү нәтиҗәсе дә. Ул тарих продукты һәм милләт байлыгының иң кыйммәтле өлеше дип әйтергә дә була. Башка исемнәр файдасына үз милли этнонимыбыздан баш тарту, ул исемдә «татар» компоненты калган очракта да, гади бер механик акт кына була алмый, чөнки бу адымның эчендә милли мәдәният белән булган бәйләнешне өзүнең потенциаль мөмкинлеге ята.

**V бүлек**

## ТАТАРЛАРНЫҢ ДЕМОГРАФИК ҮСЕШЕ ҺӘМ ТАРАЛЫП УТЫРЫШЫ

Россиядә яшәүче татарларның саннары буенча ышанычлы мәгълүматлар XVIII йөзнең башларыннан бар. XVIII-XX гасырлардагы татарларның сан динамикасы 1нче таблицада бирелә.

**1нче таблица**

**1719-2002 елларда Россиядә, Советлар Союзында һәм дөньяда татарларның сан динамикасы**

| Еллар һәм сан исәбе (мең кеше) | | |
|---|---|---|
| XVIII йөз | XIX йөз | XX йөз |
| 1719 ел—290,0* | 1833 ел—1327,7 | 1912 ел—3253,9 |
| 1744 ел—495-500** | 1857 ел—1705,4 | 1926 ел—3369,4**** |
| 1762 ел—435,0* | 1897 ел—2552,0 | 1939 ел—4314,0 |
| 1782 ел—672,7*** | | 1959 ел—4967,7 |
| 1795 ел—835,1 | | 1970 ел—5930,7 |
| | | 1979 ел—6317,5 |
| | | 1989 ел—6920,5***** |
| | | 2002 ел—7920,5***** |

**Искәрмәләр:**
**төгәл мәгълүматлар юк:**
*** Кырым һәм Литва татарлары буенча;**
**** Себер татарлары буенча;**
***** Литва татарлары буенча;**
****** шул исәптән Кырым татарлары—1926 елны—179,1 мең һәм 1989 елны—271,7 мең (1989 елгы мәгълүматлар тулы булмаска мөмкин)**
*******—дөнья буенча татарларның гомуми саны.**

Кайбер төркем татарларның XVIII йөздәге саннары буенча мәгълүматлар житешмәсә дә, таблицада китерелгән саннар без өйрәнә торган халыкның XVIII йөздә дә, XIX-XX гасырларда да, күзәтелгән сан үзгәрешләре турында төшенчә бирәләр. Таблицада китерелгән саннарны гомумиләштерсәң, XVIII гасыр башында Россиядә яшәгән яисә аннан соң бу илгә кушылган татарларның саны XIX йөз ахырына биш тапкыр арта. XX йөздә исә татарларның саны тагы ике мәртәбә артты. Ләкин демографик үсешкә ясалган гомуми анализ XVIII-XX гасыр башларындагы аерым татар төркемнәренең сан динамикасында булган үзенчәлекләрне күрсәтми. Бу мәсьәлә буенча безгә 2нче таблицага мөрәҗәгать итәргә кирәк.

**2нче таблица**

**Аерым татар төркемнәренең XVIII-XX йөз башларындагы сан динамикасы**

| | Еллар, сан исәбе (мең кеше), шәһәр халкының % | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1719 | 1744 | 1762 | 1782 | 1795 | 1833 | 1857 | 1897 | 1912 |
| 1.Идел-Урал татарлары | 261,1<br>0,7 | 327,1<br>1,6 | 396,8<br>1,7 | 509,3<br>1,7 | 617,3<br>1,8 | 1019,5<br>2,3 | 1416,1<br>2,0 | 2249,5<br>4,9 | 2936<br>4,9 |
| 2. Кырым татарлары | ...<br>* | 150-160<br>* | ...<br>* | 120,2<br>* | 166,5<br>* | 237,5<br>12,0 | 211,1<br>14,0 | 185,4<br>21,0 | 181,4<br>20,0 |
| 3. Себер татарлары | 23,0<br>* | ...<br>* | 29,0<br>1,2 | 32,3<br>1,4 | 35,0<br>* | 41,8<br>1,1 | 45,2<br>2,2 | 69,4<br>4,5 | 75,6<br>4,7 |
| 4.Әстерхан татарлары | 6-8<br>19-25 | 5,4<br>37,0 | 9,2<br>21,7 | 10,9<br>16,5 | 13,0<br>25,4 | 22,9<br>21,4 | 25,7<br>19,5 | 38,8<br>39,7 | 48,4<br>37,8 |
| 5.Литва татарлары* | ... | 3,0 | ... | ... | 3,3 | 6,00 | 7,3 | 8,9 | 12,5 |

**Искәрмә: *—шәһәр халкы буенча мәгълүматлар юк.**

Башта ук аерым татар төркемнәренең XVIII-XX йөзләрнең башларындагы сан үсешләренең тигез булмауларын күрсәтергә кирәк. Әйтик, бу чор эчендә Идел-Урал татарларының саннары 11,2 тапкыр, Әстерхан татарларының 4,2 тапкыр, Себер татарларының 3,3 тапкыр, ә Кырым татарларының—тик 10-13 процент кына арткан. Мондый аермалыклар социаль-икътисади үсеш үзенчәлекләре белән дә, этник процесслар белән дә аңлатыла. Мәсәлән, соңгы факторларны Идел-Урал татарлары мисалында күрергә була—алар ассимиляция һәм консолидация процесслары нәтиҗәсендә үз составларына шактый күп санлы башка этник төркемнәрне кертеләр. Башка сәбәпләр дә булды. Әстерхан татарларының бер өлеше (нугай этник тамырлылары) күчмә тормыш алып барып, XVIII йөздә Төньяк Кавказга, Кырымга һ.б. төбәкләргә күчтеләр. Кырым татарлары өчен массакүләм күчешләр (эмиграция), бигрәк тә Кырым сугышыннан соң, хас булды. Беренче төркем Кырым татарлары (30 мең кеше чамасы), төрек гаскәрләре артыннан ук 1857 елны эмиграциягә киттеләр. Эмигрантларның төп өлеше Төркиягә 1860-1865, 1874-1875 елларны күчте (135,5 мең кеше чамасы). Кырым татарларының эмиграция хәрәкәтенең алдагы дулкыны 1890нчы еллар башына туры килде—ул елларда 18 меңгә якын кеше Россиядән китте. Төркиягә күчү XX йөз башларында да көчәелде (бигрәк тә 1902-1903 елларда). Нәтиҗәдә, XX йөз башына кырым татар этносының күпчелек өлеше тарихи ватаннарында яшәми иделәр инде.

Тарихи яктан караганда мөстәкыйль татар ханлыклары дәверендә барлык татар төркемнәрендә дә шактый зур шәһәр катламы булганлыгы билгеле. Ләкин, Казан, Әстерхан һәм Себер ханлыкларын Мәскәү дәүләтенә кушканнан соң татарларда шәһәр катламы кискен кимеп, урта гасыр чорыннан чыкканда Идел буенда һәм Көнбатыш Себердә яшәүче татарлар аз санлы шәһәр катламын саклап калганнар иде (ул катлам вәкилләренең күпчелеге Казанда, Әстерханда, Касыймда, Тоболда һ.б. кайбер шәһәрләрдә яшәделәр). Кырымда гына 1783 елга кадәр милли шәһәр тормышы булды. Шулай да, XVIII-XIX гасырлардагы социаль-икътисади үзгәрешләр нәтиҗәсендә, бигрәк тә XIX йөзнең икенче яртысыннан, татарлар арасында шәһәрләшү процессы шактый интенсив рәвештә үсә башлады. Бу процессның тарихи аспекты 3нче таблицада чагылыш таба.

**3нче таблица**

**Идел-Урал регионында XIX йөзнең ахырында—XX йөзнең башында эре шәһәрләрдә яшәүче татарларның саны**

| | Халыкны исәпкә алу еллары | | | |
|---|---|---|---|---|
| Шәһәрләр | 1897 | 1912 | 1920 | 1926 |
| Казан | 28520 | 31449 | 28416 | 44646 |
| Әстерхан | 15355 | 16823 | 16879 | 22234 |
| Оренбург | 11321 | 16835 | 15182 | 14751 |
| Уфа | 5190 | 15400 | 10318 | 14556 |
| Самара | 2302 | 3361 | 3383 | 3895 |
| Сембер | 2191 | 2207 | 2791 | 2581 |
| Саратов | 1711 | 1350 | 2285 | 3150 |
| Пермь | 1305 | 1838* | 2313 | 3539 |
| Царицин | 1671 | 2782 | 2772 | 2533 |
| Түбән Новгород | 912 | 1415 | 780 | 2151 |
| Екатеринбург | 605 | 1000** | 1197 | 2972 |
| Чиләбе | 719 | 1900* | 2280 | 2338 |
| Кострома | 580 | 600 | 108* | 1045 |
| Пенза | 387 | 155 | 450 | 1444 |
| Вятка | 227 | 695 | 296 | 557 |

***—тулы булмаган мәгълүматлар**
**** реконструкция нигезендә**

XXIII-XX йөз башларында Идел-Урал регионында шәһәрдә яшәүчеләрнең саны

77 тапкырдан артыгракка үсте, XIX йөз ахырында Россия шәһәрләрендә яшәгән 240 мең татарның (ә бу бөтен татарларның 8,8 проценты дигән сүз) 160 мең чамасы Идел-Урал татарлары иде. Дөрес, Идел-Урал татарларының шәһәрләшү дәрәҗәсе XX йөз башында да шактый түбән булып кала бирде (аларның гомуми саннарының 4,9 проценты). Шәһәрләшкән татарларның зур күпчелеге Идел-Урал төбәгендәге эре шәһәрләрдә тупланды (Казанда, Уфада, Оренбургта, Самарада, Сембердә. Саратовта, Түбән Новгородта, Костромада, Пензада, Екатеринбургта, Пермьда, Чиләбедә, Троицкта һ.б.). Аннан тыш. бу төбәктән чыгучылар Россиянең Аурупа өлешендәге бер рәт шәһәрләрдә дә яшәделәр (Мәскәү, Санкт-Петербург һ.б.). шулай ук Кавказ аръягында Бакуда), Урта Азиядә һәм Көнбатыш Себердә дә бар иде (аларның гомуми саннары XIX йөз ахырына 50 мең булып, XX йөз башына 70 меңнән артып китте).

Көнбатыш Себердә татарлар арасында шәһәрләшү акрын темплар белән барды. Шуның өстенә, XIX йөзнең ахырына мондагы шәһәрләшкән татарларның 2/3 өлешеннән артыграгын Идел-Урал төбәгеннән чыгучылар тәшкил итте.

Әстерхан татарлары арасында шәһәрләшкән татарларның бер өлеше XVIII йөздә үк чагыштырмача күп булуы мондагы бер рәт татар авылларының Әстерхан шәһәренә якын булып, ахыр чиктә аның чикләренә керүләре белән аңлатыла. XX йөз башларына Әстерхан шәһәрендә яшәүче татарларның күпчелек өлешен Урта Идел буеннан чыгучылар тәшкил итә иде инде.

Литва татарларында шәһәрләшү дәрәҗәсе шактый югары булды: XIX йөзнең 30нчы елларында аларның шәһәрдә яшәгән өлеше губернасына күрә—8 ппроценттан алып 33-42 процентка кадәр җиткән булса, бу сан XIX ахырына Литва татарларының яртысына кадәр җитә язды. Шәһәрләшкән Литва татарлары шактый нык таралышып яшәделәр (Минскида, Новогрудкада, Игуменда, Сломинда, Вильнода, Гроднода. Ковнода, Варшавада).

Кырым татарларында шәһәрдә яшәүчеләрнең күләме әле XVIII гасырда да шактый зур иде (1783 елга—20 процент чамасы). Россияга кушканнан соң Кырымда шәһәрләшкән татарларның саны беркадәр кимегән булса кирәк. Шулай да, Кырым татарлары XIX йөздә Россия татарлары арасында иң нык шәһәрләшкән төркем иделәр. Кырым татарларының Төркиягә күченеп китүенә (алар арасында шәһәр халкы да булды) карамастан, XIX йөз ахырларына кадәр алар арасында шәһәрдә яшәүчеләрнең проценты гел үсеп торды. Иң эре төркемнәр XX йөз башларында Кырымда мондый шәһәрләрдә яшәделәр: Бакчасарайда (10 мең), Симферопольда (7,9 мең) ( Евпаториядә (6,2 мең), Карасубазарда (6,2 мең), Феодосиядә (2,6 мең) һәм Керчьта (2 мең).

1920-1980 елларда татарларның шәһәрләшүе яңа масштаблар алды (4нче таблицаны карагыз). Таблицадан күренгәнчә, татарларның шәһәрләшүендәге борылыш вакыты 1950 еллар ахырына—1960 елларга туры килә. 1960 еллар ахырыннан илдәге татарларның яртысыннан артыграгы шәһәрдә яшәүчеләр була башлады 1979-1989 елларда шәһәрдә яшәүчеләрнең проценты шактый үсте: 63тән—69га кадәр. Хәзер БДБ илләрендәге халыклар арасында татарлар иң шәһәрләшкән халыклар рәтенә керә.

**4нче таблица**

**Советлар Союзында татарларда шәһәрләшү процессы (1926-1989 еллар)**

| Еллар | Шәһәрдә яшәүчеләрнең абсолют саны (мең кеше) | Шәһәр халкының проценты |
|---|---|---|
| 1926 | 400,1 | 11,9 |
| 1939 | 1291,6 | 26,0 |
| 1959 | 2345,0 | 47,0 |
| 1970 | 3260,6 | 55,0 |
| 1979 | 3979,4 | 63,0 |
| 1989 | 4777,8 | 69,0 |

Урта гасыр чорында татарларның этник территорияләре киң мәйдан биләделәр: Кырым, Идел буе, Урал буеның бер өлеше, Көнбатыш Себер. Шул ук төбәкләрдә

татарлар XVI-XX йөзләр башларында да яшәүләрен дәвам иттеләр һәм монда жирле халык булып санала алалар.

Ләкин татарлар арасында XVI гасырдан соң көчле миграцион процесслар да күзәтелде, бигрәк тә бу Идел-Урал татарларына хас күренеш булды. Урта Идел төбәгеннән Урал буйларына татарларның актив күчеше Казан ханлыгы жимерелгәч күзәтелде. Хәлбуки, Урал буйларының аерым төбәкләрендә татарлар һәм аларның бабалары моннан элек тә яшәгән иделәр һәм ул төркемнәр жирле төркемнәр рәтеннән саналырга тиешләр. Ләкин татарларның Урал якларына күчүләренең иң югары ноктасы күп сәбәпләр нәтижәсендә (социаль-икътисади басым, дини кысулар көчәю һ.б.), XVIII йөзнең беренче яртысына туры килде. Урта Иделдән көнчыгышка таба татарларның бу чорда күпләп күчүе Урал буенда аларның санын кискен арттырды (XVIII йөз урталарында татарларның мондагы саннары 89 меңгә житте). Алга таба исә Урал буйларына күчү темплары кимеде, әмма бөтенләй үк бетмәде. 1860нчы еллардагы реформалардан соң Идел-Урал төбәгеннән күчүчеләр төньяк һәм төньяк-көнчыгышка—Казакъстан аркылы Көнбатыш Себергә һәм Урта Азиягa юнәлде (аларның гомуми саннары XIX йөз ахырында 94,3 мең булып, шуларның 40,3 меңе Себергә юл тотты). Татарларның бүтән күчеш юнәлеше Россиянен Аурупа өлешендәге промышленность районнары һәм Кавказ Аръягы булды (XIX йөз ахырларына монда 28 мең кеше килеп урнашты). Идел-Урал буе татарлары, инде әйтелгәнчә, XVIII—XX йөзләрнең башларына Әстерхан төбәгендәге һәм Көнбатыш Себердәге татарларның күзгә күренерлек өлешен тәшкил итә башладылар. Литва татарлары XIX йөзнең уртасына Вильно, Минск, Слоним, Гродно, Ковно, Подольск, Волын, Августов һәм Люблин (соңгы икесе—Польша патшалыгы чикләрендә) губерналарында таралып яшәделәр, 1783 елдан соң, Кырым АССР төзелгәнче, Кырым татарлары Таврия губернасына керделәр (Симферополь, Евпаторий, Феодосий, Перекоп, Днепровск һәм Мелитополь өязләре—соңгы өчесендә нугай татарлары яши иде). Мондагы татарларның таралып утыруы һәм саннары Кырым татарларының XIX-XX йөз башларындагы Төркиягә күченеп китүләре нәтижәсендә шактый нык үзгәрде (ул турыда алдарак язылды инде).

XX йөздә татарларның урнашуларында шактый зур үзгәрешләр барлыкка килде, алар 5нче таблицада китерелгән мәгълүматлардан күренә.

**5нче таблица**

**1926-1989 елларда татарларның элекке союздаш республикаларда урнашулары**

| Союздаш республикалар | Саннары | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1926 ел | 1937 ел | 1959 ел | 1970 ел | 1979 ел | 1989 ел |
| РСФСР | 3214043 | 3610718 | 4074669 | 475913 | 5016087 | 5543371 |
| Украина ССР | 22281 | 24242 | 61527 | 76212 | 90542 | 133596 |
| Белоруссия ССР | 3777 | 3475 | 8654 | 10031 | 10911 | 12552 |
| Үзбәкстан ССР | 28297 | 2796 | 444810 | 573733 | 648764 | 656601 |
| Казакъстан ССР | 79758 | 92096 | 191925 | 287712 | 313460 | 331151 |
| ГрузияССР | 599 | ... | 5441 | 5856 | 5165 | 4714 |
| Әзәрбайжан ССР | 9948 | ... | 29552 | 31787 | 31350 | 28564 |
| Литва ССР | ... | ... | 3023 | 3460 | 4006 | 5188 |
| Молдавия ССР | ... | ... | 1047 | 1859 | 2637 | 3477 |
| Латвия ССР | ... | ... | 1836 | 2688 | 3772 | 4888 |
| Кыргызстан ССР | 4902 | 17483 | 56266 | 69373 | 72018 | 72992 |
| Тажикстан ССР | 982 | 16604 | 56893 | 70803 | 79529 | 79442 |
| Әрмәнстан ССР | 27 | ... | 577 | 581 | 753 | 506 |
| Төркмәнстан ССР | 4790 | ... | 29946 | 36457 | 40321 | 39277 |
| Эстония ССР | ... | ... | 1535 | 2205 | 3195 | 4070 |

1920-1930 елларда илдәге татар халкының абсолют күпчелеге әле РСФСРда яши иде (1926 елда—95,4, ә 1937 елда—95,2 процент). РСФСРдан тышта бу чорда татарларның иң зур төркеме Казакъстан һәм Урта Азиядә тупланган булган (1926 елны—91,2 мен., 1937 елны—129 мен). Инде билгеләп үтелгәнчә, бу регионга татарлар XIX йөздә үк күчкәннәр, (Казакъстанга XVIII йөздә күчү очраклары да билгеле). Татарлар Украинада (күбрәк өлеше—Донбасста) һәм Әзәрбайҗанда (күпчелеге—Бакуда) да әле революциягә кадәр үк яши башладылар.

1950нче еллар ахырларына РСФСРдан читтә яшәүче татарларның саннары кискен артты, бигрәк тә Казакъстан һәм Урта Азиядә (1959 елгы исәп вакытында анда 780 мең татар теркәлде). 1930нчы еллар белән чагыштырганда бу чорга татарларның бу төбәктә саннарының алты тапкыр үсүенең берничә сәбәбе булды. Беренчедән, 1944 елны Урта Азиягә, беренче чиратта, Үзбәкстанга, Кырым татарлары көчләп күчерелде (ул күчерелү вакытында халыкның зур өлеше юлда үлде). Икенчедән, чирәм җирләрне үзләштергәндә зур төркем татарлар Казакъстанга күчте (ирекле рәвештә һәм партия органнары кушуы буенча). Болар өстенә, илнең Аурупа өлешеннән татарларның гомумән Урта Азиягә китүе дә күзәтелде.

Шушы процесслар нәтиҗәсендә 1970-1980-елларга Казакъстан һәм Урта Азиядә татарларның саны 1 млн. кешедән артты, бу төркем иң зур татар диаспорасын тәшкил итә башлады. Ләкин 1979—1989 еллар арасында бу төбәктә татарларның саннары үсмәде диярлек (1154,1 меңнән 1179,5 меңгә кадәр генә артты. Моның сәбәбләре: Кырым татарлары бу чорда үзләренең тарихи ватаннары—Кырымга кире күчә башладылар, ә башка татарлар Урта Азиядән илнең бүтән төбәкләренә юнәлделәр.

Кавказда татарларның иң зур төркеме Әзәрбайҗанда яши, ләкин 1970 елдан башлап анда да татарларның саны кими башлады—монда шулай ук читкә күчеш процесслары күзәтелде.

Балтыйк буе илләрендә һәм Белоруссиядә татарның саннары чагыштырмача зур түгел. Мәгълүм ки, монда яшәүчеләрнең бер өлеше җирле Литва татарлары.

Гомумән алганда, татарларның төп өлеше (1989 елгы исәп буенча—4/5 өлеше) элеккечә Россия Федерациясендә яши. Аларның таралып утырышларын 6нчы таблицадагы мәгълүматларга таянып карарбыз.

**6нчы таблица**

**Россия Федерациясе территориясендә татарларның 1939-2002-елларда таралып утырышларының үзенчәлекләре***

| № п/п | Регионнар, республикалар һәм территориаль берәмлекләр | 1939 | 1959 | 1970 | 1979 | 1989 | 2002 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1. Төньяк-Көнбатыш регионы** | | | | | | | |
| 1. | Архангел өл. | [4845] | ... | 4613 | 4906 | 5391 | 3076 |
| 2. | Ненец Р. | | ... | 167 | 284 | 524 | 211 |
| 3. | Вологда өл. | [346] | ... | 1028 | 1582 | 1843 | 1859 |
| 4. | Калининград өл. | | ... | 2752 | 3226 | 3556 | 4734 |
| 5. | Санкт-Петербург шәһәре | 31506 | 27178 | 32861 | 39416 | 43997 | 35616 |
| 6. | Ленинград өл. | | 4330 | 5376 | 6255 | 7757 | 9447 |
| 7. | Мурман өл. | 4446 | 5566 | 7521 | 9532 | 11459 | 7954 |
| 8. | Новгород өл. | | ... | 804 | 1355 | 1963 | 2083 |
| 9. | Псков өл. | | ... | 465 | 705 | 1010 | 1502 |
| 10. | Карелия Р. | | 4692 | 2603 | 2611 | 2992 | 2629 |
| **2. Үзәк һәм Үзәк Кара туфраклы регионнар** | | | | | | | |
| 1. | Брянск өл. | | ... | ... | ... | ... | 1179 |
| 2. | Белгород өл. | | ... | 575 | 1217 | 1539 | 3397 |
| 3. | Владимир өл. | | 8268 | 8447 | 9202 | 9214 | 8678 |
| 4. | Воронеж өл. | - | ... | 1193 | 1428 | 1860 | 3501 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Тверь (Калинин) өл. | - | ... | 4712 | 5196 | 6256 | 6719 |
| 6. | Кострома өл. | | ... | 3355 | 3054 | 2965 | 2732 |
| 7. | Калуга өл. | | ... | 1290 | 1814 | 2963 | 4306 |
| 8. | Курск өл. | - | ... | ... | ... | ... | 1581 |
| 9. | Иваново өл. | [14761] | 9851 | 10511 | 11061 | 9910 | 8208 |
| 10. | Липецк өл. | | ... | 715 | 749 | 1000 | 1751 |
| 11. | Мәскәү шәһәре | 57687 | 80489 | 109293 | 132388 | 157376 | 166189 |
| 12. | Мәскәү өл. | 53469 | 52520 | 49193 | 52141 | 51059 | 52892 |
| 13. | Орлов өл. | - | ... | ... | ... | ... | 1424 |
| 14. | Рязань өл. | [8926] | ... | 4057 | 4334 | 4922 | 5575 |
| 15. | Смоленск өл. | - | ... | 571 | 1105 | 2163 | 2429 |
| 16. | Тамбов өл. | [31553] | ... | 2141 | 2193 | 2298 | 2732 |
| 17. | Тула өл. | [10636] | 15431 | 11500 | 10306 | 9551 | 8974 |
| 18. | Ярославль өл. | [13558] | 7166 | 7211 | 7400 | 7162 | 6175 |
| | **3. Төньяк-Кавказ регионы** | | | | | | |
| 1. | Краснодар крае | [10475] | ... | 17709 | 26072 | 34430** | 25615 |
| 2. | Ростов өл. | [8926] | 13857 | 16106 | 16948 | 17132 | 17892 |
| 3. | Ставрополь крае | - | ... | 9405 | 10610 | 12951 | 12909 |
| 4. | Адыгей Р. | - | 1886 | 2154 | 2420 | 2666 | 2904 |
| 5. | Карачай-Черкес Р. | - | ... | 1668 | 1890 | 2496 | 2022 |
| 6. | Дагестан Р. | - | 6013 | 5770 | 5627 | 5579 | 4669 |
| 7. | Кабардин-Балкар Р. | - | ... | 2664 | 3169 | 3005 | 2852 |
| 8. | Төньяк Осетия Р.—Алания | - | ... | 1658 | 1903 | 1968 | 2113 |
| 9. | Калмык Р. | 2490 | 1044 | 1230 | 1331 | 1312 | 1086 |
| 10. | Чечен-Ингуш Р.<br>Ингуш Р.<br>Чечен Р. | [3910] | 5225 | 5571 | 5484 | 5102 | <br>151<br>2137 |
| | **4. Идел-Урал регионы** | | | | | | |
| 1. | Түбән Новгород өл. | 88241 | 66996 | 71798 | 68637 | 58603 | 50616 |
| 2. | Ульян өл. | | 96918 | 122409 | 134767 | 159093 | 168773 |
| 3. | Пенза өл. | 64660 | 62233 | 74838 | 78236 | 81307 | 86806 |
| 4. | Мордовия Р. | 47386 | 38636 | 44955213 | 45765 | 47328 | 46261 |
| 5. | Саратов өл. | 21329 | 34075 | 43238 | 47948 | 52867 | 57583 |
| 6. | Волгоград өл. | 64223 | 17744 | 23518 | 25531 | 25973 | 28848 |
| 7. | Әстерхан өл. | | 57230 | 67062 | 70781 | 71655 | 77142 |
| 8. | Киров өл. | 31401 | 41211 | 45309 | 44900 | 45666 | 43637 |
| 9. | Удмуртия Р. | 40561 | 71930 | 87151 | 99141 | 110347 | 109868 |
| 10. | Коми Р. | - | 8459 | 11908 | 17837 | 25980 | 15690 |
| 11. | Мари Р. | 27149 | 38821 | 40280 | 40917 | 43747 | 43464 |
| 12. | Чувашия Р. | 2907 | 31357 | 36217 | 37573 | 35689 | 36399 |
| 13. | Татарстан Р. | 1421514 | 1345195 | 1536431 | 1641607 | 1765404 | 2018893 |
| 14. | Башкортстан Р. | 617188 | 768566 | 944507 | 940446 | 1120702 | 995253 |
| 15. | Самара өл. | 130471 | 74226 | 93687 | 103605 | 115280 | 127984 |
| 16. | Пермь өл. | 80727 | 165829 | 169372 | 157726 | 150460 | 135534 |
| 17. | Коми-Пермяк автоном округы | | 5623 | 3432 | 1910 | 1454 | 1100 |
| 18. | Свердлов өл. | 80983 | 158222 | 176029 | 179347 | 183781 | 168224 |
| 19. | Оренбург өл. | 104843 | 120944 | 145376 | 151384 | 158564 | 165989 |
| 20. | Чиләбе өл. | 119527 | 190227 | 216809 | 219744 | 224605 | 214220 |
| 21. | Курган өл. | | 19567 | 23932 | 23507 | 22567 | 21986 |
| 22 | Идел буе Немецлары АССРы | [2638] | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **5. Себер регионы** | | | | | | | |
| 1. | **шул исәптән: а) Көнбатыш Себер** Төмән өл. | | 72306 | 102861 | 136757 | 103306 | 116055 |
| 2. | Ханты-Манси автоном округы—Югра | | 2938 | 14046 | 36899 | 97689 | 107954 |
| 3. | Ямал-Ненец авт. окр. | | 3952 | 4653 | 8556 | 26431 | 27795 |
| 4. | Омск өл. | 91876 | 36421 | 44330 | 46714 | 49784 | 48116 |
| 5. | Томск өл. | | 13449 | 15226 | 17630 | 20812 | 20151 |
| 6. | Новосибирск өл. | 62212 | 24926 | 28825 | 28549 | 29428 | 27886 |
| 7. | Кемерово өл. | | 67382 | 69313 | 64821 | 63116 | 51065 |
| 8. | Алтай крае | [7388] | ... | 8052 | 7864 | 8078 | 8904 |
| 9. | Таулы Алтай Р. | | ... | ... | 334 | 388 | 462 |
| 1. | **б) Көнчыгыш Себер** Краснояр крае | 31266 | 39945 | 46623 | 49894 | 54052 | 43872 |
| 2. | Таймыр (Долган-Ненец) авт.округы | | ... | 429 | 522 | 783 | 427 |
| 3. | Эвен авт.округы | | ... | ... | 141 | 330 | 162 |
| 4. | Иркутск өл. | 30046 | 39061 | 41500 | 41474 | 36609 | 26987 |
| 5. | Усть-Орда Бурят авт.округы | | 4213 | 5692 | 4782 | 4374 | 4102 |
| 6. | Бурят Р. | [6098] | 8058 | 9991 | 10291 | 10496 | 8196 |
| 7. | Тува Р. | | ... | 822 | 988 | 1071 | 588 |
| 8. | Якут-Саха Р. | 4420 | 5172 | 7679 | 10980 | 17415 | 10817 |
| 9. | Чита өл. (ш.у. Аги-Бурят АО) | 19133 | 4014 | 14283 | 13372 | ... | 7769 390 |
| 1. | **в) Ерак Көнчыгыш** Приморье крае | 11016 | 17004 | 18256 | 19464 | 20211 | 14572 |
| 2. | Хабаров крае | 16012 | 14130 | 14571 | 16591 | 17591 | 10982 |
| 3. | Еврей авт.өл. | | ... | 1158 | 1460 | 1499 | 1196 |
| 4. | Амур өл. | | ... | 5369 | 7948 | 9095 | 4889 |
| 5. | Камчатка өл. | | 2921 | 3728 | 4652 | 5837 | 3404 |
| 6. | Коряк авт.окр. | | 298 | 353 | 441 | 471 | 216 |
| 7. | Чукот авт.окр. | | 504 | 1607 | 1995 | 2270 | 535 |
| 8. | Магадан өл. | | 3021 | 5295 | 6793 | 8024 | 2002 |
| 9. | Сахалин өл. | | 11679 | 11153 | 11030 | 10699 | 6832 |

**Искәрмәләр:**

*** Кырым татарлары татарлар эчендә исәпкә алынган.**

**** 1989 елгы халыкны исәпкә алу вакытында Краснодар краенда 17217 Кырым татары теркәлгән.**

***** Сан кимү территориаль үзгәрешләргә бәйле.**

Таблицадан күренгәнчә, 1939-2002 елларда Россия территориясендә татарларның төп яшәү төбәге булып Идел Урал регионы торды (1939 елны 2945,7 мең кеше, 1959 елны 3414,0 мең кеше, 1989 елны 4010,7 мең кеше, 2002 елны 4614,3 мең кеше, ягъни, илдәге бөтен татарларның 4/5 өлеше), Төбәктәге татарларның иң укмашып урнашкан җирләре Татарстан Республикасы һәм Башкортстан Республикасы. Соңгы республикада 1970нче елларда татарларның саны үсмәде генә түгел, хәтта кимеде дә. Бу бик сәер бер күренеш булды. Анын шулай икәнлеген Башкортстанда 1970-1979 еллардагы татарлар белән башкортларның сан үсешен чагыштырганда күреп була:

| Еллар | Башкортлар саны үсү | Татарлар саны үсү (кимү) |
|---|---|---|
| 1959-1970 | + 20,9 % | + 22,9 % |
| 1970-1979 | + 4,9 % | —0,4 % |
| 1979-1989 | —3,8 % | + 9,6 % |
| 1989-2002 | + 20,7 % | —11,2 % |

Күренә ки, 70нче елларда бу республикада татарлар кинәт «юкка чыга» башлый. Шул ук чорда Татарстанда яшәгән татарның саны 6,8 процентка арта. Бер үк татар (Татарстанда һәм Башкортстанда яшәүче татарлар социаль яктан аерылмыйлар) республиканың берсендә үрчеп ятkan, ә икенчесендә кимеп барган. Ә шул ук вакытта башкорт саны арткан. Хәзер инде тәгәл билгеле; мондый «сәерлекнең» төп сәбәбе 1979 елгы исәп вакытында татарларның бер өлешен Башкортстанда башкорт дип язу белән бәйле булган. Нәкъ менә шушы төркемнең 80нче еллар ахырларына демократияләшү шартларында үзләренең чын милләтенә әйләнеп кайтулары (бәлки әле тулаем ук та түгелдер) Башкортстанда татарлар санының шактый артуына китерде (1979 елдагы 940,5 меңнән 1989 елгы 1120,7 меңгә кадәр). Ләкин 2002 елгы халыкны исәпкә алу нәтиҗәләрендә бу республикада татарларның саны янадан кимеде, ә бу үз чиратында шушы исәп вакытында 200 меңнән артык татарны башкорт итеп язу белән бәйле. Шулай да 1959-1989 елларда бу төбәктә яшәүчеләрнең өлеше 2,7 процентка кимеде. Бу очракта кимүнең төп сәбәбе—Идел-Урал төбәгеннән татарларның Көнбатыш Себергә, бигрәк тә нефть чыгаручы районнарга күчүләре белән бәйләнгән иде. Мәсәлән, Төмән өлкәсендә, Ханты-Манси һәм Ямал-Ненец автономияле округларында 1970-1989 еллар арасында татарларның саннары 3 тапкыр чамасы артты.

Хәзер татарлар Россиянең барлык төбәкләрендә диярлек яшиләр. Әгәр дә БДБ илләрен алсак, татарлар, ахрысы, иң таралып яшәүче халыктыр.

Чит илләрдә дә татар диаспоралары бар. Алардагы халыкның саны, Төркиягә XVIII-XX йөзләрдә күчкән Кырым татарларын санамаганда (бу илдә рәсми статистика аларны аерып күрсәтми), 100 мең кеше чамасы. Шактый зур чит ил татарлары төркеме Румыниядә тупланган (саннары төрле мәгълүматлар буенча 23 меңнән 35 меңгә кадәр булган Буджак татарлары, мондагы җирле төркем). Төркиядә 20 мең чамасы татар бар (Кырым татарларының саны 1 млн кеше яисә аннан да күбрәк). Башка илләрдә татарлар күп түгел; Польшада—5,5 мең (3 меңе чамасы—җирле Литва татарлары), Болгариядә—5 мең (күпчелеге—румын, ягъни, Буджак татарлары), Кытайда—4,2 мең, АКШта—1 мең, Финляндиядә—950 кеше, Австралиядә—500, Даниядә—150, Швециядә—80, Японииядә 30 гаилә. Шулай ук аз санлы татар төркемнәре Германиядә, Франциядә, Австриядә, Венгриядә, Норвегиядә, Канадада, Согуд Гарәбстанында, Мисырда, Әфганстанда һ.б. илләрдә дә бар. Күп кенә чит илләрдә татар диаспорасының саны арта бара. Билгеле булганча, чит ил татар диаспорасы (БДБ илләрен исәпкә алмаганда) төрле вакытта формалашкан. Румыния һәм Польшада татарлар—урта гасырлардан ук яшәүче җирле төркемнәр. Башка илләрдә алар күбесенчә XIX-XX йөзләрнең башларында һәм соңрак чорларда да утырып калдылар. Чыгарма булып Төркия генә тора—анда, инде әйтелгәнчә, Кырым татарлары XVIII йөзнең ахырларында ук яши башлыйлар.

*Ахыры киләсе санда*

# БӨЕКЛЕК БАСКЫЧЛАРЫ

## 1907 ел

**6 гыйнвар.** Тукай, үзенең адресын күрсәтеп, газетада игълан урнаштыра:

«Мин бу көннәрдә генә «Мәдрәсәи Мотыйгыя»дән чыктым. Бинаән галәйһи, дустларым вә якыннарыма игълан итәмен ки, бу көннән ары миңа язачак мәктүбләренең адресын болай язсыннар: Уральск. Гостиница «Казань». А.Тукаеву.

Бакый ихтирам белән Г.Тукаев.»

Шушы вакыттан башлап Г.Тукайның рәсми белем йортына кереп укуы тәмамлана, ул шагыйрьлек, публицист-журналистлык юлыннан китә.

«Төш күрдем!» мәкаләсе «Шүрәле» имзасы белән басылган.

«Казан миһманханәсендә мәжлес» исемле мәкаләсе имзасыз чыккан.

Һәр ике мәкаләдә Уральскида «Казан» миһманханәсендә «Җәмгыяте хәйрия» мәжлесе турында сүз бара. («Фикер», 1 нче сан.)

**12 гыйнвар.** «Ахырзаман галәмәте» исемле шигыре «Мөәррих» имзасы белән чыккан. Шигырь «Бакырган» китабындагы (XII йөз) «Килең, дустлар, бу дөнья кичде—ахыр булдыя» дип башланган шигырь калыбына салынган.

**4 февраль.** «Уральск хәбәрләре» исемле мәкаләсе имзасыз чыккан. Мәкаләдә Хәсәнҗан Хөсәенов дигән кешенең «Бәянелхак фи хаккыл хиҗаб» («Хатын-кызны качыру турында дөрес сүз») исемле китабы тәнкыйтьләнә.

**8 февраль тирәсе.** Хезмәт хакын арттыруны сорап матбага эшчеләрен эш ташларга котырта, дип, К.Мотыйгый Тукайны эшеннән чыгара. «Матбагам ябылмастан борын, ике атна әүвәл бөтенләй хезмәттән чыгарырга туры килде»,—ди К. Мотыйгый «Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем»ендә.

К. Мотыйгый аны эштән чыгардым дисә дә, Г. Тукай «Фикер» һәм «Әлгасрелҗәдит»тә бу матбугат органнары ябылып беткәнче эшли. Башта хәреф җыючы, аннан корректор, соңыннан бөтен эшләрне үзе башкара. Аның Уральск чоры иҗаты нигезендә «Фикер» газетасында, «Әлгасрелҗәдит» һәм «Уклар» журналында тупланган.

**15 февраль.** «Шагыйрьгә» (Михаил Юрьевич Лермонтов хәзрәтләренең бер нәсихәте) шигыре басыла. Шигырь М. Ю. Лермонтовның «Г-ну Павлову» исемле эпиграммасыннан файдаланып язылган.

**18 февраль.** «Уральскида Думага сайлаулар» исемле мәкаләсе «һәйьят идарә» имзасы белән баш мәкалә урынында басылган.

**22 февраль.** «Кайгыру» исемле шигыре «Болгар» имзасы белән басылган. «Г. Тукайның «Государственная думага» әсәре дөнья күргәннән соң («Фикер», 1906, 22 октябрь) төгәл дүрт айдан соң басылып чыккан бу шигырь алдагысына формасы, аерым сүзләре һәм гыйбарәләре белән генә түгел, бәлки, бөтен рухы, мәгънәсе белән бик якын тора. «Государственная думага» патша Дәүләт думасына карашта беренче этап, «Кайгыру»ны икенче этап дип карарга мөмкин. Беренче этапта Думага пассив кына булса да, ышаныч бар, икенче этапта исә ышаныч сулларга гына»,—ди Р. Гайнанов.

*Дәвамы. Башы 8 санда*

**11 март.** Уральскида, «Казан» миһманханәсе залында әдәби-музыкаль кичә үткәрелә. Тукай, Хәкимҗан Йосыфов исемле бер егетне хәерче киеменә киендереп, үзе шул егетнең өстенә карап, «Теләнче» шигырен укый. Бу шигырьне укыганда, көлмичә, нәсер шикелле итеп, җөмләләрен аерып, калын тавыш белән әйтә. Сонынннан «Төрек маршы» дигән җырны җырлый.

**11 март.** «Тартар кошы сайрый» (яки «Татарский марш») шигыре чыга.

**15 март.** «Син булмасан», «Теләнче» шигырьләре чыга. «Идарәдән» исемле мәкаләсе басыла. Мәкаләдә мондый юллар бар: «Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин җәнабләренең кулыннан администрация тарафыннан мөхәррирлек вә нәширлек хокуклары алынгач, табигый, «Әлгасрелҗәдит» мәҗәлләсенең мөхибләре кайгырдылар... Шунгар күрә без бәян итәбез ки, «Әлгасрелҗәдит»нең мөхибләре вә дуслары күңелләрен хуш тотсыннар. Вә дошманнары да куанмасыннар: без «Әлгасрелҗәдит»нең ушбу 3 нче нумирыны мәйданга куйдыкымыз кеби, аны һаман да дәвам иттерәчәкбез».

1907 елның 22 февраленнән, К.Мотыйгый нәширлек һәм мөхәррирлек хокукыннан читләштерелгәннән сон, ул матбагасын сәүдәгәр Мортаза Гобәйдуллинга сата. М. Гобәйдуллин матбаганың эшен дәвам иттерергә үз өстенә алса да, вәгъдәсен үтәми. 1907 елның 25 маеннан (№ 5) «Әлгасрелҗәдит» туктала. Тукайның әлеге мәкаләсе М. Гобәйдуллинның вәгъдәсенә ышанган вакытта язылган.

**2 апрель.** «Күрдегезме?» исемле шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылган.

1906—1918 елларда Оренбургта чыккан «Дин вә мәгыйшәт» журналы хатын-кыз азатлыгына каршы чыгып, аларның ирләрдән качуларын таләп итеп, мәкаләләр бастыра. Шигырь шуна каршы юнәлдерелгән.

**15 апрель.** «Әлгасрелҗәдит»тә «Бишектәге бала» шигыре басылып чыккан. Шигырь М.Ю.Лермонтовның «Дитя в люльке («Из Шиллера») шигыреннән файдаланып язылган.

**4 май.** «Ана мәктүбләре» исемле педагогик язмасы басыла башлый. «Дәвамы бар» дип куелган.

Г. Тукайның биш томлы «Әсәрләр»ен төзеп чыгаручы Р. Гайнанов аны Л. Н. Толстойның «Педагогик хатлар»ын хәтерләтә дигән фикер әйтә.

**6 май.** «Ана мәктүбләре»нең дәвамы басыла. «Ахыры киләсе санда» диелгән.

«Пар ат» шигыре чыга. Шигырь Г. Тукайның Казанга килү хыялларын чагылдыра һәм «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре»ндә (Казан, 1914) «Лермонтовның «Тройка» шигырен уку тәэсиреннән» дигән искәрмә белән басылган.

«Фикер» хәбәре: якын көннәрдә безнең типографиядә Г. Тукайның шигырь җыентыгы басылып чыгачак. Бу җыентык басылып чыкмаган булса кирәк.

«Партияләр» әсәре баш мәкалә рәвешендә имзасыз чыга.

**25 май.** «Әлгасрелҗәдит» журналы чыгудан туктый. Бу соңгы санда Г.Тукайның «Пар ат», «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» Г. Исхакыйга багышланган «Кем ул?» шигырьләре, «Царь-Голод, яхуд Ачлык-Падишаһ» дигән тәрҗемә мәкаләсенең дәвамы басылган. Мәкаләгә «Ахыры бар» дип куелса да, журналның чыгудан туктавы сәбәпле, ахыры басылмый калган.

**Май.** Г. Тукай хат аркылы Казан матбагачысы Гыйльметдин Шәрәф белән таныша. Ана хат яза. Хатында: «Сез могтәбәр татар шагыйрьләренең шигырьләрен нәшер итә башлагансыз икән. Мин дә үземнең берәр мәҗмугамның шулар арасында булуын телим»,—ди. Хатның төп нөсхәсе сакланмаган.

«Китмибез!» исемле шигырен яза. Дәүләт думасының 1907 ел май аенда булган унбишенче мәҗлесендә, мәсәлән, Уфа губернасыннан сайланып килгән депутат мөгаллим Кәлимулла Хәсәнов (1878—1949) мөселман мәктәпләренең хәле начарлыгыннан, хөкүмәтнең мона бер чара да күрмәвеннән зарланып сөйли. Суллар кул чабалар, ә уннар (Пуришкевич, Созонович һ. б. карагруһлар) урыннарыннан сикереп торып, йодрыкларын төйнәп, ораторга ташланалар һәм: «Төркиягә китенез!»—дип кычкыралар. «Китмибез!» шул унай белән иҗат ителгән һәм анын язылу вакыты да шушы вакыйга эзеннән, ягъни 1907 елның май ахырларында булырга тиеш».

**Җәй.** Әтисенең йортын сатудан Тукайга берникадәр мирас калган була. Гурьевтагы әтисе ягыннан туганнары сәүдәгәрләр Әхмәди һәм Әүхәди Абдуловлар

шул акчаны (кайбер мәгълүматларга караганда 100 сум) Тукайга җибәрәләр. Тукай туган якларына солдатка каралырга һәм Казанга шушы акча белән кайткан булырга тиеш, дип фараз ителә.

**1 июнь.** «Дөньяда торыйммы?»—дип кинәшләшкән дустыма» шигыре чыккан.

**27 июнь.** Вафа Бәхтияров («Әл-ислах»ның мөхәррире) «Әл-ислах» газетасын чыгарырга Казан губернаторыннан рөхсәт ала. Уральскида чыккан «Фикер» газетасы, «Әлгасрелҗәдит» һәм «Уклар» журналлары аркылы танылган Г. Тукайга «Әл-ислах» газетасында катнашырга чакырып хат яза.

**Июнь, 5 июльгә кадәр.** «Шүрәле» поэмасын, «Бездә истигъдад бар» шигырен яза. Шигыренең исемен Г. Тукай соныннан «Безне урынсыз яманлыйлар» дип үзгәртә.

**5 июль.** Г. Тукай Казан матбагачысы Г. Шәрәфкә Уральскидан хат җибәрә. «Тарафыгызга тагы да «Шүрәле» вә «Тәрбиятел-әтфаль»гә сәрләүхәле шигырьләремне күндердем. Шуларны «Китмибез» вә «Бездә истигъдад бар» шигырьләре белән бергә рисаләнең башына куярсыз. «Кечкенә генә бер көйле хикәя» (бу әсәр тиздән матбугатыбызда чыкса кирәк) сәрләүхәле шигырь басылмый калса да зарар итмәс зан итәм»,—ди шагыйрь.

Монда «Г. Тукаев шигырьләре»нә («Шигырьләр көтепханәсе»н-нән 3 нче дәфтәр, 1907) керәчәк шигырьләр турында сүз бара.

**20 июль.** Тукай, Уральскида М. Мусин, К. Төхфәтуллин белән бергә, «Яңа тормыш» газетасын чыгару турындагы килешүгә кул куя. Газетаны чыгару аерым кешеләрдән җыелган керемгә нигезләнгән.

Газета Уральскида «Яңа тормыш» исеме белән 1907 елның ноябреннән 1908 елның мартына кадәр чыга. Редакторы Мөхәммәтгали Мусин. Тукай бу вакытта Казанда инде. Газетада басылган әйберләре күренми.

**24 июль.** «Җуаныч» исемле шигыре чыга.

**Июль ахыры.** В.Бәхтияровның тиздән чыга башлаячак «Әл-ислах» газетасына язышуын үтенеп сораган хатына каршы Г. Тукай: «Берничә номер гәзитәгез чыкмыйча торып, берни дә әйтә алмыйм. Үзем көзгә таба Казанга барып чыгачакмын, шунда сезнең белән сөйләшермен»,—дигән җавап хаты җибәрә. Хат сакланмаган.

**Сентябрь.** Г. Тукай Уральскида берьялгызы фоторәсемгә төшкән. Фотоның күчермә нөсхәсе Г. Ибраһимов исемендәге институтның Кулъязмалар бүлегендә саклана.

**20 яки 25 сентябрь.** Г. Тукай Уральскидан Казанга чыгып китә. Туган якларына кайтуның максаты һәм бер сәбәбе солдат хезмәтенә каралу өчен дә була. (Тукайның тормыш юлын өйрәнүчеләр аның Казанга 10 октябрьдә килеп җитүен әйтәләр. Күрсәтелгән датадан чыгып караганда, бу килү вакыты озак кебек тоела. Ул вакытта Җаектан Казанга поезд белән йөрмәгәннәр, күбрәк ат белән килгәннәр. Тукайның Казанга нинди транспорт белән килүе мәгълүм түгел, бу турыда төрле фаразлар йөри. Ат белән дә, су юлы белән дә, диючеләр бар. Хөсәен Зәбиров күрсәткән шагыйрьнең Казанга чыгып китү датасы да документаль расланмаган, бәлки, автор фаразы гына. Тукайның Казанга килеп җитү датасы да якынча гына алына.)

**3 октябрь.** Казанда демократик яшьләр, шәкертләр органы «Әл-ислах» газетасының беренче саны чыга (ул 1909 елның 22 июлендә туктала). Редакциясе «Болгар» номерлары, 12 нче бүлмәгә урнаша. Мөхәррире Вафа Бәхтияров. Газетада төп эшне Ф.Әмирхан алып бара. Казанга килгәч, Г. Тукай монда башта әдәбият бүлеген, соныннан хатын-кызлар бүлеген алып бара, иҗаты белән дә актив катнаша.

**10 октябрь.** Г. Тукай Казанга килеп җитә. «Болгар» номерының (Татарстан һәм Киров урамнары кисешкән чат 14/59 нчы йорт) өченче катында Кабан күленә таба карап торган почмактан өченче тәрәзә, 40 нчы бүлмәгә урнаша. Кыска вакытлы күченүләрне исәпләмәгәндә, ул бу номерда 1912 елның декабренә кадәр яши. Тукайның Уральскидан алып килгән әйберләре бер кәрзингә сыеп беткән. Бу фактлар якынча гына әйтелә, төгәл документлар сакланмаган. «Болгар» номеры Тукайның ин озак яшәгән урыны.

**10 октябрьдән соң.** Г. Тукайны журналист Борһан Шәрәф Ф. Әмирхан белән

таныштыра. Бу танышу Ф.Әмирхан фатирында, хәзерге Мәҗит Гафури урамы, 35 нче номерлы йортта (элекке Яна бистәдәге Кече Сембер урамы) була. Бу ике зур әдип арасындагы эчкерсез дуслык гомерләре буенча дәвам итә. Әмирхан Ф. Тукай турысында искә төшкәннәр.

Г. Тукай «Йолдыз» газетасы редакциясендә ул вакытта әлеге газетаның җаваплы секретаре булып эшләгән Г.Камал белән таныша. Бу ике зур әдип арасындагы дуслык гомерләре буенча дәвам итә.

Г. Тукай «Әл-ислах»чылар белән фоторәсемгә төшкән: Г. Тукай, И. Әмирхан, Ф. Әмирхан, К. Бәкер, В. Бәхтияров. Фотоның төп нөсхәсе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Кулъязмалар бүлегендә саклана.

**17 октябрь.** «Тәнкыйть—кирәкле шәйдер» исемле мәкаләсе басыла. Мәкаләне «Әл-ислах» газетасының төп хезмәткәре һәм оештыручысы Ф. Әмирхан редакцияләп бастыра.

В. Бәхтияров истәлегенә караганда, «Тәнкыйть—кирәкле шәйдер»—Тукайның Казанга килгәч язган һәм бастырган беренче мәкаләсе. Г. Тукай бу мәкаләне язганда, В. фон Поленцның «Крестьянин» романына Л. Н. Толстой язган кереш сүздән файдаланган. Бу роман 1902 елда басылып чыккан.

**17 октябрьдән соң.** Г. Тукай солдат хезмәтенә каралу өчен туган авылы Кушлавычка кайта. Кайтышлый Каенсар, Кырлай авылларына туктала. Каенсар авылында яшәүче Сажидә апасының әйтүенә караганда, Казаннан кайтканда Габдулла, Күәм авылы кешесенең атына утырып, аягына күн ботинкалар, кулына күн перчатка, өстенә кыска гына кием киеп кайткан. Юлда бик туңган булган, чөнки искечә октябрьнең 25 ләре булганга, көннәр салкынайтып торган. Өйгә кергәч тә, кулларын уа-уа «туңдым, апай» дип сөйләнеп торган.

Казанга кире киткәндә, Сажидә апасы аңа бер пар киез итек һәм бияләй биргән.

**24 октябрьдән соң.** Г. Тукай солдатка каралу өчен чират, җирәбә алгач, Олы Мәңгәргә, Габделвәли исемле туганына барып, ике-өч көн кунак була.

**26 яисә 27 октябрь.** Буйга кечкенә һәм чандыр гәүдәле, бер күзенә әзрәк ак төшкән Тукай солдатка каралу бүлмәсеннән ак билет алып чыга. Ул, Олы Әтнәдә каралып, солдатка алынудан азат ителә.

**5 ноябрь.** «Бер манигы тәрәккъыйгә» исемле шигыре басыла. Шигырь турында В. Бәхтияров болай ди: «Тукай Казан яшьләре арасында Ишми Ишан турында төрле сүзләр ишетә. Аның яңалыкка каршы икәнен аңлый. Аны яңалыкның чын дошманы итеп санап, «Бер манигы тәрәккъыйгә» исемле шигырен яза. Бу—Тукайның Казанга килгәч язган беренче, шуның белән бергә «Әл-ислах»та басылган беренче шигыре».

**15 ноябрь.** Г. Тукайның беренче шигырь җыентыгы чыга: Г. Тукаев шигырьләре («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр), беренче кыйсем. Казан, Шәрәф матбагасы, 1907.

**26 ноябрь.** «Әл-ислах»та «Театр» исемле шигыре басыла. Шигырь турында В.Бәхтияров болай ди: «Ноябрь аеның ахырларында «Сәйяр» труппасы тарафыннан Г.Камалның «Бүләк өчен» комедиясе уйнала. Тукай да театрга бара. Тукайның татар театрын беренче күрүе була. Уен шагыйрьгә ошый, яратып кайта. Шул тәэсир йогынтысында ул «Театр» шигырен яза. 26 ноябрьдә шигырь «Әл-ислах»ның 8 нче номерында басылып чыга.

**1 декабрь.** «Габдулла Тукаев шигырьләре». «Габдулла Тукаев шигырьләрене тәкъдир итүчеләрнең иң элеккесе, ихтимал ки, «Вакыт» улмыштыр. Бик күп кемсәләр ялгыз назыйм улдыклары халдә, Габдулла әфәнде һәм назыйм, һәм шагыйрьдер».

Бу бәя Габдулла Тукаев шигырьләре («Шигырьләр көтеп-ханәсе»ннән 3 нче дәфтәр, 1907) чыгу уңае белән әйтелгән.

**3 декабрь.** Ф.Әмирханның «Габдулла Тукаев шигырьләре» исемле рецензиясе «Дамелла» имзасы белән басыла.

**5 декабрь.** Г. Камалның «Габдулла Тукаев шигырьләре» исемле рецензиясе басылган. Рецензия «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән

3 нче дәфтәр, 1907) чыгу унае белән язылган.

Г. Камал җыентыкның авторын түбәндәгечә бәяли: «Минем каршымда Габдулла әфәнде илә Габделмәҗит әфәнделәр алга чыктылар. Хәзерге көндә шагыйрь исемен итлак кылырга шул икесе лаектыр. Габдулла әфәнденең язган нәрсәләре арасында хакыйкатән шигырь итлакына мөстәхикъ булган гали тасвирлар, гүзәл тәрсимнәр күренәдер».

**12 декабрь.** «Мәхбүс» (Пушкиннан) исемле шигыре чыга. А. С. Пушкинның «Узник» шигыреннән ирекле тәрҗемә.

**17 декабрь.** «Вәгазь» (Лермонтовтан) исемле шигыре басылган. Ул М.Ю.Лермонтовның «Описание» дигән шигыреннән файдаланып язылган.

**24 декабрь.** «Бер гәзитә идарәсе хәленнән» шигыре басыла. В. Бәхтияров «Тукай турында кайбер истәлекләр»ендә шигырьне «Бәянелхак» нашире Әхмәтҗан Сәйдәшевтан көлеп язуы турында әйтә. Ә.Сәйдәшев—Мәскәү байларыннан бурычка мал алып, түли алмыйча, банкротлыкка чыккан сәүдәгәр. Акча юк дигән сылтау белән ул «Бәянелхак»та басылган күп мәкаләләргә гонорар түләми торган була.

**30 декабрь.** Г. Тукай Казаннан Уральскига апасы Газизә Госмановага хат яза. Шул хаттан бер өзек: «Әле бу арада бик яхшы гына авырып алдым. Хат яза алмадым. Кәефем вә тормышым яхшы. Дуст-ишләр күп. Казанда тору күңелле, Уральск бик сирәк искә төшә. «Шүрәле» китабы җибәрдем. Монда кечкенә вакытымда тәрбия иткән әнкәмне дә таптым. Иртәгә күрешмәкче булдым».

**30 декабрь.** Тукай Казаннан Уральскига дусты артист Г.Кариевка хат яза. Хатта мондый юллар бар: «Казанны вә туган җирем булган Казан арты авылларын күреп, күп гыйбрәтләр вә хиссиятләр алдым. Мин хәзер Казанда инде. Уральскида вакыт шуны сөйли-сөйли авыз суларым кибеп бетдеге вә шунда бару хакында шигырьләр яздыкым Казанда инде.

...Үзем теләп кенә «Әл-ислах»та хезмәт итәм. Жалунье башка җирдән алам». Тукай «жалунье» дигәндә Дәүләтшинның «Китаб» нәшриятыннан алган хезмәт хакын күздә тотса кирәк.

«Шигырьләр яздыкым» дигәндә, ул Уральскида язылган «Пар ат», «Туган җиремә» шигырьләрен күздә тота.

**Декабрь.** Г. Тукай Париж коммунасы урамы, 9 нчы йортта, элекке «Сарай» номерларының ишегалдына караган ягында, 2 нче катта, 9 нчы бүлмәдә В. Бәхтияров белән бергә яши.

**Ел ахыры.** Г. Тукай Казанга килгәч, Казанда үзен сабый чакта асрамага алып, берникадәр вакытлар тәрбияләгән үги әнисе Газизә апаның адресын эзләп таба һәм Гарәфә (бәйрәм алды) көнне әнисенә кеше аркылы бүләкләр җибәрә.

**Ел дәвамында.** Г. Тукай Казанга Уральскидан үпкә авыруы алган килеш килә. Казанда табиб аңардан икенче стадия үпкә авыруы таба. Ләкин шагыйрь авыруына әллә ни илтифат итми, дәваланмый.

«Күп вакыт шагыйрь, иртә йокыдан торып, караватөстендә ике тезен кочаклап йөткерә торган иде. Йөткереп арыгач, йоклап китә яки йокламый түшәмгә карап дәшми, сөйләшми, монаеп, тирән уйга батып, ятып карап тора торган иде»,—ди В. Бәхтияров.

Тукай шигырьләре Өфе өязе Кара Якуп волосте (хәзерге Чишмә районы) Келәш авылына да килеп житә. «Һичбер көтмәгәндә, 1907 елда безнең авылга Тукай шигырьләре килеп чыкты. Тукай безгә аңлаешлы телдә, ләкин әлегә чаклы ишетелмәгән яна бер тавыш белән:

*Ник йоклыйсың, мужик?*
*Яз җитте һәм усте*
*Чирәмнәр йортында,*
*Тор, уян, күтәрел!—*

дип, безне гасырлык йокыдан тарткалап уятты,—ди шагыйрь Сәйфи Кудаш.

Халисә
Ширмән

# ХӘЛ ИТӘСЕ ИДЕ...

*Газета теле беркайчан да яхшы атлы булмады. Аны язучылар, тел белгечләре, журналистлар һ.б. сүккәннәр. Мәсәлән, Сомерсет Моэм «газета минем өчен үләт базы чималы ул» дип белдергән; атаклы лингвист А.М. Пешковский газета телен әдәби телнең иң түбән формасы дип атаган. Бер сүз белән әйткәндә, газета телен тәнкыйтьләүчеләр бихисап.*

Г.Я. Солганик

Күренекле стилист Григорий Яковлевич Солганик газета телен тикшерүгә багышланган хезмәтен әнә шундый сүзләр белән башлап китә. Чыннан да, гасырлар дәвамында иҗтимагый тормышның юлдашына әйләнгән газета тәнкыйть утына элек ничек тотылган булса, бүген дә нәкъ шул хәлдә.

Әлбәттә, беренче кульязма хәбәрләр белән хәзерге электрон газеталар арасындагы аерма җир белән күк арасы кебек булса да, максатлары бер—халыкка хәбәр җиткерү. Әлеге функциясе өчен һәр газета хөкүмәтнең күз уңында тотылган, аның рөхсәте (цензурасы) белән генә басыла алган. XIX гасырның икенче яртысыннан ук татарлар туган телдә газета бастыру өчен рөхсәт сорап, патшага мөрәҗәгатьләр, үтенечләр язганнар (Ольга Лебедева—Гөлнар ханым—эшчәнлеген искә алу гына да ни тора!), тик 1905 нче елгы буржуаз инкыйлабтан соң гына мондый мөмкинлеккә ирешкәннәр. Татар телендә беренче татар газетасы «Нур» дөнья күргән. Хәер, патшадан гына түгел, совет хөкүмәтеннән дә татар яшьләре журналын даулап алырга туры килгән безгә...

Бу тарихны язуым—халык өчен, бигрәк тә татар халкы өчен, «газета» дип аталган мәгълүмат чарасының никадәр газиз, кадерле һәм кирәкле булганын искә төшерәсе килүдән. Газета эшчәнлеге минем үзем өчен дә бөтенләй үк ят түгел. 90нчы елларда Лениногорск шәһәрендә чыга торган «Заман сулышы» газетасында эшләп алганым бар, аз гына вакытка булса да, редакция эшенең кыенлыклары, борчу-шатлыклары белән очрашырга туры килгән иде. Әлбәттә, яшь журналист өчен беренче кыенлык «материал» табу булса, икенчесе—шул «материал»ны матур, төзек, камил телдә укучыга сөйләп бирү. Мин эшләгән чорда бу тел, һичшиксез, татар әдәби теленең җитмеш ел дәвамында чарланган, калыпка салынган, традицион шәкелләре булган публицистик стиле иде әле. Ә менә шаукымлы туксанынчы еллардан соңгы иҗтимагый вакыйгалар дулкынында әлеге стиль җимерелде, ватылды, үзгәреп, төрле трансформацияләр, метаморфозалар кичереп, янадан торгызылып ята. Егерме ел дәвамында айкалган-чайкалган публицистик стиль, ниһаять, үз ярларына кайта кебек... Шулаймы икән? Әллә бүген дә ул үз ярларын таба алмыйча, үрсәләнәме әле?

...Хәзерге вакытта татар телендә чыга торган газеталарның саны шактый. «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Татарстан яшьләре», «Мәдәни җомга» һәм район газеталары белән беррәттән шәхси карамактагы газеталарның булуы («Безнең гәҗит», «Акчарлак» һ.б.) сөендерә. Һәркайсының—үз укучысы, үз юлы, үз йөзе. Татарда игезәктәй бер-берсенә охшаган газеталар юк (кайбер очракта темалар бертөрлерәк яктыртылса да). Ә менә «газета теле» дигәндә көч сынашалар әле алар...

Билгеле булганча, газета теле публицистик стильнең (өслүбнең) бер өлешен тәшкил итә. Соңгы елларда кеше тормышына төрле массакүләм мәгълүмат чараларының (матбугат, кино, радио, телевидение, фотография, видео, интернет) тәэсире артуы сәбәпле, аларны өйрәнә торган аерым бер фән тармагы барлыкка килгән. Аның әле тәгаенләнгән исеме дә юк (алманлылар medienwissenschaft дип атарга тәкъдим итсә, Россиядә медиалогия термины кулланышка кереп бара). Мәгълүмат чараларының төрләре, техник яктан тәэмин ителеше, мөмкинлекләре һ.б. өйрәнелә. Белгечләрне бигрәк тә тел ягы кызыксындыра, чөнки журналистның төп коралы—тел. Мәскәүдә ике тапкыр (2001, 2008 елларда) рус мәгълүмат чараларының телен өйрәнүгә багышланган халыкара конференция булып узды. Бу конференцияләрдә рус матбугатының тел торышын билгеләп, аның перспективасын, үсеш кануннарын һәм житешсезлекләрен күрсәткәннәр. Татар журналистлары һәм тел галимнәре өчен дә шундый конференцияләрнең булмавы аяныч, әлбәттә, чөнки уртага салып сөйләшер сүзләр, киңәш-табышлар байтак бит.

Публицистика теле—функциональ стильләр арасында иң ачык система, ягъни биредә барлык функциональ стильләрнең тел үзенчәлекләре катнашып, салават күпере сыман төрлелек хасил итәләр. Бу—газета битләрендә төрле жанрга караган язмалар урын алуы белән бәйле. Әмма публицистик жанрлар никадәр күп булмасын, аларны берничә төркемгә берләштереп карарга мөмкин. Һәркайсының сөйләмне оештыру өчен үзенә генә хас мөмкинлекләре бар. Мәгълүмати язмаларга хәбәр житкерү һәм аны раслау, аналитик язмаларга—аңлату һәм гомумиләштерү, әдәби-публицистик язмаларга реаль-документаль күренешләрне типиклаштыру хас. Димәк, беренчеләренә—гомум кабул ителгән, тотрыкланган гыйбарәләр (стандартлар), һәркемгә аңлаешлы терминнар, кыска җөмләләр, сурәтләү чараларының файдаланылмавы хас булса, икенчеләрендә чагыштырмача ирекле сүз байлыгы, фәнни терминнар, фикерләүдә логик эзлеклелек саклану (текст төзүнең аерым закончалыгы), кереш сүзләр, аныклагычларның күп кулланылуы күзәтелә. Өченче жанрга караган язмаларга исә экспрессив-эмоциональ сурәтләү чаралары, кушма җөмләләрне актив куллану, тел байлыгының төрле катламнарыннан ирекле файдалану хас. Шул ук вакытта һәр өч төр язмаларның нигезендә дә татар Әдәби теле ятарга тиеш, ягъни язмаларның телендә әдәби нормаларның саклануы мөһим.

Татар телендә басылган мәгълүмати язмалар нигездә бу таләпләргә җавап бирә. Мәсәлән, «Ватаным Татарстан» газетасыннан алынган өзек (05.05.10) хәбәр текстының үрнәге булып тора: «Кичә бөтен дөньяда матбугат иреге көнен билгеләп үттеләр. Бу уңайдан «Репортеры без границ» хокук яклау оешмасы сүз ирегең тыючы түрәләр исемлеген төзегән. Әлеге исемлеккә 17 президент һәм премьер-министр эләккән. Оешма вәкилләре фикеренчә, Кытай житәкчесе Ху Цзиньтао, Иран президенты Мәхмүт Әхмәди Нижад, Куба башлыгы Рауль Кастро һәм Талибан башлыгы Омар мулла сүз ирегенә каршы. Бу юлы әлеге исемлеккә беренче тапкыр Россия Премьер-министры Владимир Путин һәм Чечня президенты Рамзан Кадыйров та эләккән...». Өзектән күренгәнчә, текст гади, җәенке, тулы, ике составлы хикәя җөмләләрдән оешкан, хәбәрләр үткән заман формасында бирелгән; лексик берәмлекләр гомумкулланыш даирәсенә карыйлар, терминнар аңлаешлы; сурәтләү чаралары кулланылмаган. Мәгълүмати язмалар һәрбер газетада да диярлек бар һәм алар укучының информацион ихтыяҗын канәгатьләндерә. Берничә төрле хатаны да очратырга була. Беренчедән, кайбер терминнар, татар телендә синонимнары булуга карамастан, тәрҗемәсез бирелә. Мәсәлән, «Казанда шәһәрнең мәгариф учреждениеләре коллективлары арасында «Һөнәр музасы» дигән иҗат бәйге-фестивале башлана.» («ВТ», 09.12.09). Биредә «учреждение»

сүзен «оешма» сүзе алыштыра алыр иде. Тагы бер мисал: «Ә валютада кредит алучыларның акчасын рубльгә күчереп, югалу куркынычыннан саклап калачак.» («Кәеф ничек?», 24.12.2008). «Рубль» сүзен «сум»га күчерүдән текстның мәгънәсе үзгәрми, минемчә.

Аерым очракларда мәгълүмати текстта татар теленә тәрҗемә итәргә кыен булган рус сүзләре дә урын ала: «Килешү нигезендә ике як та боеголовкалар санын 1550 данәгә кадәр кыскартырга тиеш булачак.» («ВТ», 27.03.10) «Әл-Кагыйдә» боевиклары кулыннан һәлак булган мөселманнар башка дин вәкилләреннән күбрәк,—дигән ул.» («ВТ», 18.08010.) «Боеголовка», «боевик» сүзләренең татарчага тәрҗемәсе сүзлекләрдә күрсәтелмәгән, ләкин тәрҗемә сорала бит. Һич булмаса, еш кабатлана торган мондый сүзләрнең иң уңышлы тәрҗемәсенә газетада конкурс-бәйге игълан итәргә мөмкин.

Хәбәр текстларында гына түгел, аналитик, әдәби-публицистик язмаларда да урын алган иң куркыныч хата—рус теленнән лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик калькалар ясау. Бу күренешне хата дип атау да кыен бугай инде, чөнки ул әдәби нормага әйләнеп бара. Бу турыда Илдар Низамовның «Тел язмышы—сөйләмдә» мәкаләсендә җентекле аңлатыла («ВТ», 23.04.10). Кызганыч ки, бер генә газета да калькадан котыла алмый. Мәсәлән, «Патруль-пост хезмәте экипажы кайнар эзләрдән беркайда да эшләмәүче ир-атларны тоткарлаган.»(«ШК», 11.08.09.), «Германия кешесе Карл Фридрих Ленце ышандыруынча, ул банан турайта торган машина уйлап тапкан. («ТЯ», №75 (11476)). Рус телендәге «задержали по горячим следам»—«кайнар эзләрдән тоткарлаган», «по утверждению»—«ышандыруынча« булып киткән. Болар—татар теле гыйбарәләре түгел, шуңа күрә колакны ярып керәләр, телнең яңгырашын бозалар.

Татар газеталарында эчтәлек ягыннан да, тел үзенчәлекләре ягыннан да барлык таләпләргә җавап биргән чын аналитик язмалар сирәк күренә, күпчелек очракта алар вакыйга үткәннән соң гына, җәмәгатьчелек бу турыда фикер алышып бетергәннән соң гына басылалар. Аларның телендә русча фикер йөртү, рустан алынган җөмлә төзелеше булуы да гаҗәп түгел. Мондый язмаларның күбесе сәясәткә, иҗтимагый, мәдәни тормышка багышланган. «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Мәдәни җомга» газеталарында чын аналитик язмалар басыла әле. Калган газеталарда исә алар еш кына мәгълүмати, әдәби-публицистик язмаларга хас булган үзенчәлекләр белән катнашып укучыга тәкъдим ителә. Хәер, монда газетаның тоткан юнәлеше, журналистның тәҗрибәсе, һөнәри осталыгы да зур роль уйный.

Газеталарда басылган күпчелек язмалар әдәби-публицистик жанрга карый һәм журналистның телдән файдалану осталыгына, тел байлыгына һәм белеменә бәйле, шуңа күрә биредә сөйләмнең матур үрнәкләрен күрергә мөмкин. Сөйләм камиллегенә мисал итеп, «Ватаным Татарстан» газетасыннан алынган өзектә синонимнарның (мәгънәдәш сүзләрнең) бирелешен күрсәтергә мөмкин: «Эссенең 35-40 градусы да халыкны үтерергә сәләтле икән. Бер тәүлек эчендә Мәскәүдә генә дә 449 кеше якты дөнья белән хушлашкан. «Газета.ru» хәбәр итүенчә, бу гадәттәгедән 4,5 мәртәбә күбрәк. Мондый хәлнең сәбәбен белгечләр башкаладагы эсселек һәм сөремнән күрә. Аларның сүзенә караганда, шундый һава торышы сакланса, Мәскәүдә бер ай эчендә 13 меңнән артык кеше дөнья куярга мөмкин. Сөрем хроник авырулары булганнарга аеруча начар тәэсир итә, ләкин аннан урта яшьтәгеләр дә кырыла, ди табиблар.»(«ВТ», 09.08.10). Әлеге өзектә синонимнарның кулланылуы текстның тискәре мәгънәсен беркадәр йомшарта һәм стильгә дә төгәллек кертә.

Кызганыч ки, газета текстларында хәреф хаталары да, сүз хаталары да еш очрый. Бу—күптәннән килә торган, укучыларны борчыган мәсьәләләрнең берсе. Соңгы вакытта газета укучылар моңа аерым игътибар бирә башладылар. «Татарстан яшьләре», «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» газеталарында тел мәсьәләләренә багышланган Варис Мираслы мәктүпләре, Илдар Низамов, Фәһимә Хисамова мәкаләләре, Зәки Җанибәк һ.б. тәнкыйте басылуны укучылар да уңай бәяләделәр, хәтта хаталарны күрсәткән «Тел чүплеге» дә булдырылды. Бу тема татар журналистларын берләштергән «Матбугат.ру» электрон сайтында кызу бәхәс уянуга этәргеч ясады... һәм мине дә узган тормышыма әйләнеп кайтып, «Заман сулышы»

редакциясендә эшләгән көннәрне искә төшерергә мәҗбүр итте...

...Кулыма ничек килеп эләккәндер—әйтә алмыйм, әмма ул вакытта әлеге кечкенә генә кулланма-китапчык миңа бик нык тәэсир итте. «Тәрҗемә нигә татарча түгел?» дип атала иде ул. «Яшь журналистларга һәм тәрҗемәчеләргә тәкъдимнәр». КПССның Татарстан өлкә комитетының идеология бүлеге рөхсәте белән 1989 елда басылган. Авторы—Илдар Низамов. Йотлыгып укып чыкканымны хәтерлим һәм шул көннән бирле мин бу кулланмадан аерылмадым дияргә була, гәрчә авторның сөйләмият һәм тәрҗемә фәненә багышланган башка хезмәтләрен укысам да. Кулланманың исеме астында кечкенә хәрефләр белән «Сүзгә-сүз тәрҗемәнең сәбәпләре һәм аннан котылу юллары» дип язылган. Фәнни телдә «калька» була инде бу. Редакциядә эшләгәндә мин әле бу мәсьәләнең никадәр катлаулы булуы һәм татар әдәби теле үсешенә нинди зур зыян салуы турында уйланмый идем, чөнки мин—авылдан күптән түгел генә аерылган, рус теле йогынтысын кичерергә өлгермәгән саф татарча уйлый һәм сөйли торган бер бала... Калька—гади сөйләм теле өчен куркыныч түгел (алынмалар күпкә хәтәррәк!), калька ул—әдәби телнең корткычы. Шәһәр мохитендә бигрәк тә. Ул вакытта мин Илдар абыйның үз сүзен ярып әйтә белүенә һәм газетада басылган мәкаләләрне, тәрҗемә китапларның телен тәнкыйтьли алуына шаккаткан идем. «Ничек инде газетада басылганны тәнкыйтьләргә була!»,—дип уйлыйм бит. Хәзер генә гаҗәп түгел ул. Совет заманында матбугатка басылганнан да дөресрәк нәрсәнең булмавына халыкның иманы камил иде... Тел кагыйдәләрен дә дәреслектән түгел, әдәби китаптан, газета-журналдан өйрәнеп үстек ич без.

...Аннан соң да тел «чүп»ләренә багышланган мәкаләләр, фәнни хезмәтләр укырга туры килде. Рүзәл Йосыпов, Сәгадәт Ибраһимов, Вахит Хаков, Фәһимә Хисамова, Равия Абдуллина, Хәлил Сәлимов, Флера Сафиуллина һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә күрсәтелгән хаталар әйтерсең бүгенге матбугаттан әле генә алынганнар! Нәкъ шулар ук. Менә бу мәкаләмдә күрсәтеләчәк хаталарның күбесе дә «яңа» барлыкка килгән түгел, моннан ун-унбиш еллар элек тәнкыйтьләнгәннәр, тик «арба гына һаман да үз урынында»...

...Беренче төркемгә орфографик һәм пунктуацион хаталарны кертеп карарбыз. Корректор һәм редакторлар өчен моннан да гадирәк эшнең булуы мөмкин түгел кебек. Орфографик сүзлекне аласың да, сүзнең дөрес язылышын карап, төзәтеп куясың. Тик... 1983 нче елда басылган норматив сүзлектә соңгы елларда телгә кергән яңа сүзләр юк, ә аннан соңгы 2004 нче елда чыкканында «алтыпочмаклы», «дүртсумлык», «күпхатынлы», «күптармаклы» язылышларын күреп, ирексездән тукталып каласың. Димәк, «Шәһри Казан» газетасы «Ләкин күпфатирлы йортлардагы почта тартмаларын әледән-әле вату, китерелгән газеталарны ягу очрагы булды.» («ШК», 11.08.09.) җөмләсендә күпфатирлы сүзен рус телендәгечә кушып язып, дөрес эшләгән?! Димәк, шул ук принцип белән оешкан туң йөрәкле, зур комлык, ак җәймәле сүзтезмәләре дә, лексикалашып, кушылу процессын кичерә?! Ә бу җөмләдә нинди сүз кулланылган: «Евровидение-2008« җыр бәйгесенең сайлап алу концертында соңгы урынны алган җырчы Асылъяр үзе Мәскәүдән кайтып төшкәнче диярлек татар матбугат чаралары кемузардан булып әлеге чараны яктыртты.» («КН», 27.03.2008)? Кем+узар+дан? Орфографик сүзлектә күрсәтелгәнчә, тәүфикъмы, әллә «Шәһри Казан» язганча, тәүфыйкмы? («Бары тик Маһибәдәр әби генә һәр көн намаздан соң шул баланың тәүфыйк белән кайтуын тели.» («ШК», 11.08.09). Әнә, «Кәеф ничек?» газетасы «вәзгыять» дип язганда (18.08.10), «Шәһри Казан» «Рубрика: Вазгыять» дип яза... («ШК», 11.08.09.). Пошимы, әллә пошыймы? Мин язганча мәгълүматимы, әллә мәгълүматыймы?

Мондый мисалларны бик күп дәвам итәргә булыр иде. Орфография турында бик озак бәхәсләшеп була. Тел белгече Равия Абдуллина дөрес әйтә: «...иң әүвәл, хәзерге татар орфоэпиясенең һәм орфографиясенең фәнни нигезләнгән камил системасын булдырырга кирәк». Икенче төрле әйткәндә, аерым сүзләрнең язылышы турында бәхәс куертырга түгел, дөрес язылышны тәэмин итә торган кагыйдәләрне яңадан эшләргә кирәк. Озакламый галимнәр тарафыннан төзелгән тагы бер орфографик сүзлек дөнья күрәчәк. Тик шуннан соң да дөрес язылыш турындагы бәхәс туктар дип уйламыйм. Күпләр тәкъдим иткән «халыкчанлаштыру» процессы, ягъни

«ишетелгәнчә язу» принцибы да мәсьәләне хәл итмәячәк, чөнки «сәләм, бәлә» язылышлары кабул ителгән очракта да, «мәкалә, гайрәт, гади» кебек сүзләрнең язылышы сакланачак («мәкәлә, гәйрәт, гәди» дип язып та, укып та булмый). Димәк, орфография мәсьәләренең төп чишелеше—алфавитта. Алфавитны үзгәртми торып, язылыш белән әйтелеш арасындагы упкынны бетерү мөмкин түгел. Латин алфавиты—татар теле янгырашын язуда иң камил чагылдырган алфавит. Әгәр аны гамәлгә кую хәзерге заман шартларында берничек тә мөмкин түгел икән, кирилл алфавитына өч хәреф өстәү юлы белән дә күп ялгышлардан котылып булыр иде. Кайбер төрки халыклар, әнә, калын [к], [г] авазларын калынлык билгесе язып (къ, гъ), [w]ны у белән алыштырып булса да, дөрес әйтелешне саклап калганнар бит әле!

Пунктуациядә дә шундый ук кыенлыклар: тыныш билгеләрен дөрес кую өчен хәзерге сөйләмә тел үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән яңа кагыйдәләр системасы кирәк. Тыныш билгеләре сөйләм үзенчәлекләрен (интонацияне) язуда чагылдыра. Теләсә кайсы урынга өтер тӛрткәләп, автор әйтергә теләгән фикернең нәкъ киресен күрсәтергә мөмкин. Газета телендә еш кына туры һәм кыек сөйләм дөрес чагылмый. Менә бу җөмләләргә игътибар итик. «Моннан тыш, «Татаркино» оешмасыннан, Илдар Ягафаровның «Брелок» дигән фильмы да күрсәтелә, дип хәбәр иттеләр.» («ВТ», 20.08.10). «Русиялеләрнең 94 проценты больничный артыннан йөрмим, үрмәләп булса да эшкә барам, чөнки минем эшне башка кеше башкара алмый дип белдергән.» («ТЯ», № 38 (11361), 2009). Югыйсә, автор сөйләме белән чит сөйләм бик җиңел аерыла ич, ни өчен аны язуда дөрес күрсәтеп булмый икән?

Икенче төркем хаталар сөйләмне дөрес оештыруга карый. Кайбер татар газеталары материалны рус газеталарыннан яисә рус телле интернеттан алалар һәм татарчага тәрҗемә итәләр. Бу начар күренеш түгел, газета укучы һәр кеше интернетта утыра алмый, рус газеталарын да укымый, шуңа күрә һич кенә дә журналистларны гаепләмим, мактыйм гына. Ләкин тәрҗемә ителгән мәкаләләр әллә кайдан ук «Мин—тәрҗемә!» дип кычкырып торалар... Менә шул вакытта журналистларыбыз тагы бер кат Илдар Низамов һәм Рүзәл Йосыпов хезмәтләрен исенә төшерсә иде. Тәрҗемә—катлаулы процесс, ике телне дә камил белүне таләп итә, ләкин телне бик яхшы белгән журналистларның язмаларында да синтаксик калькалар күренә. Әгәр тәрҗемәдән башка берниндй материал табып булмый икән, ул вакытта сүзен-сүзгә тәрҗемә итмичә, эчтәлеген сөйләп чыгу ярдәм итәр иде... Һәрхәлдә, синтаксик калькалардан котылуның бер юлы—үз сүзләрең белән (татарча!) сөйләп бирү.

Текст төзелешендә логик хаталарның ешаюы да күзәтелә. Авторның әйтергә теләгән фикере аңлашылмый, укучыда сорау уята. Мәсәлән: «Җәйге ялдан соң балаларның башы әйләнә. Ә шәһәр ыгы-зыгысы, транспорт хәрәкәте беркемне дә аямый. Белгечләр сабыйлар катнашындагы аварияләр саны артуны әнә шулай аңлата.» («ВТ», 18.08.10.). Ни өчен балаларның башлары ялдан соң әйләнә? Туры мәгънәдә әйтелгәнме, әллә күчерелмә мәгънә дип аңларгамы? Сораулар бар, ә текстта җавап юк... «Голландиягә поезд белән барырга чыккан немес акчасын сәяхәтенең башында ук югалта.»(«ТЯ», №73(11474)) Немес акчасы Голландиягә поезд белән барырга чыкканмы? Бәлки, «Голландиягә поезд белән барырга чыккан немес сәяхәтенең башында ук акчасын югалта»,—дип аңларгадыр? (автор язылышын һәм морфологиясен саклаган очракта да).

«Русия хакимнәре кризис белән бәйле хәлләр аркасында халык тузына башламасын өчен ил җитәкчелегенең уңай образын тудыру өчен махсус сценарий-документ эшләгән, имеш.» («ТЯ», №75(11242), 2008). «Кеше үзенә кирәклесен ала да, ел саен Җир өстенә 10 миллиард тонна пычрак ташлый—экология начарлана бара. Адәм балаларының явызлыгы елдан-ел масштаблырак була бара.»(«ТЯ», №19, 2010) Бер үк сүзләрнең, кисәкләрнең кирәксез кабатлануы тавтология дип атала. Күргәнебезчә, журналистлар бу күренешне җөмлә эчендә дә, текст эчендә дә бик «яратып» кулланалар...

Өченче төркем ялгышлык—сүзләрнең мәгънә үзенчәлекләрен дөрес кулланмыйча язу. Мәсәлән, «Казан дәүләт университетының астрономия каланчасы түбәсендә шундый бер антенна инде биш ел тора» (ШК, 10.08.10)». «Астрономия каланчасы»

дигәндә, автор, әлбәттә, обсерваторияне күз алдында тоткандыр, ләкин каланча сүзе һәм обсерватория ... ««Мерседес» уфалласы» кебегрәк янгырый... «Каланча—тирә-юньне күзәтү өчен тар һәм биек итеп эшләнгән баскычлы корылма»,—дип язылган «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә. (29 бит) Сурәтләү чарасы буларак кулланылырга хаклы, тик мәгълүмат җиткерү максатында әйтелгән мондый сүзтезмәне кабул итү кыен.

«Әле жылылыкны, кайнар суны аеру бер хәл, бурычы булганнарның фатир канализациясен гомуми челтәрдән аеру турында да сүз бара бит»,—дип яза «Татарстан яшьләре» («ТЯ», № 38, 2009)». Сүз жылылыкны өзү турында бара булса кирәк.

«5 августтан руль артына шыр аек килеш кенә утырырга ярый дигән закон гамәлгә керә. (ТЯ, №14, 2010). Шыр аек гыйбарәсе, күрәсең, телдә йөргән шыр исерек (лаякыл исерек) гыйбәрәсенә охшатып ясалган. Марат Кәбиров, Зөбәер Мифтахов шигырьләрендә очратып, гаҗәпләнгәнемне хәтерлим. Шигърияттнең үз законнары—бәлки, сурәт ясау өчен кулланылырга да мөмкиндер. Тик сөйләм телендә шыр кисәкчәсе тискәре мәгънәне күрсәтергә кирәк булганда ялгана: шыр тиле, шыр дивана, шыр ялангач, шыр надан, шып-шыр (буш), шыр сөяккә калу, шыр җибәрү... Шыр аек гыйбарәсе урынына ап-айнык дип әйтеп булганда, мәгънә белән төрле тәҗрибәләр ясарга ярамый, минемчә.

Тагы бер төркем хата морфологик күрсәткечләрне (кушымчаларны) дөрес файдаланмауга карый. «Вафат булучы группадашларымны искә алуым юкка гына түгел.» («ТЯ», №13, 2010) Бу очракта сыйфат фигыль *—учы* кушымчасы белән түгел, үткән заман мәгънәле*—ган* кушымчасы белән бирелергә тиеш (вафат булган группадашларымны).*—Учы* кушымчасының бары затларны гына ачыклап килә алуы турында хөрмәтле галимәбез Фәһимә Хисамова күп тапкырлар язды, тик әлегә кадәр газета телендә*—учы* теләсә кайсы исем янында кулланыла: «Нәкъ шул алымны пропагандалаучы максатчан программаны җәелдерү нәтиҗәсендә бездә 2005 елда бер яшькәчә сабыйларның 74,5 проценты күкрәк сөте имеп үсүе билгеле булды.«(«КН», 27.03.2008)

Журналистлар төшем кушымчасының бик җиңел төшеп кала алуы турында да оныталар: «Мондый куркыныч хәлне кичергән балаларны сугышны күргән балалар белән тиңләргә була, ди Ениколопов.» (ТЯ, №69-70 (11471)) . «Сугыш күргән балалар» дип язу морфологик тавтология булдырмас иде.

Диалекталь сүзләр куллану да газета теле өчен ят түгел: «Ә бүген бер уйдык үлән өчен сугышыр дәрәҗәгә җиткән авыллар бар». («КН», 14.07.10) Кеше сәламәт булып үссен өчен аның үсеше тәү сәгатьтән үк күзәтү астында булырга тиеш, диләр табиблар». («КН», 27.03.2008.) Күршесе белән әчелешле яшәүче бу адәм «Дружба» пычкысы алган да...» («ТЯ», №10, 11489)

Бер караганда, бу хаталарны «журналист ялгышы» дип кабул итәргә дә мөмкин. Газета—оператив мәгълүмат чарасы, редакторның да, корректорның да хаталарны күреп бетермәве мөмкин. Шулай да техник хаталар янында махсус хаталы язылышларның очравы гаҗәпләндерә: «Әл-Кагыйдә»—«Әл-Каида», Геленджик—Геленжик—Геленчәк, «Ак барс»—«Ак барыс», Грузия—Гөрҗия, Каһирә—Каир, Түбән Новгород—Нижгар, Башкортстан—Башкортостан...

...Г.Я. Солганик дөрес әйтә: газета телен тәнкыйтьләүчеләр бихисап. Шул ук вакытта бик матур, йөгерек тел белән язылган мәкаләләрнең булуын да әйтергә кирәк. Бар андый мәкаләләр, һичшиксез, бар! Татар матбугатын бары тик хурлап язучылар ягында түгелмен. Киресенчә, соңгы вакытта журналистларның тырышуларын, хәреф хаталарыннан, сүз ялгышларыннан котылырга омтылуларын унай бәялим. Афәрин генә! Ә хаталарның күзгә күбрәк ташлануы—гадәти хәл...

...Матбугат турында сөйләгәндә, безне, һәрвакыттагыча, Рәсәй халкы хәл итә алмый торган ике сорау борчый: кем гаепле һәм нәрсә эшләргә? Хәер, бу очракта гаеплеләр билгеле дә инде: язучы һәм журналистлар—галимнәрне, галимнәр—язучы һәм журналистларны тел бозуда гаеплиләр. Эт—эткә, эт—койрыкка. Тик моңа карап кына хәл үзгәрми: тулаем алганда, татар әдәби теленең публицистик стиле авыру килеш кала бирә... Нишләргә соң?

Моннан чыгу юлын мин шәхсән үзем болай күрәм: бүгенге көндә тел

реформасыннан башка тел мәсьәләләрен хәл итү мөмкин түгел. Журналистлар, язучылар һәм галимнәр берләшеп, «Татар теле: хәл-торышы һәм үсеш перспективасы» дип аталган вәкаләтле конференциягә җыелырга; төп кыенлыкларны, бәхәсле сорауларны уртага салып сөйләшкәннән соң, карар (резолюция) белән Дәүләт Советына мөрәҗәгать итәргә. Карарда мондый мәсьәләләрне күрсәтергә мөмкин: 1) Әлифбага өстәмә хәрефләр кертү яисә язылышны үзгәртү турында (латин графикасын кайтару бүгенге вәзгыятьтә реаль түгел инде); 2) Татар теле кагыйдәләрен яңадан эшләү буенча комиссия төзү; 3) ТВ, радио, газета-журнал һ.б. мәгълүмат чараларында эшләүче яшь журналистларның һөнәри осталыкларын күтәрү курслары оештыру, кулланмалар чыгару.

Телевидение, интернет, радиода эшләүчеләр, язучылар үз тәкъдимнәрен әйтерләр иде. Эшне конкрет оешмаларга йөкләргә һәм контрольгә алырга. Әлеге пунктлар материаль чыгымнар таләп иткәнгә күрә, бу мәсьәләләр дәүләт ярдәменнән башка хәл ителә алмый...

...Бу тәкъдимнәр бәлки кайберәүләр өчен тормышчан да тоелмас. Дәүләт теле булган татар телен гаиләгә һәм мәктәпнең дүрт сыйныфына бикләргә омтылганда, кая инде ул әлифба үзгәртүләр! Әмма кул кушырып, зарланып кына утырганчы, нәрсә дә булса эшләү теләге гаеп түгел. Өметсез—шайтан, диләр бит...

---

## *«Казан утлары»—интернетта*

## «МАТБУГАТ.РУ»ДАН БЕЗНЕ УКЫГЫЗ

### Бәләкәй Дания. 2010 ел, август

Балачакта балыкка йөргән Идел болыннары күптән су астында калды. «Меховой»дан Иделгә озак бара идек болын буйлап. Балыкларны колхоз базарына илтеп сатып, акча эшли идек. «Бабай» бакчасында кызлар белән йөргән чаклар... №13, 35 мәктәпләр безнеке иде. Ул чордагы Ш.Камал, К.Якуб, Яшьләр урамнары балаларының күбесе бүген юк инде...

Вәт бит Дания, күзләргә яшьләр китерден!

**Исемсез**

«Казан утлары»ндагы «Бәләкәйләр»не күтәреп алып, гел укып барам. Ә менә бу сандагы «бәләкәй» мине ныграк дулкынландырды, ныграк сихерләде. Үткән гомердәге уртаклыклар, ул сөйләгәннәрдәге матур хатирәләрне үзеңдә дә тою, кичерү—болар күңелгә якын, җылы, бик тә рәхәт әйбер икән.

Әйе, мәркәзебез үзгәрә, матурая. Кемгә ничектер, минем күңелемә дә элеккеге без үскән бәләкәй, яшүсмер чактагы Казан якын шул. Бәләкәй чакта уйнап үскән җирләр, коенган сулар нигә шулчаклы якын икән?! Гомерләр үткәч киләсең шул тансык якын җиргә. Ярый ла, алар исән булса? Эзлисең балачак, яшьлегең хатирәләрен. Юк шул инде, күбесе исән түгел, яңарталар, үзгәртәләр. Синең үткәнеңдә беркемнең эше юк...

**Моңсылу**

# БЕЗ ЯНМАСАК...

«ШӘҺРИ КАЗАН» ГАЗЕТАСЫ БАШ МӨХӘРРИРЕ
МАНСУР МОРТАЗИН БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

**—«Шәһри Казан» газетасына 20 яшь. Моңа ышанасы да килми шикелле. Тарих өчен бу—мизгел генәдер. Ә менә татар халкы өчен милли матбугатыбызның офыкларын киңәйтүгә бик зур адым ясаган еллар иде бу...**



—Әйе, аның беренче саны 1990 елның 17 августында дөнья күрде. Ул чын мәгънәсендә могҗиза, сенсация буларак кабул ителде. Газеталарыбыз санаулы гына иде, шулар янына көн саен чыга торган, зур форматтагы өр-яңа басма өстәлде. Еллары бик үзенчәлекле иде шул: киләчәккә зур өметләр белән карый башладык, туган телебез үсә, дәүләтчелегебез ныгый, иншалла, дип шатландык. Хәтта читтә яшәгән татарларыбыз да безгә карап үрнәк алдылар һәм аларга үзебез дә күпмедер ярдәм күрсәтергә тырыштык.

Әмма тормыш, җәмгыятьтәге борылыш-үзгәрешләр һәрнәрсәне үз урынына куйды. Кызганыч, күп кенә хыялларыбыз чынга ашмый калды. Бу сүзләремне шәрехләп тормыйм, һәммәсен дә күреп, белеп торабыз ич...

**—Мондый юбилейларны элегрәк, гадәттә, театр бинарлары алып, шаулатып, «жу-у...» итеп үткәрә торган идек. Ә бүгенге шартларда «жулатып» алулар, ай-һай, теләсә-кайсы редакциянең көченнән киләме икән. Бигрәк тә бюджетның күзенә карап торган басмалар дип әйтүем. Бәйрәмегезне ничегрәк билгеләп узарга җыенасыз?**

—Бүген, чыннан да, зур бәйрәм үткәрә торган заманалар артта калып бара. Кызганыч, әлбәттә. Мәдәният йорты алып, зур акчалар исраф итеп, халыкны җыеп, житәкчеләрне һәм артистларны чакырып йөрүнең фәтвасын күрмим мин. Сәбәпләре анлашыла ки, безнең бу бәйрәмебезгә генә түгел, бүгенге хәлебезгә дә финанс кризисы нык сукты. Әмма кризисны сылтау итеп кенә бәйрәмнән баш тартырга җыенмыйбыз. Август ае—урак өсте вакыты, житмәсә аннан алдарак ике-өч ай буена республикабызны корылык җәфалады. Килешмәс, дидек. Өстәвенә, халыкның да, студентларның да җәйге ялда чагы. Газета укучыларыбыз белән күрешеп, күргәзмә оештырып, буклетлар бүләк итеп, үзебезнең конференц-залда җылы гына очрашу үткәрергә исәп бар.

**—«Шәһри Казан». Газетаның җанга якын бу исеменә шулкадәр ияләштек ки, ул инде ташка уелган кебек, аны бернинди вакыт җилләре дә тормыштан һәм аңыбыздан сөртеп алалмас кеби. Басмагызга исем кушу тарихын искә төшерик булмаса...**

—Мин газетаның беренче саннарын чыгаруда катнашкан журналист түгел, әмма

яхшы хәтерлим: яна басмага исем эзләү ниятеннән конкурс игълан ителде. Кызыклы гына байтак исемнәр килә. Шулар арасыннан Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин тәкъдим иткән «Шәһри Казан» дигән исем жюри тарафыннан хуплана. Укучылар ягыннан да яклау таба. Шагыйрь, күрәсең, «Шәһри Болгар» дигән мәгълүм атамага таянып, газетаның исемен тарихи яктан тагын да ныграк калкытып куярга теләгәндер. Хәтта еллар узгач, республикабызның Чаллыда нәшер ителә торган икенче бер газетасы да үзенең исемен «Шәһри Чаллы» дип үзгәртәләр. Без инде 20 ел буе шушы исем белән җәмәгатьчелеккә таралабыз.

**—Һәм газетада, һәм төрле журналларда эшләгән кеше буларак шундый чагыштыру китергәнем бар: газета эшләү—моторлы көймәдә унга-сулга чапкан кебегрәк, журналда эшләү исә еракка йөзгән пароход барышына тиң. «Шәһри Казан»—көндәлек басма, мин аның катлы-катлы, йөз каптырмалы мәшәкатьләрен күз алдына ачык китерәм. Журналист хезмәте—иң авыр һөнәрләрнең берсе түгел микән? Заманча, тирән эчтәлекле һәм укымышлы газетаны вакытында чыгарырга ничек өлгерәсез?**

—Чагыштыруың бик урынлы, бик дөрес. Газетада, радиода, матбугат үзәгендә, журналда төрле вазифалар башкарган кеше буларак, мин үземне чагыштырып карап әйтү мөмкинлегенә ия дип саныйм. Мина калса, иң авыры—көндәлек басманы нәшер итү, аны вакытында өлгертү. Чөнки көне-сәгате белән килгән хәбәрләр ташкынын аралап, алны-ялны белми эшләп, аларны вакытында укучыга җиткерә белергә кирәк. Чыңгыз Айтматов болай дигән: «Мин һәр язган әсәрем белән үләм, янасын язар өчен өр-янадан туам». Безнең хәлләр дә әнә шуна охшаш булса кирәк.

Дәүләт карамагындагы газеталарның үз кыенлыклары да бар. Аларга да күпмедер дәрәҗәдә ярарга кирәк, шул ук вакытта халык фикеренә колак салу, укучы ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек итеп эшли белү дә фарыз. Мондый газетаны чыгару өчен редакциядә үз эшен, үз һөнәрен яратучы, тырыш, булдыклы һәм вакыт белән исәпләшмәүче кешеләр генә эшли ала. Ләкин мондый хезмәт режимы бигрәк тә яшь журналистлар өчен кирәкле дип саныйм, аларны ул тәртипкә, оператив эшләргә, ялкауланмаска өйрәтә. Әйе, журналист һөнәре—җинел һөнәр түгел, тикмәгә генә ул кыенлыклар җәһәтеннән дүртенче урынга куелмагандыр. Бу эш—тынгысыз җанлы кешеләр өчен. Ә инде йөрәген мүк басканнар бу мәйданнан ерак йөрсен.

**—Газетаны оештырган кешеләрне искә алып китү урынлы булыр, минемчә...**

—«Шәһри Казан»ның беренче баш мөхәррире—Хәлим Гайнуллин. Ул газетага килгәнче зур тәҗрибә туплап, «Татарстан яшьләре»нең тиражын 270 меңгә җиткерә алган иде. Шул тәҗрибәсен ул яна басма эшчәнлегендә дә нәтиҗәле кулланды. Язучылардан, журналистлардан, сәнгать әһелләреннән яхшы коллектив туплады. Ул җитәкчелек иткән елларда барлык милли басмалар да күтәрелеш кичерә иде, әлбәттә. «Шәһри Казан» да шул чорда киң катлам җәмәгатьчелектә танылу алды.

**—Проблемалар юк түгелдер. Сезнең эштә иң кыены нәрсә?**

—Кайда гына юк соң ул кыенлыклар! Без бит аерым бинада утырабыз. Күршебез, «Казанские ведомости» газетасының баш редакторы Венера Якупова әйтә мина: «Без синең белән завод директорлары»,—ди. Әйткәненең мәгънәсе болай: урам себерү, бүлмә-коридорларны җыештыру, өстән коеп яңгыр яуганнан соң түшәмнән су үтү, сантехниканы карап тоту дисеңме—болар бар да безнең җилкәдә. Бөтенесен үзебез карап, кайгыртып торабыз. Сезнең «Идел-Пресс»та хәлләр бүтәнчәрәк бит, анда Ислам Әхмәтҗанов дигән гендиректор бар. Төп хуҗа кеше—ул. Ә безнең күпне кайгыртып торучы Ислам абыебыз юк.

Мин бирегә эшкә килгәч, гаҗәпләндем: бер генә бүлмәгә дә ремонт ясалмаган иде. Үз көчебез белән линолиум җәйдек, буясын буядык, стеналарны обойладык. Агарттык та, чистартык та. Эш киемнәрен алмаштырып баш мөхәррир үзе башлап йөри икән, коллективтагылардан кем генә «ак карга» булып читтә калсын икән... *(Шкафындагы пакеттан эш киемнәрен алып күрсәтә. Р.Н.)* Хәтта ял

көннәрендә чыгып эшләүдән дә тайчанмадык. Ай саен диярлек рәссамнарның иҗат үрнәкләреннән күргәзмәләр оештырабыз. Тантаналы ачыш вакытында шагыйрьләр, артистлар, музыкантлар һәм газета укучыларыбыз катнаша. Җылы очрашулар сирәк заманда бу бик мөһим дип саныйбыз. Әгәр ремонтны үзебез ясамасак, боларны оештыру мөмкин булыр идеме соң? Яңа эшкә килгәч тә мине оялу, унайсызлану хисе биләп алган иде. Шөкер, коллектив мине дөрес аңлады, башлангычны күтәреп алды. Без бит һәммәбез диярлек авылда эшләп үскән балалар. Ә эшнең, кайсын гына алсаң да, ояты юк.

Икенчесе—татар газеталары өчен акча, финанс кытлыгы. Өстәвенә, татар матбугаты реклама юлы белән әллә ни майтара алмый. Реклама битләрен укучылар да берән-сәрән генә булырга мөмкин. Безнең өчен нәтиҗәсе, файдасы юк диярлек моның.




**—Туган телебез язмышы һәркайсыбызны борчый, йөрәкләрне пәра-пәра китерә. Ничек уйлыйсыз: тиражларыбыз һаман да төшә барса, бу хәл милли матбага һәм ана телебезнең яшәвенә, киләчәгенә кара шәүлә булып ябырылмас микән?**

—Чыннан да, хәлләр мөшкелләнә бара бугай. Без күпме генә мактанышсак та, әгәр дә татар теле язма тел буларак сакланмый икән, татар матбугатының киләчәге юк диярлек. Ни генә дисәк тә, соңгы елларда язма телебезгә урын көннән-көн тарая бара. Моңа бигрәк тә зур сәбәп—ашкынып-кабаланып интернетка үтеп керү булды. Вак-төяк мәгълүматны шуннан укып, көне-сәгате белән таныша барып, «Миңа шул бик җиткән» дип уйлаучылар күбәя бара. Андыйларга газетаң да, журналың да кирәк түгел. Мин моны укучылар белән очрашулардан чыгып әйтәм. Әгәр дә дәүләт туган телебезне үстерү һәм саклау буенча, бүгенге заман таләпләрен истә тотып, яңа программа булдырса яисә искесен өр-яңадан карап чыкса, бу мәсьәләне үзенең канаты астына алса, бәлки әле югалып бетмәгән кыйммәтләрне сакларга һәм кире кайтарырга өлгерер идек. Чаң кагарга, акыл көчләрен уятырга кирәк! Без дә янмасак, безнең өчен кем яныр икән?..

**—Совет заманындагы цензураны хәтерлисең микән? Матбугатны корыч куллар авызлыклап тота иде ул чакта. Ә хәзер... бер яктан ирек килде, әмма газета һәм журналларның аяк-кулы барыбер бәйдә әле. Бу фикер белән килешәсеңме?**

—Финанс ягыннан дисәк, бик дөрес. Нишләтәсең, дәүләт матбугаты ул һәрвакытта да үзенең оештыручыларына, гамәлгә куючыларына бәйле булды һәм шулай булачак та. Моның формалары гына үзгәрә. Дәүләт канаты астында булсак та, без әле барыбер күпмедер дәрәҗәдә дәүләт сәясәтенә карата һәм түрәләргә тәнкыйть сүзләре әйтә алабыз. Шуның белән азмы-күпме юанып була.

**—Яхшы газета чыгарасы урында, журналистларның бик күп көче тиражны арттыру, саклап калуга исраф ителә түгелме?**

—Элекке еллар белән чагыштырганда журналист фәкать үз эше белән генә шөгыльләнеп утыра алмый. Ул бик күп төрле вазифалар башкара. Кыскасы, бүгенге журналист—универсал кеше, ул төрле темаларга яза да белергә, реклама оештырырга һәм абунәчеләр табарга да тиешле. Бу—заман таләбе, прогресска ныграк якынаю билгесе.

*Әңгәмәне **Рашат НИЗАМИ** үткәрде.*
*Август, 2010.*

# БЕЗ БИТ КӨРӘШЧЕЛӘР ЗАТЫННАН

*Шәрәфетдинов Дамир Рәуф улы (1940), журналист, архивчы. ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1990), «Татарстан яшьләре» һәм «Социалистик Татарстан» газеталары хезмәткәре (1963-74). 1974-90 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты инструкторы, партия архивы мөдире. 1990-91дә «Татарстан» журналының баш мөхәррире. 1991-92дә ТРның Тарихи-сәяси документларны саклау үзәк дәүләт архивы директоры. 1993 елдан 2005 елга кадәр ТР МК каршындагы Баш архив идарәсе җитәкчесе, 1994 елдан «Гасырлар авазы»—«Эхо веков» журналының баш мөхәррире. Хезмәтләре татар халкы бәйрәмнәренә, тарихи эзләнүләргә карый.*

(«Татар энциклопедия сүзлеге»ннән).

**—Дамир кардәш, әгәр синең титулларны, мактаулы исемнәреңне тулаем санап чыксак, чиккән сөлге буе озын бер исемлек килеп чыгар иде. Иң яхшысы—син үзең җавап бир әле: кем соң ул Дамир Шәрәфетдинов? Спортчымы, журналистмы, архивчымы, тарихчымы, мөгаллимме?..**



—Мин үземне барыннан да элек спортчы дип саныйм. Бу—минем язмышым, тәкъдирем. Биографиямнең өр-яңа битләре шунардан башланды. Югыйсә, Иске һәм Яңа Бистәләрдә туып-үскән күп кенә яшьтәшләрем кебек, минем дә трамвай-автобус тәгәрмәчләренә эләгеп яисә урам сугышларында, хулиганлыкта катнашып, бу якты дөньядан китеп баруым бик ихтимал иде. Классташларымның күбесе әнә шулай харап булды. Мин Кабан күле янындагы 12нче татар мәктәбендә укыдым. Искиткеч матур урыннар! Су, комлык, яшел чирәм, таллыклар дисеңме...

Укучы, зинһар өчен, мактану дип кабул итә күрмәсен: минем сабый һәм балачак биографиясендә сөекле шагыйребез Тукайга бәйле «урыннар» да бар. Хаста Тукаебыз Клячкин шифаханәсендә вафат була, ә мин (1940 елның 12 сентябрендә) нәкъ менә шушы Клячкин бинасында дөньяга килгәнмен. Аннары... Без әни белән элекке «Болгар» номерларының беренче номерлы бүлмәсендә озак яшәдек. Тукай яшәгән кырыгынчы бүлмәдә исә сыйныфташым Карл яши. Аның янына еш керә идем. Шулай итеп, мин... кайчандыр Тукай дөньяга караган тәрәзәдән Казан урамнарына күз ташлаган, тарихи бу бүлмәнең һавасын иснәп караган бер татар баласы булам түгелме соң? Менә инде 2 ел вакыт узды, «Болгар» номерларын җимерүгә катнашы булган чиновникларның әле һаман да тәүбәгә килгәне юк.

Биографиямнең бер өлеше булганга күрә, курыкмыйча әйтәм: 16 ел буе КПССның Татарстан өлкә комитеты бүлегендә инструктор булып эшләдем. Менә шул елларда Тукайның булачак музеена бина табу мәсьәләсе калкып чыкты. Сөйләшүләрнең берсендә мин тоттым да «Шамил йорты»н тәкъдим иттем. «Син нәрсә, анда бит инде

шахматчылар клубы эшләп ята»,—диделәр. Мулланур Вахитов һәйкәле тирәсендә менә дигән мәктәп бинасы буш ята, дип тау башына игътибарларын юнәлттем. Нәтиҗәдә, Тукай музее Тукай урамында үзенең ныклы урынын тапты.

Тагын балачакка әйләнеп кайтам әле. 1 яшь тә 2 айлык вакытта мине Буа районының Татар Буасы авылына кайтарып куйганнар. Ни өченме? Чөнки әти сугышта, фронтовик. Юрист булып эшләүче әниемне, адвокат буларак ниндидер төркемне әйбәтләп «яклаганы» өчен, шулар җөмләсеннән төрмәгә ябалар. Мин ятим бала хәлендә. Авылдагы Габделкадыйр бабам һәм Мәсруҗиһан әбием үзләренең канат астына сыендыралар.

Бабам турында, аның рухына атап, берничә сүз әйтеп узасы килә. Донбасс шахталарында күмер чыгара. Невск портында йөкче булып эшләгәндә Петроградтагы Кышкы сарайны штурмлауда катнаша. Аның биш улы да Ватан сугышына китә, икесе яу кырында ятып кала. Бабай—авылның сабантуй батыры. Үсә төшкәч, ул миңа татарча көрәш турында бик күп сөйли, киңәшләрен бирә иде.

Сугыш бетәрәк, март урталарында бабам белән авыл советына барганым хәтердә. Миңа биш яшьләр тирәсе. Бабамның кулына пичәтле «кара кәгазь» тоттырдылар. Шул чакта ул аның югалтыр дәрәҗәгә житте, аның күз яшьләре белән елаганын беренче тапкыр күрүем иде. Алдына тезләнеп, мин дә мышык-мышык елый башладым...

Әтиемнең вафаты тарихы исә болай булган. Фин сугышында катнашканнан соң ул Ватан сугышы кырларына килеп эләгә. Утлар-сулар, күпме үлемнәрне кичеп чыга алса да, 1945 елның 13 мартында, Кёнигсберг янындагы Трансау бәрелешендә (хәзерге Калининград өлкәсенең Мурманское бистәсе) һәлак була. Җиңүгә нибары ике ай чамасы калганда бит... Ул да—көрәшче, Сабантуйлар батыры булган. Мин аны бер тапкыр да күрмичә, ләкин гел сагынып-юксынып үстем. Шөкер, архивлар аша каберe кайдалыгын ачыклагач, 1984 елны Калининград өлкәсенә барып, аның каберенә улым белән туган якның бер уч туфрагын салып кайттык...

**—Сугыш алдыннан гына туган буын үскәндә ашау, тамак туюлар дан булмагандыр. Син заманында—классик көрәш батыры. Спортка, аерым алганда көрәшкә тартылуның сәбәпләре, хикмәте нәрсәдә булды икән?**

—1950 елга кадәр мин авылда яшәдем. Өченче сыйныфны тәмамлаганнан соң бабам: «Бөтен кешегә көтүче һөнәре димәгән, бар Казанга, әйбәт укысаң, кеше булырсың»,—диде. Әнием инде ул вакытта иреккә чыккан иде, бергә яши башладык.

Әйе, 1957 елны Баку шәһәрендә, классик көрәш буенча яшүсмерләрнең Бөтенсоюз чемпионатында икенче урынны яулаган идем. Казанның «Динамо»чылар клубы даның якладым. Әйткәнемчә, миңа хәер-фатиханы көрәшче бабам бирде. Әтием дә Сабан туйларында дан тоткан кеше. Табигать, язмыш мине шулай бүләкләгән: без бит көрәшчеләр затыннан. Каннан, нәселдән килә бу. Яшьтән үк «Динамо» спорт клубында шөгыльләндем. Остазыбыз—СССРның атказанган тренеры Николай Иванович Моряшичев иде.

Бакудан кайткач та минем янга микрофон тотып, радиодан журналист Мәгъсүм Гәрәев килде. «Көрәшчеләр арасында татарча белә торган син генә,—диде.—«Соңгы хәбәрләр» өчен сөйлә әле.» Сөйләдем. Шул чакта репортер һөнәренә кызыктым. Тугызынчы класста укыганда «Татарстан яшьләре»нә мәкаләләр яза башладым. Русча да әйбәт сукалыйм. «Народные виды спорта»—беренче олы хезмәтем. «Комсомолец Татарии» битләрендә 1959 елда басылып чыкты. Казанның педагогия иститутында укый башлагач, татарча көрәш тарихы белән мин инде нык лап кызыксына идем.

**—Бу җәһәттән «Татар барда Сабан туе бар» дигән фәнни-этнографик китабыңны энциклопедик басма дип икеләнми әйтергә мөмкин. Исемennән үк күренгәнчә, 480 битлек бу саллы китап татар халкының Сабан туена багышланган. Анда бай фактологик материал тупланган, бу олуг бәйрәмебезнең социаль-тарихи асылы ачылган, күп кенә**

**халыкларның йола һәм гореф-гадәтләре белән тарихи-чагыштырма анализ ясалган. Ул ак-каралы һәм төсле фотосурәтләр белән дә бизәлгән. Әлеге китапны мактаучылар да, тәнкыйтьләргә тырышучылар да булмый калмагандыр...**

—Син әйткәнчә, чыннан да, аны энциклопедик басма дип бәяләделәр. Безгә Сабан туен сакларга, аның географик чикләрен киңәйтергә, күркәм традицияләребезне башка халыкларга житкерә белергә, дуслык-туганлык бәйләнешләрен үстерергә кирәк. Шагыйребез әйтмешли, халыкара сабантуйга хәтле күтәрелү фарыз безгә. Сабан туе—татарның милли туплану, халыкара дуслыкны ныгыту мәйданы да ул. Хезмәтемдә Сабан туеның Болгарстанны төзегәнгә кадәрге кучмә чорларда ук барлыкка килүенә карата төпле дәлилләр китерергә тырыштым. Россия халыкларының милли спорт төрләре Федерациясе президиумы әгъзасы буларак, мин—көрәш, ат чабышлары, йөгерү, гер күтәрү, аркан тарту, кул көрәштерү, хәтта тауга каршы йөгерү, ат өсли чирәмдә хоккей уйнау (чайган) кебек спорт төрләрен камилләштерү, халыкара мәйданда таныту тарафдары булдым. Шушылар нигезенә таянып, Евроазия Сабантуй фестивале оештырырга да мөмкин. Мин бу тәкъдимнәрне югары оешмаларга тапшырдым да инде. Төрле сәбәпләр табып, арада каршы килүче спорт түрәләре дә юк түгел.




Сабантуйны пропагандалау, аны зур спорт мәйданына чыгаруга көчемне кызганмадым. Әйтик, «Ватаным Татарстан» газетасының М. Җәлил исемендәге призына татарча көрәшне оештыруда, башлап җибәрүдә катнашым зур булды (1965). Беренче ярышларга ук районнардан утызлап команда килгән иде. Бу популяр бәйге инде 45 ел үткәрелә килә. Әлеге спорт бәйрәмендә әдипләрдән Равил Фәйзуллин, Аяз Гыйлаҗев, Нурихан Фәттах, Мөдәррис Әгъләм, Эльс Гаделов, Рашат Низами һ. б. еш очрата идем. Милли көрәшкә мөкиббәнлек тартып китергән аларны бирегә.

Әмма барлык зыялыларыбыз да бу юнәлештә алып бара торган эшләребезне, эзләнүләребезне гел шулай хуплап килделәр дисәм, бу хакыйкатькә туры килеп бетмәс иде. Чөнки газета призына ярышларны да спортның милли төрләрен пропагандалауга багышланган хезмәтләрне дә «милли тайпылыш» кебегрәк нindидер уңай булмаган күренеш итеп күзаллаучылар да булмады түгел. Шуның аркасында минем «Яшь батыр», «Толымбай уңганнары» дип исемләнгән күләмле генә китапларым дөнья күрми калдылар, өлешчә-өлешчә газета битләрендә генә басылып чыктылар. Ә инде танылган чемпионнарыбыз, шул исәптән чит төбәкләрдә яшәгән батырларыбыз турында «Жир шары алкышлый» исемле китабым тупланма булып чыккач, язучыларның әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш секцияләренең берсендә, «интернационализмны һөнәргә әйләндереп» озак еллар дәвамында шушы төшемле эш белән шөгыльләнүче кайбер каләмдәшләр» мина «милләтче» ярлыгы тагуга кадәр үк барып життеләр. Шуның артыннан ук, ул елларда, гадәткә кергәнчә, партия өлкә комитетына әләк-шикаять юллаучы да табылды. Андый чакларда мин үземне остазларым өйрәткәнчә, «Көрәш дөньясына кереп киткәнсең икән, келәмдә генә түгел, тормышта да көрәшергә җиңәргә әзерлән «,—дип тотарга тырыштым.

**—Соңгы елларда «татар-башкорт көрәше» дигән сүзләр-билгеләмәне киң кулланылышка кертеп җибәрделәр. Миңа калса, бигүк дөрес түгел. Бу гыйбарәне куллану, бәлки, милли көрәшебезнең географик чикләрен киңәйтү ниятеннән эшләнгәндер. Башкортлар, тарихны бозып янсә ясалма юл белән, безнең мәдәни байлыкны «үзләштергән» чакта (М. Гафури, Ш. Бабичны әйткән дә юк, хәтта Тукайдан башкорт каны эзли башладылар...)—менә сиңа мә, дигәндәй, «башкорт»**

**сүзен үзебезнең милли көрәш мәйданы түренә кертеп җибәрдек.**

—Татарча көрәш, дибез... Мишәрләребез әнә аяк чалып үзләренчә көрәшә. Өченче төр дә бар әле—билбау (кушак) көрәше. Япониядә сумо көрәшенең күп төрләре бар. Урмандагы чәчәкләр санының күплеге берәүгә дә комачау итми бит. Көрәштә тегесе дә, монысы да булсын. Ләкин һәркайсына махсус әзерлек кирәк. Рәшит абый Азизов һәм Мәгазь Сәхәбетдинов белән берлектә без татарча көрәш кагыйдәләрен, аның методикасы турында кулланма дәреслек әзерләдек, басылып та чыкты ул.

Татар-башкорт көрәше билгеләмәсенә килсәк, син әйткәнчә, ясалмарак килеп чыкты ул. Бөтенроссия милли спорт төрләре федерациясе оешкач, аның рәисе Гайрәт Шәфигулла улы Әпсәләмов (Мәскәү), чыннан да, географик чикләрне киңәйтү өчен, «татар-башкорт көрәше» дигән термин куллануны кирәк дип тапты. Миңа куйган таләбе шул иде: әгәр бу терминнан баш тартасыз икән, батырларга Россия спорт мастеры дигән исем бирү мөмкин булмаячак. Әлеге дәрәҗәле исемне татар-башкорт көрәше аша гына үткәрә алачакбыз, диде. Ирексездән ризалаштык. Ләкин язган хезмәтләребездә без һәрвакытта да хезмәт бәйрәме һәм татарча көрәш турында сүз алып бардык.

**—«Гасырлар авазы—Эхо веков» журналының эшчәнлеге, тоткан мәсләге һ. б. турында аның баш мөхәррире сөйләвеннән ишетү дөресрәк булыр шикелле...**

—Октябрь революциясеннән соң 1925 елда чыга башлаган бу журналны яңарту, өр-яңадан нәшер итә башлау тарихы болайрак булды. Россиядә, шул исәптән безнең өлкә комитетында да зур үзгәрешләр бара, обком органы саналган «Коммунист Татарии» журналы бетүгә, ябылуга мәхкүм ителгән, аның татарчасы нибары дубляж, хәрефтән-хәрефне кабатлауга корылган иде. Менә шул чакларда—яшәп яткан обкомның «Татарстан» дигән теоретик журналы булдыру мәслихәте калкып чыкты. Журналист һәм тәҗрибәле архивчы буларак, мине баш редактор вазифасына «кодаладылар», синең белән бергә мине дә яңа оешкан реском члены итеп тә сайладылар. Ул елларда бер гаепсезгә репрессияләнгән әдипләрне, партработникларны, «халык дошманы» ярлыгын алган шәхесләрне реабилитацияләү дулкыны бик нык көчәйде. Чагыштырмача кыска бер арада, тарихчылар катнашы белән, ике телдә «Возвращенные имена» һәм «Хаклык аклаган исемнәр» дигән китаплар чыгардык, «Татарстан» журналының исә киң катлам җәмәгатьчелек өчен укылышлы, кызыклы булуын теләдек. Милли лидерыбыз М. Солтан-Галиев фаҗигасе, хәтта Мөхәммәт пәйгамбәр турында да берничә санга мәкаләләр бирдек. Ләкин дубляж һаман койрык булып «өстерәлеп» килә тора, ике телдәге мөстәкыйль журнал чыгарырга ирек бирмәделәр... Шул ачудан яңадан үз эшемә—архивка кайттым.

Мәсьәләне кат-кат күтәргәч кенә, ниһаять, яңа журнал чыгару уңай хәл ителде. Тарихи факт: 1995 елның маенда Казанда «Гасырлар авазы»—«Эхо веков» дигән тарихи-документаль журнал дөньяга чыкты, үзенең даими укучыларын тапты. Безнең төп максатыбыз—тарихыбызны архив материаллары нигезендә дөрес итеп яктырту, милли үзаңны үстерү, рухи-мәдәни казанышларыбызга янарыш рухы өстәү. Борынгы Казан, Казан Кремле, Болгар шәһәрләре, татар халкының традицияләре турындагы язмаларыбыз киң кайтаваз алды. Дагыстан, Калмыкия, Карагай-Черкессия, Удмуртия, Омск, Свердловск, Тверь өлкәләрендәге архивчы-коллегаларыбыз бергә хезмәттәшлек итү турында теләкләрен белдергән икән, бу инде үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Инде «Казан утлары» журналына килсәк, мин аны «Совет әдәбияты» заманыннан, 1960 еллар бирле үк һәр санын укып, карап барам. Аны халкыбызның төп журналы дип саныйм.

**—70 яшь... Ә менә яшьлегеңне, яшәгән гомереңне өр-яңадан кабатларга туры килсә, нинди хаталардан качарга тырышыр идең?**

—Минем шагыйрьлеккә дәгъва кылганым юк, ләкин сирәк булса да шигырьләр язгалыйм. Бу сорауга үземнең дүртюллык белән җавап бирәсем килә:

*Һәрчак дөрес яшәлдеме икән—*
*Кайчак дәрья, кайчак яр идем.*
*Әгәр яшьлек кире кайтыр булса,*
*Икеләтә кабатлар идем!*

**—Шагыйрьләрнең сиңа багышлап шигырь язганнарын беләм. Кайбер юлларын искә төшереп китә аласыңмы?**

—Бик теләп! Менә Роберт Әхмәтҗановтан:

*Йөрәгемдә бүген Олимп уты,*
*Читтә торсын*
*Токио һәм Инсбрукларың...*
(1968 ел).

Яки үзе дә архивчы, эзтабар булган Шаһинур Мостафиннан:

*Сез тарихны ничек күтәрсәгез,*
*Тарих Сезне шулай күтәргән...*
(2010 ел).

**—Бу дөньяда сине иң нык борчыганы нәрсә?**

—Җәмгыятьтәге гаделсезлек күренешләре. Бу исә илдә демократия җитәрлек булмаудан килә. Зур трибуналардан хаклык турында күп әйтелә, күп сөйләнә, әмма халык мәнфәгатьләрен бик еш кына онытып җибәрәләр. Төбәкләрдә дә, Россиянең үзендә дә халыкның иҗтимагый контролен көчәйтәсе иде.

**—Уйлаган ниятләрең, хыялларың барысы да чынга аштымы? Эшләнми калган эшләр дә юк түгелдер. Безнең эрага кадәр яшәгән грек философы Гераклит әнә бит нәрсә дигән: «Әгәр кешенең барлык теләкләре дә чынга ашса, яшәүнең кызыгы бетәр иде...»**

—Бу юлларны минем дә укыган, ишеткәнем бар. Туган авылым Татар Буасы турында документаль повесть бик тә язасым килә. «Татар халкының традицион культурасы» дигән күләмле хезмәтемне тәгәлләп бетерәсем бар. Тарих фәннәре докторы һәм профессор буларак, мин бит әле Казан дәүләт энергетика университетында студентларга дәрес тә бирәм. Нишләтәсең, вакыт җитми, ә бу мине шатландыра гына.

**—Сабан туеның географик чикләре елдан-ел киңәя бара. Болай булса, Япония һәм Америка кыйтгаларына барып җитүебез дә ерак түгелдер...**

—Алдарак син атап киткән китапның исеме үк әйтеп тора ич: «Татар барда Сабан туе бар». Шулай булгач, аның географик яктан киңәюе—татар бәйрәменең эчтәлеген баетуга гына түгел, безнең милли-мәдәни традицияләребезне башка милләт вәкилләренә дә җиткерүгә, халыклар арасындагы дуслыкны үстерүгә дә хезмәт итәргә тиеш.

**—Билгеле булганча, 2013 елны Казанда Универсиада ((дөньякүләм) уздырылачак. Анда татарча көрәш тә булачакмы?**

—Булачак. Бу хакта югары дәрәҗәдәге сөйләшүләр бара.

**—Язган хезмәтләрең турында нинди бәяләмәләр бар?**

—Алар күп. Урын алмас өчен берсенә генә тукталып китәсем килә. «Исторические корни и развитие традиционный культуры татарского народа XIX—начало XXI веков» дигән китабым белән танышкач, безнең Казан педагогия институтында аспирантура тәмамлаган, хәзер инде Россия күләмендә танылган чуваш галиме Геннадий Николаевич Волков миңа тәфсилле һәм бик эмоциональ хат язган иде.

Анда мондый юллар да бар: «Бөек китабың белән котлыйм сине! Башыннан ахырына кадәр укып чыктым. Хезмәтең миндә олы соклану тудырды, зур эш эшләгәнсең. Рәхмәт, чувашлар турында син аларның үзләреннән дә югарырак фикер йөртәсең. «Демократик» 10 ел эчендә чувашларның яртысы диярлек туган тамырларын алмаштырдылар, бу—бетүгә бару дигән сүз. Татарларга мин бик рәхмәтле: үзләренең үрнәге белән алар милли йөземне саклап калуда зур йогынты ясадылар...»

Шөкер, борынгы Сабан туебызның яшьлеге дәвам итә! Моңа һәрбер татар шатланырга, горурланырга тиеш.

*Әңгәмәдәш*—***Рашат НИЗАМИ***
*Август, 2010 ел.*

**Автордан өстәмә.** Дамир абый Шәрәфетдиновны, судья яки жюри әгъзасы буларак, Татарстан һәм Россия күләмендәге татарча көрәш ярышларында, төрле бәйрәм тантаналарында, эш урыннарыбыз янәшә булганлыктан хәтта «Идел-Пресс» каршындагы бакчада да еш күргәли идем. Беркайчан эшләгән эшләре белән масаеп-мактанып сөйләшмәс, гаҗәеп тыйнак шәхес. Шуны аңладым: күз тимәсен, аңарда өч кешелек энергия кайнап тора, чынлыкта ул «каторжан» хезмәтен башкаручы эш аты икән...

**Редакциядән.**
***Дамир Шәрәфетдиновны «Казан утлары» журналының күпсанлы укучылары исеменнән 70 яшьлек юбилее белән котлыйбыз, киләчәктә аңа яңа иҗат уңышлары, ныклы сәламәтлек теләп калабыз.***

---

## КИЛӘСЕ САНДА УКЫГЫЗ

Журналыбызның 11 санында бик күп кызыклы әсәрләр, язмалар тупланган.

Проза бүлегендә күләмле әсәрләрдән **Зәки Зәйнуллин**ның «Лотфулла солдат», **Дамир Гыйсметдин**нең «Божра» бәяннары урын алган, шулай ук «Сатирик әсәрләр конкурсы» да дәвам итә.

Шигърият сөючеләрне **Айдар Хәлим, Нәҗибә Сафина**ның яңа шигырьләре көтә.

**Дамир Исхаков**ның татарның этник тарихы, халыкны исәпкә алу һәм сәясәт турындагы «Татар юлы такыр түгел» исемле саллы мәкаләсенең дәвамын, **Илшат Вәлиулла** һәм **Локман Закир** язмаларын, Тәлгать Насыйровның татар матбугаты турындагы тәфсилле мәкаләсен дә киләсе санда укый аласыз.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Мамадыш

Әгәр Мамадыш шәһәре янындагы Пузан тавы өстенә менеп карасаң, искиткеч матур манзара ачыла. Шәһәргә терәлеп диярлек Нократ суы ага. Яшеллеккә күмелгән Мамадышны ак каеннар бизи. Бу шәһәрне курортка тиңләп булыр иде.

Нократ елгасы моннан 2 гасыр ярым элек Казан һәм Вятка губерналарының чиген билгеләгән. Аның уң ягы—Казан, сул ягы Вятка губернасына караган. Бу елганың Камага койган урыныннан егерме чакрымнар тирәсе өстәрәк, Ушмы инеше тамагына Казан губернасының өяз каласы—Мамадыш урнашкан. Ул Нократ елгасында беренче зур пристань булган.

1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә күрсәтелгәнчә, Ушмы һәм Вятка суы ярларына утырган өяз шәһәре Мамадышның 569 хуҗалыгында 1783 ир-ат һәм 1836 хатын-кыз көн иткән. Анда 2 чиркәү, 4 часовня, өяз һәм мәхәллә училищесе, хастаханә, пристань булган. Кечеатна көнне базар үткәрелгән. Ярминкә эшләгән. Шәһәрдә 2 кирпеч, 1 путаш, 2 канат, 2 ярма яргыч, 3 күн, 2 терлек мае эретү заводлары булган.

Олылар сөйләвенә караганда, Болгар дәүләте җимерелгәннән соң, XIV гасырда берничә гаилә бирегә, Нократ (Вятка) суы буена күчеп килгән.

Мөшһид Иван Казанны басып алгач, татарларга зур елгалар тирәсендә яшәү тыелган. XVII гасырда Мамадышка урыслар килеп чиркәү салганнар һәм ул Троицкий авылы дип йөртелә башлаган, ләкин Мамадыш исеме дә сакланып калган. Руслар килгәч, Мамадыш-Троицкий Зөядәге Богородицкий монастырена буйсындырылган. Монастырь 1617 елда яна биләмәсендә приказчикларын һәм андагы төрле запасларын нугайлар һөҗүменнән саклау өчен Мамадышны койма белән әйләндереп алган. 1711 елда, Екатерина II җирләргә генераль ызанлау үткәргәндә, шәһәрнең иске исеме яңадан кайтарыла. Шул ук елны Мамадыш Казан административ-территориаль берәмлегендә өяз шәһәре итеп расланган һәм аның гербы булдырылган. Ул гербның өске өлешендә канатлы аждаһа сурәте, аскы өлешендә яшел җирлектә ике көмеш урак һәм алар уртасында алтын көлтә гәүдәләнгән. Алтын көлтә бу төбәктә арышның мул уңыш биргәнлеген аңлаткан.

Мамадыш өязенә хәзерге Саба, Кукмара, Мамадыш районнары кергән. Бу өязгә караган 16 волостьта 2433 кеше тегүчелек белән шөгыльләнә, 12 волостьта 881 кеше киез итек басучылар, киез эшләпә, тула оек басучылар була.

1774 елның июлендә Мамадыш крестьяннары Емельян Пугачевны алкышлап каршы ала. Пычак авылы кешесе Мәсәгут Гомәров өяздән 2000нән артык гаскәр җыеп, Пугачев гаскәрләре сафына кушыла.

Өяздә аз-маз гына промышленность предприятиеләре дә булган. 1883 елда

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Мамадышта Щербаков фамилияле сәүдәгәр спирт заводына нигез сала. Гражданнар сугышы башлангач, ул Парижга качып китә һәм шунда яши. Бу вакытта спирт заводы туктап тора. Мона кадәр крестьяннардан спирт ясау өчен олау-олау бәрәнге ала торган булганнар. 1931 елда спирт заводы янадан эшли башлый.

1897 елда җан исәбе алганда Мамадышта 4200 кеше яшәве теркәлгән, анда 2 чиркәү, өч башлангыч училище, шәһәр җәмәгатьчелеге китапханәсе, суднолар хәрәкәте конторасы һәм шәхси типография булган. 1900 елда шәһәр хуҗалыгының кереме 12 мең сумны тәшкил иткән. Щербаковның аракы заводы 50 эшче тотып, ел саен 130 мең сумлык спирт җитештергән.

Мамадыштан дүрт чакрым читтә Изге чокыр дип аталган урын бар. Анда май аеның икенче яртысында Мамадыш һәм Алабуга өязләрендә яшәүче кешеләр гыйбадәткә килгәннәр.

Мамадыш өязендә элек берничә урында бакыр эретү заводы (Нырты, Иске Оча, Кукмара авылларында) булган. Анда бары тик читтән китерелгән кешеләр генә эшләгән. Ләкин ул заводлар руда кытлыгы аркасында ябылганнар.

Кышкы сарайны штурмлый башларга сигнал биргән легендар «Аврора» крейсеры матросларының өчесе Вятка буе егетләре—Андрей Ведерников, Александр Бичурин—Отарка авылыннан, Иван Александров—Пойкинодан. Албай егете С.В.Дымолазов гражданнар сугышы тарихына «Албай Чапае» дигән исем белән кереп кала.

1918 елның 20 мартында мөселман комиссариаты төзелә. Ул Мамадыш өязе советы башкарма комитеты каршында оеша. Башта Гаяз Байкиев, аннары Басыйр Тажетдинов комиссар булып эшлиләр. Өяз тарихында беренче тапкыр татар телендә «Мамадыш тавышы» исемле газета чыгарыла башлый.

Мамадышлылар Ватан сугышында да зур батырлыклар күрсәтәләр. Район халкы арасыннан 4 герой чыга.

Ватан сугышына Мамадыш районыннан барысы 13 мең кеше киткән. Шуларның 7 меңе орден-медаль белән бүләкләнгән. Районда туып-үскән 4 геройның рәсеме район үзәгенең Мактау тактасына куелган.

Мамадышның Пузан тавы башындагы һәйкәл Совет власте урнаштыручылар истәлегенә булса, шәһәрнең үзәгендәге һәйкәл Ватан сугышыннан әйләнеп кайтмаган мамадышлылар хөрмәтенә күтәрелгән.

1919 елның апреленә өяздәге һәр авылда мәктәпләр ачыла. Татар авылларында мәктәпләр саны 215кә тула.

Өяздә күбрәк татарлар яшәгән. Алар барлык халыкның 55 процентын тәшкил иткәннәр.

Мамадыш районыннан түбәндәге күренекле шәхесләр чыккан: язучы Шәйхи Маннур, композиторлар Фәрит, Заһидулла һәм Мирсәет Яруллиннар, язучы Ринат Мөхәммәдиев, Басыйр Рәфыйков, Рафаэль Газизов, җырчылар Мингол Галиев, Георгий Ибушев һ.б.

Мамадыш—Казаннан 172 чакрымда урнашкан район үзәге. Ул Чаллы-Казан трассасы буенда гына урнашкан. Мамадышта мамык-җеп тукымалар комбинаты һәм «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсе филиалы, спирт, сыр ясау заводлары бар.

Хәзер анда 15 меңгә якын кеше яши. Шәһәрдә өч урта мәктәп, клублар, китапханәләр, кинотеатрлар бар.

## Әйшияз (Әшиасты)

Әйшияз (Әшиасты) авылы Әтнә районына керә, ул район үзәге Олы Әтнә авылыннан 11 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Күәм авылыннан—5, тимер юл станциясе Коркачыктан—41, Казан шәһәреннән 82 чакрым ераклыкта урнашкан. Әйшияз атамасы тарихи-статистик белешмәләрдә, халык авыз иҗаты әсәрләрендә һ.б. чыганакларда искә алына.

Бу авыл Казан ханлыгы чорында да булган. Әйшияз авылы янындагы «Хан зираты» дип йөртелгән зиратны тикшергәннән соң археологлар анда якынча XVI йөзгә мөнәсәбәтле, ләкин язусыз өч кабер ташы табалар. Д. А. Корсаков тарафыннан бастырып чыгарылган тарихи белешмәдән күренгәнчә, Үртәм суы ярына утырган

Әйшияз авылы Якшияс дип бирелгән һәм анда 63 йомышлы татар яшәгәнлеге әйтелгән.

1859 елда авылдагы 47 хуҗалыкта 177 ир-ат һәм 191 хатын-кыз көн иткән. Бер мәчет эшләгән. Әйшияз халкы күршедәге Күәм, Үртәм, Казак Үртәме, Күлле Киме, Җилгелде, Бактачы, Каенсар авыллары белән бергә июнь аеның беренче декадасында Калатау җыенын бәйрәм иткән.

Авыл түбәнлеккә урнашкан. Авылдан ерак түгел бормаланып Ашыт елгасы ага. Риваятьләргә караганда, авылның тарихы әнә шул елга белән бәйле. Моннан күп еллар элек бу якларга килеп чыккан кешеләр Ашыт суы буена шәһәр төземәкче булганнар. Алар ярыйсы гына зур бер авыл салганнар һәм аны Әйше дип атаганнар. Әйшедә яшәүчеләр иген иккән, мал-туар асраганнар.

Бу урыннар шәһәр төзү өчен бик унайлы булмаган. Җирләре дә артык уңдырышлы түгел, Ашыт суы да зур көймәләр йөзәрлек тирән булмаган. Шуңа да кешеләрнең бер өлеше башка урыннарга күчеп киткән, күчәсе килмәгәннәре Әшиасты авылына нигез салган. Авыл элегрәк нигезләнгән Әйше авылыннан түбәндәрәк урнашкан булганга, аны Әйше асты дип атаганнар. Вакытлар уза торган һәм бу авылны Әйшияз, ә кайберәүләр әле дә Әйшиасты (Әйшеасты) дип йөртә. Әйшеләрнең зиратын «Изгеләр зираты», ә андагы чишмәне «Изгеләр чишмәсе» дип атыйлар. 1995 елда Изгеләр зиратын койма белән әйләндереп алганнар һәм ян-якларын чистартканнар.

Кала төземичә ташлап киткән таулыкларны, Ашыт буйларын Кала тавы асты дип атыйлар. Бу урында куе урман кебек агачлар үсә.

Әшиасты авылы Үртәм суы буена утырган. Ул Ашытка уң яктан килеп кушыла, ә Үртәм суына Әшиасты инеше коя. Каенсар авылыннан килеп чыккан Инеш яисә Каенсар суы да Үртәм елгасына төшә. Каенсар дип ул янында каен агачлары үскәнгә аталган, әлбәттә.

Авылның бер ягында Ишми базар өсте дип аталган урын бар. Элекке вакытларда бу җирдә өч-дүрт хуҗалык булып марилар яшәгән дип сөйлиләр.

Баязит тавы. Авыл янындагы таулырак чокырлы урынны Баязит тавы дип атыйлар. Бу урын елга буена урнашкан. Элек монда Баязит исемле яхшы күнелле бер бай кешенең тегермәне булган. Аның хөрмәтенә бу урынны Баязит тавы дип атаганнар.

Авылның «курыпса», «чабата» исемле кушаматы бар. Элек авыл халкы чабатаны бик матур итеп ясаган. Чабата ясауны Нәҗметдин исемле абзый уйлап чыгарган. Авыл халкы чабатаны Кече Әтнә авылына барып сата торган булган. Әйшиязнын чабата турында җыры да бар:

*Әйшиасты чабатасы*
*Аякка җайлы ята,*
*Иртә белән киеп чыксаң*
*Кич белән чәчәк ата.*

Чабата ясау өчен юкә ташыганнар. Шуннан «курыпса» дигән сүз барлыкка килгән. Ул «юкә кайрысы» дигән мәгънәдә.

Авылның нәкъ уртасында мәчет балкып утыра. Авыл халкы әби-бабалар күмелгән зиратны хөрмәтли, күз карасыдай кадерле, тәртиптә тота. Барлык каберләргә дә чардуган тотылган, таш куелган, зират койма белән әйләндереп алынган.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# К

**КУДАШ** (Кудашев) Сәйфи (Сәйфетдин) Фәттах улы (3.10.1894, Уфа өязе Кара Якуп вол. (хәзерге Башкортстан Респ.-сы Чишмә р-ны) Келәш ав.—26.6.1993, Уфа шәһ.), шагыйрь, Башкортстан АССРның халык шагыйре (1964), РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1984). «Галия» мәдрәсәсен тәмамлагач (1918) Уфа губернасы Красная Горка авылында (1918-19), Омск шәһ.-нең №2 ирләр урта мәктәбендә (1919-20) татар телен һәм әдәбиятын укыта, бер үк вакытта «Азат Себер» газетасында хезмәттәшлек итә. 1925 елдан Уфа шәһ. яши. «Башкортстан» газетасында (1925-33), «Октябрь» ж-лында (1931-33) эшли. 1935 тән Башкортстан АССР Язучылар берлегендә (1943-48 дә идарә рәисе). К.ның 1914 елда «Тормыш» газетасында (Уфа) һәм «Кармак» ж-лында (Оренбург шәһ.) басылып чыккан беренче шигырьләре идея-тематик юнәлеше һәм сатирик алымнары б-н Г.Тукай әсәрләренә охшаш. Анын яшьрәк чор иҗатына җәмгыять төзелешеннән риза булмау, самодержавие изүенә каршы протест, җәберләнгән халык, хатын-кызның хокуксызлыгы өчен әрнү кебек мотивлар б-н беррәттән, өметле киләчәккә ышану чалымнары да хас. 1917 елда аның татар телендә басылган ике шигырь җыентыгы дөнья күрә: «Ак билетлар бәете» һәм «Азатлык җырлары» дип аталган бу җыентыкларда шагыйрь ул чор өчен мөһим булган тынычлык, җиргә һәм иреккә хокук, татар халкының суверенлыгы кебек мәсьәләләрне күтәреп чыга, тарихи үткәнгә мөрәҗәгать итеп татарларның кайчандыр үз дәүләтләре булганга басым ясый («Татар теләге», 1918). Гражданнар сугышы чоры шигырьләреннән К.ның бу үзгәрешләрне кабул иткәнлеге күренә: шагыйрь яна эпоханың бөеклегенә, ирекле иҗади хезмәткә, эшче һәм крестьяннар дуслыгына дан җырлый («Сабан җырлары», Уфа, 1926; «Утауда», 1927; «Көрәш батыры», Уфа, 1928 җыентыклары). 1930 еллар башыннан К. башкорт телендә иҗат итә. «Бәхет законы» (Уфа, 1937), «Республика йырлай» (Уфа, 1940) шигырь җыентыклары, «Икенсе йәшлек» (Уфа, 1934), «Хәмизәнең шатлыгы» (Уфа, 1936) хикәя җыентыклары, «Атаклы кешеләр» (Уфа, 1935) очерклар сериясе, «Кушкаен» шигъри романы һ.б.ларнын төп темалары—туган республикасының соц. төзелештәге уңышлары, замандашларының үрнәк образлары. Шулай ук К. заман чынбарлыгын җанландыруны да үз күрә («Алтын аскыс», Уфа, 1939; «Кауышыу», Уфа, 1939 поэмалары). Бөек Ватан сугышы еллары иҗатының геройлары фашист илбасарларына каршы көрәшүче фидакарь сугышчылар («Сакырыу», Уфа, 1942; «Бөтә йөрәктән», Уфа, 1943 шигырь җыентыклары; «Башкорт атлылары», Уфа, 1943 очерклар җыентыгы). Сугыштан соңгы шигырь һәм поэмалары тормыш мәгънәсе, замандашлары язмышы турында фәлсәфи уйланулар белән тулы («Минең мөхәббәтем», Уфа, 1956; «Япрактар койолганда», Уфа, 1960; «Минең баксамда», Уфа, 1964; «Тау юлында», Уфа, 1972; «Һөйөү һүззәре», Уфа, 1981). К. шулай ук сатирик шигырьләр һәм мәсәлләр, проза әсәрләре дә иҗат итә. «Яззы каршылаганда» (Уфа, 1954) исемле тарихи-биографик повестында 1912 елның язында Г.Тукайның Уфага килеп М.Гафури б-н очрашуга бәйле вакыйгалар яктыртыла. «Хәтерзә калган минуттар» (Уфа, 1958), «Йәшлек эззәре буйлап» (Уфа, 1964), «Бабич менән осрашканда» (Уфа, 1964) дигән истәлекләр китапларында К. 1910-30 елларда Башкортстанның, Татарстанның һәм Казакъстанның күренекле әдәбият әһелләре б-н шәхси очрашып сөйләшүдән алган тәэсирләре белән уртаклаша. К.ның балалар өчен язылган китаплары да бар: «Боярзар бар сакта» (Уфа, 1928); «Әзер бул!» (Уфа, 1935); »Урман әкияте» (Уфа, 1937); «Бәхетле балалык» (Уфа, 1940). Ул хәзерге әдәбиятка, әдәби иҗатның теоретик һәм практик мәсьәләләренә караган публицистик мәкаләләр б-н дә чыгыш ясады. Аның күп кенә әсәрләре рус, татар, үзбәк, украин, таджик, казах һ.б. телләргә тәрҗемә ителде. Башкортстан АССРның Салават Юлаев исем. респ. премиясе лауреаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт Билгесе», Халыклар дуслыгы орденнары белән бүләкләнгән.

Әсәр.: Сайланма шигырьләр. Уфа,

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынан басылып килә.*

1940; Шигырьләр һәм поэмалар. К., 1941; Хәтердә калган минутлар. К., 1959; Яшьлек эзләре буйлап. К., 1964; Әсәрзәр: 4 томда. Өфө, 1946-53; Һайланма әсәрзәр: 3 томда. Өфө, 1965-67; Шигырзар. Өфө, 1974; Избранные произведения: в 2 т. Уфа, 1970; Стихи и поэмы. Уфа, 1984.

Әд.: Кудашев А. жизненный путь поэта. Уфа, 1943; Кудашева С., Кузеев Р. Жизнь длиною в один век: Воспоминания. Уфа, 1998; Хөсәйенов Г. Сәйфи Кудаш ижады. Өфө, 1959; Сәйфи Кудаш ижады: Мәкәләләр йыйынтыгы. Өфө, 1986.

*Ф.Ибраһимова.*

**КУПАЛА** Янка (псевд., чын фам. һәм исеме Луцевич Иван Доминикович) (25.6.1882, хәзерге Белоруссия Респ. Минск өлкәсе Молодеченск р-ны, Вязынка а.—28.6.1942, Москва), Белоруссия ССРнын халык шагыйре (1925), Белоруссия ФАнен (1928) һәм Украина ФАнең (1929) хакыйкый әгъзасы. «Жалейка» (1908), «Тормыш юлыннан» («Дорогой жизни», 1913), «Мирас» («Наследство», 1922), «Йөрәктән» («От сердца», 1940) шигъри жыентыклар, «Курган» (1910), «Оресса елгасында» («Над рекой Орессой», 1933) һ.б. поэмалар, «Таланган оя» («Разорённое гнездо», 1913), «Мондагылар» («Здешние», 1924) пьесалар авторы. 1941 нең октябреннән 1942 нең июненә кадәр Печищи авылында эвакуациядә була. Биредә ул «Сугыштагы малай һәм лётчик» («Мальчик и лётчик на войне»), «Тормыш янә ирекле һәм бәхетле булыр» («Жизнь снова станет вольной и счастливой») шигырьләрен, «Тугыз усак казыгы» («Девять осиновых кольев») поэмасын яза. Радиода, 1942 нең мартында Казанда узган Белоруссия ССР ФАнең сессиясендә чыгышлар ясый. 1975 тә Печищеда Купала Янка музей-квартирасы ачыла.

Әсәр.: Сочинения: В 3 т. М., 1982.

Әд.: Берюзкин Г.С. Мир Купалы. М., 1973; Нури З. Янка Купала һәм анын ижади варислары // Казан утлары. 1972. № 7.

**КУТУЙ** (Кутуев) Гадел (Гаделша) Нурмөхәммәт улы (28.11.1903, хәзерге Саратов өлкәсе, Кузнецк р-ны Татар Кынадысы а.—15.6.1945, Польша, Згеш ш.,), язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Башта авылы мәдрәсәсендә, 1912 дән—Саратов губ. Алексеевск а. рус мәктәбендә, соныннан Самара ш. рус-татар мәктәбендә укый. Шул вакытта ук рус әдәбиятына тартыла башлый: А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, М.Горький, В.В.Маяковский һ.б. әсәрләрен укый. 1920 дә Казанга килә. 1922 гә кадәр Казан политехнол. ин-тында укый, аннары 6 нчы Берләштерелгән татар-башкорт (хәрби) команда мәктәбендә (бүген Казан югары танк командирлары уч-шесы). Көнчыгыш пед. ин—тын тәмамлаганнан соң (1929), мәктәптә, Казан авиация техникумында (1932-41), Казан коммуналь төзелеш инженерлары интында (бүген Казан архитектура—төзелеш ун-ты) рус теле һәм әдәбиятын укыта. 1920 нче елларда хикәяләр, пьесалар яза, республика вакытлы матбугат чараларында күпсанлы фельетоннар, очерклар, мәкаләләр, ш.у. Татар академия театрының һәр спектакленә диярлек рецензияләр бастыра. 1922 дә «Безнен юл» ж-лында анын беренче шигырьләре дөнья күрә. К. шигъри форма өлкәсендә тәҗрибәләр б-н шөгыльләнә, конструктивизм рухындагы композиция ысулларына, революцион-романтик образларга мөрәҗәгать итә. Анын тәүге ижади эзләнүләрендә беренче «Көннәр йөгергәндә» (1925) исемле шигъри жыентыгында чагылыш тапкан футуризм йогынтысы сизелә. Бу жыентык ул еллар поэзиясендә билгеле бер күренеш була. К. шигырьләренен темалары арасында халыклар дуслыгы, җәмгыятьтә рев-цион үзгәрешләр, социаль гаделлек өчен көрәш; алар иске тормышны инкяр итү рухы б-н сугарылган: «Егерменче броневик», «Октябрьдә», «Тимер чәчәкләрдән», «Биш минутка дөнья туктады», «Эшче шагыйрь», «Атла, дингез». Шагыйрь, метафорага нигезләнеп, кинаяле, фантастик, ләкин психологик яктан реаль булган, күренеш тудыра. К.нын лирик герое бөтен дөнья, бөтен табигать өчен җаваплылыкны үз өстенә ала (мондый «Ходай кешесе» татар әдәбиятында идеологик схемачылыкнан чыгунын бер варианты булды). Коммунистик идея б-н сугарылса да, анын поэзиясе көчле эмоциональлек б-н аерылып тора. 1930 нчы еллар К. өчен ижади яктан күтәрелеш чоры. Ул яна кеше һәм яна соц. әхлакнын формалашуын катлаулы процесс икәнен күрсәтергә тырыша. «Фәрзәнә» (1927-28), «Солтаннын бер көне» (1938), «Вөждан газабы» (1939), «Нишләргә?» (1940) хикәяләренен, «Балдызкай» (1926), «Күк күтәрчен» (1929), «Җавап» (1929) пьесаларынын, «Сәлимә» (1927) поэмасынын геройлары—автор идеалы югарылыгына күтәрелгән, сәләтле, гайрәтле яшь кешеләр. Аларнын эшләре һәм хыяллары К.да якты киләчәккә ышаныч б-н карарга өмет бирә. Язучы иҗатының иң югары ноктасы—«Тапшырылмаган хатлар» (1935, рус теленә тәржемә 1954) һәм «Рөстәм мажаралары» (1944) повестьлары. «Рөстәм мажаралары»нда яшүсмер күзлегеннән чыгып Бөек Ватан сугышы елларында халык кичергән фажига тасвирлана. «Тапшырылмаган

хатлар» повестының асылын татар хатын кызы язмышы тәшкил итә. Авторны әхлак мәсьәләләре, кешенең рухи дөньясы борчый. Яшь ир б-н хатын арасында барлыкка килгән конфликт гаиләдә хатын-кыз роленә карата булган искергән патриархаль һәм яна карашлар бәрелешен чагылдыра. Повесть героинясы Галия— йомшак, мөлаем, берүк вакытта көчле ихтыярлы хатын. Ире ташлаганнан соң да, ул төшенкелеккә бирелми, врач булу максатына ныклы адым б-н бара, балаларын үстерә, кешеләр хөрмәтен яулый, чын мәхәббәтен таба. Повесть тиз арада киң популярлык казана, рус, башкорт, казах, каракалпак, кыргыз, мари, тува, үзбәк, хакас, чуаш, албан, корея, кытай, монгол, чех телләренә тәрҗемә ителә. Әсәргә Ж.Фәйзи тарафыннан музыка һәм либретто языла һәм 1960 та Татар опера һәм балет театрында шул исемдә опера, 1961 дә Татар күчмә театрында пьеса (авторы Г.Минский) куела.

Бөек Ватан сугышы елларында К. «Кызыл сугышчы», «Ватанны саклауда», «Тревога», «Алга, дошман өстенә» фронт газеталарының хәбәрчесе була, аларда, сугышта күргәннәрен чагылдырып, үзенең очерк сериясен, хикәяләрен, шигырьләрен бастыра. Аның сугыш еллары герое—батыр кеше, үзен-үзе аямыйча көрәшә торган сугышчы: «Без—сталинградчылар», «Хәнҗәр». «Сагыну» нәсерендә туган ягын сагынучы солдат образы тудырылган. Сугыш еллары әсәрләренә гражданлык пафосы, җиңүгә ышаныч хисе хас.

Хәрби госпитальда вафат була. Кызыл Йолдыз, 1 нче дәрәҗәле Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Публицистика. К., 1957; Сайланма әсәрләр. К., 1965.

Әд.: Усманова З. Адель Кутуй: Жизнь и творчество. К., 1966; Нуруллина Р. Һәрвакыт сафта: (Гадел Кутуйның публицистик эшчәнлеге). К., 1966.

*Н.М.Йосыпова.*

**КУТУЙ** (Кутуев) Рөстәм Гадельша улы (11.10.1936—7.1.2010, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Г.Кутуй улы. Рус телендә яза. 1960 та Казан ун-тын тәмамлый. 1960-61 дә Татарстан китап нәшрияте, 1961-63 тә Казан телевидение студиясенең әдәби тапшырулар мөхәррире. 1994 тән «Казан» ж-лы редколлегия әгъзасы. Беренче шигырь һәм хикәяләре «Ленинец», «Комсомолец Татарии» газеталарында, күмәк җыентыкларда басыла. Инде беренче әсәрләрендә үк: «Малайлар» («Мальчишки», 1961), «Яңгыр явачак» («Дождь будет», 1963) хикәя һәм повестьләр, «Мин җирдән барам» («Я иду по земле», 1962) шигъри җыентыкларда язучының төп тематикасы һәм кызыксыну даирәләре күренә башлый: сугыш чоры балачагы, сугыштан соңгы яшьлек еллары, тол хатыннар һәм ятим балалар язмышы. К. кабахәтлекне, түбәнлекне, хыянәтне инкярь итә: «Мин Кар бабай ясыйм» («Я леплю снежную бабу», М., 1966), «Учымдагы кояш» («Солнце на ладони», М., 1973), «Бер көз» («Одна осень», М., 1985), «Көләм, буылам һәм елыйм» («Смеюсь, задыхаюсь и плачу», 1996). Аның геройлары батыр, дуслыкка тугры кешеләр. К.ның шигырьләрендә: «Өмет учаклары» («Костры надежды», 1965), «Яшь ай туганда» («Новолуние», 1971), «Җир яфрагы» («Лист земли», М., 1980), «Язгы җыр» («Песня весенняя», 1993) кояш, һава, музыка өстенлек итә; алар нәфис, оптимизм б-н сугарылган. К.—балалар өчен язылган шигъри җыентыклар авторы: «Алтын болан» («Золотой олень», 1979), «Иләктәге могҗиза» («Чудеса в решете», 1989) h.б. Аның әсәрләре кыргыз, литва, польша, испан h.б. телләргә тәрҗемә ителде. Үзе Г.Тукай, Г.Кутуй, Ә.Еники, С.Хәким, Ә.Давыдов, Р.Фәйзуллин h.б. әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итте.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970; Паушкин Г. Зрелость таланта // Казанские ведомости. 1996. 11 ноябрь.

*В.С.Мостафин.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ТАТАР ЯДКАРЕ

Татар авылларындагы капкаларны кояш сурәте белән матурлау борынгыдан килә торган гадәт. Әйтерсең лә көндез балкыган кояш, көн сүрелсә дә, тирә-юньгә нур таратып, ямь өстәп тора!

Сәнгать белгечләре аны «соляр билге» дип атый (французча «solej»—«кояш») һәм ул Идел буенда яшәүче халыкларның декоратив-гамәли сәнгатендә тотрыклы рәвештә кулланып–муллык, иминлекне ишарәләүче символ булып санала. Татарларда да ул–гадәти билге.

Шундый орнамент белән, мәсәлән, торак йортларны, кием-салымны, монументаль архитектура корылмаларын бизиләр. Келәмне бизәгәндә, мәсәлән, борынгы төрки бабаларыбыз бәхетле, мул тормыш, сәламәт нәсел калдыру өметләрен, хыялларын чагылдырган, төрле чир-зәхмәттән саклый торган билгеләр төшерергә омтылганнар.

Төрки халыкларның телләре, милли бизәк ясау, орнамент төшерү дә, нигездә, охшаш–ул берүк ритмга, симметрик бизәкләргә, геометрик фигураларга, дулкынсыман композицияләргә корылган. Һәрбер бизәкнең нигезендә ниндидер символ бар һәм аның мәгънәсен ачыклау өчен аны «сүтеп җыярга» мөмкин. Гомумән алганда, орнаментта галәмнең чиксезлеге: җәйрәп яткан далалар, үткәннәрнең шанлы вакыйгалары, ерак бабаларыбызның дан-шөһрәте, төрки халыкларның борынгы шигърияте, көй-моңнарының затлылыгы, күнелгә ятышлы аһәңе сизелә...

Орнамент тирән мәгънәле фикерне дә, халыкның ихтыяр көчен дә, хис-тойгыларның нечкәлеклеген дә үзенә сыйдырган, туплаган... Орнамент–уңдырышлы, бәрәкәтле туфрак сыман. Ул тормышның һәрдаим янарып, яшәреп торуын, мәхәббәт һәм сафлыкны чагылдыра. Шуңа да байтак чорлардан бирле символларны шартлы рәвештә белдерүче булып хезмәт итә, милли эмблемаларны күрсәтә торган халыкчан форма булып санала. Орнамент сәнгатенә таянып олы бер тармак–геральдика барлыкка килә. Милли орнамент төрледән-төрле гербларда һәм байракларны бизәүдә файдаланыла. Әлбәттә, ул бүгенге көндә төрле илләрнең милли үзенчәлекләрен чагылдыручы дәүләт символларын бизәүдә дә кулланыла.

Орнаментны безнең бабаларыбыз болгарлар да киң файдаланган. Алар торак йортларны, сарайларны, мәчетләрне, көнкүреш әйберләрен–савыт-саба, бала уенчыкларын орнамент белән бизәгәннәр. Идел буе Болгарстаны шәһәр-калалары урынында уздырылган археологик эзләнүләр алып барганда имәннән кырып ясалган савытлар табылган. Шул савытларның кырыйлары нәфис орнамент, гарәп язулары белән бизәлүен чамаларга мөмкин. Мәгълүм ки, агачтан ясалган әйберләрнең гомере әлләни озак түгел. Алар чорлар алышынуы, һава торышы йогынтысы аркасында төрле бактерияләр һәм кортлардан да зур зыян күрә. Әмма шуңа да карамастан, шул борынгы заманнан бирле, бәхетебезгә күрә, агач кашык сакланып калган. Шунысы кызык, әлеге кашыкның сабы эллипс рәвешендә савытына без гәдәтләнгәнчә уңайга түгел, ә бәлки аркылы урнашкан. Бактың исә, болай да була икән! Чыннан да, җайлырак лабаса!

Агачтан кырып ясалган, борынгы чорлардан бүгенге көнгә кадәр сакланган бизәкле әйберләрне фәнни нигездә өйрәнүне шушы эшнең остасы, профессор Фоат Хәсән улы Вәлиев башлаган. Бу олпат галимнең эзләнүләрен һәм аның идеяләрен тагы да үстерүче, дәвам итүче булып рәссам, Россия һәм Татарстанның Рәссамнар берлеге әгъзасы Зөфәр Сәет улы Низаметдинов санала.

–Бүгенгә кадәр без бу зур галимнең хезмәтен тиешенчә бәяли алмадык. Ул рәсми фәндә Бөек Болгар мәдәнияты турында дөресен сөйләү тыелган заманда ук эзләнүләр алып барды, шунын нәтиҗәсе буларак, хакыйкать ачылды,–дип тәкърарлый Зөфәр әфәнде.–Ул Идел буе һәм Урал төбәгендә яшәгән халыкларның декоратив-гамәли сәнгатен классификацияләде һәм шул хакта монографияләр әзерләде, уку йортларында шул декоратив-гамәли сәнгать буенча дәрес бирергә яраклы академик басма әзерләде һәм нәшриятка тапшырды. Аны һич тә икеләнмичә Дмитрий Лихачёв, Тур Хейердал, Лев Гумилёв, Борис Пиотровский кебек галимнәр рәтенә кертергә була.

Зөфәр Низаметдинов фикеренчә, Фоат Вәлиев исемен Казан урамының берсенә биреп мәңгеләштерергә һәм дә аның сурәтен һәйкәл итеп куяр вакыт житте. Ф. Вәлиев өйрәнгән агач йорт җиһазларында, савыт-сабада, тәрәз йөзлекләрендә һәм төрле бизәкләрдә, мәчетләрнең эчке бизәлешендә халкыбызның югары зәвык, рухи байлык, матурлыкны, нәфисләкне аңлавы ярылып ята.

Дөрестән дә, Зөфәр Низаметдиновны аның рухи һәм фикри остазы Фоат Вәлиев эшчәнлеген дәвам итүчесе дип санарга була. Ни дисәң дә, унбиш еллык иҗатын төрки халыкларның бизәү үрнәкләрен өйрәнүгә багышлаган бит ул.

Зөфәр 1949 елны Свердловск өлкәсенең Серов шәһәрендә туган. Сабый чагыннан ук рәсем сәнгате белән җенләнгән; «Уралмаш» мәдәният йортының сәнгать студиясенә йөри. Армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң бизәүче-рәссам булып эшли, кичләрен сәнгать училищесында РСФСРның атказанган рәссамы Павел Хожателев остаханәсендә укый. Мәскәүдә Перовск декоратив-гамәли сәнгате Россия фондының остаханәләрендә Сергей Тер–Григорян житәкчелегендә эшли. Бу иҗади төркем Свердловск һәм Краснотурьинск, Финляндия башкаласы Хельсинки, Гыйрак һәм Кипрда сәнәгать корылмаларын монументаль мозаик паннолар белән бизәүдә катнаша.

Рәссам буларак белемен арттыру нияте аны 1982 елны Түбән Тагилдагы педагогия институтының сәнгать-графика факультетына алып килә. 1988 елда исә ул, конкурс нигезендә, Чаллы дәүләт педагогия институтына эшкә чакыру ала. Ул чактагы институт ректоры Зиннур Шәрәфетдинов художество-графика факультетында татар графикасы бүлеге оештырырга тәкъдим ясый. Шулай итеп, Зөфәр Низаметдиновнын уку-укыту эшчәнлеге башлана. Ул үзенең бай тәҗрибәсе, белеме, илһамын укучылары белән уртаклаша. Гадәти булган шамаил, тугра, гарәп каллиграфиясе, милли декоратив-гамәли сәнгатьне өйрәнү өчен укыту программасын төзи. Казанның 40нчы һөнәри училищесында укучыларны бизәк ясаунын композициясе, милли татар орнамент, декоратив-гамәли сәнгате буенча дәресләр алып бара.

1999 елның ахырында рәссам иҗатында яңа бер дәвер башлана. Бер-бер артлы төрки этносның тарихына, татар халкының мәшһүр эшлеклеләренә багышланган графика, нәгышь әсәрләре туа. Әлеге әсәрләрендә рәссам нечкә хисле романтик буларак та танылa. Ул, төрки халыкларының гаять үзенчәлекле мирасына таянып, сурәт ясаунын үзенә генә хас булган концепциясен, ысул-кануннарын ачыклый. Графика жанры кануннары буенча З. Низаметдинов нәгышь әсәрләрен иҗат иткәндә төсләр гаммасыннан нибары берничәсен генә файдалана. Янәсе, киндергә, декоратив эшләнмәләргә төшәргә насыйп төсләрне тарих үзе сайлап алыр...

Бөек Болгарның һәм Казан ханлыгының тарихына һәм мәдәниятына багышланган картиналардан « Болгар җилләре», «Яңадан туу», «Яшәү агачы», Болгарда беренче дарелфөнүнгә нигез салучы «Якуп бине Ногъмани», «Сөембикә ханбикә» кебек әсәрләрен иҗат итә. XIX-XX гасырларга караган татар тарихына мөнәсәбәтле, реалистик рухтагы картиналар да ясый. Шул исәптән иҗтимагый фикер ияләре һәм мәдәният әһелләре портретлары галереясен булдыра. Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, композитор Солтан Габәши һәм Салих Сәйдәшев, татар сынлы сәнгатенә нигез салучы Бакый Урманче, атаклы җырчы Илһам Шакиров портретлары иҗат ителә.

–Зөфәр рәссам гына түгел, ә бәлки эзләнүче, тикшеренүче-рәссам,–дип сөйли аның иҗатташ дусты Абрек Абзгилдин.–Аны, тасвирлана торган материалдан гайре, мәдәниятның, рухи халәтнең чыганагы–темалар, вакыйгалар үзенә җәлеп итә. Ул иҗат иткән нәгышь әсәренең графикага тартым булуы ярылып ята. Картиналардагы сызыкларның төгәллеге, сюжет төзелешендә төрки халыкларның гаять бай тарихы һәм мәдәнияты аермачык сизелә... Аның кулы астыннан төшкән әсәрләрдән бик күп нәрсәне аңларга мөмкин.

«Рәссамның нәгышь әсәрләрендә борынгы шәрыкъ миниатюрасы, татар милли бизәге, мөселман дини архитектурасының үзенчәлеге чагыла. Сынлы сәнгатебездә бүгенге көндә нәтиҗәле эшләүче, төрки халыкларның этнос буларак милли үзенчәлекләре, аларның сынлы һәм декоратив-гамәли сәнгатен фәлсәфи кимәлдә төгәл билгели алучы рәссам булып санала. Ул иҗаты белән дөньякүләм, гомумкешелек, милли һәм индивидуаль мираска, традицияләргә нигезләнеп эшләнгән әсәрләренең чиксезлеген күрсәтә алган рәссам,–дип иҗатчы эшчәнлегенә бәя бирә сәнгать белгече Розалина Шаһиева.–Аның иҗаты аңлы рәвештә этник, җирле кыйммәтләргә нигезләнә, шуна да карамастан, бу иҗат җимешләре сынлы сәнгатьне колачлаган бинибая олы киңлектә югалмаган, ләкин киресенчә, үзенең йөзен һәм рухи үзенчәлеген саклап кала алган. Рәссамның нәгышь әсәрләре хискә, кичерешләргә бай, аларда иркенлек һәм нур-яктылык сизелеп тора.»



*Күргәзмә белән танышканнан соң...*

90нчы еллар башында ул Чаллыда иҗади зыялыларның әйдәп баручысына әверелә. Ул еллар гадәттән тыш, фантастик үзгәрешләр чоры иде, соңыннан асылда аларның коры хыялга нигезләнгәнлеге билгеле булды. Үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлык шаукымыннан айнып биш ел узгач, гади кешегә «гадәттән тыш серле» дигән мөһер сугылган бик күп нәрсәләр ачылгач, иҗат әһелләре иреклек һавасының кинәт зур йотымыннан сулышлары кабынып, нәрсә турында язарга, дип аптырап калды. Бу вакытта иҗаткәрләребезнең иң алдынгы һәм азатлыкны сөюче булып торган бер катламы–рәссамнар беренче булып аваз салды. Гүя алар өчен мондый сорау әллә бар, әллә юк иде... Алар XX гасыр башындагы шагыйрьләр–символистлар, акмеистлар, футуристлар, имажинистлар–кебек үзләренең беренче декларацияләрен игълан итте. Чаллы рәссамнары Зөфәр Низаметдинов, Рифкат Вахитов, Хәмзә Шәрипов, Ким Сафиуллин, Казаннан Канәфи Нәфыйков, сәнгать белгечләре Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова һәм Розалина Шаһиева Татарстан рәссамнары берләшмәсен төзеделәр.

Әлеге төркем игълан иткән декларациянең асылы, төп фикере–республикабызның милли сәнгатен торгызу, Евразия киңлегендә Татарстанның бүгенге сәнгатенә яңача караш, генетик тамырлары бер булган тугандаш төрки халыклар сәнгатенең якын торуын билгеләү, Лев Гумилёв, Фуад Вәлиев, Бакый Урманчелар традицияләрен дәвам итеп, аларны алга таба үстерү иде.

Халык авыз иҗатыннан–күпсанлы риваятьләрдән, бәетләрдән, әкиятләрдән алынган сюжетлар һәм образларга нигезләнгән әсәрләр иҗат итә башлады. Илне аркылыга-буйга гизгән–Урал, Көнбатыш Себер, Ерак Көнчыгыш, Россия үзәгендәге өлкәләрне, Кырымны йөреп чыккан Зөфәр Низаметдиновның алдынгы карашлы иҗат әһелләре хәрәкәте башында торуы очраклы түгел иде. Яңа агымның төп нигез–киң мәгънәдә Евразия киңлегендә кешенең үзенең урынын танып-белү, үзенең мәдәниятының әһәмиятен, төркиләрнең гаять борынгы цивилизациясенең бер өлеше,

төрки халыкларының рухи һәм мәдәни мирасына ислам диненең йогынтысын күзаллау һәм, ниһаять, татар халкы мәдәниятенең үзенчәлеген һәм кабатланмаслыгын тоеп эш итү иде. Шушы максатлар Татарстанның сынлы сәнгать өлкәсендә уздырыла торган үзгәрешләрне үткәрүдә һәм аларның юнәлешләрен билгеләүдә төп роль уйнады.

1990 елларда дистәләгән күргәзмә, иҗади очрашу, лекцияләр үткәрелде. Аерым алганда, берләшмә әгъзаларының эшләрен җыеп Болгарда булган күргәзмә, «Алтын Урда» дигән экспозициянең Чаллыда, Алабуга, Чулман тәбәгендәге районнарда, Урал һәм Себер шәһәрләреннән Североуральск, Түбән Тагил, Чиләбе, Пермьдә үткәрелүен атарга була. Зөфәр Низаметдинов иҗат иткән картиналар Милли мәдәният музее һәм Казанның 1000 еллыгы музейларының бүгенге көн сәнгатенә багышланган залларын бизәп тора. Рәссамның иҗат үрнәкләре Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, башка җирле галереяларда һәм чит илләрдәге күргәзмә залларда күрсәтелә.

Рәссамның иҗат уңышлары күпсанлы дипломнар һәм мактау грамоталары белән билгеләнде. 2002 елда ул «Чаллы шәһәренең ел рәссамы» исеменә лаек булды.

Бүген исә Зөфәр Низаметдинов үзен яңа юнәлештә сынап карарга булды. Ул Казаныбызның асылда традицион бүләк-һәдия, кызыл балчыктан ясалган керамика эшләнмәләр белән шөгыльләнә башлады. Шунысы да мәгълүм, әлеге эш күп хезмәт һәм байтак чыгымнар таләп итә. Нәтиҗәдә декоратив сувенирларны тәшкил иткән «Савыт-саба» сериясе барлыкка килде. Сүз уңаеннан, рәссамның хәзинәсендә мондый эшләнмәләрнең илледән төрләре бар инде, һәм алар көннән-көн арта бара. Әлеге сувенирлар нигездә юкәдән кырып эшләнгән һәм аларның һәркайсы билгеле бер образны гәүдәләндерә. Мәсәлән, Ватан-ана, Хатын-кыз, Җиңүче-батыр, Дәүләт образлары бар. Игътибарны «Шәһри Казан», Болгар дәүләте башкалалары–«Болгар», «Биләр», Казан ханлыгы патшабикәләре «Сөембикә», «Нурсолтан», Казандагы мәшһүр гаскәри, баһадир–«Рөстәм батыр»га багышланган миниатюралар җәлеп итә. Әлеге сувенирларны сәнгать үрнәге буларак та, бизәнү әйберләрен саклау, конфет–йөзем савыты, өстәлләрне ямьләндерү предметы буларак та файдалану мөмкин. Бу искиткеч матур, күз явын алырдай әйберләргә Болгар дәүләте, Казан ханлыгы чорының милли бизәкләре төшерелгән. Алар сәнгать фәннәре докторы Ф. Вәлиев тикшеренүләре нигезендә башкарылган.



*3. Низаметдинов тарафыннан ясалган декоратив шахматлар.*

2003 елда рәссам шәхси чакыру буенча Эстониядә булып кайтты. Пярну һәм Таллин сәнгать белгечләре кунак алып килгән бүләкләргә сокланып туя алмаган... Пярну шәһәрендә яшәү, эшләү, иҗат итү өчен шартлар булдыру вәгъдә итеп, бер еллык мастер-класс үткәрү тәкъдиме ясалган.

Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә сувенирлар Санкт-Петербург һәм Мәскәү күргәзмәләрендә күрсәтелеп, сәнгать белгечләре һәм халыкта зур кызыксыну уятты.

Хәзер исә Зөфәр әфәнде һәдияләрне балчыктан җитештерүне җайга салды. Мәгълүм булганча, керамик савыт-саба, уенчыклар Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорында киң кулланыла булган. Борынгы осталар тарафыннан кызыл балчыктан ясалган нәфис савыт-саба Идел буенда гына түгел, хәтта аннан ерак илләрдә дә югары бәяләнгән. Шунысын да әйтергә кирәк, Татарстанда уздырылган археологик эзләнүләр вакытында җирле чүлмәкчеләр җитештергән чүлмәкләр белән бергә, Византия, Кырым, Урта Азиядә эшләнгән бодай, ярма, су, май саклый торган амфоралар–күпсыешлы савытлар да табылды. Бу–болгарларның ерактагы илләр, халыклар белән тыгыз аралашып яшәүләрен күрсәтүче бер дәлил. Археологлар

фаразы буенча, болгар бабаларыбыз Византиядә эшләнгән керамика белән Урта Иделгә төпләнгәнче үк, әле Дунай буйларында гомер иткәндә үк таныш булган. Керамик савыт-саба ясауны болгар бабаларыбызның византияле юнан һәм рум халыкларыннан өйрәнгәнлеген дә фаразларга мөмкин. Чөнки болгар керамикасы формасы буенча Византия савыт-сабасына, чүлмәкләргә бик якын.

Һәр олы рәссам кебек үк, Зөфәр ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнми. Ул декоратив-гамәли сәнгатьнең барлыкка килүен, үсешен чагылдырган фундаменталь хезмәт бастырырга, мәктәп һәм гимназияләрдә укучы балалар өчен дәреслек язып нәшер итәргә хыяллана. Сүз уңаеннан, Чаллы педагогия институты художество-графика факультетының өлкән курс шәкертләре анарга консультация алырга килеп йөри. Мәгәр рәссамның иң зур хыялы–Татарстанның барлык мәктәп һәм гимназияләрендә декоратив-гамәли сәнгать нигезләрен, гадәти төрки орнамент-бизәген өйрәнү, укытуны оештыру һәм татар сувенирларын күпләп житештереп, аларны дөньяның барлык кыйтгаларына тарату.

Зөфәр әфәнде белән аралашканда шуңа игътибар итәсен, аның иң еш кабатлый торган сүзләре–«тәрбия» һәм «мөнәсәбәт». Бала чагыннан ук аны татар халык авыз ижатын, халкыбызның гореф-гадәтләрен яхшы белгән әбисе тәрбияләп үстергән. Нәкъ менә әбисенең сабагы аша Зөфәр туган халкының зирәклеген, рухи байлыгын, күп гасырлык тәжрибәсен үзләштерә алган да инде. Зөфәр Низаметдинов–яшь буынга тәрбия бирүче укытучы.

...Канкардәш үзбәк халкының борынгыдан килгән чүлмәк, керамика бизәү ысулларын яңадан торгызу тарихы бик кызыклы һәм безнең өчен дә гыйбрәтле. 80нче елларда бер төркем үзбәк рәссамнары инде югалган, хәтердән жуелып беткән үзбәк керамикасы сәнгатен торгызу турында хыяллана. Алар тугандаш халкының сынлы сәнгатенә нигез салучы, Үзбәкстан халык рәссамы, милләттәшебез Чыңгыз Әхмәровка мөрәжәгать итәләр. Ул республика хөкүмәтенә барып мәсьәләне уңай хәл итеп кайта. Нәтижәдә, мәшһүр рәссамның абруе хисабына дәүләт дәрәжәсендә традицион үзбәк керамикасы торгызыла.

Соңгы елларда шәжәрә, тарихыбыз, тамырларыбызны ачыклау мәсьәләләре белән кызыксынуның артуы нәрсә белән аңлатыла соң? Әлеге хәл һич тә очраклы түгел. Глобальләшү, унификацияләү чорында яшибез ләбаса. Бу агымга каршы хәрәкәт баруын да инкарь итмәскә кирәк, чөнки адәм баласы биосоциаль зат буларак, үзен башкалардан аерып торучы билгеләрне сакларга тырыша һәм, әйтергә кирәк, бу табигый күренеш. Ихтимал, бу каршылык генетик дәрәжәдә дә үзен сиздерәдер. Нәкъ шул ук хәл үзенең асыл үзенчәлекләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, телен саклап калырга омтылучы халыкларда, милләтләрдә күзәтелә дә инде.

Төрки халыклар сынлы сәнгатенең чишмә башы бизәк ясаудан, орнаменттан, аның символларын, мәгънәсенә, серенә төшү–ерак гасырларны аңлауда ачкыч була ала, гел үзгәреп торучы күпкырлы әйләнә тирәбез, тормышыбыздагы тотрыклы бер нигез һәм киләчәктә милли үзенчәлекләребезне саклап калу мөмкинлеге.

...Мин шушы язманы сырлап утыра торган өстәлдә төрле төстәге карандашлар салынган,агачтан уеп эшләнгән савыт. Аның өске бизәлгән өлеше ачык яшел төстәге сәдәф буяу белән каймаланган. Савытының ак өслегенә матур итеп бизәкләр төшерелгән. Бераз астарак бизәк-орнамент кабатлана.

Ниндидер үтә-күренмәле жеп шушы бизәкләрдән үзенең аһәңе, матурлыгы белән рухи көч, илһам биреп тора сыман. Нәни генә карандаш савыты, әйтерсең лә дөньяда булган барлык төсләр дә сыйган...

**Расим МӘҺДИЕВ**

Фирдәвес
Хуҗин

# КҮКЛӘР ШАҺИТ

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

## Отпуск ялында

Командировка кәгазендә: «тоткарлыксыз юлда булуын тәэмин итәргә», дип язылган булса да, мин Рязань тимер юл вокзалыннан егерме беренче июнь көнендә утырып китә алмадым. Вокзал коменданты документларымны җентекләп карап чыкканнан соң:

—Сезгә кирәкле поезд иртәнге сәгать өчтә генә була, аңа кадәр станция ашханәсендә тамак ялгап алыгыз, яхшылап ял итегез,—дип, хәлемә керергә тырышып, киңәшләрен бирде. Ял һәм тамак кайгысы димени монда: минем күңел инде күптән Казанда, бронь белән сугыштан калдырылып, заводта эшләп йөрүче иптәшләрем янында; хыялым киртәләрне белмичә, Түбән Барышта кайтуымны зарыгып көтүче әни-карчыкны күрергә ашыга.

Билет Казанга кадәр булмады, аны көтәргә озак дип, Уразаево станциясенә кайтырга ниятләдем. Юл кешесенең юлда булуы хәерле, ди. Аннары күз күрер тагын.

Поезд Уразаевога җиткәндә кич якынлашып килә иде инде. Мондагы вокзалда да биш сәгать көтәргә туры килде. Ниһаять, репродуктордан Казан исемен телгә алып, белдерү ясадылар.

Егерме өченче июнь иртәсендә Татарстан башкаласы моннан дүрт ел элек Кызыл Армия сафларына озаткан улын йокыдан уяныр-уянмас хәлдә каршы алды. Дүрт ел эчендә берни үзгәрмәгән диярлек: шул ук таныш урамнар, Татар бистәсендәге яшелчә-җимеш бакчалары, күптән буяулы пумала күрмәгән соры йортлар, купшакайланган коймалар. Болар бар да таныш, тансык миңа. Иң башлап кода абыйларга керү уе белән аларга киттем. Капкалары эчтән эленгән булып чыкты. Шакуыма эчке яктан: «Кем кирәк?»—дип, урысчалап эндәштеләр. Гаҗәпләнеп, мин дә урысчалап җавап бирдем, кем һәм нинди йомыш белән йөрүемне аңлаттым. Кода абыйлар инде күптән биредә яшәмиләр икән, яңа йорт хуҗалары аларның кая күчеп киткәннәрен дә белми. Сөйләшкән тавышка күрше хатыны чыкты. Бусы шулай ук безгә туган тиешле Нәсимә апа. Кыстый-кыстый үзләренә алып керде. Нәсимә апаларның өстәл өстендә самавыр кайнап утыра. Хәзинәдә барын чыгарып тезгәннән соң туганый апа әллә кайдан гына пичәте дә куптарылмаган аракы шешәсе чыгарды. Үзе мине чәй белән дә, катырагы белән дә сыйлый-сыйлый сугыш хәлләрен сорашты. Мин аннан завод яңалыклары, авылдагы үзгәрешләр турында белештем. Соңгы

*Дәвамы. Башы 8 санда*

көннәрдә бик арылган иде, тәнем ял сорый. Нәсимә апа минем ярымйокылы халәттә утыруымны аңлап, баш астыма йомшак мендәр салып, ак җәймәләр җәелгән урын хәстәрләп бирде. Шул ятудан кичкә кадәр онытылып йоклаганмын. Уянып, күземне ачканда, кояш инде түбәнәеп килә иде. Торып, чәйләп алганнан соң, кайбер танышларны очратмаммы дип, бистә клубына киттем. Кызганычка, клубта кинога хәтле һәм аннан соң да танышлардан ник берәрсе күренсен. Нәсимә апаларга кайтып төн кунудан башка чарам калмады.

Икенче көнне заводта бергә эшләгән дусларны, танышларны һәм авылдан күчеп, хәзерге вакытта Казанда яшәгән кайбер авылдашларны күреп сөйләшүгә багышладым. Сөйләшеп сүз бетә димени—мин пристаньга төшкәндә төнге сәгать бердәге пароход ярдан кузгалып кына киткән иде, иртәнге биштәгесен көтәргә туры килде.

Менә инде мин пароходта. Су юлы буйлап йөрмәгәнгә дә дүрт ел узып киткән. Минем белән авылдашлар да бар. Антон кызы Дуся һәм безгә берничә йорт аша гына яшәүче Мәрзия белән сөйләшеп кайтып вакыт үткәнлеге сизелмәде дә. Үзем кызлар белән сөйләшәм, үзем яр буенда утырып калган авылларны, урманнарны күзәтәм. Су өсте тигезлегеннән чак кына күтәрелеп торган яшел хәтфә тугайлыкларга йотылып карыйм. Бар да сагындырган, бар да күңелгә тансык.

Пароход Тәмте пристанена килеп борынын төрткәндә кояш инде төшлектән шактый авышкан иде. Юлыбыз уң булып чыкты, Югары Барышныкылар ике җигүле ат белән утын китергәннәр һәм безне юл уңаенда утыртып кайтырга ризалаштылар. Югары Барышка кайтып җиткәндә җир өстенә кичке эңгер инде. Югары һәм Түбән Барыш аралары бер чакрым булса да, җәяүләп туган авылга кайтып кергәндә җәйнең кыска төне сыек караңгылыгын арып йоклаучы авыл өстенә тулысынча салып өлгергән иде. Бер генә өйдә дә ут яктысы күренми. Көнозын басуда эшләп талчыккан кешеләр генә түгел, азык чырае күрергә тилмергән этләр дә басылып йоклый булыр, ник берәрсе өреп карасын? Әни карчык хатларында кырда узган елдан калган башак ашап балаларның, карт-карчыкларның агуланып үлүләре турында яза иде, адәм баласына ашарга булмаганны, мескен этләргә юк та юктыр инде ул.

Ишегалдына узарга теләп, капканы эчкә эттем. Бикле икән, шакырга туры килде. Кемдер ишекне ачып баскыч төбенә чыкты.

—Кем бар анда?—дип сорады ул. Әни тавышы! Мин аны җир читендә булып, меңләгән кеше берьюлы эндәшсә да танып идем. Әни тавышын башка берәүнеке белән бутап була димени.

—Әни, бу мин әле—улың Габделхак,—дидем дулкынлануымны басарга тырышып.

—Габделхак?! Бәбкәем, балам, кайттың мени?

Әни капка келәсен ача алмыйча азапланды. Аннары ачкач, калтыранган куллары белән муеныма килеп сарылды. Үзе тыела алмыйча елый.

—И, балакаем, сине күрер көннәребез дә бар икән,—дип сөйләнә. Миңа да кыен иде, күз яшьләремне чак тыеп торам. Сеңлем Рәйсә йөгереп чыкты. Ул да:

—Абый!—дип икенче яктан килеп сарылды. Ике кыз-хатын татар халкына гына хас сабырлык белән артык кычкырмыйча үксеп елыйлар. Аларның иңнәре, башлары дерелди. Гаҗизлектән нишләргә белмичә, юатырга тырышып чәчләреннән сыйпыйм.

—Булды инде, булды. Менә кайттым ич, күрәсез. Исән-сау мин. Тиздән фашист мәлгуньне дөмектергәч, бөтенләйгә кайтырмын,—дип сөйләнәм.

Беренче булып әни исенә килде. Ул үзенең йомшаклыгыннан оялган шикелле:

—И, үземне әйтер идем инде—карт җүләр. Юлдан ачыгып, арып кайткан кешене елап бимазаламасам. Әйдә, улым, өйгә керик, тамагың ачыккандыр. Хәзер чәй куеп җибәрәм,—дип, кечкенә баланы җитәкләгәндәй кулымнан тотып эчкә әйдәкләде.

Әни туктагач, Рәйсә дә елавыннан шып туктады. Анда һаман бала холкы

әле, ул инде май кояшы кебек балкып елмая иде.

Йортка узып, әнинең чәе кайнап чыгуга, минем кайтуны кемнән ишеткәндер, аксак аягын сөйрәп Равил абый килеп керде. Ул Гариф абыйның якын дусты иде. Абыйга яу кырыннан әйләнеп кайтырга насыйп булмады, ә менә Равил бер аягын югалтса да, исән. Хәер, кемгә ничек язган бит. Абыйның дусты кергә керешкә:

—Кайттыңмени, фронтовик, бөтенләйгәме, әллә күреп китәргә генәме?—дип, мине сораулар белән күмеп ташлады.

—Фашист явыз көчле иде шул, ә безнең әзерлек түбән. Аның танкына каршы мылтык белән ничек бармак кирәк. Кырык беренче елны мылтыгы да бөтен солдатка җитми иде хәтта. Сугыш барышында иптәшегез үлсә, аныкын алырсыз, дип әйтәләр иде командирлар. Шуңа да безнекеләр чебен урынына кырылды инде. Мәскәү, Сталинград астында югалтуларның чамасыз күп булуы турында әйтәләр. Тик менә мин Ржев тирәсендә корбаннар тагы да күбрәк булгандыр, дитп уйлыйм. Көне-көне белән санаулы сәгатьләр эчендә тулы дивизиядән берничә солдат кына исән калган вакытлар аз булмады. Мин үзем шунда сугыштым. Аягымны өздереп госпитальгә эләкмәсәм, мөгаен, күптән җир астында яткан булыр идем,—дип сөйләде Равил абый. Без аның белән чәйләп, озак гапләшеп утырдык әле.

Иртәгәсен хәл белергә балалары белән Вагыйзә апа, олы абыемның тормыш иптәше—дәү апа (бездә шулай диләр) килеп җитте. Алар артыннан башка туганнар җыелды. Көне буена кеше өзелмәде. Кичкырын гына урамга һава суларга чыга алдым. Авыл урамы буйлап колхоз кәнсәсе урнашкан очка юнәлдем. Зиннәтулла абыем көн дә моннан эшкә бара иде, юл тузаны әле һаман аның эзләрен саклыйдыр кебек. Ул үзе дә сугышка китеп һәлак булмагандыр, авыл Советында сәркатип вазифасын башкарадыр сыман. Үзем дә сизмәстән адымнарымны кызулаттым. Кәнсәләргә барып кергәндә, анда колхоз председателе Галиуллин белән авыл Советы рәсие Заһидуллин Хәлил утыра иде. «И, хыялый»,—дип битәрләп алдым үземне эчемнән. Җитәкчеләр өстәлләре артыннан чыгып яныма килделәр һәм инемнән кочаклап:

—Фронтовик, хәл белергә кайттыңмы? Яхшы булган,—диештеләр.—Чын ир-егет булгансың бит,—дип соклануларын белгерттеләр. Абыем Зиннәтулланы яхшы сәркатип иде, дип искә алдылар. Гариф абыйның хәбәрсез югалуын әсирлеккә эләккәнлеккә юрадылар.—Менә күрерсез, кайтып төшәр әле, андый хәлләр була ул,—дигән өметләндергеч сүзләр әйттеләр. Алар белән әңгәмә озынга сузылды. Конторадан чыккач, колхоз бакчасын урап кайтырга уйладым. Анда хуҗалык умарталыгы бар, караучысы—Герасим дәдәй. Герасим дәдәй яңа рамнар куеп маташа иде, мине күргәч, эшеннән аерылып, яныма килде. Көрәктәй куллары белән учларымны кысып, озак кына селкеп торды.

—Сине күргәч, улымны күргәндәй булдым,—диде ул керфегенә эленгән яшь бөртеген җиңе белән сыпырып. Мине умарта өенә керергә кыстады. Өлкән кешенең чакыруын кабул итмәү, аны кимсетү булыр иде, шуны уйлап, умартачы картка иярдем. Герасим агай чиреге белән күләгәдә сакланган ачы бал чыгарып куйды, тустаганнарга хуш исле салкынча эчемлек койды.

—Синең кайтуыңа махсус саклап тоткан шикелле булган бу, әйдә, улым, җиңү өчен тотып куйыйк әле,—диде карт ихлас кыстап. Рәтен белеп әзерләнгән ачы бал күңелгә ятышлы иде, кунакчыл умартачының өч касә эчемлеге башны рәхәт иләсләндерде. Анда озак утырмадым, рәхмәт әйтеп, өйгә кайтып киттем. Өйдәгеләр мине югалткандыр...

## Әсирлектән качу

Әле моннан ике ел элек кенә Гитлерның рәсми пропагандасы якын арада СССР башкаласы Мәскәүне басып алачагы турында лаф оруына немецларның зур күпчелеге ышанса да, кырык бишенче елның апрелендә фюрерның яңа ко-

рал ярдәмендә союзниклар армиясен туздырачакмын дип шапырынуына инде ышанса да, «гитлер-югенд»та хезмәт итүче унбиш яшьлек фанатиклар гына ышангандыр. Моның шулай икәнлеген сакчыларнын безнен белән мөгамәләдә үзләрен бөтенләй башкача тотулары ук күрсәтеп тора. Алар инде юкка-барга бәйләнмиләр, таяк яки мылтык түтәсе белән җилкәгә дә менеп төшмиләр, хәтта җирдән тәмәке төпчеге үрелеп алганга да күз йомалар. Тиздән, бик тиздән Кызыл Армиянең өченче рейх башкаласы Берлинда булачагын яхшы аңлыйлар иде. Кем белә, бүген—без, иртәгә алар безнең урында булырга мөмкин.

Тугызынчы апрельдә утырган поездыбыз куе кара төтен белән капланган Гамбург шәһәре аша үтте. Тимер юл вокзалы нык җимерелгән, әллә ничә юл полотносыннан да бер генә линия исән калган иде. Состав Ильцен шәһәренә ике-өч чакрым барып җитмичә ачык кырда туктады. «Алда юл ватык»,—диделәр. Анда ремонтчылар шпаллар, рельслар салып мәш килә. Кичке эңгер җир өстенә караңгылык пәрдәсе япканда күк йөзендә союзниклар авиациясе пәйда булып, келәм бомбардировкасы башлап җибәрде. Шәһәр өстен ут, ялкын телләре камап алды. Безнең алда сугыш театрының коточкыч панорамасы җәелеп китте. Анда йортлар җимерелә, кешеләр үлә. Каты шартлауларга түзә алмыйча, җир безнең тирәдә дә сизелер-сизелмәс тетрәнә. Бу мәхшәр төн буена дәвам итте.

Поезд яктыргач кына кузгалып китте. Аның юлда хәрәкәтләнүе ташбака тизлеге белән бер, кечкенә станцияләрдә дә хәтсез озак тора. Никтер әсирләрне еш кына бер поездан икенчесенә күчереп утырта башладылар. Кич белән Целле дигән шәһәргә җиткәч, вагоннан төшереп, җәяү генә алып киттеләр. Соңгы бер-ике көндә юньләп ашау чырае күргән юк, хәлсезлектән аяк буыннары сыгыла. Әсирләр адымы белән алты чакрым араны дүрт сәгатьтә үттек.

Таң атып килә. Көнбатыштан канонада тавышлары ишетелә. Безгә килеп ирешкән хәбәрләргә караганда, союзниклар фронты моннан утыз чакрымнарда гына булырга тиеш, ә Көнчыгыш фронт—ике йөз.

Унынчы апрель көнне төш турларында Хильдескин станциясендә кабат поездга утыртып ары таба алып киттеләр. Караңгы төшеп килгәндә Фульда шәһәре аша үттек. Таң алдыннан поезд Франкфурт тимер юл вокзалына килеп туктады. Тик монда безне озак тотмадылар, тиз генә вагоннан төшереп, Вюрцбург ягына баручы икенче бер поездга утыртып җибәрделәр. Болай ашыгуларының сәбәбе: американлыларның алдынгы частьлары Франкфурт тирәләренә үк килеп чыккан, диделәр. Безне озатучы немец сак хезмәтенең өлкән офицерлары сакчы солдатларның әсирләрне үз белдеге белән ташлап китүләреннән курка иде бугай, алар әсирләрне генә түгел, сакчыларны да инде бер минутка да күздән ычкындырмый.

Унберенче апрельдә, Вюрцбургка барып җиткәч тә, әсирләргә ашарга бирмәделәр, составны Нюрнбергка күрсәтелгән юк ягына борып, алга ашыктырдылар.

Уникенче апрель көнне, төш алдыннан, поезд «Плауэн» дип язылган станциягә килеп туктады. Ниндидер тылсым белән станция авиаударлардан сакланып калган. Вокзал бинасы бик матур булып күзгә ташланып тора. Тирә-як яшеллеккә күмелгән, акацияләр арасында чәчәк клумбалары үсә. Әйтерсен, биредә сугыш бөтенләй булмаган, бераз арырак кына җимерек йортлар шәйләнә. Плауэнда, ни сәбәптәндер, озаграк торасыбыз икән. Әсирләрне вагоннан чыгарып, яшел чирәмлеккә куаладылар. Ашарга бирделәр. Кем утырып, кем ятып ял итә. Күктә кояш елмая. Аның яктысында сәләмәләргә төренгән, тире белән сөяккә калган гәүдәләрне җылытабыз. Озак мунча күрмәгәнлектән, арык тәннәребезне бет басты. Көн яктысында тик утырганда кечкенә хәшәрәтләр ныграк активлаша, алар көтүләре белән гәүдәнең әллә кай төшләрендә кыймылдыйлар, сакал-мыек баскан биткә кадәр үрмәлиләр. Кычытынуга чыдый алмыйча, өсләрдән гимнастеркаларны салып ташлап, бет афәтенә каршы сугыш башлап җибәрәбез. Тик монда да тынычлап утырырга насыйп булмады, әледән-әле һава тревогасы белгерттеләр. Союзникларның еракка ата торган туплары снаряд арты снаряд яудырып, каланы үлем «бүләге» белән сыйлады.

Немец хәрбиләренең нервланулары күренеп тора, конвой башлыклары еш кына планшетларыннан карталарын чыгарып салып, дәррәү аның өстенә иеләләр дә үзара ни турындадыр сөйләшә башлыйлар. Күрәсең, алар картадан барасы маршрутны билгелиләр. Кызып, үзара бәхәсләшкәннәре ишетелә. «Капут», дип сөйләшкәннәрен без дә аңлыйбыз: алынган шәһәрләрне атаганда шулай әйтүләредер. Кичке тымызык табигатьне җиләслеккә күмгәндә, безне җайлап урнашкан урыннарыбыздан торгызып, янарак кына авыр уфылдап Плауэн станциясенә килеп туктаган составның бер вагонына куалап керттеләр. Фриц ашыга, чөнки аның артыннан авызыннан ут бөркегән җиде башлы аждаһа шикелле фронт куып җитеп килә иде.

Унөченче апрель иртәсендә Цвикау шәһәрендә кабат поездан төшереп, җәяүләп алып киттеләр. Ун тәүлек буена кайда җәяү, кайда составтан составка күчереп ярымач килеш йөрүләр әсирләрне тәмам йончыткан иде, аяклар тузанлы юлдан шуышып кына диярлек атлый. Сакчыларның «шнелле», дип автомат түтәсе белән җилкәләргә төрткәләп куалауларыннан да файда юк, аңа карап кына тизлек артмый. И-их, менә монда союзникларның мобиль отряды килеп чыксын да, безне әсирлектән аралап алсын иде! Кояш ярыйсы ук кыздыра. Төш турлары җиткәндә өстәге киемнәр сыгып алышлы булды. Тик немецлар ялга туктарга һаман рөхсәт итмәделәр. Кайберәүләр хәлсезлектән тузанлы юлга гөрселдәп ава башлагач кына «һальт!» әмере яңгырады. Һәр әсиргә яртышар стакан чамасы җылымса су өләштеләр. Аны эчкәч чак кына хәл кереп китте. Дошманның әсирләрне үзләренә мәшәкать тудырып концлагерьгамы, кая да булса башка җиргәме алып барырга омтылуларының серенә һаман төшенеп җитә алмадык. Югыйсә, менә шушында, утырган урында, автоматчылар ут ачып безне юк итәр өчен өч-дүрт минут вакыт җитә. Никтер һаман сузалар.

Озаклап ял итәргә ирек бирмәделәр, утырган урыннарыннан кузгалмаганнарны төрткәләп торгызып, кабат тузанлы юл буенча куаладылар. Безнең төркемне гражданский киемдәге бер кеше куып җитте. Кырыйдан узып барышлый акрын тавыш белән урысчалап:

—Американылар моннан алты чакрым гына,—диде. Үзе «аңладыгызмы?» дигән шикелле әсирләргә мәгънәле карап алды да, адымнарын кызулатып китеп тә барды. Мондый хәбәрне аңламыйлар димени, пышылдап кына әйткән булса да, барыбер ишеткән булыр идек. Яшәү нуры сүнеп барган күзләребезгә өмет чаткысы кунды, җегәре беткән аякларга хәл кереп киткәндәй тоелды. Тик нишләргә соң хәзерге мәлдә, нинди карар кабул итәргә? Аптырашып бер-беребезгә карадык, кычкырып әйтмәсәк тә, әлеге сорау чыраебызга аермачык язылган. Бер юл бар билгеле, аны һәркайсыбыз чамалый: кинәт кенә дошман өстенә ташланып, автоматчыларны коралсызландыру, юк итү. Тик бу безнең очракта күрәләтә үлемгә бару булачак, чөнки тук һәм таза сакчыларга ярымскелет әсирләр икешәрләп ташланса да, аларны аяктан ега алмаячак. Димәк, әлеге ысул кулай түгел. Нишләргә соң, нишләргә?! Фашистлар әсирләр төркемендә дулкынлану купканын сизенде булса кирәк, «шнелле!» дип безне ашыгыбрак куаларга кереште. Кинәт качу уенын барып чыкмавын аңлау икеләтә авыр икән, җилкәләргә автомат түтәләренең ешрак төшә башлавына карамастан, адымнарыбызны тагын да акрынайттык. Шулай булса да, алга бару—алга бару булып кала, күп тә үтмәде, каршыбызда чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган бараклар күренде. Бу—оккупацияләнгән совет җирләреннән фашистлар төрле эшләргә көчләп алып киткән гражданский кешеләр өчен эшләнгән концентрацион лагерь иде.

Аның капка баганасына, әсирләрне куып узганда, американыларның якын булуы турында хәбәр ирештергән кеше сөялгән дә, тик басып тора. Ул тыныч кына безнең төркемне күзәтә. Йөзенә ник бер билге чыгарсын, нервлары баудыр моның! Безнең төркемне лагерь капкасы каршында ук туктаттылар. Конвой башлыгы утырып ял итәргә мөмкин икәнлекне белгертте. Кайсыларыбыз җиргә утырышты, кемнәрдер сузылып ук ятты. Ачлыктан һәм сусызлыктан, эссе кояш астында җәяү килүдән хәлсезлек баскан гәүдәләргә ял кирәк иде. Аркага

ябышкан эчләр ашарга сорап сулкылдый, аннан битәр эчәсе килү интектерә. Кибеп яргаланган иреннәрне коргаксыган телләр белән ялап күпме утырырга туры килер иде икән, әйтүе кыен—лагерь капкасыннан берничә кызның йөгереп чыкканы күренде. Алар туры безнең янга юнәлделәр. Тик юлларына конвоирлар аркылы төште, якын килергә ярамаганны аңлатып, немецча кычкырындылар. Кызларның үзара урысча сөйләшкәннәрен ишетеп, аларның урыс кавеменнән икәнлекләрен инде анышкан идек. Эчкә жылы йөгерде. Жиргә сузылышып яткан аеруча хәлсезләр дә торып утырды. Кызларның берсе ярыйсы гына немец телендә дә сукалый икән, конвой башлыгы белән елмаеп кына ни турындадыр сөйләшергә керешге. Мөлаем кыз да, немец офицеры да вакыты белән кулларын селти-селти баракларга төртеп күрсәтә, кайчагында сакчылар башлыгы кызып китеп тавышын күтәрә. Тик дошман офицерлары белән аңлашуны үз өстенә алган сары чәчле гади генә маржа кызы тавышын һич күтәрми, ипле генә итеп аңлатуын белә. Әллә кызның дипломатларча җайлап сөйләшүе, әллә башка сәбәптән, ахырда гитлерчы офицер «ярар» дигән мәгънәдә кулын селтәде һәм сакчыларга безне капкадан эчкә кертергә әмер бирде. Әсирләр төркемен икешәрләп тезеп баракларга таба әйдәделәр. Баракларга ябалар икән дип уйлаган идек, алай булып чыкмады—капкадан кергәч тә уң якта таштан эшләнгән мунчага охшаш корылмага керттеләр. Бина төзелеп бетмәгән, никтер, тәрәзә өлгеләре дә куелмаган, хәтта бер ягы чәнечкеле тимерчыбык эчендә дә түгел. Кыскасы, сакчылар искәрмәгәндә, качар өчен менә дигән урын. Бина янәшәсеннән үк вак куаклыклар белән капланган инкүлек башланып китә.

Конвоирлар үзләре дә нык ачыкканнар иде. Моны аларның әсирләрне таш йортка ашык-пошык куалап керткәннән соң, капка алды мәйданына ни максаттандыр тезеп куелган озын өстәлләрнең берсе артына барып утырып, кызлар тәлинкәләргә салып китергән ашка ач бүредәй ташланулары раслый. Тик аш кайнар, булары чыгып тора, алар калакларына өрә-өрә ашарга мәжбүр. Ул арада әсирләр арасындагы өлкән офицерлар качу планын уйлап өлгерде. Күрше штурмовиклар авиаполкы капитаны кыска-кыска әмерләр биреп, икешәрләп качарга кирәклеген аңлатты. Сакчылардан соң безгә аш китерә башладылар. Ачык тәрәзә аша аш бирүче кызларның берсеннән штурмовик-капитан: «гражданский киемнәр китерә алмассызмы?»—дип сорады. Кызларга запас каян килгәндер: һәр тәлинкә аш китергән саен култык асларына кием дә кыстырып киләләр. Шул рәвешле кыска вакыт эчендә һәммәбез дә жиңнәренә «OS» дип язылган киемле булдык. Безгә планны чынга ашырырга ашның кайнар булуы нык ярдәм итте, сакчыларның тамак туйдыруы озакка сузылды. Безнең дә өзелеп ашыйсы килүдән авызга сулар килә, тик ана вакыт юк—качарга кирәк. Әсирләр инде тәрәзәдән сикереп төшәләр дә, икешәрләп-икешәрләп, булдыра алганча кызу адымнар белән куе чаукалыкка кереп югалалар. Минем чират өлкән сержант Метелкин белән туры килде. Ниһаять, без чаукалык эчендә. Тик уйсулык буйлап озак бармадык, алай-болай немецлар эзли чыкса дип, эз югалтыр өчен олы юлга чыктык. Өстәге «OS» билгесе сугылган шахтерлар киеме безне йомшартылган режимда тотылучы гражданский әсирләргә охшатып калдырган, тик кесәдә аларга бирелә торган аусвайслар гына юк. «Бездән соң качарга тиешле башка иптәшләр ничек микән?»—дигән уй тынгы бирми.—Тәрәз төбендә әсирләрне тәртибе белән берәмтекләп ирекка чыгарып торучы капитан үзе качып өлгерә алдымы?» Хәлебез җиткәнчә башта юл буенча, аннары басуга таба йөгерәбез, ә бөтен игътибар анда—концлагерь ягында. Ул тарафтан автоматтан аткан тавышлар ишетелде. Димәк, күпмедер вакытка уяулыкларын югалткан фрицлар әсирләрнең юкка чыкканлыкларын сизенеп алган. Хәзер эзли чыгасыларын көт тә тор. Метелкин белән мин аякларны чак сөйрәсәк тә, баруыбызны дәвам иттек. Бу вакытта кояш инде офыкка төшеп бара иде. Күнел һаман ышанып житми: без чыннан да иректәме соң? Бу—мең тугыз йөз кырык бишенче елның унөченче апрель киче иде.

## Казандагы күрешү

Отпуск ялында Түбән Барыштан китеп Казанга килгәч, анда яшәүче туганнарда, таныш-белешләрдә бер-ике көн кунак булдым. Сөйләшеп сүз бетәмени. Туры килүен кара: шунда, һич уйламаганда, беренче мәхәббәтем Мәхмүзәне очраттым. Дөресрәге, ул үзе күреп эндәште.

—Хак, исәнме?—дигән тавышка әйләнеп карасам, янәшәмдә басып тора. Нәүмизләнүе йөзенә чыккан. Минем сәламен дә алмыйча торуымны күреп хәтере калды бугай.

—Башкага кияүгә чыгуымны гафу итә алмыйсыңдыр инде, әйе бит,—диде аннары үпкәсен эчкә йотып.

—Юк, нишләп алай булсын?! Һәркем үз тормышын үзенчә корырга иректе,—дидем, гәрчә ана үпкәм зур булса да, сер бирмәскә тырышып.

Мәхмүзә акланырга ашыкты:

—Сине үлгән диделәр ич. Шуны ишеткәч, Ибраһим атлы берәүгә тормышка чыктым. Чыгасым да калмаган икән, барыбер аның белән кешечә яши алмадык.

—Ирсез калырмын дип курыккансыңдыр. Сугыш вакыты булгач, ирләргә кытлык бит,—дип чәнчеп куйдым мин-минлегемнең кимсетелүе өчен аз булса да үч алырга теләп.

Яшь хатын соңгы сүзләремне әллә ишетеп җиткермәде, әллә ишетеп тә аңламаганга сабышты. Сөйләвен дәвам итте:

—Шофер булып эшли иде гаилә башы булырга тиешле кеше, сугыштан бронь белән калдырылган. Өстемнән хатыннар белән йөрде. Андыйлар күп бит хәзер, чак кына күз уйнатсаң, муеныңа сарылырга торалар. Хыянәт итүен белгәч тә ишеккә күрсәттем. Ялынып әллә ничә килде, «бер кискән ипи кабат ябышмый», дип, кертмәдем. Вакыт тапсаң, бүген кичке сәгать алтыга кил. Үткәннәрне искә төшереп, сөйләшеп утырырбыз,—дип, Мәхмүзә күзләрендә нинди сәер очкыннар уйнатты. Аерылышканда ялынгандай итеп:—Кил, котәм!—дип өстәде.

Миңа нәрсә, әле өйләнмәгән, беркемгә берни белән бәйләнмәгән ирекле егет. Халыктагыча әйтсәк: «минем өчен ике чабата—бер кием». Мәхмүзәгә хәтерем нык калган булса да, кызыксынуым көчлерәк иде: нәкъ кичке алтыда мин фәкыйрегез инде ялгыз хатын Мәхмүзә бүлмәсендә идем. Элекке мәхәббәтем хәленнән килгәнчә ярыйсы ук бай табын хәстәрләгән. Өстәл өстенә балыкның каклаганы да, кыздырылганы да куелган, алар янәшәсендә түтәлдән яңа өзелгән кыяр урын алган; кискәләп тәлинкәгә тезелгән сыр, колбаса ише ризыклар күренә; күпереп пешкән ак күмәч хуш исләрен бүлмәгә тараткан. Ризыклар уртасында әле пичәте дә куптарылмаган «акбашлы катысы» кукыраеп утыра. Йөзенә дулкынлану галәмәте чыккан булса да, Мәхмүзә елмаерга тырыша. Тик бу ясалма елмаю иде. Моны ул да, мин дә яхшы аңлыйбыз. Шулай да аңламаган атлы кыланабыз. Тормыш шулай яратылган инде. Театр кебек. Ә без театрда уйнаучы артистлар. Киеренкелекне йомшартырга теләптер, мин өстәл артына утырып җитәр-җитмәс үк Мәхмүзә:

—Әйдә, Габделхак, чәркәләргә кырык градуслысын сал әле. Ярап бетмәсә дә, мин дә очрашу хөрмәтенә чак кына тотармын,—дип үзе дә сизмәстән корсагына ымлады. Ул чыннан да бу сүзләрен аны-моны уйламыйча әйтте. Минем гаҗәпләнеп, түгәрәкләнеп килгән корсагына күз төшерүемне күргәч, угрылык өстендә тотылган карак кебек бурлаттай кызарынды. Беравык зиһене чуалып, сүзенең мәгънәсен югалтудан ни диярргә белмичә торганнан соң кулын селтәде дә лып итеп урындыкка утырды.

—Бүл инде. Ир кеше ич син, хатын-кызга шешәгә тотыну килешми,—диде аннары нинди дер чит, арыган тавыш белән. Миңа шешәдәге сыеклыкны чәр-

кәләргә коюдан башка чара калмады. Артык ялындырып тормадым, беренче йомрыны авызыма капладым. Зәһәр сыеклык бугазымны яндырып үтте. Кабымлык капмыйча, үземә тагын аракы салдым. Мәхмүзә дә салынганны бераз уртлап куйды. Икенчесен эчеп куйгач кына гәүдәмә йомшарткыч җылылык таралганын тойдым. Мәхмүзә мине ашарга кыстый башлады.

—Рәхмәт. Барысы да алдымда, барысыннан житешәм,—дип мыгырдандым кыяр артыннан авызыма колбаса кисәге озатып. Йөрәк януын басар өчен эчеп исерәсем, күпмедер вакытка онытыласым килде. Шулай да күп еллар дәвамында чарланган очучылык инстинкты кыска вакытлы күңел йомшаклыгына азынырга ирек бирмәде—янадан бер чәркә салып эчкәннән соң аз-маз капкалап, әһәмиятле булмаган нәрсәләр турында сөйләшеп утырганнан соң сәгатькә карап:

—Мина китәргә кирәк,—дип аягыма бастым. Мәхмүзәнең югалып калуы йөзенә чыкты. Ул мине шулай тиз китәр дип уйламаганлыгы күренеп тора.

—Бәлки куна калырсың?—диде яшь хатын кыяр-кыймас. Минем очрашуга килгәнче дә уемда андый нәрсә юк иде, чөнки Мәхмүзәнең башкага кияүгә чыгуын берничек гафу итә алмадым, ә инде Ибраһимнан көмәнле икәнен белгәч, күңелем бөтенләй сүрелде.

—Юк, китәм. Сау бул. Сабыең бәхете белән тусын,—дидем өзек-өзек итеп.

—Рәхмәт. Син дә бәхетле бул, Габделхак. Үзеңә тиң насыйп ярыңны очратып, куанып яшәргә язсын.—Яшь хатын тавышсыз гына елый иде. Мин аңа озатырга чыкмаска кушып, ишекне яптым.

Төнне туганнан туган апаларда уздырганнан соң, икенче көнне җәяүләп тимер юл вокзалына киттем. Трамвай линияләренә ремонт ясалганлыктан, әлеге төр транспорт йөрми иде. Вокзалда, фронтовик буларак, билет алу зур кыенлык тудырмады. Ә икенче көн иртәсендә мин инде эскадрилья командирына отпусктан килүем турында рапорт бирә идем.

## Иректә икенче көн

Басу эчендә былтыргыдан калган салам эскерте күренде. Метелкин белән бер-беребезгә карашып алдык та, шунда ташландык. Эскерт безнең өчен бердәнбер котылу урыны булып тоелды. Саламны кул белән аралап, кеше кереп урнашырлык урын ясау хәлсез әсирләр өчен озак вакыт таләп итүче шөгыль булып чыкты. Куышка кереп яткач, тишекне салам белән томаладык. Инде кояш күптән баеган, салкынча дымык ис аңкыган җир өстенә төн пәрдәсен япкан. Үлеп арыган булсак та, күзгә тиз генә йокы кермәде: ээзәрлекләп килүче немец солдатлары менә-менә өскә килеп чыгарлар төсле. Өстәвенә союзниклар артиллериясе телгә килде. Ерак түгел снарядлар төшеп ярыла, мәрткә киткән кешең дә уяныр мондый хәлдә. Инде котылдык дигәндә, шуларның берсе эскерткә туры килсә, беттең дигән сүз. Снаряд шартлаулар тынып торган арада үзара акрын гына сөйләшәбез, иртәгәсе көнгә планнар корабыз. Берзаман, биргән соравыма Метелкиннан җавап ишетмәдем.

—Саша, син йокладыңмы?—дигән соравым кабат җавапсыз эленеп калды. «Йоклагандыр инде, көне чамасыз катлаулы булды», дигән уй ми күзәнәкләремнең әллә кайсы почмагында тоныкк кына кабынып алды да, сүнеп, йокы патшалыгы мине үз кочагына алды.

Соң йоклаган булсак та, иртә уяндык: кояш җир читеннән кызарып бер читен генә күрсәткән иде әле. Салкынлык юка кием аша бөтен гәүдәгә үткән. Авызга ике тәүлектән артык ипи валчыгы да эләкмәгәнлектән, арык тәндә нинди җылы торсын! Бүген апрельнең ундүрте. Без иректә икенче көн. Ышанасы килми хәтта. Хәер, безнең хәлне ирек дип шартлы рәвештә генә әйтеп буладыр, чөнки союзникларның янәшәдә икәнен белсәк тә, әлегә үзләрен күргән юк.

Юл буенча кырга эшкә баручы немецлар күренде, күбесе инбашына тырмадыр, көрәктер күтәргән. Без дә алардан аерылып тормас өчен, куак агачыннан, ике җәпле тырнавыч сыман нәрсә хәстәрләп, иннәргә салдык. Тоткан юнәлешебез көнбатышка таба, чөнки котылуның анда икәнен яхшы беләбез. Шулай да юлга ук чыкмадык, кояш югары күтәрелгән саен анда тыз да быз чабышкан автомашина, мотоцикллар саны артты. Кайсылары фронт ягына ашыкса, кайберләре аннан качу ягын карый. Тик качып кая бара инде бу мәхлуклар, шунысы аңлашылмый. Тиздән Көнчыгыш һәм Көнбатыш фронтлар кушылачак һәм тозак шартлап ябылачак. Зур булмаган җир кишәрлегендә орлык өчен утыртылган гәрәнкәләргә тап булдык. Саклык чарасы күрергә кирәклекне дә онытып, йомшартылган туфрактан яшел үсентеләр чыгарып кына килүче яшелчәләргә ташландык. Шалкан гәрәнкәсе икән. Кеше газап-михнәткә, җәберсетүләргә дә чыдый, күнегә. Ә менә ачлыкка берничек чыдап та, күнегеп тә булмый. Бушаган ашказаны ризык даулап бөтен организмга чаң суга, баш миенә тимер чөй кебек: «аны каян табарга?» дигән уй кага һәм адәм баласының бөтен булмышы һәм кылмышы шушы юнәлештә генә эшли башлый. Ул азык табу юлында соңгы чиккә барырга, үз кавемендәгеләрнең бугазын чәйнәргә дә әзер. Җирдән казып чыгарылган шалканның сабакларын кул белән сыдырып атып, кабыгын да әрчемичә, комсызланып кимерергә керештек. Икешәр шалканны шул килеш авызга озаткач, тагын берничәне кабыгыннан чистартып ашадык, кесәләргә тутырдык. Юньле азыктан тәмам бизгән эчләребез чи тамыразыкны өнәмәде—борып авырта башлады. Бусы юлны дәвам итәргә бер комачаулык тудырса, икенче комачаулык—юлда техника һәм кешеләрнең кайнап торуы иде. Һәр мизгелдә немец хәрбиләре туктатып «аусвайс» таләп итәргә, ул булмагач, үзләренә артык мәшәкать тудырмыйча, атып үтерергә мөмкиннәр. Иң яхшысы дигәндә дә, якындагы концлагерьга илтеп тапшыру куркынычы яный.

Шалкан басуыннан ерак та түгел бер трактор торганны күрдек. Ул ватык булса кирәк, тирәсендә җан иясе күренми. Киңәшләшеп алгач, шунда киттек. Хуҗасы килеп чыкса, андый-мондый сүз озайтмыйча, китеп барырга исәп. Әгәр беркем дә килмәсә, көнне шунда үткәрергә уйладык. Үзебезчә, техника янында мәш килгән булабыз, тирә-юньне дә күзәтәбез. Бәхеткә, янныбызда беркем пәйда булмады. Немецларның үз хәлләре хәл иде, күрәсең. Кояш баер алдыннан күк йөзен болыт басты, чиләкләп яңгыр койды. Ышыкланыр урын юк, бөтен өс манма су булды. Монда туңып, дер калтырап утырудан файда юклыгын аңлап алга хәрәкәт итәргә карар кылдык. Машиналар колоннасы, җәяүләп атлаучы хәрбиләр төркеменә юлыкмас өчен саклык белән генә атлыйбыз. Шул ук вакытта, шик тудырмас өчен кыр эшеннән кайтып килүчеләр роленә дә керергә кирәк бит әле. Алдагы уйсулыкта берничә йортлы гына кечкенә авыл күренде. Аның эченә керергә шикләндек, астын ачык калдырып өелгән печән кибәне табып, астына кереп яттык. Инде күз тәмам бәйләнгән, төнне йоклап уздыру турында уйларга да вакыт җиткән иде. Бер-беребезгә ышыкланып, баш астына, ян-якларга күп итеп печән түшәп салганнан соң гәүдәгә җылы керде. «Йокы мендәр сорамый», дигән сүз безнең хәлгә бигрәк туры килә—изрәп йокыга киткәнбез.

## Тәскиядән хат

Отпуск ялына кайтып киткәч, минем исемгә өч хат килгән. Шуларның берсе Тәскиядән. Дустым Мәхмүт аларны миңа биргәндә:

—Хак, сөйгәнеңниләр язды икән, бергәләп укыйк әле,—дигән гозерен белгертте. Серләрне уртаклашырга атлыгып тормасам да, ризалаштым. Тәскиянең хатын ачканда үземә дә аңлашылып җитмәгән катлаулы хисләр кичердем. Минем бу кыз алдында гаебем дә бар кебек, чөнки авылга кайтып та, аның

хәлен белешергә вакыт тапмадым. Теләк булса, ничек тә бер көнне Тәскияләр авылына барып кайтырга була иде. Белгәч, аның мина үпкәләргә тулы хакы бар. Икенче яклап фикер йөртсәң, минем Тәскиягә беркайчан да сине генә сөям, көт, дошманны жинеп кайткач сиңа өйләнәм, дип язганым булмады. Без әле вәгъдәләшкән егет белән кыз түгел. Аннары, соңгы тапкыр Мәхмүзәне Казанда очраткач, ана карата башкага тормышка чыгуын белсәм дә, һаман да хисләрем суынып бетмәгәнлеген аңладым. Бу хисләр каядыр күңел эчкәресенә яшереп куелган да, шунда сакланган икән. Ә инде Мәхмүзәнең Ибраһим атлы кешедән көмәнле икәнен дә күзләрем белән күреп ышангач, беренче мәхәббәтемнән мәңгегә гайрәтем чикте. Миндә кызларга карата: «ышан син аларга, жае чыкса, беренче очраган ир-ат куенына керергә торалар»,—дигән фикер формалашты. Шуңа да Тәскиянең хатын ачканда кәефем чамалы иде. Мәхмүт гажәпләнеп:

—Әллә ялдан балтаң суга төшеп килдеңме?—дип әйтә куйды.

—Юк ла, болай гына,—дип мыгырдандым уңайсызлануымны яшерергә тырышып.

Тәския гадәттә язылу көнен хатының башына куя. Бу юлы да гадәтенә тугры калып: «Сагыну сәламе. 28.06.44 ел,—дип башлаган. Аннары болай дип язып киткән: Саф йөрәктән кайнап чыккан сагыну сәламнәремне жибәреп калам. Дустым, синең 3.06.44тә язган хатынны кичә, 27.06.44тә алып укыдым һәм чиксез шатландым. Чөнки күптәннән хатың юк иде, ә сугыш каты бара. Хатынны кичә алсам да, шундук жавап яза алмадым, чөнки мин хәзер укучы балалардан отряд оештырып, кырга чүп утарга йөрим. Беркөнне аларны яхшы эшләгәннәре өчен урманга экскурсиягә алып барырга булдым. Урманга барырга чыккач, синнән килгән хатны китереп бирделәр. Экскурсиядән соң кайттык. Шуның өчен бүген иртән иртүк жавап язарга утырдым.

Тормышлар, сөеклем, дөресен әйтергә кирәк, авыр. Бик нык кыйммәтчелек. Кайчан гына бу немес этләренең юк ителгән көннәре килеп житәр икән...

Табигатьнең искитмәле матур вакыты. Тик бу матурлыкны күреп, күңел шатланмый. Сугыш—сугыш, авырлык һәм кыенлыклар. Шулай да сыгылып төшмәскә кирәк.

Нигә чәчәк алсу була,
Аны сөя һәр кеше.
Чөнки алсу чын дуслыкның
Мәңге шиңмәс билгесе.
Нигә чәчәк ап-ак була,
Жырлыйлар данлап аны.
Чөнки ул безнең яшьлекнең
Гомергә аткан таңы.

Нигә чәчәк кызыл була,
Ут кебек балкып яна.
Чөнки безнең йөрәкләрдән
Кан тамган диләр ана.
Аллы-гөлле чәчәкләрне
Бүген мин кырдан өздем.
Хисләремне жырга салып
Синең юлыңа тездем.

Хуш, сөеклем, сау булып тор, кулыңны кысып калам. Кайнар сәламнәр белән, өзелеп сагынып хат язучы Тәския дип белерсең.»

Хатны кычкырып укып чыктым да, Мәхмүткә күтәрелеп карадым. Ул, мәгънәле генә итеп, башын селеккәләде.

—Мин сиңа бер әйткән идем инде, тагын кабатлыйм: бу кыз сине өзелеп ярата. Югалта күрмә аны, ул—синең бәхетең!—диде.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Күзләрнең дә теле бар

Үзем кыска буйлы булгангадыр инде, «телеграмм баганасы» ишеләргә кызыгып карый идем. Таныш-белеш, дус-ишләрдән дә шундыйлар күбрәк хәтергә сеңеп калган.

Кәрим Жаманаклы да (үз фамилиясе Рәшидов) гаҗәеп бер пәһлеван зат (үз сүзләре) иде. Кем соң ул Кәрим Жаманаклы, дисезме? Гасырлар буе кимсетелгән, рәнҗетелгән, куркытылган-өркетелгән милләт вәкиле ул. Кырым татары. Шагыйрь. Мөгаллим. Олуг галим.

Кәрим Рәшидов Кырымның гөлбакчалар иле—Жаманак авылында туып-үсә. Ходай аңа матур буй-сын, мул итеп көч-куәт, акыл һәм гыйлем биргән. Пәһлеван гәүдәле бу инсан, ни хикмәт, сабый җанлы, нечкә күңелле, самими, хөрлеккә омтылучы бер очар кош иде. Аның 1939 елда Кырымда басылып чыккан шигырьләр җыентыгы да «Азатлык җырлары» дип атала.

Башка ватандашлары кебек ул да, илен яклап, фашистларга каршы көрәшә. Яралана. Савыга. Егет сугыштан кайтканда инде Кырым шәһәрләре, авыллары таланган, туздырылган, җимерелгән, ә халкы Себер, Урал, Урта Азия якларына сөргенгә сөрелгән була. Кәрим Жаманаклы да беркадәр вакыт шул тарафларда каңгырап йөри. Аннары Татарстанга кайтып урнаша. Казанга түгел читкәрәк. Алабуга шәһәренә. Шунда, педагогия институтында мөгаллимлек итте.

Шагыйрь Кәрим Жаманаклыны пәһлеван гәүдәле, куркытылган-өркетелгән кеше, дигән идем. Хак сүзләр. Шәхсән, мин үзем шушы гаярь затның күзләрендә гел моңсулык, куркуга охшаган ниндидер сискәнүле караш күреп аптырый идем. Ишекне акрын гына шакыр. Аннары, башын тыгып, бүлмә эченә багар. Күзләрендә елмаю катыш сорау. Кабул итәрләрме, янәсе.

—О, безгә Жаманаклы килгән! Әйдә, рәхим ит, түрдән уз, Кәрим бәй,—дип каршы ала кунакны редакциянең җаваплы сәркәтиб урынбасары Хан Җәмил.

Өрлектәй гәүдәсен бөгә төшеп, түбәнчелек белән Жаманаклы бүлмәгә уза. Монда аңа рәхәт. Казан каласында Кәрим бәйне аңлаучы, аз-маз серен сөйләрлек ике генә кеше бар иде. Берсе—якташы, укытучыларның белемен күтәрү институты директоры Мидхәт Үмәр улы Ягъяев (Алабугага кайтып урнашырга ул ярдәм итә), икенчесе—«Кызыл Татарстан» гәзитеннән Хан Җәмил. Ни өчен Җәмилме? Чөнки Хан ага редакциягә Кытайдан уйгыр телендә чыга торган «Сенҗезән гәзите»н алдыра иде. Уйгыр теле—безгә тугандаш, татар теленә бик якын. Шуны рәхәтләнеп укыйлар...

Күзләрнең дә теле була икән, әкәмәт. Мин үзем Кәрим бәй Жаманаклының күзләрендәге серне сөргеннән Хәсән Туфан, Ибраһим Салахов, Сөббух һәм Мәҗит Рафиковлар кайткач кына аңладым...

## Даһилыктан ваз кичү

Киләчәк буынны кызганам. Алар Даһи белән Бөекне күрмәячәк. Барыбыз да Такташ юлыннан китеп барачакбыз—«безнең заман халкы онытылыр».

Халык шагыйре Тукай бүләге иясе Мөдәррис Әгъләмовның кушаматы—Даһи.

Жан дусты Зөлфәтнең (тулы исеме Дөлфәт Маликов) шуна жен ачулары чыга. «Мөдәррис даһи булса, мин—Бөек»,—ди. Кайсының кем булуын ачыклап бетерәселәре бар әле исән-имин чакта.

*Түрәләргә инде өмет бетте,*
*Ничек кенә булыр киләчәк?*
*«Кәләпүше кирәк»,—дисә Мәскәү,*
*Болар*
*Башың кисеп алып киләчәк.*

Даһи дигәннәре менә шундыйрак шагыйрь.

—Мөдәррис, син үзеңне Тукайга тиңлисең, диләр.

—Башлары булмаганнар әйтә.

Монысын бәхәскә нокта кую, дип аңларга кирәктер, ахрысы. Железно!

## Сөннәтлеләр дуслыгы

Казан яһүдләре—үзебезнең яһүдләр шулай да. Элек «Советская Татария» газитендә хезмәт куйган Бруно Зернет, Анатолий Мелузников, Владимир Берлянд (бусы алман яһүде), Юрий Белостоцкий, Ян Винецкий, аннары Абрам Кринкин (радио), Соломон Оффенгенден (аны үз итеп Оффен дип кенә йөрттек), Рубим Левин (икесе дә «Чаян»чылар) безнең белән дустанә, тату яшәде, жылы мөнәсәбәттә булды. Ялгыш кына да конфликтка кермәделәр. Соңгы елларда Мәскәүнекеләр кыюлана төште, тәмам шомардылар, эшне дәүләт күләмендә йөртергә өйрәнделәр. Хөкүмәт тә, Дәүләт Думасы да шулар кулында.

Берләштерелгән «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газитләре редакциясендә (3 ел шулай яшәдек) язучы фронтовик Ян Винецкий белән күрше бүлмәдәш идек. Ул—элеккеге хәрби очучы. Утызынчы елларда инкыйлаб кичерүче Испаниядә һава сугышларында катнашкан. Берничә китап авторы. Көннәрдән бер көнне кош тоткандай килеп керде бүлмәмә.

— Гумерчик (коллективта иң яшь журналист буларак, бөтен редакция халкы сөепяратып мине шулай ярты фамилиям белән йөрттеләр. Рәхмәт хезмәттәшләремә!), син сөннәтлеме?—дип сорый бу, колагыма иелә төшеп.

Теге заманда бит! Үземне партия сафларына әзерләгәндә житмәсә. Шулай да Винецкийның йөзендә «фальш» күрмим, «провокатор»га охшамаган. Икеле-микеле жавап бирдем тегенә.

—Сәер сорау,—дим.—Татар баласын шулай кыерсыталар инде, нишлисең...

—Безнең арада аерма юк, алайса.

—Бәлки...

—Курыкма, партиягә кергәндә бот арасын тикшермиләр хәзер.—Эчкә жылы йөгерде.

—Менә нәрсә, Гусманчик-Гумерчик, шатлыгымны уртаклашырга кердем синең янга иртәнге сәгатьтән. Хатын улыбыз Янны сөннәтле итте бит кичә. Күптәннән жыена иде. Табибә ул минем хатын. Ян 9 нчы сыйныфта укый. Операцияне әйбәт кичерде.

Эч серен татар егете белән уртаклашырлык булгач, яһүд дигәнең, безне үз иткән икән шул. Ә бәлки сөннәт хикмәтедер. Кем белә?.. Ул чактагы үсмер малай Ян Казан дәүләт медицина институтын тәмамлап, әнисе шикелле табиб һөнәрен сайлады. Алай гына да түгел, Йошкар-Ола каласында баш табиб дәрәжәсенә үсте.

Талантлы язучы өлкән Ян Винецкийны ике табиб та алып кала алмады. Сөннәт белән китте яһүдебез.

**Госман ГОМӘР**



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

# КЫЛЫЙ

ХИКӘЯ

Нишләсен соң инде песи малае: ары барды, бире килде, тик хуҗабикә күренмәде. Әбекәе усал булса да, саранлыгы белән дан тотса да, песиләрне ярата иде. Кылыйга аның белән һәрвакыт рәхәт булды: өй җылы, ашарга бар.

—Карале, мине нигә Кылый дип атады икән ул? Әй, ярый, әйбәт сүздер әле. Үскәч, бәлки, мәгънәсен дә аңлармын...—Ал тәпиләренә башын куеп, йомарланып, пескәй йокыга китте.

Соңгы вакытларда әбисе катырак авырый башлады әле. Аның янына бер апа килгәләп йөрде. Исемен хәтерләми Кылый, «әби караучы» дип кенә йөртәләр иде бугай аны.

Әби караучы... Күпләр мохтаҗ хәзер аларга. Балалары да бар югыйсә, авылда туганнары да җитәрлек, тик берсенең дә вакыты гына юк. Менә тагын оныттылар. Песи генә түгел, урын өстендә ятучы карчык та ач. Әби караучының да берничә көн инде күзгә-башка чалынганы юк. Хәер, анысында әллә ни өмете дә юк инде Мәликә әбинең. Әнә, ул караган Сәлимәне дә үлеп ике көн яткач кына күрделәр. Ике җирдә эшләгән була, кайсына җитешсен. Акча боза бит кешене. Булган саен күбрәк кирәк, моңа да шулай...

—Ни хәлләрдә ятасың, түткәй?

Мәликә әбинең уйлары еракта иде: ишектән керүчене ишетмәде дә, күрмәде дә, шуңа күрә тып-тын ятуында булды.

—Әстәгъфирулла, әллә үлгән инде? Өен җаддыралмай калды болай булгач,—дип, сөйләнә-сөйләнә сеңлесе Зөмәйрә якын ук килгәч кенә, исән икәнлеген сиздереп, кыймшап куйды.

—Ни хәлләрдә, түткәй?—дип кабатлат сорады Зөмәйрә.—Менә, әдрәк ашарыңа алып килгән идем, урын-җирләреңне дә чистартырга кирәк. Теге катын килмәдемени?

Бераз апасын тәрбияләгәч, ничек сүз башларга белми торды.

— Түткәй, теге... ни... Карале. Үдең исән чакта өеңне әфәрмит итәргә кирәктер. Кемгә җадып калдырырга уйладың?— тирләде, пеште, тәки ерып чыкты: күңелен тырмап торган күптәнге соравын апасына юллады.

Мәликә әби сүз башларга ашыкмады. Үләсе килми иде әле аның. Теге дөнья бик еракта кебек иде әле ана.

—Минем өйдә берәүнең дә эше җук. Торып эчерсен шунда. Эчертәсегед килмәсә, өелеп сугышырсыд да, бүләрсед, песиемне генә урамда калдырмагыд,—диде ул ачу белән.

Зөмәйрә килеп бу хакта башка сүз кузгатмады. Хәер, инде вакыт та калмады. Мәликә әби теләмәсә дә, аны алырга килделәр. Ә өе, моңаеп, чрергә әзерләнде. Бөтен өйгә хуҗа булып калган Кылый хәлләренең мөшкелләнәсен сизенми иде әле.

Тавык төшенә тары керә ди, Кылый да әллә күп уйланудан, әллә сагынудан төшендә Мәликә әбине күрде: ак яулыгын аркасына салып бәйләгән дә, пескәйгә сөт бирә, имеш.

Их, нигә уянып киттем инде менә! Төштә генә булса да сөтне эчәсе иде бит! Тәм-том ашап ятып, тычкан тотарга да өйрәнмәгәнмен бит ичмасам. Чү, аяк тавышлары ишетелә түгелме соң? Ниһаять!

Инде хуҗабикәсенең аягына сарылам гына дигәндә, каядыр очып китте дә, стена янында торган шкафка килеп бәрелде Кылый. Нәрсә булганын аңларга теләп, әкрен генә басып, алга атлады. Ә анда һич кенә дә хуҗабикә түгел, ә ниндидер чит кешеләр иде.

—Ярый әле үләр алдыннан васыять язмаган, менә хәзер бөтен әйберсен төяп үзебезгә апкайтырбыз, өен дә, улым, синең исемгә яздырырбыз,—дип сөйләнә иде Мәликә әбигә охшаган бер олы яшьтәге апа.

Үләр алдыннан диме? Кем үлгән? Әллә минем яраткан әбиемме? Әйтәм аны күренми. Ә болары кемнәр? Ә-ә-ә... Боларны ике тапкыр күргәнем бар. Менә бу малай әле озаграк та торган иде. Килгән саен эчеп, әбине үртәп китә иде. Өй шуның исеменә була диме? Ай-яй-яй! Ә мин кемгә булам ул чагында?

Песи малае шулай аптырап торганда өйдән суыткыч, телевизор, савыт-сабаише әйберләр ташылып та бетте. Хәтта утынлыктагы ярып өелгән утынга хәтле төяделәр. Эшләре беткәч, машина ишекләрен шап итеп ябып, кузгалып та киттеләр.

—Нигә монда Мәҗит бабай килми соң? Утынны аның малае ярып өйгән иде, телевизорны да шул алып кайтты. И, сөенгән иде Мәликә әби! Аларга берни дә кирәкми микәнни? Һич булмаса, мине күрерләр иде.

Кылыйга тагын ямансу булып китте. «Кешеләр әллә көннән-көн явызлана инде?—дип уйлый иде ул.—Балалары да шул явызлыкны күреп үскәч, ничек тыныч картлык өмет итә инде алар?»

Мәликә әбинең бер малае бар иде. Бик чибәр, мәһабәт гәүдәле егеткә кызлар күп булса да, әнисенең усаллыгы аңа беркем белән дә яшәргә мөмкинлек бирмәде. Фәнәвис ялгызлыктан туеп якты дөньядан китте.

Ә әби нык булып чыкты. Яшәргә теләге шулкадәр көчле иде, ул авыруы беленгәч тә зур табибларга күренде, хастаханәләрдә ятты, дәвалану курсы үтте һәм—ни могҗиза!—үләргә дип киткән җиреннән аякка басты. Авылда туганнары күп, ташламадылар. Мәҗит дигәне бигрәк ярдәм итте, аның балалары да гел хәл белеп торды. Кылыйга да өлеш чыга иде аларның кучтәнәченнән.

Ашарга бирәр нәрсә табылмасмы дип песи малае эзләнергә тотынды. Шулчак арткы тәпиен нидер яндырып, өтеп алгандай булды. Капкын! Әллә кайчан, кумыклар кубәйгәч куйганнар иде моны. Ничек онытып өстенә килеп менде аның Кылый? И, елады пескәй. Язмышыннан бер дә риза түгел иде ул. Ач көенә аяк та ныграк авырткан кебек, ычкындырып булсын иде ичмасам! Кычкырып ук елаган икән песи, шулай булмаса, аның тавышын ишетеп күрше Фәридә кермәс тә иде.

Әти-әнисенә мал карашып йөрүе булган икән. И, кызганды пескәйне эзләп тапкач, күзенә яшь тулды. Күпме генә тырышмасын, ычкындыра алмады тәпине капкыннан. Нишләргә? Әти-әнисенә әйтсәң, йөрмә эч пошырып, нигә кирәк сиңа әллә кайчан үлгән әбинең песие диячәкләр. Песинең ни гаебе бар инде, йә?! Кылый белән бергә елап торганда сызгырынган тавыш ишетелде. Атылып урамга чыкты Фәридә. Күрше Зөлфәт икән.

—Нәрсә аягыңны капкага кыскан кебек керәлми дә, чыгалмый да торасың?—дип эндәште аңа ике-өч елдан егет булачак малай.

—Мин түгел, песи, Мәликә әбинең песие капкынга эләккән. Зөлфәт, әйдә аңа ярдәм итик әле?

Егет кеше кызның гозерен аяк астына салып таптамас бит инде, коткардылар песине.

—Мескен, ашарына да юктыр инде аның. Зөлфәт, син монда торып тор, мин аңа ашарга алып килəм,—диде дə, Фəридə чыгып йөгерде.

Зөлфəт исə пескəйне күзəтте.

—Кара, кылый икəн бит бу, күзе дөрес күрмəгəнгə капкынга килеп элəккəн дə инде ул,—дип уйлады егет.

Пескəй əле авырткан аягын ялый, əле Зөлфəткə күз атып ала иде. Кылый дигəч, ул үзен чакыра дип белеп, малайга елышты.

—Менə дуслаштыгыз да,—диде Фəридə сөенеп,—Зөлфəт, бəлки син аны үзегезгə алып кайтырсың. Күрəсең бит, əйберлəрен ташып бетергəннəр, ə песи берсенə дə кирəк булмаган. Мин үзебезгə алыр идем дə, əни кертмəячəк.

—Минем дə əни этлəр, песилəр алдырмый.

Бераз сүзсез тордылар. Икесе дə песине кызгана иделəр, лəкин əти-əнигə дə каршы килеп булмый. бит.

— Карале, əйдə без көн дə аны монда килеп ашатыйк, ə ул өй саклар.

Кич җиттеме, Зөлфəт Мəликə əбилəр ишек алдына ашыга. Шундук Фəридə дə килеп керə. Əти-əнилəре, əбилəреннəн аермалы буларак, песине бик яраттылар алар. Бер-берсенə мəхəббəт уты да Мəликə əби милегендə кабынды. Инде бəхетлəре булсын.

**Энже УСМАНОВА**

---

# БƏХЕТ БИЯЛƏЙЛƏРЕ

ХИКƏЯ

Миңа унҗиде яшь иде... Əбием миңа Яңа елга кызыл биялəйлəр бүлəк итте. Бу кар бөртеклəре чигеп эшлəнгəн биялəйне əбекəйне үпкəлəтмəс өчен генə алдым, ник дигəндə инде күптəн биялəй түгел, кара күн перчатка иде кулда! Ə мəктəптə унберенче класс «мода»ны бөтен түбəн сыйныфлар өчен тудыра. Мин кемнəн ким!!!

Шулай, бу биялəйлəр шүрлектə мин беренче курста укый башлаганчы ятты да ятты. Ул елны кыш бик матур килде. Кар башка елларны күрелмəгəнчə көртлəп-көртлəп өелде. Кышкы сессия үткəч, тыныч күңел белəн өйгə ял итəргə кайттым. Баш миен айлар буе интектереп эшлəткəннəн соң телəсə нинди физик хезмəт бəйрəм булып тоела икəн ул. Иң əүвəл өйне җыештырып чыгарга уйладым, бер тотынгач, эшне эш итəргə кирəк дип, бөтен киштə-шкафларны да тəртипкə китерергə булдым. Нəкъ менə шул вакытта килеп чыкты да инде ул биялəйлəр—үзлəре кызыллар, өслəренə ак кар бөртеклəре чигелгəн.

Шул ук көнне биялəйлəремне киеп кар көрəргə чыктым. Алар шундый уңайлылар, шундый җылылар иде. Əйтерсең, əбиемнең бар җылысы шушы кечкенə кул киеменə күчкəн. Мин көрəккə тотынганда җиргə караңгы төшə башлаган иде инде. Айның сихри нуры тирə-якны серле моңга күмеп йолдызларны бер көйгə талгын гына биетə иде. Шулчак күктəн берничə йолдыз минем биялəемə сикереп төште. Алар кышкы төнне яктыртып яна башлады. Менə бу, ичмасам, могҗиза!.. Минем биялəемдə күкнең бер кыйпылчыгы ялтырап ята! Тик шулай да безнең—кешелəрнең могҗизалардан кача торган сəер гадəте бар. Үзлəре шуны гомере буе көтə, ə тапкач, юк, янəсе, болай була алмый!..

Мин дə капка төбен көрəп бетерергə дип көрəгемне тизрəк хəрəкəтлəндерə башладым. Ə кар ява... Эшне бетереп ишегалдына керсəм, песнəклəр чөкердəшə-чөкердəшə милəш кимерə. Иң кызыгы шул: аларның сөйлəшүе нəкъ кешелəрнекеке төсле:

—Мин җылы якка киткән кошларны аңламыйм! Ничек инде ниндидер уңайлыклар дип шушы ак карны, тәмле кызыл миләшне, бозлы өй кыекларын ташлап китеп була икән?

—Мин китәр идем дә, тик бөтен туган-тумача каршы...

—Ә минем тыным тиз бетә, барып җитә алмам дип куркам...

Менә сиңа мә! Кошларның да уенда чит ил, эмиграция! Сәер, моңарчы нигә мин алар сөйләгәнне тыңламадым икән?

Арып-талып өйгә кереп чишендем, хыялга юл бирсәң, әллә нинди булмаган әйберләрне дә бар дип күрсәтер ул! Ә минем әле бүген шугалакка тимераяк шуарга барасым бар. Без кызлар белән гел шулай кич белән төн кавышкан мәлдә очрашабыз. Кызлар булган җирдә исә егетләр булмый калмый...

Кайда соң минем перчаткам! Эзли-эзли җаным чыкты, юк кына бит! Аның саен күзем бияләйләргә төшә. Гүяки алар үзләре үк: «Мине ки, мине ки!»—дип әйтәләр иде. Йә, ярый соң!

Шугалакта шау-шу! Әйтерсең лә, урамда кышкы салкын көн түгел, җәйге сабан туе. Кемнәр генә юк монда. Их, бөтенесен таң калдырып шуасы иде кана... Юк шул, мин әле өйрәнеп кенә килем. Шулай да кем әле мине керүгә үк егылыр ди?! Йөрәктә кыюлык җитәрлек, хәтта җебек малайларны төртеп егарлык! Ә шулай да могҗиза мине бүген кич буе саклап торырга булган, ахры. Шугалакка керүгә, тимераякларым үзләре выжылдатып алып китте! Мин болай тиз, шома, җиңел итеп шуа алам димени! Ә кызыл бияләйләр яныпмы-яналар! Бу хәлләр миңа әкиятне хәтерләтә башлады. Советлар Союзы чорындагы: «Без әкиятне чынбарлык итәр өчен туган»—дигән сүзләр искә төште... Кызыклы булды бу кич, инде өйгә кайтыр вакыт та җитте. Ярый ла шугалак янын бергәләп үтәбез, тик алда аннары мине ялгызым гына кереп китә торган тыкрыгым көтә. Дуслар янда чакта җылырак та, күңеллерәк тә бит ул... Җылы дигәннән, кайда соң минем бияләйләрем? Их, тишек борын! Тимераякларны салганда онытып калдырганмын лабаса, дип уйларга да өлгермәдем, артымнан исемем белән Ул эндәште. Мине унынчы сыйныфтан бирле мәхәббәт утына салган иң татлы серем!

— Син бияләеңне оныткансың!

— Рәхмәт...

— Әйдә, озатып куям.

Менә шулай. Хәзер безнең кулда пар балдаклар. Ә бияләйләрне—мине бәхетле иткән бияләйләрне мин әле дә киям. Аларда күкнең могҗизасы бар сыман!

**Алисә ЗАРИПОВА**

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@telebit.ru*

# БӘЛӘКӘЙ ГӨЛФИЯ

*Гөлфия Солтанова—Лаеш районының Имән Кискә авылында 25 ел балаларга физика-математика укыткан 45 яшьлек педагог.*

## Беренче сикереш

Әни әйтә, сабый чакта син иртә белән йокыдан гел елмаеп уяна идең, ди. Мин аңа да елмаюлар синең көнеленне көтәрер өчен булгандыр, дим. Синең бәхетеңә тудым бит мин, диям. Бала табу йортында да акушерка кызлар аңа, бу кызны бәхетле язмыш көтә. Йә артистка, бәлки укытучы булыр, күзләре бик матур, маңгае киң, исеме Ләйлә булсын, дигәннәр. Ләкин исемне мина Гөлфия дип кушканнар. Бик тиз—тугыз айдан йөреп тә киткәнмен. Ашыгыбырак кителгән шул аякка басуларым. Әни йоклатырга дип салгач, бишектән сикереп төшә торган булганмын. Күпме һәм кайлардан гына мәтәлеп төшелмәгән?.. Физик-математик булу өчен бер дә юньле алым түгел инде бу очышлар. Әллә шуның файдасы булды микән?..

Бер көнне, өч яшьлек чагымда әни мине мич башында калдырып, үзе терлек карарга чыгып киткән. Әле хәтерлим. Берәү дә өйдә юк. Миңа куркыныч булып китте. Бар көчемә: «Әни! Әни!»—дип кычкыра башладым. Нигәдер үзем еламыйм да. Шул мизгелдә башыма «Сикерергә кирәк!» дигән уй килде. Һәм шулай эшләдем дә. Беренче мизгелдә бөтен тәнне биләп алган рәхәтлек шундук юкка чыкты, аякка ут капкан кебек булды, мин тирән бер упкынга, карангылыкка чумдым...

Әни кергәндә аңсыз килеш идәндә ятканмын. Атна буе мине аякка бастыра алмаганнар. Үзем дә аякларыма язгы сарык йонын кызыл чүпрәкләр белән ураган килеш сәкедә ятканымны хәтерлим. Аякларым бик сызлый иде. Жинги әби килеп имләп, өшкереп мине бер айда терелткән, йөрер дәрәҗәгә җиткергән.

Тугыз айда йөреп киткән кебек, өр-яңадан йөрергә өйрәнгәнмен. Көн саен килеп, мине үзенең шифалы тыны белән дәвалаган җинги әбинең нурлы йөзе әле дә исемдә, аның пышылдап укыган сихри догалары колакта тора. Терелтте бит, терелтте. Им-томга, өшкерүләргә ышанмас жиреннән ышанырсың. Кырык яшьтә тагын нык кына авырып китеп, догалар белән өшкергәннән соң хәлем яхшыргач, мин моңа тагын бер тапкыр инандым. Әлбәттә, хирургларга да рәхмәтем зур. Кырык бер яшем тулгач, больница коридорында мин кабат йөрергә өйрәндем. Инде хәзер, Аллага шөкер, сикереп-сикереп йөрибез!..

## Нигә кердем чишмәләргә...

Биш яшем тулган чак, без яңа өй салып, башка авылга күченеп киттек. Яңа җирдә барысы да яңача. Бар нәрсә дә зуррак: өй дә, авыл да, кибете дә, коелар да, хәтта чишмәләренең сулары да мулрак ага кебек, таулары да биегерәк. Таулы як

булгач, чишмәләр әллә ничәү: Әтәч чишмәсе, Чәнечкеле чишмә, Солтан чишмәсе, кое чишмәсе һәм әллә никадәр исемсезләре. Чәнечкеле чишмә дип аның тирәсендә бик күп шайтан таягы үскәнгә атаганнардыр инде. Иллә дә матур шул шайтан таягынын чәчәге, ә үзе чәнечкеле. Кагылырлык түгел.

Солтан чишмәсен минем бабай исеме белән атаганнар. Бабам лесник иде—урманчы. Ул бу чишмәне чистартып карап торган. Атына гел шуннан су эчерткән.

Әтәч чишмәсе дип нигә шулай кушканнардыр, әйтә алмыйм. Димскәй авылыбыз халкы хәзер дә шуннан су эчә.

Чишмә дигәннән... Җәйге бер эссе көндә минем кечкенә башыма бер уй килде. Дим елгасына төшеп коенырга ярамагач, нигә улакта гына су кереп чыкмаска? Чәнечкеле чишмә суы атлар эчәр өчен тирән эчле улакка ага бит. Тиз генә әни теккән күлмәгемне салдым да, чумдым улакка. Салкын чишмә суы тәнемне куырып алган кебек булды. Аннан күнектем бугай, рәхәт кенә. И коенам, и коенам! Чыгып җылынып алам да, тагын салкын суга чумам, йотлыгып суын эчәм. Чишмә суының сафлыгы һәм салкыны һәр күзәнәгемә үтеп кергән кебек була, судан аерыласы килми. Улактан чыксам нәрсәнедер югалтырмын, бүтән мондый рәхәтлек бер дә кабатланмас кебек тоела.

Шулай күпме вакыт узгандыр, ни күрим, чишмә янында кулына бер бәйләм кычыткан тоткан әни басып тора. Салкын суда назланган тәнемдә карт кычыткан бәйләмен уйнаткан әнинең: «Авырсаң, нишләрбез?» дигән сүзләре әле дә колагымда яңгырап ала.

Әлбәттә инде, мин бик озак авырдым. Тамагым шеште. Чишмәләр янына бармаска, суын эчмәскә дип әнигә кат-кат ант иттем. Инде менә хәзер мин яшәгән авылда бер генә чишмә дә юк. Челтерәп аккан чишмә тавышын бикләр дә тынлыйсы, саф суын эчәсе килә. Күңелгә җыелган бар керне, сагышны чишмә суы үзе белән житмеш җиде кат җир астына алып китәр дә, кире чыгармас кебек тоела.

Чишмәләр сагындыра.

## Алка бәласе

Өченче сыйныфта укыганда Фәүзелҗәннәт әбием минем колакны тиште. Алка тагасым килә. Бик авыртса да түздем, чөнки дус кызым Резеда инде күптән матур алкалар тага. Алкаларым да алынган. Һәр көн иртән колагымдагы җепләрне төкереклә әйләндерәм, күздән утлар чыга. Алкаларыма карыйм да авыртулар онтыла: бигрәкләр дә матурлар шул, кызыл кашлылар, тизрәк тагып йөрисе иде шуларны!

Менә ике колак та төзәлде. Дулкынланып көзгә каршында алкаларымны тагып маташам. Берсен алып карасам... бөгәлҗәсе сынык, икенчесенеке дә шулай. Нәрсә инде бу? Тәнемә салкын йөгерде. Алгы өйдән йөгереп әбием янына чыктым. Эшнең нидә икәнен белгәч ул да аптырашта калды. Ай буе авыртуларга чыдап көткән бәхетле мизгел челпәрәмә килде. Әбинең алдына яттым да, үксеп елап җибәрдем. «Күпме еласаң да, мин сиңа алка тактырмыйм. Оялмыйча артист Резеда кебек алка тагып мәктәпкә бармакчы идеңме әллә?—диде каяндыр кайтып кергән абыем. Баксаң, алкаларның бөгәлҗәсен ул сындырып куйган икән.

Бу хәлләрдән соң озак еллар мин алка тага алмадым. Казанда укыган чакта ялгышып кына да бизәнү әйберләре алмадым. Хәттә иренгә иннек тә тидерми идем. Гасырлар буе татар хатыннарында яшәп килгән ир-атка буйсыну үзенекен итте. Абыем сабагы егерме елга сузылды. Эшли башлап, утыз яшемә житкәч кенә алтын алка алдым мин. Бетәшкән колак тишекләрен яңадан тиштерергә туры килде.

Хәзер инде хәлләр башкача. Алка тагып, бизәнеп йөргән кызлардан «артист Резеда» дип көлмиләр. Алканы да берне генә түгел бишәрне, колакка гына түгел, кендеккә дә тагып, эчләренә кадәр күрсәтеп йөриләр. Заманы шундый микән, әллә минем кебек сабак бирердәй абыйлары юк микән ул кызларның?

## Без шундый идек

Димскәйдәге мәктәп укытучыларының коллективы бик көчле иде. Ул безне укыткан Шаһинур абыйны әйтәсеңме, Асия апанымы? Менә шулар миндә физика-математика фәненә мәхәббәт уяттылар. Гомумән, мин барлык фәннәрдән дә бишлегә укыдым. Әле уку гына җитми, гимнастика белән шөгыльләнәбез, спорт ярышларында катнашабыз, тегү-чигү, бәйләү дигәндәй. Ул экскурсияләргә йөрүләр. Тимурчылык. Тимурчылык дигәннән... Ул чорда бу хәрәкәт бик киң җәелгән иде бит.

Авылыбызда ярдәмгә мохтаҗ өлкән яшьтәге әби-бабайлар байтак, шуларга булышабыз. Безгә бирәү дә бар, булышыгыз дип әйтми, без үзебез. Менә без бер сукыр әбидә (исеме хәтердә калмаган) өен җыештырабыз, тәрәзәләрен чистартабыз, көзгеләрен сөртәбез, савыт-сабаларын юабыз, идәннәрен себерәбез—эш муеннан. Малайлар утын кисә, яра, су ташыйлар. 22 бала—барыбыз да мәш килә. Шулай, без бик дус идек. Бер заман бу әбинең Бөгелмәдән сеңлесе кайтып керде. Безгә карап шаккатып торды да бу: «Барыгыз әле, ычкыныгыз моннан,—дип барыбызны да куып чыгарды. Нигә алай итте икән? Әбинең әйберенә тиярләр дип курыкты микән? Кеше әйберенә тиябезме соң? Алла сакласын! «Без бит изге ният белән—булышырга гына килдек»,—дип әйтеп тә карадык. Юк.



«Барыгыз, өерегез белән йөрмәгез монда!»—диюен белде. Киттек инде. Менә, эшлә изгелек! Рәхмәт әйтәсе урынга. Җә, ярый, әйдәгез, Вәлиша бабайга киттек. Аңа булышабыз! Вәлиша бабай ялгыз тора. Карар кешесе дә, туганнары да юк, мескеннең. 80 яшь үзенә. Көчкә йөри. Мунча да кирә алмый. Димдә коена. Җәйнең җылы көннәре—аның мунчасы инде.

Бабайның бөтен эшен башкарып, ашарына пешереп, керләрен юып кайта идек. И рәхәт тә иде аның рәхмәтләрен ишетүе.

## Башсызлык

Бер дә тик тормый идем инде мәктәптә укыганда. Башыма нинди уй килә, шундук кул-аягым шуны эшли башлый.

Алтынчы классны тәмамлагач, бер кешегә әйтмичә, җәйләүгә чыгып киттек. Мин—атаман. Әти-әниләр укытучылары белән дип уйлый бит инде, бергә баралар дип. Палаткалар алдык. Баргач, шалашлар кордык. Малайлар ятмә белән балык тоттылар. Уха пешердек. Кич булды, караңгы төшә. Йокларга әзерләнеп йөрибез. Бер заман утлар яктыртып автобус килә. Әти икән. Үзе белән класс җитәкчебез Халидә апаны да китергән. Барыбызның да әти-әниләре кайгыга батып беткән булганнар. Халидә апа йөрәгенә ябышкан. Безнең кайда икәнне сизеп, автобуска матраслар, юрганнар төяп килгәннәр. Халидә апа безнең белән кунды. Әти нигәдер ачуланмады. Нишләп ачулансын инде без тинтәкләрне? Ачуланып ни кырасың?

Хәзер классташлар белән очрашулар булган саен искә төшерәбез шул чакларны. Ул вакыттагы «батырлыкларны» беркайчан да кабатлап булмастыр. Үз балаң шулай чыгып китсәме?

Заманы да әшәкерәк, куркынычрак шул...

## «Өйрәтәләр мәктәпләрдә»

Мәктәпне гел бишлегә тәмамласам да, берле алганым булды. Урыс теленнән. Әйтеп торган өчен.

Шулай дәрес бара. Укытучыбыз Разия апа Гүзәлияне бастырып, дәресен сорый. Гүзәлия ык-мык. Мин астыртын гына Гүзәлиягә пышылдыйм. Кагыйдә сөйләргә кирәк иде аңа.

Разия апа бик усал укытучы.

—Гөлфия!—ди, кисәтеп. Әйтеп торма, янәсе.

Мин һаман үземнекен.

—Гөл-фи-я!!—ди Разия апа, тавышын күтәребрәк.

Миңа ни булган инде. Үҗәтләнәм бит. Разия апа бу юлы кисәтеп тормады, тотты да журналга «1»ле чәпеде. Менә сиңа, мә!

Берле алгач бик хурландым. Әле бит аны линейкада һәр дүшәмбе әйтәләр. Оялуымны күрсәгез!..

Ефрейтор булмый генерал булып булмаган кебек, «1»ле алмаган укучы киләчәктә нинди завуч инде ул. Үземне әйтәм, мин бит мәктәптә завуч булып та эшләдем.

## Бриллиант апа дәресе

Бриллиант апа—башлангыч класслар укытучысы. Бик пөхтә, чиста, зифа буйлы. Үз-үзен тотышы шундый килешле. Тавышы ягымлы. Без ул сөйләгәндә эреп китә идек. Идеал! Без бөтенебез аңа гашыйк.



Барыбыз да аның кебек булырга тырышабыз. Хәтта язу почеркларыбыз да аныкына ошаган иде. Аның шундый булуы бездә укытучы һөнәренә зур ихтирам уятты. Хатын-кыз образын илаһиландырды. Әдәбиятка мәхәббәтебезне үстерде. Әдәби әсәрләрне ул шундый итеп сөйли иде—без барыбыз да колакларыбызны торгызып, күзләребез белән кино караган кебек утыра идек. Ул Газинур романын сөйләве! Мин шунда онтылып, аны-моны уйламыйча, Газинурны исән калдыру теләге белән: «Ул амбразураны тимер кисәге белән каплап булмый идемени?—дигән ачынулы сорау да биргән идем. Малайлар миңа; «Нинди тимер кисәге булсын анда, кызып сугышкан вакытта»,—дип авызымны томаладылар.

## Әйбәт малай иде

Яшьлектә истәлек дәфтәрләре язмаган кеше юктыр, мөгаен. Дәрес карамасаң карамыйсың инде, дүрт-биш классташыңның дәфтәреннән сырлап, матурлап, бизәп апаңның йә абыеңның саргаеп беткән истәлек блокнотыннан сайлап-сайлап шигырьләр, җырлар күчерәсең. Ул шигырьләрнең авторы да юк, «буыннан-буынга күчерә-күчерә» халык сүзләренә әйләнеп беткәннәр. Кычкырып әйтә алмаган сүзләреңне, хисләреңне шушы шигырьләр аша әйтәсең дә бирәсең, ни дисәң дә шигырь белән күп нәрсә аңлатып була. Ә икенче көнне дәресләр бетеп өйгә кайткач, серле сандык ачкан кебек үзеңнең яздырып алган истәлек дәфтәрең ачасың. Аны уку күңелгә бәйрәм була инде. Каян гына табып бетерәләр диген шулчаклы матур шигырьләр, әйтемнәр. Җаның чистарып, сафланып кала. Үсәрәк төшкәч малайлар да шушы истәлек дәфтәрләре аша яраткан кызларына хисләрен аңлата, җиткерә башлыйлар.

Жиденче классны тәмамлаганда минем истәлек дәфтәремдә дә сөю хисләре белән тулы дүртюллыклар пәйда булды. Аларны миңа Илгизәр язган иде. Үз чиратымда мин дә аның дәфтәренә җавап итеп шундый шигырь язарга тиеш булганмындыр инде. Ләкин каян килсен ди ул андый кыюлык. Горурлык та комачаулагандыр, бәлки. Карашы белән миннән күпме генә җавап көтсә дә, мин таш кыя кебек эчемдәгене егеткә сиздермәдем. Ә шулай да яратмаслык малай түгел иде Илгизәр.

Җәй җитте. Бер көнне кыр бәрәңгесен утап кайтып керсәм, алдагы өйдә өстәл уртасында минем зурайтылган фотосурәтем тора. Каян килеп чыккан инде бу? Аптыраш! Фотосурәтнең сере кичен әни эштән кайткач кына билгеле булды. Илгизәрнең әнисе китереп киткән икән аны безгә. Өйдән өйгә фотосурәтләр зурайтучы йөргәндә Илгизәр биреп җибәргән икән дә, зурайтып ясап китергәч әнисе алып калган. Малаен әрләп, ачуланганнан соң фотоны безгә алып килгән.

Кыскасы, аларга бик кыйммәткә төшкән фотосурәтне әни акча биреп алып калган. Әни боларның барысын да сөйләгәндә күренеп торган берәр тишек булса, мин шунда кереп китәрлек булып тынлап тордым. Ярый әле әти өйдә юк, апа, абый...

Илгизәрне үземчә ошата да башлаган идем бит инде мин. Хәзер исә аңа булган ачуым җанны көйдерә, үзе янымда булса, белмим, нишләтер идем икән мин аны шушы мизгелдә? Кичне сабырсызланып көттем дә, клубка ашыктым. Илгизәр үзе дә бик борчулы күренә иде. Сүзсез, караш белән генә аңлатмакчы идем, барып чыкмады. Бар кыюлыгымны җыеп: «Сөйләшәсе бар иде синең белән»,—дип кырыена килеп бастым. Илгизәрнең минем фотоны каян алганыннан башлап, үзе өйдә булмау аркасында гына әнисе кулына эләккән сурәт өчен үзен бик гаепле санавын аңлатуын тынлап өйгә кайтып җиткәнне сизми дә калганбыз. Шунда мин нәрсә әйткәнемне белештермичә тездем дә тездем. «Ни хакың бар иде синең?»—дигәч, көтмәгәндә Илгизәр мине кочаклап алды. Болай да ташып чыккан ачуыма шул җитә калды. «Әле син шулаймени?»—дип аны этеп җибәрдем дә капкада эленеп торган зур йозакны алып аңа китереп тә суктым. Бөтен дөнья туктагандай булды. Әйтерсең лә Илгизәрнең аркасына эләккән теге йозак безнең йөрәкләрдә шытып килүче мәхәббәткә үзе чаклы нокта куйды...

Күнелләр бушап, гамьсез көннәр башланса, әле дә истәлек дәфтәрләрен алып укый торган гадәтем бар. Чыгарылыш алдыннан яздырганында Илгизәрнең дә дүртюллыгы тора:

*Очкын сипкән синең күзләрең*
*Юлларыма нурлар таратты.*
*Ишет мине, ышан сүзләремә,*
*Мин яраттым сине, яраттым...*

## Тормыш—көрәш

Суворов әйтмешли: «Трудно в учении, легко в бою!» Мәктәптә эшләгәндә сыерын да саудык, икене әле! Эремчеген дә, каймагын да, сөтен, катыгын да саттык Казанда. Эшләмәгән эш калмады. Аллага шөкер, укытуын да яхшылап башкардык. Чират белән булса да көтүен дә көттек. Каз-үрдәк тә асрадык. Каз-үрдәк дигәннән, кечкенә вакытта үземне күркә талаганы истә.

Бәләкәй чагында яшемә күрә гәүдәм бик кечкенә булган. Кызыл плюш пәлтәм бар иде. Каршы якта безнең апалар тора. Шуларга кергәләп йөрим. Күркәләре кабарынып килеп чыкмасынмы! Әй бәргәли мине, аяклары белән тибә, тешли. Бик хәтәр икән ул күркә! Һич котылып булмый. Битемне каплап күзне саклыйм. Менә әле дә битемдә күркә ясаган яра эзе бар.

Зур әни:

—Нигә бу кызыл пәлтәне кидең?—ди. Әйтерсең, пәлтә гаепле. Мин бала бит—минем нинди гаебем бар. Сезгә кыярга керешем иде, мәйтәм.

Тормышта, гомер буе кайбер «күркәләр» белән байтак бәргәләшергә туры килде. Теге күркә кебек биткә түгел, йөрәккә, күңелгә яра ясаучылар бар. Шулай да бүгенге халәтемнән канәгатьмен.

Укытучы дигән бөек исемне йөртү—зур горурлык, олуг мәртәбә!

# ГАЛИЛЕЙНЫҢ БЕРЕНЧЕ АЧЫШЫ

Атаклы галим Исаак Ньютон, аның төрле фән өлкәләрендә башкарган бихисап ачышларының нигезе нидән икәнен сорагач: «Миңа гигант даһиларның инбашына күтәрелү насыйп булды», дип җавап биргән. Шундый гигантлар арасында иң әүвәл табигатьне өйрәнүче төгәл фәннәрнең нигез ташын салуда актив катнашкан Галилео Галилейны искә алалар. Аның бихисап фәнни тикшеренүләрен һәм гүзәл ачышларын санар өчен генә дә шактый вакыт кирәк булыр иде.

Борынгы, Аристотель заманнарыннан мирас булып калган белем системасында революцион үзгәрешләр көтелә. Моның өчен яңача фикерләү генә җитми, тәвәккәллек һәм хәтта гайәрлек тә кирәк. Шундый сыйфатларга ия булган галимнәр арасында беренче чиратта Галилео Галилейны атарга була.

Ул бала чагында ук машиналар, тегермәннәр һәм корабларның «эшли торган» модельләрен ясый, төрле күренешләрне җентекләп күзәтүчән, «очлы күз»ле үсмер була. Әмма ул үскәч һәм олыгайгач та һәрнәрсә белән кызыксыну хәтта балаларча гаҗәпләнү сәләтен җуймаган.

Булачак мәшһүр галимнең шундый сыйфатлары беренче фәнни ачышын бернинди үлчәү җиһазларын кулланмыйча, хәтта каләм белән кәгазь кисәген дә сарыф итмичә генә, «тик торганда» гына башкарырга мөмкинлек биргән.

Урта гасыр чынбарлыгын күзаллыйк әле. Дин кануннары белән яшәгән Аурупа илләрендә чиркәүгә йөрмәгән шәхесләргә инквизиция тарафыннан эзәрлекләү янаганын беләсездер, шәт. Дини догмалар хакында алдын-артын уйламый ни булса да әйтеп ташлаган корольләр дә инквизициия суды тарафынан тәхетеннән алына торган заман бу.

Чиркәүдә һәрчак кабатлана торган вәгазьләрне тыңлаганда яшь Галилеоның дикъкатен бихисап шәмнәре янып торган люстраның акрын гына чайкалуы җәлеп итә. Гыйбадәт башланыр алдыннан чиркәү хезмәткәре, люстраны ыргак ярдәмендә якынайтып, озын таяк башындагы кечкенә факел белән андагы шәмнәрне кабызып чыккан да, кандилны үз урынына кайтканчы ук ыргактан ычкындырган. Шулай итеп зур люстра маятник булып озак вакытлар акрын гына чайкалуын дәвам иткән. Әмма һава каршылыгы һәм люстраны түшәм астында тотып торучы чылбыр боҗраларының үзара ышкылуы аркасында чайкалу чикләре өзлексез кечерәя, чайкалу амлитудасы кими бара. Яшь егет чайкалу периодының, ягъни люстраның бер үк торышының кабатлануы арасындагы вакыт озынлыгының үзгәрмәвен ачыклый. Моның өчен, әлбәттә, сәгатькә дә, люстрага да карап тору зарур. Әмма Галилей заманында кул яисә кесә сәгатьләре булмаган әле. Егет аптырап калмаган. Сәгать йөреше урынына ул йөрәгенең тибешен эталон итеп алган. Кыскасы, галим, маятник урынына чайкалган люстраның уңнан сулга һәм кирегә йөрәгенең ничә тибеше вакытында башкарганын ачыклап, бу вакытның амплитуда кечерәйгәндә үзгәрмәвен аныклаган. Димәк, маятникның хәрәкәт итү периоды амлитудан бәйсез булып чыга. Хәер, таган атынганнар яисә аны карап кына торганнар да моны яхшы аңлыйдыр, мөгаен.

Яшь галим бу ачышын формула ярдәмендә, маятник тигезләмәсе аша тасвирлый, маятник периодының аның җебе озынлыгының квадрат тамырына пропорциональ икәнлеген исбатлый. Озын баулы таганда акрын, кыска баулысында тизрәк атыну укучыларыбызга мәгълүмдер. Шунысы игътибарга лаек: маятник законын ачыклаганнан соң «телле» сәгатьләрне фән нигезендә ясау мөмкинлеге туа.

**Ким ШАКИРОВ**



*ТАССР Мәгариф халык комиссариаты карамагында эшләүче Гыйльми үзәк хезмәткәрләре. Уртада, өстәл артында, сулдан: мәгариф комиссары, язучы Шәһит Әхмәдиев, Гыйльми үзәк рәисе Галимҗан Ибраһимов, коллегия әгъзасы, язучы Фатих Сәйфи-Казанлы. 1925-26 еллар.*



*Композитор Заһид Хәбибуллин (1910-83). 1966 ел.*



*Иделдәге Маркиз утравында ял вакыты. Сулдан уңга—Эрот Зарипов, Сибгат Хәким, Алмаз Хәмзин, Эльс Гаделев, Рафаэль Фәйзуллин. 1984 ел.*



*Язучылар Аккош күле буендагы яланда. Сулдан уңга—Нәбирә Гыйматдинова, Туфан Миңнуллин, Рафаэль Мостафин, Илдар Юзеев. 2002 ел.*



*Арчада яшәп иҗат итүче язучы Радик Фәизов.*



*Шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов (1935-2008) һәм Дамир Шәрәфетдинов (бүгенге көндә ул тарихчы-галим, «Гасырлар авазы» журналының баш мөхәррире). Фото 1963 елда төшерелгән. Казан. Г. Тукай урамы.*

## Вахит Юныснның тууына 80 ел

Гомер буе дөнья гизеп йөзәрләгән илдә булган, егерме еллап чит илләрдәге илчелекләрдә эшләгән, дистәгә якын чит тел үзләштергән, ул илләрнең җитәкчеләре белән аралашкан, шул ук вакытта үз халкына, туган-туфрагына хөрмәт-ихтирамын югалтмаган, гореф-гадәтләренә тугры калган язучы ул Вахит Юныс. Кызганыч, инде күргән-белгәннәрен, белемен-тәҗрибәсен кулланып әдәби иҗат эшенә чын-чынлап тотынгач кына аны аяусыз үлем арабыздан алып китә. Күпме яңа әсәрләр язылмыйча кала.

Язучы-публицист Вахит Юныс (Вахит Закир улы Юнысов) 1930 елның 20 октябрендә Татарстанның Баулы районы Исергәп авылында туа. Үз авылларында җидееллык мәктәптән соң Бөгелмә педагогия училищесын дүрт ел урынына өч елда тәмамлап Бөгелмә укытучылар институтына керә, аны да алдан тегәлләп 1951 елда Лениногорск районының Шөгер урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый.

1953 елда исә Мәскәүнең үзенең дә бик сирәк кешеләре генә укый ала торган МГИМОга укырга керә, 1959 елда аны да уңышлы тәмамлап чыгу бәхетенә ирешә, китаплар аша гына танып белгән илләргә сәяхәте башлана. Күпчелек язмалары да—сәяхәтнамәләр. Дөнья хәлләрен, чит илләрнең тарихын ныклап өйрәнү-күзәтү аңа публицистика жанрында эш алыр барырга да җирлек бирә, милләтләр язмышы турында уйланган мәкаләләрен яза. 2001 елда Татарстан китап нәшриятында «6000 көн чит илләрдә» исемле китабы басылып чыга.

1997 елдан исә Мәскәүдә татар милли-мәдәни автономиясенең матбугат органы булган «Татарские новости» газетасының баш мөхәррир урынбасары булып эшли, Татарстан җирле матбугатының даими авторларының берсе, халыкара ПЕН-клубының Татар ПЕН-үзәге, 1992 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

«1996 елда Татар ПЕН үзәге делегациясе Мексикага Бөтендөнья Язучылар Ассоциациясе (ПЕН-Интернэшнл) конгрессына баргач та Исергәп авылы малае Вахит күпчелек илләр язучылары белән инглизчә, гарәпләр белән гарәпчә, ә кореялылар белән кореячы сөйләшеп шаккатырды. Һәм ул халыкара конгресс трибунасына чыгып, инглизчә татар мәдәнияте һәм әдәбияты турында сөйләп биргәч, Татар ПЕН үзәген бертавыштан алкышлап Халыкара ПЕН-клуб әгъзасы итеп алдылар»,—дип яза аның турында каләмдәше Разил Вәлиев.

Язучы һәм публицист В. Юныс 2006 елның 15 октябрендә Мәскәүдә вафат була.

# МЕНӘ ШУНДЫЙ ИСЕМЛЕК...

*2020 елда Бөтенроссия халык санын алуның «Л» формасындагы исәпләр кәгазендә 7нче җавап кодлаштырылган. Әлеге исемлектә кодлаштырылган 7нче җавапның мөмкин булган вариантлары алфавит буенча бирелгән. Ул Россия статистика идарәсенең 74нче карары (21.01.2010) белән расланган. Монда бер татар милләте менә шундый өлешләргә бүлгәләнгән:*

Татар, татарлар, татары, казанлы, казанские татары, татары казанские, татары алабугатские, алабугатские татары, татары астраханские, татары юртовские, карагаши, кундровцы, ногай-карагаш, ногайцы астраханские, ногайцы-карагаши, нугай татар, татары караинские, татары каринские, татары нократские, татары нукратские, татары нухратские, нократлы, нократские татары, нукратские татары, нухратские татары, караинские татары, каринские татары, татары чепецкие, чепецкие татары, тептяр, тептяри, тептяри {с любым яз., кроме башк.), тептяри (с яз. башк.}, тептяри-татары, типтяр, татаро-башкиры (с любым языком, кроме башк.), татаро-башкиры (с яз. баш.), башкиро-татары (с любым языком, кроме тат.), башкиро-татары (с яз. тат.), башкирские татары, татары башкирские, башкиры-тептяри, гайна, гайнимцы, касимовские татары, татары касимовские, сибир, сибир татарлар, сибирские татары, татары сибирские, сибирь, сибиряки, бухарцы (с любым языком, кроме тадж.), бухарцы (с яз. тадж.), бараба, барабинцы, тарлык, тарские татары, татары тарские, заболотные татары, кургатско-саргатские татары, татары курдако-саргатские, тоболик, тобольские татары, татары тобольские, ясколбинские татары, татары ясколбинские, тюрки чулымские, чулымские татары, татары чулымские, чулымские тюрки, татары заболотные, татары тевризские, тевризские татары, татары тюменско-тюринекие, татары крещеные, крешенцы, крещены, крещеные, крёщеные татары, кряшены, кряшены-русские, кряшены-татары, нагайбаки, нагай-баклар, мещеряки, мижер (с любым языком, кроме чув.) , мижер (с яз. чув.), мижерь, мишари, мишары, мишар, бигер, татаро-булгары, болгары (с любым языком, кроме тат. и чув.), болгары (с яз. тат.), болгары (с чув. яз.), болгары волго-камские, волго-камские болгары, болгары волжеские, волжеские болгары, булгары волжеские, болгары волжские, волжские болгары, волжские булгары, болгары камские, камские болгары, камские булгары, булгары камские, болгары самарские, самарские болгары, болгары семберские, семберские болгары, булгаро-татары, булгаро-тюрки, булгары, булгары волго-камские, волго-камские булгары, булгары волжско-камские, волжко-камские булгары, сувары, татары крымские, крымские татары, кырым татарлар, крымцы, крымские ногаи, ногаи крымские.

*Бу исемлекне укыгач шомланып һәм көлемсерәп, ирексездән, «тәкый гаҗәп хәлләр» дип әйтеп куярсың да. Монда сәясәтнең шовинистик асылы ярылып ята. Шагыйрь сүзләре белән әйткәндә, «Бүлгәлә! Туракла! Тарттыр да йот!» Бу исемлеккә әллә ни аңлатма бирергә кирәкмидер... Тик шуны искәртик: хәтеребезне җуймыйк, уяулыгыбызны югалтмыйк, гомуммилләтебезнең асылын тәшкил иткән Татар исемен горур йөртеп, шуны дөнья алдында раслыйк!*

## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### МӘСКӘҮДӘ ТАТАРСТАН БӘЙРӘМЕ

Мәскәүнең халыкара музыка йортында ТАССРның 90 еллыгына һәм Татарстан Республикасы көненә багышлап, «Мәскәү-Татарстан: бердәм гаилә» дип аталган тантаналы кичә булды. Тантанада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Мәскәү вице-мэры Сергей Байдаков һ.б. катнашты.

Бина фойесында «Яңарыш» республика фондын, Казанда 2013 елда узачак XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасын, Казан (Идел буе) федераль университетын тәкъдим итү стендлары урнаштырылган, китаплар, фото һәм сәнгать күргәзмәләре оештырылган иде.

Тантана ТР дәүләт симфоник оркестры чыгышы белән башланды. Оркестр Шамил Тимербулатовның «Минем Казаным» дигән әсәрен башкарды. Аннары сәхнәгә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов күтәрелде. «Хөрмәтле ватандашлар, кадерле дуслар, мин сезгә татарстанлыларның котлау сүзләрен ирештерүемә шатмын,—дип мөрәҗәгать итте ул тамашачыларга.—Республикабыз үсеш елларында илдәге барлык ватандашлары белән ныклы элемтәдә яшәде. Бигрәк тә Мәскәүдәге татар җәмәгатьчелеге белән якын мөнәсәбәтләр урнашты һәм кичәнең «Мәскәү-Татарстан: бердәм гаилә» дип аталуы да символик мәгънәгә ия».

Татарстан Президенты Россия Федерациясе җитәкчелегенә республика проектларын һәм программаларын гамәлгә куюда ярдәм итүе өчен рәхмәт әйтте. Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, 2013 елда булачак Универсиада Казанны дөньякүләм дәрәҗәдә перспективалы үзәккә әйләндереп, үсеш өчен яңа офыклар ачачак.

«Үсешнең хәзерге этабында безнең бурыч—телне, тарихны татар халкының бай традицияләрен саклап калу. Ә бу безнең көчебездән килә, минем аңа һичбер шигем юк, һәм моны халык санын алу нәтиҗәләре дә раслаячак. Татарстанның позитив үсеше нәтиҗәсендә сезнең дә мөмкинлекләрегез киңәя. Башкача була да алмый, бердәм гаиләдә Татарстанны бөтен татар халкы тәкъдим итә, ә аларның күбесе Татарстаннан читтә яши. Без бары тик бергә генә уңышларны арттыра алабыз»,—диде Президент.

Мәскәүнең вице-мэры Сергей Байдаков исә башкала мэры, хөкүмәте һәм шәһәр Думасы исеменнән кичә кунакларына һәм Татарстанга иң җылы котлауларын ирештерде.

Бәйрәм концертында Ренат Ибраһимов, Альбина Шаһиморатова, Алсу Сафина, Филүс Каһиров, Резеда Галимова, Рөстәм Асаев һ. б. җырчылар чыгыш ясады.

Татарстан бәйрәмендә язучылардан—Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Илфак Ибраһимов, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Лилия Газизовалар катнашты. Татарстан матбугаты күргәзмәсендә «Казан утлары» журналы үрнәкләре дә үзенең лаеклы урынын алган иде. Алар тантаналы кичәдә катнашучыларның игътибар үзәгендә булды.

### БЕРГӘ БУЛЫЙК!

Сентябрь уртасында Г. Камал исемендәге театрда татар дин әһелләренең ике көнлек «Милли тормыш һәм дин» дигән җыены булып узды.

Анда Россия төбәкләреннән 700ләп ислам дине әһеле катнашты. Җыен Коръән аятьләре укып башланып китте. Пленар утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, мөфтиләр Равил хәзрәт Гайнетдин, Тәлгат хәзрәт Таҗетдин, Госман хәзрәт Исхакый, РФ Президенты администрациясенең эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсе баш киңәшчесе Алексей Гришин, драматург Туфан Миңнуллин, РИУ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, БТК башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров чыгыш ясады.

—Без халкыбызның бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшергә дип җыелдык. Ислам чиста, дөрес дин булырга тиеш. Динебезне террорчылыкка бәйләүгә юл куймыйк. Булачак имамнар дөрес гыйлем алырга тиеш. Әгәр кадрлар әзерләү белән шөгыльләнмәсәк, артта калачакбыз. Без, татарлар—Россиядә сан буенча икенче урындагы халык исәпләнәбез. Илебездә татар милләтенең санын киметмәс өчен, халык санын алуда бергәләп эшләргә кирәк. Бу җыелышуыбызның файдасы булсын өчен, бер-беребезне ишетә белик,—диде Р. Миңнеханов.

Соңрак Равил хәзрәт Гайнетдиннең,

мондый колачлы дин әһелләре җыелышын ел саен уздырырга иде, дигән тәкъдимен хуплап, Татарстан Президенты, шушылай елга бер мәртәбә җыелышып сөйләшү файдалы булачак, дип ризалыгын белдерде.

### ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ДӘВАМ ИТӘ

«Казан-Эрмитаж» үзәгендә Дәүләт Эрмитажы, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы арасында үзара хезмәттәшлек турында озак вакытка исәпләнгән өч яклы килешүгә кул кую тантанасы булды.

Мәгълүм булганча, моннан 5 ел элек нәкъ шундый бер килешү төзелгән иде инде. Бу килешү нигезендә казанлыларны һәм башкалабыз кунакларын Дәүләт Эрмитажында саклана торган кыйммәтле сәнгать әсәрләре белән таныштырырга, лекцияләр, экскурсияләр үткәрергә мөмкин булды һәм әлеге эшне алга таба да дәвам итәргә карар кылынды.

Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева әйтүенчә, алдагы килешү яңа технологияләр үзләштерергә, виртуаль музей булдырырга һәм башка яңалыклар кертергә этәргеч бирде.

Дәүләт Эрмитажы директоры Михаил Пиотровский казанлыларга бик рәхмәтле булуын әйтте. «Әлеге килешүне төзү өчен Казанда бөтен шартлар һәм мөмкинлекләр бар»,—диде ул.

### ОРКЕСТРДА ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Мәшһүр милләттәшебез Фуат Мансуров вафатыннан соң, аның урынына Татарстанның дәүләт симфоник оркестрына баш дирижер итеп Александр Сладковский билгеләнде. Моңа кадәр ул «Яңа Россия» дәүләт симфоник оркестрының баш дирижеры булып эшләгән.

### КАЗАННАН—НИДЕРЛАНДКА

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры 72нче сезонын «Лючия ди Ламмермур» операсы белән ачты. Аннан соң бу спектакль ай ярымлык гастроль кысаларында Нидерланд Корольлегендә күрсәтеләчәк. 9 ноябрьдән 1 февральгә кадәр труппа Германия, Голландия, Франция, Австрия, Бельгия кебек илләрдә була һәм житмешләп тамаша күрсәтергә җыена. Шунысы кызганыч, нигездә Татарстан бюджетына яши торган театр республика тамашачыларына аз хезмәт күрсәтә һәм аның репертуарында татар композиторларының әсәрләре бик сирәк күренеш.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Аны берлек рәисе Илфак Ибраһимов алып барды. Утырышның көн тәртибенә Татарстан иҗат берлекләре вәкилләренең Мәскәүгә баруы, 25 августта Җәлил һәм җәлилчеләрне искә алу митингы, 30 августта Г. Тукай һәйкәле янында (Тукай скверы) Шигырь бәйрәме, халык санын алу уңаеннан язучыларның Россия төбәкләренә сәфәре һәм башка мәсьәләләр каралган иде. Утырышта Вакыйф Нуруллин («Әгәр син булмасаң» дигән китабы өчен, Татарстан китап нәшрияты, 2005), Иделбикә («Күңел күккә омтыла» Татарстан китап нәшрияты, 2007), Мансур Шиһапов («Язгы ташкын булып», Татарстан китап нәшрияты, 2010)—«Татнефть» ачык акционерлар җәмгыяте һәм Татарстан Язучылар берлегенең Сажидә Сөләйманова исемендәге бүләгенә; Дания Гайнетдинова («Каен җиле», Татарстан китап нәшрияты, 2008), Мөҗәһит Әхмәтҗанов («Әнием канатлары», Татарстан китап нәшрияты, 2005) Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш премиясенә тәкъдим ителде.

### ТӨРКИЯДӘ НӘШЕР ИТЕЛГӘН

«Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре» исемле китап 2009 елның март аенда Төркия башкаласы Әнкарада Karadeniz Yayənlarə нәшриятында төрек телендә чыкты. Китапның авторы—Төркиянең Могъла шәһәре университетында Чордаш төрки телләр һәм әдәбиятлар кафедрасында доцент булып эшләүче галимә, шагыйрә, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Чулпан Зарипова-Четин. Китап Р. Уразман, Ф. Баязитова кебек күренекле татар галимнәренең хезмәтләренә нигезләнеп язылган һәм кардәш төрек халкына татар халкының иң борынгы, күбесе әле бүген дә җиренә житкерелеп үткәрелә торган гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен танып белү өчен әһәмиятле чыганак булып тора, Төркиягә төрле тарихи дәверләрдә Идел-Урал төбәгеннән мөһәҗир китәргә мәҗбүр булган ватандашларыбызга да мәдәниятләрен барлап чит илдә дә үстереп яшәргә мөмкинлек тудыра.

***

2009 елның җәендә Төркиянең Могъла Университеты нәшриятында «Гаяз Исхакый. Сайланма хикәяләр» исемле китап дөнья күрде. Бу китапка бөек язучы Гаяз Исхакыйның «Сөннәтче бабай», «Остазбикә», «Кияү», «Кәҗүл читек», «Еглавык Хәйрулла» исемле татар халкының гореф-гадәтләрен һәм тормыш фәлсәфәсен оста итеп ачып бирүче хикәяләре кертелгән һәм алар шулай ук Чулпан Зарипова-Четин һәм Хаяти Йылмаз тарафыннан тәрҗемә ителгән. Китапта әдип турында биографик белешмә дә бирелгән.

## КҮРГӘЗМӘДӘ КҮРЕНӘ УЛ

10-11 сентябрьдә Ульянда III Ульяновск өлкәсе мәгълүмат фестивале булып үтте. Анда, хужалардан тыш, Чувашия, Мордовия, Удмуртия, Мари-Эл, Татарстан республикалары, Пермь крае, Пенза өлкәсе вәкилләре дә катнашты.

Фестиваль Халык мәдәнияте үзәге фойесында төбәк мәгълүмат чараларын тәкъдим итүдән, китап күргәзмә-ярминкәсеннән башланды. Катнашучылар фикеренчә, Татарстан тарафыннан оештырылган газета-журнал күргәзмәсе, китап ярминкәсе иң саллысы, иң бае иде.

Мондый фестивальләр аралашу, тәҗрибә уртаклашу ягыннан да, төбәкләрдән килүче журналистларны, җирле халыкны Татарстан матбугаты белән таныштыру мөмкинлеге буларак та бик файдалы. Аерым алганда, татар китабын кулга тотып укый алмаганнар өчен www.tatkniqofond.ru сайтын тәкъдим итү дә кызыклы булгандыр (анда меннән артык китап бар).

Фестиваль кысаларында атаклы журналистлар үткәргән мастер-класслар да күпләрдә кызыксыну уятты.

## СӘЙДӘШ БӘЙРӘМЕ

Гадәттәгечә, август аенда татар музыкасын сөючеләр Югары Осланның Кызыл Байрак авылына җыелды. Биредә татар профессиональ музыкасына нигез салучы композитор Салих Сәйдәшевнең тууына 110 ел тулуга багышланган фестиваль булып узды. Россиянең халык артисты Венера Ганиева, Татарстанның халык артистлары Салават, Хәмдүнә Тимергалиева кебек танылган җырчыларыбыз композиторның әсәрләрен башкарды. Шулай ук Татарстан дәүләт симфоник оркестры башкаруында Салих Сәйдәшевнең популяр көйләре яңгырады. Бәйрәм белән котларга ТР Мәдәният министрлыгының эшләр идарәчесе Кадрия Идрисова, драматург Туфан Миңнуллин, ТР прокуроры Кафил Әмиров, Г. Камал исемендәге академия театры директоры Шамил Закиров һ. б. да килгән иде.

## ТЕЛЛӘР БЕЛҮ—КИРӘКЛЕ ШӘЙ

«Полиглот» исемле республика чит телләр конкурсында катнашу өчен, студентлардан гаризалар кабул ителә. Аны ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм, Мәгариф һәм фән министрлыклары һәм ТР Ректорлар советы ярдәмендә ТР Студентлар лигасы үткәрә. Башта жюри конкурсның төрле юнәлешләре буенча иң яхшы фәнни эшләрне сайлап ала, соңыннан алар студент-активистлар, шулай ук вуз укытучылары һәм республиканың яшь галимнәре тарафыннан оештырылган йомгаклау фәнни-гамәли конференциясендә тәкъдим ителә. Конференция нәтиҗәләре буенча иң яхшы мәкаләләрне бастырачаклар, ә аларның авторлары 2дән 5 мең сумгача премия алачак. Тулырак мәгълүматны http://ligastudentov.ru/. сайтында табарга була.

## ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Татарстан Республикасы хакына нәтиҗәле иҗади һәм җәмәгать эшчәнлеге, милли әдәбиятны һәм драматургияне үстерүгә лаеклы өлеш керткәне өчен язучы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты **Миңнуллин Туфан Габдулла улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

***

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасында гаммәви мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен «Татмедиа» ачык акционерлар җәмгыяте филиалы «Чаллы-ТВ» телерадиокомпаниясе» тематик программалар бүлеге башлыгы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Разов Мирһади Мирзаян улына** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Казан Кремле янәшәсендәге Игенчеләр сарае.

*Дүртенче биттә:* шагыйрь һәм табиб **Ринат Мәннан**.

# Яңа китаплар




**Гөлчәчәк Галиева.** Газзәбану. Повестьлар. Казан: «Идел-Пресс» нәшр., 2010.—368 б. Тиражы—4000 данә.

Гөлчәчәк Галиеваның укучы хөкеменә тапшырылган бу китабында «Газзәбану» романы белән «Тулгак» повесте бирелгән. Романда Коръән рөхсәт иткән, әмма үтә дә четерекле, шулай да татар дөньясында шактый киң тарала барган күпхатынлылык темасы күтәрелә һәм ул күпләрне уйланырга, тормыш-көнкүрешебезгә төрле яклап күз салырга ярдәм итәчәк.

Китапның башында «Газзәбану» әсәренең, тормышта булган конкрет фактларга нигезләнеп, ничек язылу тарихы турында язма да бирелгән.




**Рәҗәп Бәдретдинов.** Каһәрле еллар корбаны. Казан: «Ихлас» нәшр., 2010.—175 б. Тиражы—500 данә.

Китапта үткән гасырның беренче яртысында актив иҗат эшчәнлеге алып барган язучы, драматург, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Афзал Мөхетдин улы Таһировның тормыш һәм иҗат юлы яктыртыла. Әсәрләренә анализ ясала. Моңа кадәр әдәбият белемендә читләтеп үтелгән байтак әдәби факт-мәгълүматлар кулланышка кертелә, татар әдәбияты тарихының «күләгәдә» калган кайбер яклары ачыклана.

Хезмәт татар әдәбияты тарихын өйрәнүче студентларга, аспирантларга, музей хезмәткәрләренә, мәктәп укытучыларына, югары сыйныф укучыларына, гомумән, татар халкы тарихы белән кызыксынучыларга, әдәби мирасыбызга битараф булмаган барлык укучыларга тәкъдим ителә.



Ринат Мәннан

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)